# казан утлары

12
ДЕКАБРЬ-1972

## СССР ТӨЗЕЛҮГӘ ИЛЛЕ ЕЛ




**Җирләр төрле, гөлләр төрле — юллар бер,**
**Җырлар төрле, телләр төрле — уйлар бер.**
**Һәр дәүләттә барлык милләт һәр, тигез,**
**Бертуганнар кебек гөрләп яшибез.**

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

12
ДЕКАБРЬ
1972

## Бу санда

С. БАТЫЕВ. Тугандаш халыклар гаиләсендә . . . 3
Р. МИНГАЛИМОВ. Күз карасы. Поэма . . . . 5
Б. КАМАЛОВ. Урамнар киңәя. Повесть . . . . 14
Роберт ӘХМӘТҖАНОВ. Гомер учагы. Шигырьләр 58
ГӨЛШӘҺИДӘ. Минем кала алуым. Повесть . . . 65
Ф. ХӨСНИ. Без яшь идек... Повесть . . . . . 88

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ӘГЪЗӘМОВ. Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы . . . . . . . . . . . . . . . 116
М. ЗАРИПОВ. Яшел хәзинә . . . . . . . . . 126

ОЧЕРКЛАР

А. ХӘСӘНОВА. Батрак Фатих кызлары . . . . 139

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

Л. ШӘЙДУЛЛИНА. Пирамидалар илендә . . . 150

МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Я. АБДУЛЛИН. Татар мәгърифәтчеләре философиясенең кайбер мәсьәләләре . . . . . . 159

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. ИБРАҺИМОВА. Заман темасы өчен . . . . 170

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## КИТАП КҮЗӘТҮ

**И. АХУНҖАНОВ.** Поэзиянең ышанычлы көче . . 175
**Р. ГӘРӘЙ.** Ул безнең үз шагыйребез . . . . . 179

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Ә. Ерикәй — халыклар дуслыгы җырчысы . . . 181

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 182

1972 елда журналда басылган әсәрләр . . . . 186

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 11/IX-1972 ел. Басарга кул куелды 2/X-1972 ел. ПФ 09035. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 86046 экз. Заказ Г-596. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советының нәшриятлар, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман урамы, 19. 1972 ел.

**Салих Батыев,**
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе

# ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ГАИЛӘСЕНДӘ

«Дистәләрчә милләтнең һәм халыкларның үзара мөнәсәбәтендә бездәге төсле какшамас бердәмлекне, максат һәм мәнфәгатьләрнең, ихтыяр һәм гамәлнең, рухи туганлыкның, бер-береңне кайгыртып һәм ышанып яшәүнең шул кадәр дә зур чагылышын дөнья тарихы әле белми».

КПСС Үзәк Комитетының «Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелүгә илле ел тулуга әзерлек турында»гы карарында гаҗәеп бер төгәллек белән әйтеп бирелгән шушы билгеләмәне Татарстан мисалларында алып карыйк.

1920 елның кышында Казанга, запастагы армиянең Революцион Хәрби Советы исеменә Владимир Ильичтан телеграмма килә: «Мәскәү, Петроград, Көнбатыш һәм Төньяк фронт армияләре икмәксез калу куркынычы алдында торалар... Аз гына кичегү дә һәлакәткә китерәчәк, чөнки дүрт-биш көннән барлык икмәк запасы бетәчәк...»

Татарстан хезмәт ияләре юлбашчыбыз чакыруына җавап итеп Мәскәүгә һәм Петроградка 10 миллион пот икмәк җыеп җибәрәләр. 1921 елны Идел буена ачлык килә. Афәт 1922 елны да кабатлана. Советлар иле ачлыкка каршы күтәрелә. Татарстаннан азык налогын чигерәләр. Совет хөкүмәте Татарстанга туклану өчен дип 6 миллион пот, орлыкка дип 10 миллион пот ашлык бүлеп бирә.

Совет власте елларында татар халкының тормышы, көнкүреше, хезмәт шартлары танымаслык булып үзгәрде. Совет Татарстаны бөек рус халкының һәм башка тугандаш халыкларның эчкерсез ярдәме белән промышленностен, авыл хуҗалыгын бик нык үстерде, фәне, культурасы гөрләп чәчәк аткан республикага әйләнде. Хәзер безнең промышленностебыз төгәл приборлар, станоклар, компрессорлар житештерә, миллионнарча пар аяк киеме, кинофотопленка, медикаментлар, суыткычлар эшләп чыгара. Казан мехлары дөнья базарында иң зур призларны яулап ала. Чистай сәгатен илле бер илнең гражданнары тагып йөри.

Татарстанда зур нефть табылу туган ягыбызны бик нык үзгәртте. Яңа калалар, эшчеләр поселоклары үсеп чыкты, асфальт юллар салынды. Татарстан нефтьчеләре нибары чирек гасыр вакыт эчендә дөньяның бер генә төбәге дә ирешмәгән югарылыкка — елына 100 миллион тонна нефть чыгара алуга ирештеләр. Мондый темп илебездәге «дистәләрчә милләтләрнең какшамас бердәмлеге, бер-берсен кайгыртып, булышып яшәүләре» аркасында гына була алды. Татарстанда нефть чыга башлаган беренче елларда безгә Бакудан, Грозныйдан, Украинадан, Башкортстаннан, хәтта Сахалиннан бораулаучылар, төзүчеләр, нефть чыгару осталары, инженерлар килде. Ә хәзер Татарстан нефтьчеләре Маңгышлакта, Төмәндә, Белоруссиядә, халык демократиясе илләрендә кара алтын чыгаралар.

Татарстан индустриясен үстерүгә бөтен илебез катнаша. Гөрләп утырган буровойларда йөргәндә без Уралмашны, Мәскәү, Ленинград, Баку, Сумгаит, Волгоград, Харьков, Куйбышев эшчеләрен күз алдына китерәбез. Бораулау установкалары, корыч торбалар, насослар һәм башка җиһазлар алар кулы белән эшләнә.

Социалистик төзелеш елларында республикабызның промышленность житештерү күләме 360 мәртәбәдән артыграк үсте. Элекке Казан губернасы бер ел буе житеш-

тергәнне хәзер без бер көндә җитештерәбез. Республиканың индустриаль йөзен бүген нефть чыгарудан тыш химия промышленносте билгели. Түбән Камада соңгы ун ел эчендә үсеп чыккан гигант химия комбинаты, Казанда салынган оргсинтез заводы республика масштабында гына түгел, ил күләмендә үзгәреш тудырырдай корылмалар булдылар. Аларны бөтен ил төзеде. Бөтен дөньяга даны таралган легендар КамАЗны алыгыз. Борынгы Кама ярына 40 тан артык милләт вәкиле җыелды. Дөньяда тиңе булмаган автомобиль заводы безнең республикада төзелә, һәм шул төзелештә эшләүчеләрнең яртысын диярлек татарлар тәшкил итә. Днепрогэста, Магниткада эшләп дан алган татар эшчеләре монда да сынатмыйлар. Мирсәет Ардуановлар традициясе дәвам итә.

Бөек Ленин акылы тудырган Совет Социалистик Республикалар Союзы илебез халыклары язмышында гаять зур тарихи роль уйнады. Республикадагы халык хуҗалыгы уңышлары хезмәт ияләренең материаль хәле, культура дәрәҗәсе үсүгә ныклы нигез тудырдылар. Соңгы биш елда бер миллион кеше яңа йортларга күченде, яки квартир шартларын яхшыртты. Кайчандыр «дөньяның чите, караңгылыкның мисалы» булып йөргән Казан губернасында бүген халык хуҗалыгында эшләүче 1000 кешенең 468 е югары, урта, тулы булмаган урта белемле. Казан шәһәрендә бу сан тагын да югарырак — анда 1000 кешенең 615 е югары, урта һәм тулы булмаган урта белемгә ия.

Татарстан АССР да 11 югары уку йорты, 53 махсус урта белем бирүче уку йортлары, 3071 мәктәп бар (кечкә мәктәпләр дә шуңа керә). Татарстанның вузларында, техникумнарында, мәктәпләрендә һәм профессиональ-техник училищеларында 863 меңгә якын кеше укый. Әгәр без республикада яшәүче халыкның 3 миллион 202 мең 400 кеше икәнен исәпкә алсак, димәк, республикабызда яшәүче өч кешенең берсе диярлек укый булып чыга. Бу хәл патша заманында Казан губернасының төшенә дә кермәгән! Хәзер безнең вузларыбызда гына да 4262 педагог эшли, шуларның 174 е фәннәр докторы, 1624 е фәннәр кандидаты. Татарстан мәктәпләрендә бүгенге көндә 37 мең укытучы балаларга белем бирә.

Татар халкы революциягә кадәрле үк зур әдәби традицияләре булган халык. Аның Тукай, Ибраһимов кебек бөек уллары иң авыр реакция елларында, ил өстендә «көзге җилләр җылаган» чакта да иркле көннәр килеренә, татар халкының да бәхетле булачагына өметләрен өзмәделәр. Габдулла Тукай бәхетне олы туганыбыз рус халкы белән бергә булуда, «тел, лөгать, әхлак вә гадәт алмашып» яшәүдә күрде. Бөек Тукайның алдан күреп әйткән бу сүзләре безнең көннәрдә аеруча зур колач алды. Татарстан китап нәшрияты өч көнгә бер матур әдәбият китабы бастырып чыгара, республикада ана телендә дистәләгән газета-журнал басылып, халыкка тарала. Соңгы елларда Татарстанның иҗат оешмалары, театрлары, җыр һәм бию ансамбле, концерт бригадалары Мәскәүдә, Ленинградта, Украинада, Белоруссиядә, Ульяновскида, Уфада, Казагыстанда, Үзбәкстанда, Себердә булдылар, безнең республикабызда украин, үзбәк, әзербәйҗан, кыргыз, башкорт, чуваш әдәбияты һәм сәнгате атналыклары үткәрелде. Казанда әдәби тәрҗемә мәсьәләләренә, балалар әдәбиятына, Идел буе әдәбиятларында бүгенге проза мәсьәләләренә багышлап бөтенсоюз киңәшмәләре, РСФСР язучылар союзы идарәсенең күчмә секретариатлары үткәрелде. Социализм төзелеше дәверендә, халыклар дуслыгы һәм пролетар интернационализм идеяләрен пропагандалауның әнә шундый яңа формалары рухи байлыклар алмашуны көчәйтте һәм яхшыртты, социалистик милләтләрнең һәм халыкларның берберсе белән алмашыр хәзинәләре зур икәнен күрсәтте. Безнең китапларыбыз, сәнгать хәзинәләребез, рус теле аша, бөтен илгә, иң күренекле әсәрләребез дөнья күләменә чыкты. Бөек Горький, үз сүзләре белән әйткәндә, «Казанда рухи яктан туган» Горький башлаган һәм үзеннән соңгы буыннарга васыять итеп калдырган рухи байлыклар алмашу көннән-көн арта бара.

Бөек рус халкының һәм совет илендә яшәгән башка халыкларның культурасы татар халкының канына сеңгән. Ил күләмендәге уңышлар нигезендә ул үзе ирешкәннәрне барлый, тагын да тизрәк үсү юлларын билгели.

Совет иле халыклары нибары илле ел вакыт эчендә кешелек дөньясы гасырлар буена ирешкән югарылыкка күтәрелделәр. Бу — бер максатка омтылып, ярдәм итешеп яшәү нәтиҗәсе. Бу — безнең хәтта дошманнарыбыз да кире кага алмастай хакыйкать.

СССР төзелүгә 50 ел тулган, Ленин идеяләре гамәлгә ашкан, тантана иткән дәвердә «Казан утлары» журналы укучыларын бөек бәйрәм белән котлыйм һәм эшләрендә яңадан-яңа уңышларга ирешүләрен теләп калам.

Рөстәм Мингалимов

# КҮЗ КАРАСЫ

ПОЭМА

> Милләтләрдән монда кем генә юк!
> Хезмәт көе тора яңгырап.
> Яңа Чаллы!
> Нигезеңә мин дә
> Татар җыры салып калдырам.

## Җыр башы

Җирдә бомба, бомба, бомбалар бар,
Янгын, янгын, янгын, янгыннар...
Ятим, ятим, ятим, ятимнәр бар,
Кайгы, кайгы, кайгы, кайгы бар.
Хәбәр, хәбәр, хәтәр хәбәрләр бар,
Гел яралый шулар бәгырьне...

Күз карасы кебек түгәрәк Җир
Күз карасы кебек кадерле.

Ерак күккә уза безнең юллар,
Юл башлары Җиргә таяна...
Сөйгән ярлар көтә юл башында,
Юл башында тора чал ана.
Җир өстендә безнең тузган йортлар,
Җирдә әткәйләрнең кабере...

Күз карасы кебек түгәрәк Җир
Күз карасы кебек кадерле.

Якты чишмә чыга елтыр-елтыр,
Нурга коенып үсә ак гөлләр.
Ташлар тезеп кеше йортлар сала,
Матур үтсен өчен гомерләр...
Кеше йортын кайчак кеше вата,
Күңелләрне шунысы җәберли.

Күз карасы кебек түгәрәк Җир
Күз карасы кебек кадерле.

Күлдә соңгы чаткы булыр күзләр.
Әгәр Җирне саклый алмасак!..
Ник йөрәкне кыса шушы тойгы,
Хыял канатларын ник баса?!
Хәбәр, хәбәр, хәтәр хәбәр нигә?
Нигә кайгы, кайгы, кайгы бар?

Нигә чыга янгын, янгын, янгын?
Нигә бомба, бомба, бомбалар?!

## Җыр дәвамы—җимерелмәскә

Сүзен
Чаллыдан башлаган иде бит,
Бомба турында
күбрәк сөйли, дип,
әйтүче булыр булуын.

Ләкин
миңа
моны әйтмәс
минем буын.

Минем буын —
Бомба ярылганда,
Йортлар ауганда
аунап
елаган малайлар.

Безнең —
җимерүчегә
үзебезнең караш,
үзебезнең —
үзгә —
ачуыбыз бар.

Шул ачудыр, ахры,
Безне
кырысрак итә,
Ләкин тырышрак итә,
төзелешләргә
ныграк
рухландыра.

Шул ачудыр —
41—45 нче еллардан бирле,
«Әзер бул, аң бул, сак бул!»
дигәндәй,
канымызда
сулкылдап тора...

...Дуслык,
Азатлык,
Бәхет өчен
илара килешүләрдә,
халыкара сөйләшүләрдә көрәшеп
Минем буын —
Таңнар тыныч тусын өчен яши...
...Чаллы — җимерелмәскә салына.
Кичер, кешелек,
Синдә җимерүче барын күреп,
минем буын —
яңа солдатлар әзерли
яңа Чаллы сагына.

— Бер-ике-өч!
Бер-ике-өч!
Ил чикләрен,
ил байлыгын
барлап,
яшь кенә кешеләр
бара...

— Бер-ике!
Яшь кенә кешеләр
баса
ракеталар янына.
...Чаллы — җимерелмәскә салына!
Яшь кенә кешеләр керә
корыч танкларына.
...Чаллы — җимерелмәскә салына!
Яшь кенә кешеләр чума
диңгезләр кочагына.
...Чаллы — җимерелмәскә салына!
Яшь кенә кешеләр —
«Тиздән кайтам», диеп
хат яза
әнкәсенә,
сөйгән ярына.

## Җыр дәвамы—шатлык өчен

Өр-яңа урамда йөрим...
Тормышта шунсы кызык —
Урамнардан мең узсаң да,
Булмый бит тыныч узып.
Шагыйрь башы уйлар өчен,
Уйлары — халкы өчен;
Шуларга таянып халкы
Өскәрәк калкыр өчен...
Якты яшен уйнагандай
Балкып ала уйларым,
Күзләреннән күрәм шул чак
Кемдә нинди уй барын.

Чагыштырып карыйм аннан
Хисләрен кешеләрнең,
Шәһәрләр киләчәгенә
Мин шулай төшенәмен.
Шулай итү хәвефләрдән
Саклану өчен кирәк,
Шулай итү алга карап
Шатлану өчен кирәк.
Яңа үсеп чыккан Чаллы
Ул сабый кебек әле —
Кайдадыр күке кычкыра,
Ул саный кебек әле.
Тик аның яшәр еллары,
Язлары, ярсулары —
Бүгенге безнең максатка
Таянып тора бары.
Ә максат — корал була ул
Хискә әйләнү белән;
Ул коралдан куәтлерәк
Коралның югын беләм.

## Җыр дәвамы—эш көне

Яшьләр —
Көчлеләр!
Эшлиләр!
Дөнья күргән
Картлар нишлиләр...
Берсе гаҗәпләнеп карап тора;
Торсын гына, ирек!
Берсе киңәш бирә;
Бирсен генә, ирек!
Берсе эшкә керә;
Керсен генә, ирек!
...«Туктале,
Нинди эш,
Нинди цех турында син?» диеп
Сүземне бүлдерсәң, ирек!
Ләкин беләсеңме, туганкай,
Миңа хәзер
Шигырьне —
Кирпеч, балчык, ком итәргә түгел.
Комны, балчыкны, кирпечне
шигырь итәргә кирәк,
Цехларны, машиналарны
шигырь итәргә кирәк.
Эш көне!
Бар да эшли...
...Күрәсеңме,
Күбәләк кебек кенә кыз —
Кранда,
Авыр панельләрне
югары этажга күтәрә.

Буем җитмәс аңа,
үрелсәм дә
гөлләр бүләк итәргә.
Әй, сеңлем,
Исемең ничек дип кычкырсам,
тавышым ишетелмәс үзенә.
...Каршымда үкереп,
Төяүле
Көчле машиналар —
Төзелеш мәйданына керәләр...
Бал кортлары кергәндәй
умарта күзенә.
Керәләр...
Монда юл кая?
Ничек барырга?
Ничек чыгарга биредән?
Карашың адашыр беренче күрүдә.
...Тегендә
Нинди тау иде, ә?!
Иске тау,
Гасырлар кичкән тау;
Эшчеләр —
Тотындылар аңа
хисләрен,
мускулларын киереп...

...Инде...
Горур тау...
каршыңда...
балавыздай эри:

Салдырып
Кара балчыгын
Ташыйлар бер якка —
Анда яңа тау, кара тау —
калка тора,
Бу ашлы кара җир —
Игенчегә,
комлы кырларына таратырга.
Яңа тау калка тора...
Иске тау — чүгә,
чүгә, урын бирә —
Кешеләр,
Тракторлар, экскаваторлар,
Тимер тешле машиналар
тауның сары балчыгын
гасырлар кичкән чокырга
төшерә...
Зур чокыр — тигезләнә;
Өстендә кызлар йөгерә,
егетләр йөгерә,
Тракторлар йөгерә.
Тормыш бара...
Читтәрәк өч шофер,
Озын рус
папирос өләшә

Һәм, бутап колгадай кулларын,
нәрсәдер сөйләшә;
Чандыры,
Казакъка охшашы,
үпкәли нигәдер;
Төп кебек татары
и көлеп кинәнә...
Аннан
өчесе өч машинага утыра,
каршыда
күренеш алышына:
...Шулай,
Эш көне, туганкай!
Бирелә кеше,
вакыт,
хәрәкәт —
барысы да ашыга.

## Җыр дәвамы—сүзләр

Ял кичеңче синең булдем инде,
Сиздермәдең үзең арганың...
Бүген менә хатыныңны алып
«Чулпан»га да керә алмадың.
Син шулай да кичерерсең мине,
Кичерерсең яшьтәш булганга...
Язмышларда безнең охшашлык зур,
Әтиләр бит бергә югалган...
Без «Чулпан»га бүген кермәгәннән
Югалтмадык, ахры, берни дә.
Үзебездән бүген, сүзебездән —
Кино чыгар иде бер дигән!
Безнең буын хәзер — җыр башында,
Җир башында, дөнья башында.
Күз тимәсен, кешелекне шулай
Матур гына илтә барсыннар.

Матур юлдаш итеп кешелеккә
Без Чаллыны биек күтәрик;
Мәшәкатьле, кыен минутларны
Бергә-бергә җиңел үткәреп...
...Сизелә ич иңгә мондагы йөк,
Чынлап-чынлап баса, нык баса.
Кыен булыр иде янәшәңдә
Алмаз кебек дуслар булмаса.
ГЭСлар төзеп үскән Рудаковлар,
Абдуллалар янда тору — шәп!
Алар белән кызык эш башкармак,
Бәхәсләшмәк, аннан килешмәк.
Ә Рәисләр, Умат Нурбиевлар,
Карпенколар — шундый егетләр!
Партиянең бөек чакыру булып
Яңгыраган сүзе кебекләр...

Синең хезмәтнең дә бик зурлыгын,
Мөһимлеген яхшы төшенәм...
Син генә дә... Сөйлисең генә дә,
Кешеләр бит янда, кешеләр!
Бер уйласаң, сиңа җиңел төсле
Нидер оештыру торакта:
Чәчрәп чыгып башлаучы да табыла,
Күрсәтүче табыла җырлап та.
Һәр эш аслы Җирдә нидер сөйли,
Синең сәхнә эше — синең сүз!
Ничә кеше залда, кемнәр алар —
Залдан сиңа карый ничә күз!
Безнең йөрәк, шундый гаҗәп йөрәк,
Анда күпме милләт тамыры!
Һәр тамырга сүзең көч бирдеме?
Син уйлыйсың җуеп сабырың.
Тоясың син — бу зал гына түгел,
Чаллы мәйданы бу, ил кыры!
Мондагы сүз — ул газорез кебек —
Металларны кисә сызгырып...
Сүз куәтен белгән кеше әйтмәс
Булмас диеп сүздән өй корып.
Тарих шаһит,
Сүзләр чыгардылар
Дәүләтләрнең нигезен суырып.
Яңа дәүләтләргә мәйдан булып,
Нигез булып сүзләр яттылар...
Сүзләр көрәшәләр, сүзләр җиңә.
Сүзләр тавыш биреп
Атлыйлар...

Синең хезмәтне мин яхшы аңлыйм;
Сынатмаска безгә ничек тә!
Без елмайсак — дөнья күрә аны,
Ютәлләсәк — дөнья ишетә.

## Җыр дәвамы—туйлар

Машиналар, машиналар, машиналар
Илнең барлык почмагыннан монда җыела.
Яңа завод эшен күреп сокланырга
Кама җыена, Идел җыена, ил җыена.

...Бер вакыйга
 әйтерсең мең тау артында
Һәм биредә сөйләргә дә аны бик соң:
Иң беренче булып кыю керган иде —
КамАЗ булыр җиргә Носков машинасы.
...Юк, соң түгел...
Батырлыкны сөйләү кирәк,
Тик сүземнө зур хәрәкәт булә тора:

Кырыс йөзләр, елмаюлар, шаян сүзләр;
Бертуктаусыз машиналар гүләп тора!
Машиналар, машиналар, машиналар —
Балчык этә, балчык ала... Бетон ясый.

Ә бер өйдә ял сәгатен туй итүче
Яңа парны биетеп яңа гармун ярсый.
Эх, Никола!
Ничек баса!
Оста баса!
Маринасы —
Шундый дәртле, өзә генә!
Өстәлләрдә стаканнар һәм чәчәкләр
Биемичә ничек кенә түзәр менә...

Бораулыйлар, бораулыйлар машиналар,
Машиналар субай суга, субай суга...
Калын нигез, авыр цехлар күтәрелә —
Кемдер авыр, кемдер җиңел сулап куя.

Ә бер өйдә ял сәгатен туй итүче
Нәсыйх белән Мәдинәгә текәлгәннәр.
Аккош кебек Мәдинәкәй шатлыгыннан
«Ачы!» тәмен аералмый баллы тәмнән.

Тракторлар, тракторлар...
Бульдозерлар...
Ярдәм килә... Чиләбедән дә Ташкенттан...
Волгоградтан, Куйбышевтан...
Сахалиннан...
Эшкә алу бүлмәсеннән чират чыккан.

Ярдәм килә —
Дулкын-дулкын самосваллар...
Грейдерлар...
Бетон изү машинасы...

Ә бер өйдә ял вакытын туй иткәннәр,
Кияү кеше,— дагстанлы сөйли басып.

Машиналар, машиналар, машиналар
Илнең барлык почмагыннан монда җыела.
Җыелуның кайтавазын тиз күрергә
Кама җыена, Идел җыена, ил җыена.
...һәм кайтаваз
Гигант КамАЗ
Капкасыннан
Күрелмәгән тимер ташкын булып китәр.
Ул ташкында кырлар аша, таулар аша
«Чаллы» сүзе, «Татарстан» сүзе үтәр.

# Җырның ахыры

Минем буын —
Таңнар тыныч тусын өчен яши...
Чаллы җимерелмәскә салына!
Кичер, кешелек,
Синдә җимерүчеләр барын белеп,
минем буын
яңа солдатлар әзерли
яңа Чаллы сагына:
— Бер-ике-өч!
Бер-ике-өч!
Ил чикләрен,
ил байлыгын
барлап
Яшь кенә
якташларым
бара...
Якташларым баса
ракеталар янына.
...Чаллы җимерелмәскә салына!
Якташларым керә
корыч танкларына.
Якташларым чума диңгезләр кочагына.
...Чаллы җимерелмәскә салына!

1971—72.

Барлас Камалов

# УРАМНАР КИҢӘЯ

ПОВЕСТЬ

## I

Зөһрәбану түти коелып инде. Телеграмма китерүче кыз татар икән, телеграф бланкасына язганнарны кат-кат тәрҗемә итеп бирде. Түтинең колакларына ышанасы килмәсә дә, кәгазьгә язганнан узар хәле юк иде. «Хатыным һәм балам белән кайтам. Августның өчендә, иртәнге унбердә Казаннан килүче пароходны каршылагыз. Улыгыз Вәдүт» диелгән иде телеграммада.

— Я рабби, әүвәлен-ахырын хәерле кыл,— диде Зөһрәбану түти, телеграмма китергән кыз артыннан капканы бикләп куйгач.— Нишләтсәң дә синең кодрәтеңдә, раббым. Кай арада хатын да, кай арада бала тагын?! Рәтлебашлы итеп хат язганы да булмады бит. Дөрес, өченче ел ук: «Монда үзебезнең як кызлары да бар»,— дип язган иде язуын. «Өйләнермен, ахры»,— дигән хәбәр кисәге дә булган иде. Күрәсең, бар киңәш-уңашы шул булып беткәндер... Мине уги ана итәр дә итәр инде ул, малай чактан ук баш бирмәс иде. Атасы белән дә авыз тутырып сөйләшмәде бит. Үзе дөньяда бик белдекле иде, хатын дигәне кем икән инде тагын?

Зөһрәбану түтинең күз алдына күгелҗем пәрдә эленде. Кояш тоныкланыбрак калган кебек булды.

— Я рабби, ният-теләкләрен генә изге ит. Ата-анага шәфкать-миһербанлы булсыннар,— дип пышылдады ул үзалдына. Кая гына китеп барды соң аталары да?!. Пенсиягә чыкмасын икән ул адәм баласы! Саусәламәт килеш, эшләмәгәнгә дә акча биреп торгач, юкка-барга аяк чарлаудан туктамый икән кеше дигәнең! «Район умартачыларының киңәшмәсе бит, ә минем гомерем бал кортлары белән үтте. Шундый көндә дә сине саклап утырыйммы?» — ди... Район хуҗалары да: «Морзахан абзый умартачылыкта остаз инде ул безнең!»—дип очындыралар,

---

Әсәрнең журнал варианты.

житмәсә. Карт жилбәзәкнең жил ягына саламны келтәсе белән кыстыралар...

Кайтмый да кайтмый дип пырлавы юкка булып чыкты. Морзахан абзый капка кыңгыравын чыңлатты. Тимер чыбыкның жилле генә тартылуына караганда, карты азрак кәефләнгән дип тә уйлады Зөһрәбану түти. Хәер, капканы ачып керткәч, Морзахан абзыйдан ис-пос сизелмәде, күзләре дә гадәттәгечә генә ялтырый иде. Карчыгының кәефе китек икәнне дә шундук абайлап алды.

— Ни бар, сиңа әйтәм? Йөзеңә көл сипкән шикелле,— диде.

— Вәдүт кайта.

— Соң, хода бәндәсе, ничә ел өндәп яза торгач, улыбыз кайта икән, куанырга кирәк. Бериш зирәк хатын булса, сөенче алырга дип каршы йөгерер иде...

— Үзе генә түгел бит, аталары.

— Өйләнеп кайтамыни? Хәерле сәгатьтә төкле аягы белән төшүче килеп булсын. Ху-у-уш! Егерме алты яшьне бастырыклап куйды дигандә, төпчек тә башлы-күзле булды, болай булгач. Ярый, ярый, шөкер. Картаймышлы көнебездә янибызда яшәргә кайта, арка таянычы булырга... Ату исә бит берсе — Сахалинда, нурлы йөзен ике-өч елга бер генә күрсәтеп китә. Кыз баламны әйткән дә юк. Анысы — кеше кешесе. Казагыстан тикле жирдән гел генә кайтып йөри алмый. Монысы да солдат хезмәтеннән соң ук Төмән тайгасына, Тубыл чытырманлыгына кереп чумган иде. КамАЗ жиле барып житте булып чыга төпчеккә. Автозавод жиле, яна кала хәбәре!..

Ул сөйләнә-сөйләнә өйгә кереп житкәч, хатыны түзмәде, чыраен сытып, кәефсезләнеп кул селтәде.

— Сабраниеңнән нитебрәк кайттыңмы әллә? Әйтер сүземне дә тыңлап бетермисең. Үз кырыгың кырык.

— Куанычлы хәбәр әйттең ләбаса!

Морзахан абзый бик нечкә кызгылт тамырлар беленеп торган коңгырт күзләрен зур ачып, түгәрәк сакалын сыйпый башлады.

— Соң, сөйли күр, хода бәндәсе. Тагын ни бар?

Зөһрәбану тәмам тулышкан, күзләренә пәрдә булып яшь саргаеп, иреннәре сабый баланың кәефсезләнгәне чагындагыча мимылдый иде.

— Икәү генә дә түгел бит, өчәүләшеп кайталар. Хатыным, балам белән кайтам, дигән. Кая гына тыктым соң шул гөнаһ шомлыгы тилиграмны?..

Зөһрәбану түти эзләгән кәгазен өстәл өстендә күрмәгәч, ашъяулыкны күтәреп карады. Аннан да электр өчен, радио өчен, базарда ит-сөт, бал һәм яшелчә сатканда урын өчен түләгәннең квитанцияләре генә очып төште. Комод тартмалары актарылды. Аннан да табылмады.

— Кайларга гына куйдым соң, валлаһи! Һай, бу хәтер дигәнең! — дип, ике янбозын чәбәкләгән иде, уң кулы күлмәк кесәсендәге кыштырдавык кәгазьгә тиде.

— Менә укы! Син бит урысчаны да шытырдатып беләсең,— диде ул, иренә телеграмманы сузып. Морзахан абзый пинжәгенең түш кесәсеннән футляр чыгарды, аны шыртлатып ачты да алтын йөгертелгән кысалы күзлеген алып киде. Зәңгәрсу кәгазьгә язылганнарны ул бик тиз укып чыкты һәм хатынына карап:

— Синеке хак, өчәү кайталар,— диде. Аннары, салмак кына атлап, аш өстәле янына барып утырды. Подрыкларын тез өстенә куйды һәм, паспортлык фоторәсемгә төшәргә җыенган кебек, башын күтәреп, түр як тәрәзәләргә карады. Йөзенә туп-туры төшкән кичке яктылык аның чал сакал-мыегын җемелдәтте, маңгаендагы һәм күз тирәләрендәге җыерчыкларны аермачык күрсәтте. Җыерчык дигәч тә, алар абзыйны күркәмлиләр генә иде шикелле. Муены нык, симез әле аның. Беләкләрендә дә

пт кимемәгән. Аркасына сизелер-сизелмәс кенә бөкре чыгып килә, ләкин әле ул таза гәүдәле, нык бәдәнле бу агайны артык картайтмый иде.

— Ху-у-уш! — диде ул, беравык уйга талган кебек торгач.— Ху-уш! Оның та булып өлгергән, димәк ки... Хатында язмады бит. Кызык итим әле дию булгандыр ташбашның... Җиденче тапкыр бабай булдым, димәк ки! Килен дигәнебез генә нәсел-ыругка төс була күрсен дә, иш була күрсен. Өченче август дигәне — иртәгә. Тубылдан Төмәнгә килгәннәр инде болар, аннан поезд белән Казанга кайтканнар, күрәсең. Казаннан пароход белән кайтасы иткәннәр. Самолет белән генә очасы итмәгәннәр, әй. Әйбер-мазарлары байтактыр, кем белсен. Пароходны сагынган, Каманы жирсегән, димәк ки...

Морзахан абзый урыныннан күтәрелде. Аннары диванда җәелеп утырган Зөһрәбануга эндәште.

— Торыйк, карчык. Өйне жыештырыйк. Аш-су хәстәрен күрик. Кешелеккә киярдәй кием-салымны сандыктан чыгарыйк. Малай гына түгел бит, килен кайта, оның кайта, рәхмәт төшкерләре!

Билгеле инде, Зөһрәбану түти дә кымшанмый булдыра алмады. Егерме елдан артык бергә гомер иткәч, хатыны яхшы белә: торып-торып Морзаханның талканы үтә коры. Җайлап бер әйтер, ике әйтеп багар, өченчесендә — өчәрләгән өзелмәс диләр ич! — җил-давыл куптарырга да күп алмас. Бигрәк тә төпчеге Вәдүт дигәндә. Ата кеше аны артыграк ярата. Улы армия хезмәтеннән туры өйгә кайтмыйча, Төмән нефтьчеләре янына елышып калгач та, карт дөньялардан үткәндәй йөргән иде. Дөрес, дорфаланып китеп: «Вәдүт синең арканда туган-үскән төбәктән йөз чөерде. Картаймыш көнемдә балаларымны биздереп бетердең!» — дип битәрләгәне булмады. Шулай да Зөһрәбану иренең күңел учагында нинди утлар янганын, сүрелде-сүнде дигәндә дә ниндирәк күмер елкылдаганын бик белеп, сизеп, аңгарып торды.

Инде атлап-тунлап әллә ни ерак жирдән кайталар икән, хәзинәдә барын өстәлгә чыгар, сөйкемсез сөяк булып күзләренә керәсең килмәсә, эчендәгене йөзеңә саркытмаска тырыш. Аталы бала арпаклы, дигәннәр. Вәдүт тә Морзаханга бә-әк газиз, бә-әк тә кадерле шул...

Олы улының кояш чыгышы ягында армия хезмәтендә булуына, кызының казакъ даласындагы чирәм жир совхозында көн итүенә Морзахан үзе әледән-әле пошынгалап алса да, бу хәлдән Зөһрәбану бик канәгать иде. Төп йорт эшенә тыгылып йөрмиләр, әтиләренә әләк сөйли алмыйлар, йомыш тапкан булып, бусага шомартмыйлар, әҗәткә акча сорап аптыратмыйлар. Тапканнары да, капканнары да картларның үзләренә генә.

Бүгенгәчә, мең шөкер, шулай иде. Инде, менәтрә, иртәгәләргә үк көн бозылып китмәгәе. Өерләре белән кайталар бит! Өйнең тынычлыгы китәсен көт тә тор инде. Бөтен тормышыңа хуҗа булып алулары бар. Үги улың белән үги килеңеңә ялчы булып йөрмәссәңме. Алла сакласын! Күрәсене күрми гүргә кереп булмый, дигәннәр. Бәбәй каратырга да күп сорамаслар. Ахирәт хатыннарың янына йөрергә дә җаең калмас. Һай, төпләнеп кала белмәде бит бу Вәдүт дигән җан иясе шул Себерендә генә! «Урай дигән бәләкәй калада әйбәт яшәп ятам»,— дип язган иде бит. Каласын да, тайгасын да мактаган иде. Ник кенә шул җирдә таш булмады икән!

Боларны Зөһрәбану эченнән генә уйлады, теленә ялгышып та рәнҗү-нирәү авазы чыгармады. Җилтерәп йөрде. Өйне жыештырды. Алгы өйдә тәрәзә пәрдәләрен алыштырды, чаршауның затлыга дигәнен элде, мичләр агартты, идәннәрне кырып юды, аяк астына кулда суккан яңа паласлар җәйде. Байтак гомер кул тими торган сандыкның капкачы шыңгырдап ачылды. Морзахан абзыйның да, Зөһрәбану түтинең дә яңа киемнәре чөйгә эленде. Йорт башы, көтү керүгә, кысыр калып симергән кара сарыкны суясын әйтте.

— Ит пешмәсә, бит пешә, дигәннәр, карчык. Ит кирәк, димәк ки. Вәдүтләргә насыйп ризык булып симергән икән рәхмәт төшкере сарык,— диде ул, чолан стенасындагы ярыкка кыстырган зур пычакны бармак битләре белән капшый-капшый.— Кайрап куйыйк әле моны. Аннары балның хәлен белешербез. Яңа бал өстисе түгелме икән?

Бал кою — бу йортта гадәткә кергән эш. Зөһрәбану анысына өзгәләнми, чөнки белә: Морзахан коюлы балны урынын, кешесен белеп кенә тота. Үзе дә алкынганчы чөмерүчеләрдән түгел. Әниләре вакытсыз дөнья куйган өч бала өстенә килеп, Зөһрәбануның шушы йортта гомер итә башлаганына егерме өч ел (ул килгәндә Вәдүт нибары өченче яше белән бара иде),— иреңең аяктан егылганын түгел, теле көрмәкләнгәнен дә күргәне юк. Ә менә кара сарыкка ашыгып пычак салырга кирәк микән? Аксап йөргән чуар тавыкны суйганда да бик җитәр иде ләбаса. Бер дә булмаса, әнә ГЭС поселогындагы зур кибеттән урыс суйган сыер ите генә алып кайтырга иде... Менә шулай башлана инде ул азар-тузар итү. Әле күзгә-башка кайтып күренгәннәре юк, аларга дигән калҗа казанга керергә тора...

Кичке чәйне соңгарып эчтеләр. Сарык суы әллә никадәр эш өстәде. Зөһрәбану түти арып китте. Өстәл башында самовары җырлап утырганда кәефе ярыйсы гына иде әле. Әмма беркавым көйләгәч, көмештәй ялтырап торган самовар ыңгыраша-сызлана башлады. Моңысы инде түтинең саруын кайната иде. Ул, уң кулы белән биленә таянып, урындыгыннан авырсынып кына торды да кече яктан самоварның «кәләпүшен» алып керде һәм «күңелгә шом салып ыңгырашмасана!» дигән кыяфәт белән аны самовар башына чәпәп куйды. Самовар тынды.

Самовар гына түгел, Зөһрәбану түти үзе дә эчтән тынды бу кичтә. Вәдүтләр кайтуга кагылышлы булып тел очына тезелешкән сүзләре байтак иде, ләкин аларны Морзахан абзыйга тукудан тыелып калды, алдан ук тәмсезләнеп куясы килмәде...

Иртәгесен картлы-карчыклы пристаньга юнәлделәр. Зәңгәр автобусның йомшак урындыкларына түш киереп утырган Зөһрәбану түти белән Морзахан абзыйны күргән кеше, мөгаен, боларның туйга баруларыдыр, дип уйлагандыр. Борын-борыннан юкка гына әйтеп килмәгәннәр шул — агач күрке — яфрак, адәм күрке — чүпрәк. Затлы киемнәрен кигәч, түти дә яшәреп китте. Абзый да бер-ике дистәне гомер чутыннан чигереп куйгандай булды. Хәер, кием-салым гына түгел, шатлык яшәртә кешене, шатлык көчнең яртысы.

— Пароход бик соңламасмы икән инде? Пристаньда берәр лювкавай туры килсә, шәп булыр иде, мин сиңа әйтәм. Ничә көн буена кояш кыздырды-кыздырды да, бүген менә мә сиңа — янгыр томалап алды гына, әй! Әнә күзеннән үткәргәндәй, сибәләпме-сибәли,— дип сөйләнде карт.

* * *

Урамда хәрәкәт, шау-шу. Автомашиналарның дәүләре үкереп узганда, янәшәндә атлап барган кешенең дә сүзен ишетми калуың бар. Шулай булгач, Григорий Прохорович Самородкин кычкырганга Гөлсемнең җәһәт кенә әйләнеп карамавы бик аңлашыла иде.

— Галя!

Гөлсем, гамендә дә булмагандай, атлый бирә. Автобус тукталышына баруы бугай.

— Галя!

Юк, колагына да элми. Шуннан соң Самородкин юлның иң кырыена ук китереп туктаткан «Жигули»ен янә тизләккә куйды һәм Гөлсем артыннан китеп барды. Тәмам тез астына бәрдерердәй булып якынлашкач, тормозга басты да тагын бер мәртәбә:

— Кара күзкәй! — дип кычкырды.

Монысын ишетми дә мөмкин түгел иде, Гөлсем үзенә эндәшүләрен аңлады. Чаллыда Гөлсемгә болай дип эндәшүче бер генә кеше бар. Ул — Григорий Самородкин. Фронтташ дуслар алар. Бөек Ватан сугышы елларыннан бирле бик якын танышлар. Сугышта русы-татары, әрмәне-грузины һәммәсе Гөлсемгә «Галя-чернокая» дип дәшәләр иде. Төн карасыдай, матур, зур күзләре өчен бирелгән исем иде бу.

Гөлсем ялт итеп борылды да өстенә килгән машинадан имәнеп тә китте. Аннары Григорий Прохоровичны танығач, көлеп җибәрде.

— Син икәнсең, хәерсез! Тавышы Гришаныкы, мәйтәм, үзе күренми, дим. Машинаңны беренче күрәм бит әле. Котлы булсын, Гриша! Исәнимин озын юллар узарга насыйп итсен. Ни хәлләрең бар?

— Хәлләр ярыйсы. Монтажникларча. Кая барышың? Әйдә утыр.

— Пристаньга барам. Сеңелем кайта. Шуны каршыларга.

— Утыр әйдә, утыр. Илтеп куйыйм үзеңне.— Самородкин кабинаның уң як ишеген ачты.— Аннары эшкә элдертәм. ТЭЦ төзелешенә.

Гөлсем кабинага иплəп кереп утыргач, хәл-әхвәл сорашып киттеләр.

Григорий Прохорович «Камгэсэнергострой»ның парткомына килгән икән. Секретарь белән сөйләшкән. Эштә көпчәккә таяк тыгучыларны сүгеп кайтып килүе, аһ-зарын түккән.

— Син тагын яңа бригада алгансың, диләрме? — Гөлсем чын түгелдер лә бу хәбәр дигән шикелле генә сорап куйды.— Ничек туймыйсың яңадан-яңа кешеләрне өйрәтеп, әй! Тагын яшьләр бригадасына күчтеңме?

— Әйе шул, Галя. Яшьләр белән эшләве күңелле. Картаерга ирек бирмиләр...

Аюны биергә өйрәтү җиңел дип әйтерсең тагын. Яшь җилкенчәк белән эшләү — тоз ашау инде ул, Гришенька...

— Кемдер өйрәтергә тиеш бит аларны.

— Шулаен шулай да соң, сиңа гына иза чигәргә димәгәндер лә инде. Бер ел дигәндә икенче бригада лабаса! Сиңа гына күп кирәкмени?

Григорий рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Миңа күп кирәк, бик күп, Галя! Аның караве, егетләрне һөнәргә өйрәткәч, куаныч эчкә сыймый. Теге бригадамны үз шәкертемә биреп калдырдым. Икәү ярышабыз хәзер аның белән.

Гөлсем дә уен-көлкегә бирелде.

— Һаман-һаман бала-чага белән мәшәкатьләнсәң, ярышучыларың бик тиз үкчәңә басарлар...

— Бассалар, мин дә ашыга төшәрмен...

Пристаньда Григорий бер дә тормады. Гөлсемне төшерде дә борылып китте.

— Кунакка кил! — дип калды Гөлсем.

* * *

Дебаркадер залында халык шыгрым тулы иде. Китүчеләр, озатучылар, каршы алучылар бихисап. Аяк төртер урын да юк. Яңгырлап торганга шулайдыр инде.

Зөһрәбану түти белән Морзахан абзый да ишек буена карап бастылар. Диван-эскәмияләрнең берәрсендә барып төртелерлек урын калмаганмы дип, тирә-юньгә күз йөртеп тә бактылар. Юк иде шул. Өстәвенә, кемнәрдер бәрелә-сугыла кереп-чыгып йөреп бимазалады. Шуннан соң Зөһрәбану түтинең түземе төкәнде, билет кассасы күршесендәге диванга барып төртеләсе итте. Шунда утырган бер хатын-кызга:

— Кая әле, канатым, кысыла төш әле! — дип, базу гына эндәште.— Син яшь әле, торып, аякларыңны язып килсәң дә гөнаһ булмас. Күрмисеңмени, карт кешеләргә дә урын юк...

«Карт кешеләргә...» дип, Зөһрәбануның Морзахан турында әйтүе

иде. Агай хатынының үтә чыккан әрсезлеген өнәп бетермәде.

— Мин басып та торырмын, үзеңне генә кара,— дип куйды.

— Басып торган чакларың да күп булгандыр бу дөньяда! Кил, утыр. Бар, канатым, бар, тәпиләп кил бераз...

Теге хатын бер калкынды, бер чүкте. Карчыгадай килеп ябырылган Зөһрәбануның чытырдап урын даулавыннан читенсенеп китте. Нидер әйтергә дип авызын да ачты, тик аның кипшенгән иреннәре генә кыймылдашты, сүзе чыкмады. Аның икенче ягына утырган Гөлсем Зөһрәбануга җилле генә бәреләсе итте.

— Син, туганкай, алай ук канатланып китмә әле! Аңлаш башта, хәл сораш. Сеңелкәш авырып тора икән әле, башы-кулы ут кебек. Бик каты суык тидергән. Ә син килеп тә кердең, почет сорап, урын даулап тәтелдәргә дә керештең. Хәтер саклап тормадың. Үзең китереп куйган персональный диваның түгелдер лә!

Зөһрәбануга энә кададыլармыни! Илле яшьләр тирәсендә булыр, кап-кара тутлы, түгәрәк йөзле, ияк очына ялгаган бер тотам тиресе агарып торган хатынның сүзләре аны чак кына сикертеп торгызмады. Урыныннан кубарга ярамаганлыкны, кузгалса, сүзе аста каласын уйлап өлгерде һәм арт саны белән этенә-төртенә җайлабрак утырды.

— Мыеклы түтүшкә! — дип мыгырданды ул, Гөлсемгә көйдергеч карап. Аннары чәрелди үк башлады.— Син тыгылма, кысылырсың, сытылырсың! Ияк очың тагын бер өзелер, сак бул!..

Бу тиклесе чамадан ашкан мәгънәсезлек иде инде. Гөлсем ялт итеп сикереп торды.

— Минем ияккә тел тидерәсе булма! Мунчага качып, кеше ире белән гыйшык-мыйшык уйнаганда тешләтеп өздермәдем мин аны. Сугышта снаряд кыйпылчыгы шулай «чибәрләде». Әй, синең белән тел әрәм итеп торганчы соң! — Гөлсем ачыргаланып, чырай сытып кул селтәде дә бер читкә китеп басты. Ярсудан, гарьлектән һәм кимсенүдән шул кадәр җилле атлап китте, ул уң аягы тездән югары протез икәнлегенә шик калдырмаслык итеп шакылдап баса иде. Тирә-күршедә утыручылар кыенсынып калдылар, Зөһрәбануга рәнҗүләре йөзләренә чыкты, сүзләренә күчте.

— Сөйли белмәгән авыздан ни артык дигәннәр? Бу апа да шулай. Сугыштан гарипләнеп кайткан кешегә тел тигезә бит!..

Дивандагылар, Зөһрәбануның чыраена төкерердәй булып, дәррәү урыннарыннан тордылар. Сырхап торган хатын да китеп барды. Әйтерсең лә һәркайсы Зөһрәбануның мәгънәсезлеге үзенә йогудан курка иде.

Урын бушады, тик Морзахан абзый хатыны янына утырмады. Ничә күз төртеп тишәрлек булып аларга карап торганда, алай гына да түгел, каһәрләп, каргап торганда, ни вөҗдан белән җәелеп утырмак кирәк? Шулай да ул Зөһрәбануның каршысына килеп басты һәм сүзләрен теш арасыннан сыгып чыгара-чыгара орышына башлады.

— Пычак тел дисәң пычак тел, адәм рисвае. Хәерле сәгатьләрне хәерсезгә борып йөрисең. Ни дип кагыласың кешенең гомерлек ярасына?! Бар, гафу сора, адәм рисвае! Кеше сине яклап утка кергән, син бәгырь талап утырасың. Бар дим, кешеләр алдында гафу сора!

Зөһрәбану, торып китәргә ниятләгән кебек, башындагы ак ефәк шәлен рәтләштергәләде, кара хәтфә тышлы җакетының чабуын тартып куйды, аннары аякларын бераз алгарак сузып, каюлы читекләренә карады. Ләкин торырга уйламады да. Башын ире ягына борып, әрепләшә башлады.

— Карт тиле төсле тормасана каршымда. Аксак-туксак хатыннар алдында кечерәю кирәксенсәң, сакалыңны сәлперәйтеп үзең тез чүк, ямә. Бик-ик исем китте, би-ик!

Сүз зурга үсмәсен дип, Морзахан да артыгын куертмады. Ярамый, диде ул эченнән, килен белән малайны этле-мәчеле каршылар хәл юк...

## II

Укытучысына гашыйк укучылар булгалый. Укучысына гашыйк укытучылар бик сирәк очрый. Шул сирәкләрнең берсе Рәйхан иде. Фаҗигале мәхәббәт ярасыннан савыгып барганда очратты ул Вәдүтне. Әмма укытучы белән укучының бер-берсенә гашыйклыгын гаепләүче булмады. Чөнки бу очракта хәл башка. Алар кичке мәктәпнекеләр. Укытучысы да, укучысы да. Рәйхан — Кама буенда туып үскән, мәктәп-интернатта тәрбияләнгән, гомер сукмагы Урайга китереп чыгарган, читтән торып пединститут тәмамлаган педагог, математика укыта иде.

Вәдүт — төзүче егет иде. Урайга килгәч, баштарак автокранда эшләде, аннары субай суктыруга күчте. Армиягә нибары сигез класс белем белән киткән иде. Шунлыктан, солдат хезмәтеннән соң, эшләргә дә, укырга да туры килде. Быел, кичке урта мәктәпне тәмамлап, кулына аттестат алды. Алда — вуз, дөресрәге втуз. Дәрте, хыялы шундый.

Аларның дуслыклары кай көнне һәм ничегрәк башлануын, бу хиснең егетләр белән кызлар арасында була торган гадәти дуслыктан кайчанрак үзып китүен тәгаен генә әйтеп тә булмас иде. Унынчы класста дәрес бирә башлаган атнада ук Рәйхан Вәдүт Шәйхаттаров дигән укучысының үзенә ничектер якын итеп каравын сизенде. Укытучы да чибәр, тыйнак бу егеткә тыныч кына карый алмый иде.

Көннәрнең берендә, нефтьчеләр клубында үзешчәннәр концерты булганнан соң, алар бергә кайттылар. Рәйхан, бер дә тартынмыйча, ләкин бик килешле генә итеп Вәдүтне квартирына чакырды. Шул көнне генә егет үзенең укытучысының балалы хатын икәнен белде. Ире юк икән инде, фаҗигале үлем белән вафат булган. Бу хакта Рәйхан читенсенеп кенә, теләр-теләмәстән генә сөйли иде. Вәдүт тә аның ярасына тоз сипмәскә кирәклекнә тиз чамалады һәм сүзне бүтәнгә борды.

— Сез төп кайсы яктан, Рәйхан Кәримовна?

— Татарстаннан. Кама буеннан. Тагын да төгәлрәк итеп әйтсәм, Чаллыдан.

— Яр-Чаллыдан әллә?

— Әйе шул.

— Менә яңалык! Без бер кала кешеләре икәнбез ләбаса!

Карап торышка гадәти генә шушы сөйләшү алар арасындагы барлык нәрсәне дә ачыклады шикелле. Һәрхәлдә, Рәйхан хәзер Вәдүт өчен бөтенләй ачып та карамаган китап түгел иде инде. Укытучысының узган көннәрен сөйләп бирүе, йөрәк ярасыннан юл читенә тәгәрәп калмыйча, көн итәргә тырышуы, баласына тиешле тәрбия бирергә ашкынып яшәве — кыскасы, мәлҗерәп, җебеп калганнардан булмавы Вәдүтне кайта-кайта уйланырга мәҗбүр итте. Үзе белән яшьтәш кенә булса да, байтакны кичерергә өлгергән бу яшь хатынга Вәдүтнең ихтирамы тагын да арта төште. Шулай да ул бермәлгә нилектәндер Рәйханнан читләшеп торгандай булды. Рәйхан үзалдына: «Минем балалы икәнемне белгәч, читкә тайпылуыдыр. Араның суынуы шушыдыр. Әгәр шулай икән, ул, ихтимал, иң дөрес юлдыр. Тормышта һәркемнең үз йолдызы булырга тиеш...» — дип уйлаган иде.

Берничә көннән Вәдүт, кыюлыгын туплап, Рәйхан квартирына килде. Өйдә аналы-уллы икәү генә иделәр. Рәйхан, гадәтенчә, алдына өем-өем дәфтәрләр куйган, контроль эшләр тикшереп утыра, ә улы Айдар (төскә-биткә суйган да каплаган әнисе икән!) идәндәге келәм өстендә уенчыклары белән әвәрә килә иде.

— Керегез! — дип, ишек шакуга җиңел генә җавап бирсә дә, бусагада Вәдүт басып торганын күргәч, Рәйхан уңайсызланып китте: чәчләрен сыпырып куйды, халат төймәләрен каптыргалаган булды, аяк астында аунап яткан уенчыкларны бер җиргәрәк җыйды, Айдарны кара-

ватына китереп бастырды. Малай, үз рәхәтен чикләгәнгә кәҗәләнеп, шыңшырга чамалаган иде, тик әнисе аңа илтифат итмәгәч, тынды. Рәйхан Вәдүткә чишенергә тәкъдим итте, урын бирде.

Һәрвакыттагыча, олы сүз әйтер алдыннан кеше дигәнен җыен юкбарны сөйләшеп алучан бит. Вәдүт тә хәл-әхвәл сорашты, Айдарның сәламәтлеге белән кызыксынды. Рәйхан, үз нәүбәтендә, Вәдүтнең төзелештәге хәлләрен сорашмый калмады. Ничек булса булды, шул килүендә Вәдүт үзенең кечкә мәктәптәге укытучысына (унберенче классны тәмамларга өч-дүрт ай вакыт калып бара иде инде) өйләнешү турында тәкъдим ясады.

Рәйхан сәгате-минуты белән җавап бирмәде, билгеле. Алай җавап бирә дә алмый иде. Егетнең бу тәкъдимен кат-кат үлчәп карамый булмый иде. Үзе хакында гына түгел, Айдар турында да уйланырга кирәк иде бит. Тормышны ничек башласаң, шул юл белән китәр, дип бик белеп әйткәннәр. Тормыш — зур остаз, түзә-чыдый өйрәтә, өйрәнмәсәң — көйрәтә дә. Көйрәп яшәргә калса, адәм баласының башы хәсрәттән, йөрәге газаптан чыкмый инде...

Көн көтте Вәдүт җавапны, атна көтте. Сабыры ике атнадан артыкка җитмәде. Ул, Рәйхан янына килеп, күңелендәген янә әйтте.

Вәдүт, Рәйханның җавап сүзен көтеп, укытучысының йөзенә текәлде. Рәйхан исә, ике арадагы сүзгә катнашы булмаган чит кеше шикелле, бүтән уйлар белән мәшгульгә охшаган иде. Аның каршында гүя эчке дөньясын каерып ачкан, тормышка бергә керергә кулын тәкъдим иткән ир-ат түгел, бәлки Урайдагы эшче-яшьләр мәктәбенең чыгарылыш классы укучыларыннан берсе, башкалардан һични белән дә аерылмый торган Вәдүт Шәйхаттаров басып тора иде.

— Син соң мине балаң куркыта дип уйлыйсыңмы? Әллә булмаса, миңа кадәр сүз кушып өлгергән башка берәр кешегә вәгъдәң бармы? — дип сорарга мәҗбүр булды Вәдүт.

— Андый бер кемем дә юк. Айдарны үз балаң төсле якын итә алырсыңмы соң? Җитди сүзне үзеңә ышанычың зур булганда гына сөйләвең хәерле.

— Һәммәсен дә уйладым, Рәйхан! — (Вәдүт беренче тапкыр аңа «Рәйхан Кәримовна» димичә, бары тик исеме белән генә эндәште.) — Айдарны мин үз улым итеп яздырачакмын.— Вәдүт шулай диде, ә үзе, шиккә калгандай, сагаеп Рәйханга карады.— Син риза булсаң, билгеле...

— Һәммәсен дә уйлаган булсаң, Вәдүт, уйларыңнан кайтмас булсаң, мин риза,— диде Рәйхан. Шул секундта аның күзләренә яшь килде, һәм ул кухняга кереп китте.

Хатын-кызларның һәркайсы кебек, Рәйхан да озак көтелгән көннең бер килэсе, үзенең яңа яуган кар төсле ак күлмәк киеп, ак бөркәнчек бөркәнәчәге турында хыялланып яшәгән иде. Аның янында дөньяда иң якын кешесе булачак. Шушы якыннан-якын кеше хакына Рәйхан ике дә уйламыйча әллә нинди михнәтләр кичерергә, кирәк икән җанын бирергә дә әзер. Алар туй мәҗлесе түрендә кулга-кул тотынып утырырлар һәм бер-берсен күз карашларыннан ук аңлашырлар... Тик ни аяныч! Ни үкенеч! Ни сагыш! Аның белән туй өстәле башына утырырмын дип хыялланган кешесе иң мәгънәсез үлем белән дөньядан китте.

Менә хәзер бөтенләй бүтән берәү гаилә корыйк дип тәкъдим ясады. Икенче мәхәббәт бармы соң ул? Чын мәхәббәтме ул? Шуңа таянып, тормышка бергә керергә вәгъдәләр беркетеп буламы?..

Әнисе күздән югалып торгач, Айдар хафалана башлады, түр башында утырган ят абыйга ятсынып карап-карап алды да елап җибәрде. Вәдүт аны юатырга ашыкты, бала караваты янына килеп, Айдарны кулына алды. Тик малай тынычланырга уйламады да, аяклары белән тибенә, куллары белән бутана башлады. Шунда, күзләрен тиз-тиз серпкәләп, Рәйхан түргә чыкты һәм баланы үз кулына алды.

— Шулай тәртипсезләнәләрмени, улым? Һай, Айдар, Айдар! Абыең үзеңне кулга алган, синең белән уйнамакчы, сөйләшмәкче була, ә син көйсезләнәсең...

Айдар: «Мин бит аны белмим әле. Ятсынып кына еладым», дигән кебек, яшьле күзләрен елтыратып елмайды да, ят абыйдан оялган сыман, йөзен әнисенең җилкәсенә каплады.

— Син гафу ит мине, Вәдүт,— диде Рәйхан, баласы тынычлангач.— Хатын-кыз балавыз сыкмый гына яши алмыйдыр инде. Әллә нишләп киттем, йөрәк кага башлады... Сүзем шул: мин риза. Алай да бер шартым бар. Уку елын тәмамламый торып өйләнешмибез, яме?

— Май азагында, алайса?

— Әйе.

— Инде мин бер шартымны әйтсәм?..

— Рәхим ит.

— Туй иткәч, Чаллыга кайтабыз. Бөтенләйгә. Автомобиль заводы төзергә. Яңа шәһәр салырга. Син ризамы?

Рәйхан көтмәгәндә икенче бер кыенлык алдында калды. Монысы да бер селтәнүдә генә хәл кылына торган мәсьәлә түгел.

— Кыен мәсьәлә куясың бит син минем алга, Вәдүт. Минем, турысын әйтим, туган туфракка кайтып яшәү турында күп уйлаганым бар. Әти-әнинең кабере шунда. Гөлсем апам шунда яши. Аннан соң, гомумән, безнең Кама буйлары бик матур як бит. Тик бүгенгә кадәр мин ул якка кайтып төпләнергә ашыкмыйм. Сыңар канат, тол хатын, ятим балам белән мин кемгә тансык? Апаның үз мәшәкате үзенә җиткән. Инвалид кеше, сугыш аркасында бөтен тормышы зир-зәбәр килгән ялгызак. Ни ире, ни баласы. Пенсиясе янына куш булсын дип эшләп әрсезләнә. Ирләр тулай торагында комендант ул. Кайтып аны тыгызлыйммы? Инде менә синең белән бергәләп кайтканда...— Рәйхан бер мәл эндәшмәде. Күңеленнән нидер үлчи сыман иде. Кыйгач кашларының җыерылгалап куюыннан, иреннәренең кысылуыннан шул аңлашылды.— Синең туганнарың безне ничек кабул күрер? Үги әнкә дигәнең бар. Ул сиңа, синең семьяңа ничек карар? Балалы хатын алуыңа әтиең ни дияр? Без алар белән бер куышка сыя алырбызмы?

— Болар барысы да урынлы сорау, Рәйхан.— Вәдүт Рәйханның тел төбен дөрес аңлап алды, шуңлыктан кабынып, дәртләнеп сөйли башлады.— Урынлы сорау, әйе. Һәммәсен хәл итеп булачак. Әткәй әйбәт кеше минем. Теләсә нинди хәлдә дә ярдәменнән ташламаячак. Бәлки әни дә олыгайган, өлкәннәрчә уйлый булыр инде. Аннан соң бит мин дә көтү каршыларга чапкан ялан аяклы малай түгел. Кулымда һөнәрем, эшем бар. Мин токарь да, шофер да бит әле. Ә сиңа эш кайда да бетәсе түгел. Бер куышка сыеша алмасак, шәһәр тикле шәһәр калыккан төштә төзүче белән укытучы урамда торып калыр дисеңме? Айдарга да ясле табылыр. Менә дигән итеп яшәрбез, Рәйхан! — Вәдүт канатланып китте.— Әткәй яза әнә, ата-бабалары моннан ачлык елында кубарылып киткән кешеләрнең балалары да кайталар, туган туфрак тарта ул, ди. Заманасында Магнитканы салышырга киткән, Днепрогэсны төзешкән кешеләр тартыла Кама буена. Урта Азиядән, Ерак Көнчыгыштан якташлар кайта. Һәм моны бик табигый дип санарга кирәк. Тора-бара алар кадровый эшчеләрнең алтын фондына әйләнәчәк. Башта төзешерләр, аннары заводның үзендә эшләрләр, шулай ич. Мин беркөн Мәскәү газеталарының кайсындадыр укыдым, КамАЗ корылышында хәзер кырыкка якын милләт кешесе бар икән. Төзелеш институтының анда ачылган филиалына беренче курска уналты милләт егете һәм кызы имтихан тапшырган! Кызык, әйеме?! Төзүчеләрнең уртача яше — егерме өч яшь! Шуннан чамала инде, без дә анда шактый олы кешеләр булабыз түгелме?

Рәйхан җилкенеп-кабынып сөйләгән Вәдүткә сокланып карап торды һәм, кәефен кырмаска теләп, җаена торып кына җавап кайтарды:

— Күчеп йөрү — миң газап,— ди минем Гөлсем апа. Ул — Чаллыга кайтып төпләнгәнче күчеп йөри-йөри байтак тоз ашаган кеше. Аптыраганнан әйтәдер. Без дә уйларбыз әле... Ишектән чыгасы булсаң — илле төрле, капкадан чыгар булсаң кырык төрле уй төшүчән бит.

Алай да, болай да исәпләп карадылар. Кайтырга дип тәмам карар кылганнан соң икеләнеп калган, янә һәр нәрсәне бәйнә-бәйнә сөйләшеп, фикерләшкән көннәре дә булды. Ниһаять, тәвәккәлләделәр. Менә аккош төсле ак теплоход яшь гаиләне ил моңарчы күрмәгән төзелешкә, Чаллыга алып кайта.

### III

Пристаньдагы халык трап сузасы төшкә ябырылды. Теплоходтан чыгучыларга тар гына ара калдырып, тезелешеп бастылар. Шау-гөр башланды. Дебаркадердагыларның беришесе теплоход ишеге төбенә килеп җиткәч, танышларына кул изи, теплоходтан да сабырсызланып кычкыралар, хәл сорашалар. Гадәттәге ыгы-зыгы башланды. Трап суздылар.

Бер кулына кечкенә чемодан, икенчесенә Айдарны күтәреп, Рәйхан алдан атлады. Авыр зур чемоданнарны алып, Вәдүт аңа иярде. Әти-әнисе халык төркеменең аргы башындарак тора иде, алга кереп кысылырга кыймаганнар инде, картлар ич.

Халык арасыннан үтеп чыгарга да өлгермәделәр, яныннан узган һәр кешене күзеннән кичереп торучы бер апа, дулкынлануын яшерә алмый, кычкырып җибәрде:

— Рәйхан сеңелем!.. Исәнме, саумы? Кайтуыгыз белән! Монысы синең бәләкәч буламыни инде? Әткәсе кайдарак?

Бу — Гөлсем апалары иде. Ул, ирләрчә колач җәеп, Рәйхан белән Айдарны икесен берьюлы кочаклады, сеңелесен дә, бәләкәй егетне дә битләреннән үбәргә өлгерде һәм, күгәрчендәй гөрли-гөрли, теплоходтан чыгучылар агымына кушылып, ярга таба атлады. Арттан авыр чемоданнар күтәреп чыгып килгән Вәдүт тә, ниһаять, якында гына әти-әнисен күреп алды, куллары буш түгел иде, шат елмаеп, өлкәннәргә сәлам бирде һәм:

— Әйдәгез, иркенгә чыккач күрешербез,— диде. Морзахан абзый белән Зөһрәбану түти улларына ияреп киттеләр. Дебаркадер басмасын кичеп, ярга чыккач, узаеры бер төркемгә бастылар.

— Исәнме, улым! Имин-аман кайтып җиттегезме? — Морзахан абзый кушучлап Вәдүтнең кулларын кысты, аннары иңеннән сыйпап куйды.

Зөһрәбану түти дә бик ачык чырай белән килеп күреште.

— Саумы, әнкәй! — диде Вәдүт тә. Ул шундук Рәйхан белән Айдарны үз янына чакырды.

— Менә киленегез, әти-әни. Рәйхан. Тумышы белән безнең як кызы. Монысы — оныгыгыз. Айдар батыр.

Карт белән карчык иң әүвәле Рәйхан белән бик кунакчыл күрештеләр, аннары Морзахан абзый малайны күтәреп үк алды.

— Шәйхаттаровлар ыруының иң яшь кешесе шушы буламыни инде? Саумы, кечкенә улым, саумы? Дәү үстеңме инде?

Бала елмаерга да, ирен ямьшәйтергә дә белмәде. Күзләрен ялт-йолт китергәләп, бер сакаллы бабайга һәм әбигә, бер әти-әнисенә карады да, үземнекен үз итәм дигән кыяфәт белән, Рәйханга кулларын сузды. Айдарны кочагына алгач, килен дә телгә килде.

— Инде, әткәй-әнкәй, сезне апам белән таныштырыйм,— диде ул, күрешү шатлыгыннан тулышкан хәлдә.— Гөлсем апам, әтиемнең туган

сеңелесе. Бәлки, күргәнегез дә, очратканыгыз да бардыр, Чаллыда өченче елын эшли инде...

Менә шунда олыларның өчесен дә — Гөлсемне дә, Зөһрәбану түти белән Морзахан абзыйны да — ток бәреп алгандай булды. Ак диярга дә, кара диярга да җай калмаган иде. Зөһрәбану дерелдәп китте. Үте сытылыр дәрәҗәгә җитеп, тыны кысылды, күкрәк читлеге өстенә тегермән ташы бастырып куйдылар диярсең. Сырты сынса да сер сынатмаска теләп, бая булган хәлне кысанлык бәласенә юрап, башлап сүз кушарга һәм барып күрешергә дә калкынып бакты, тик булмады. Юк, булдыра алмады. Балтырына таш асканнар, телен аңкавынаябыштырганнар иде. Морзахан коткарды:

— Без таныштык инде!.. Вай, хак тәгалә хикмәте, мин сиңа әйтим. Кодагый белән кайнигәч, әле сезне пароходтан каршыларга дип килгән җирдә, пристань вокзалында бер карыш урын өчен чүт якалашып китмәделәр бит, әй! Я, ярый, узган эшкә салават! Дөнья бу, талашып танышырга насыйп, күрәсең. Аның каравы, гөрләшеп, чүкердәшеп яшәргә язсын. Исәнме, Өммегөлсем сеңел? — диде ул һәм беренче булып кул сузды.

Гөлсем исә бер дә вакланмады.

— Әй, кода. Андый гына сайрашып алу була инде ул. Булган — беткән, бигайбә. Танышып җибәрик шул,— дип, кыю гына кул бирел күреште. Кодагыйга да кырын карамады. Зөһрәбануның теле шуннан соң гына ачылды:

— Ходага шөкер, балалар сау-сәламәт кайтып ирештеләр. Әүвәлеахыры хәерле була күрсен. Күрдек-күрештек, оясы тузгыган кошлар кебек су буенда басып тормыйк, өйгә кузгалыйк. Әйдә, килен, Вәдүт, киттек. Әтисе, берәр машина юнәтсәң, бигрәк шәп буласы иде дә соң... Әйдә, Өммегөлсем, кайтыйк. Минем анда һәммәки нәрсәм әзер. Самовар гына куеп җибәрәсем бар. Өф дигәнче ашым-чәем дә әзер буласы,— дип, алдан кузгалды. Морзахан абзый «люгкавай» әмәлли алмады алуын, шулай да теплоходтан төшүчеләрнең хәлен аңлаган шикелле, елкылдап торган автобуслар бер-бер артлы килә торгач, өченчесендәме, дүртенчесендәме, урын иркен булды. Автобустан төшкәч җәяү кайтасы ара ерак түгел иде инде.

Вәдүт белән Рәйхан күзенә ташланган беренче нәрсә — шәһәрдә ыгы-зыгының чамасыз артуы иде. Теге елларны авыл да авыл, Чаллы да авыл иде. Кешеләр мәш килгән төш берләнбер үзәк урам да, пароход килгән сәгатьләрдә пристань иде. Хәзер тыз-быз чапкан машиналарның да саны-исәбе юк, эш киеменнән йөрүче халык та бихисап, бәйрәмчә киенеп урам тутырганнары да аз түгел. Төп йортка кайта-кайтышка дикъкатьне тарткан урамның аргы башында, КамГЭС поселогына терәлеп торган ягында, күккә үрелгәндәй калкып чыккан күп катлы йортлар, яналарын салырга дип бушатылган мәйдан, су һәм газ, җылылык һәм канализация уздырырга дип казылган тирән, озын траншеялар булды. Кая карама, актарылып ташланган җир, өем-өем сары балчык. Туя белмәс җан шикелле әледән-әле корыч иякләрен зур каерып ачучы экскаваторлар, скреперлар, бульдозерлар. Кирпеч ташыйлар, идән һәм өрлекләр, ишек һәм тәрәзә кысалары ташыйлар. Ташпулатлар арасында калган авыл өйләре кечерәеп, бөтәшеп киткәннәр төсле.

Рәйхан шул минутларда нәрсә уйлагандыр, Вәдүткә туган урамнарындагы таныш йортларның нигездән юкка чыгуы кызганыч тоелды. Бу тирәдә төзелеш шулай барса, тиздән, бик тиздән аларның йорты да сүтеләчәк, димәк!

Менә кайтып та җиттеләр. Ташпулатлардан кул сузымында гына диярлек утырган туган йорт. Кара-каршы биек тә, киң дә итеп салынган ике өй. Чоланы үзе генә дә ярлы кешенең йорты кадәр. Гомер-гомергә бер төрле буяулар яратты Морзахан абзый. Түбә калаен гел яшелгә,

тәрәзә капкачларын зәңгәргә буятты. Хәзер дә шулай. Түр бакчадагы куаклар арасыннан зур тәрәзәләр күренде. Биек коймалар. Урыс капка. Артта — бүрәнә сарайга һәм келәткә сыенып үскән җиләк-җимеш бакчасы. Умарта оялары. Аларның кышкы торагы — чүннек.

Капканы шыңгырдатып ачып җибәрүләре булды, барчагызны берәмберәм буып ташлыйм дигән төсле җикеренеп, бәйдәге Юлбарыс өрә башлады. Бүре дә бүре, бу да бүре иде, әкәмәт! Хәтта Вәдүт сискәнә язып калды. Рәйхан белән Гөлсем, тәпиләренә суккан шикелле, капкадан керүгә, атламас булдылар. Айдар куркып елап җибәрде. Этkә әйтерсең шул гына кирәк иде. Куәт белән тартылганга муенсасы кысты, ул аның саен буыла-буыла өрә, үрсәләнә. Морзахан абзый аны әрләп баккан иде, алай да басылмады. Шуннан соң хуҗа аны оясына бикләп куйды.

Кунаклар капка төбеннән болдырга тикле җәйгән таш юлдан өйгә атладылар.

Вәдүткә һәр нәрсә таныш та, җанны чеметтерер дәрәҗәгә житеп якын да иде. Ул хәтта чолан идәненең кайсы тактасы ничегрәк шыгырдаганын да күңелендә саклаган иде шикелле. Бүрәнә ярыкларының һәммәсен кәгазьгә ясап күрсәтә алыр иде шәт. Авыл ипие исе, яңа гына сауган сөт исе, әвеслектән килгән печән исе аның борынын кытыклады. Болдырда ук чисталык ялт итеп тора. Чоланны, алгы өйне әйтәсе дә юк. Борынгыда мондый чиста-пөхтә идәннәрне «мәчет идәнемени!» дип мактаганнар.

Чиста яшәү дигәндә, аш-суга кулы яту дип әйткәндә, ирен һәм балаларын пөхтә йөртүгә килгәндә, Зөһрәбану дөньяның уңганнарыннан берсе инде. Бүтән якларына ни дисәң дә, бу җәһәттән тел тидерерлек түгел. Вәдүт моны күптән белә иде. Рәйхан да чәй өлгергән арада ук боларның барсын искәртеп алды. Гөлсем апасы, минем сенелгә кайнана йортында бик тырыш, бик житез булырга туры киләчәк, дип күңеленә беркетеп куйды. Килгән җире — килен җебе, килмәгән җире — киле сабы, диләр ич.

## IV

Зөһрәбану түти табын хәзерләде, чәй өлгертте. Кунаклар хөрмәтенә өйдә пешкән чәкчәк тә, гөбәдия дә тел йотарлык иде. Алмаларның асылы күз явыңны алырлык. Кәрәзле бал үзе генә дә ни тора! Морзахан абзый исә балның кәрәзсезен, чымырдап торганын алып керде.

— Бал бирим үзегезгә, балкып чыксын йөзегезгә! — дип, такмак аралаш улы белән килененә һәм кайнигәчкә коелган бал чәшкәләре тәкъдим итте ул.— Кендек каны тамган төшкә исән кайтуыгыз, шунда тамыр җибәрүегез шәрәфенә, балаларым! Синең белән туганлык җебен төенләү хөрмәтенә, Өммегелсем туган! Әнкәсе, мондый-мондый хәл хакына син дә ирен чылатасыңмы әллә?

Зөһрәбану, олылардан тарсынган бала сыман, кыяр-кыймас кына, бал чәшкәсен кире этәрде.

— Ни гомер яшәп тә орынганым юк. Бүген генә авызланмыйм инде. Гаеп итмәгез,— диде.

— Ихтыярың — иркең кыр, әнкәсе. Әйттем исә кайттым, әйләндем дә яттым, әйтеп кенә бактым...— Морзахан торган саен җорлана барды.— Колмаксыз нигъмәт ул, икеләнеп тормагыз, Өммегелсем, балалар...

— Икеләнү дигәнең бездә юк ул, кода,— диде Гөлсем.— Шулай да безнең татарда: «Балны башлап балчы авыз итә»,— дигәннәр...

— Һай, дөресен әйттең, Өммегелсем туган! Аллага тапшырдык...

Морзахан абзый белән Вәдүт батырып әчеп куйдылар. Рәйхан белән Гөлсем, билгеле инде, күңел күреп, авыз итеп кенә куйдылар. Зөһрәбану барысын бергә кыстарга кереште.

— Өстәлдә барыннан житешегез әле, житешегез. Ә кечкенә улымны нәрсә белән генә сыйлыйм икән, ә?

Айдар кайтып кергәннән бирле күздә-кашта булды, тик аның хәзер ашыйсы да, эчәсе дә килми иде инде. Юл аны йончыткан иде, күзләренә йокы төште. Шул сәбәпле көйсезләнә үк башлады. Рәйхан аның аяккулларын юдырып, өстен алмаштыргач, йокларга салды.

Чәйдән соң чемоданнар ачылды. Бирнәле килен — бикә килен, бирнәсез килен — чәүкә килен дип әйтүләрне белгәндерме, юктырмы, Рәйхан эти-әнисенә һәм апасына бүләк алу турында Вәдүткә кат-кат әйтә торды. Вәдүт исә ул мәшәкатьне тулысы белән Рәйханга тапшырды. Мин синең янәшәңдә шаһит булып кына басып торачакмын, бүләк алганым да юк, ала да белмим, дип котылды.

Улы белән килене бүләк өләшүне Морзахан абзыйдан башладылар. Картка лавсанлы материалдан теккән костюм һәм бик әйбәт кәләпүш алып кайтканнар иде. Морзахан абзый бик-бик канәгать булып, кат-кат рәхмәт укыды. Кеше күнеле кытыклы шул, кытыклы. Киям дисә киярена аптыраган кеше түгел дә бит, санга сугып, бүләк алып кайткач, йөрәккә май булып ята...

Зөһрәбану түти, бүләк тоттыргач, сүзсез калды. Бигрәк затлы, бигрәк матур гәрәбә муенса алганнар иде аңа. Хәер, Гөлсем апаларына да пардан шул ук бүләк иде. Хатын-кызларның да рәхмәте тау чаклы булды. Алар гәрәбә муенсаларны шундук тагып карадылар, аннары янә кулларына тотып, һәр төймәсен берәмтекләп күздән кичерделәр. Шул арада Зөһрәбану Гөлсем кулындагы муенса төймәләрен санап чыгарга өлгерде. Аның күнеленнән: «Апасына күбрәк төймәлене бүләк итмәдеме икән?» дигән көнчелекле уй сызылып үтте. Шайтан вәсвәсәсе булган икән, ике муенсадагы төймәләр саны да бертигез иде.

Яшьләргә рәхмәт укып, тигез гомер, саулык-сәламәтлек, җан тынычлыгы, имин хезмәт, бәрәкәтле тормыш теләп бетергәч, сүз акрынлап дөнья хәлләренә күчте. Төмән якларын сораштылар, Урайдагы тормыш белән кызыксындылар, ничек бер-берегезне табыштыгыз, дип тә сорамый калмадылар. Зөһрәбану түти Вәдүтне җиренә җиткереп хат-хәбәр язмавы өчен тиргәргә дә ниятләгән иде дә, Морзахан абзый, гадәттәгечә, буласы булган, буявы уңган, иң важные — балаларыбыз өй түрендә, диештергәләп, карчыгына тел озайтырга җай калдырмады. Тора-бара әңгәмә Чаллының бүгенгесе, анда иртәгә туарга борынлап торган хәлләр, завод корылып беткәч ниләр булачагы турында куерды.

— Тынлыгы бетте безнең якларның! — диде Зөһрәбану түти.— Бетте, ходаның хикмәте. Чирү басып алды Чаллыны, чирү. Ата улны, ана кызны белә торган ише генә түгел. Ирләрен хатыннардан, хатын-кызын ирләрдән аерып алыр хәл юк. Бар да чалбардан, камминзуннан. Башларында, пасха диләрме, хасха диләрме, тимердәнме, сөяктәнме әвәләгән башлык. Ул дәү пулатларда торучы халык арасында кемнәр генә юк, жаныем, ходаның хикмәте. Әрмән дә бар, яврәй дә бар, казагы да, урысы да, чегәннәр дә бар, билләһи!

Морзахан абзый аның сүзен бүлдерәсе итте:

— Син ничек исәплисең соң, әлегә тикле Рәсәй тикле Рәсәйдә атабабаң күрмәгән, аларның төшенә дә кермәгән завод корсыннар, имеш тә, Зөһрәбану белән Морзахан карт, күрше Хуҗиәхмәт белән каршы Сәмига салып бирсеннәрме аны?! Төтене туры тарткан кеше чамалый инде, дөньяда иң зур заводны, янына каласын өстәп, бөтен ил белән генә корып була. Ил дигәч, бел: Советлар Союзында нинди генә милләт халкы юк. Һәммәсе килә. Барсы үзеннән хәл-хәленчә өлеш бирә. Америкадан Форд малае килеп киткән икән бит, күреп кенә булмады. Шул әйткән, мондый колач белән сезнең ил генә төзи ала, байткә, дигән...

— Мужет, Пырт малае, әмрикан булса да, монысын дөрес әйтәдер. Күзе чыкмаган, күрәдер. Алай да бер генә дә күңел ризалашып китми

шул, эткәсе. Элек ничек иде? Халык берсен-берсе белә иде. Бүген дөнья күткәнен генә түгел, ата-бабасын, әби-әнисен... Өйләнешсә дә, өмә ясаса да, үлем-китем булса да, кайгы-хәсрәт килсә дә, шатлыгы ташыса да. Хәзер ни, ул ташпулатларда каршы фатирда кем яшәгәнне дә белмиләр, аена бер йомышка керешмиләр. Аскы этажда кеше үлгәнне, аны җирләп куйганны да өнәми калалар. Бер тәңкә акча сорап кер, ышанып бирмиләр. Ю-у-ук, бирмиләр. Кем дә ышанмый сиңа. Белми ул сине, и, ходаның хикмәте, бик белергә дә теләп тормый...

Рәйхан аның фикере белән килешмәде.

— Кичәле-бүгенле килгән кешеләр генә ятсынып тора, бер атна дигәндә бөтен подъезды танышып, үзләшеп бетә, әнкәй.

Вәдүт тә хатыны сүзен җупләде.

— Син гомереңнең күп өлешен биек койма артында уздырганга шулайрак тоеладыр, әнкәй. Элек бөтен Чаллыга күпме кеше булган? Хәзер күпме. Кырык меңнән артык төзүче генә бар, дисез. Тиз генә танышып, белешеп китәрлек тә түгел шул. Аның каравы, хезмәт урынында бер семья кебек эшлиләр. Безнең Урайдагы идарәдә кемнәр генә юк иде. Бик шәп белә идек бер-беребезне...

— Белмим инде, мужет, мин картаеп киткәнмен. Элек булыр иде, җәйге кичләрдә өздереп гармун уйнарлар, гармун моңына кушылып матур итеп җырларлар иде. Таң алдыннан йөрәк маен сызарлык итеп җырлап кайтырлар иде. Хә-зе-ер, җанкисәгем, иртә дә дөбер, кич тә дөбер. Ташка гына үлчим. Йөргәндә дә кулларына кранзистр күтәреп йөриләр бит, мырый! Һаман шуны акырталар. Кит инде, кит, аллам сакласын. Ул бию дигәннәрен күрсәгез, косарсыз, билләһи, косарсыз. Әле корсак бүлтәйтәләр, әле арт саннарын сузалар. Куллары җүләр кеше чебен тоткандагы кебек чәбәләнә. Аяклары камыр төсле, сыгылыпсыгылып төшә, билләһи!..

— Яшьләрнең барсын бер исәптән алай яманлап ташларга ярамый, әнкәй! — Рәйхан тавышына җитдилек бәреп керде.— Казан кайнаганда, күбек тә кабара, юшкын да утыра, әнкәй. Хәзерге кыз-егетләр арасында шарлатаны да, чит ил йолкышларына охшап маймылланучылары да юк түгел. Эшлиләр дә, өстәвенә, укыйлар да. Менә мин ничә елдан бирле эшче яшьләрне укытам. Күреп торасың: арыган, талган ул, калгып-калгып китә, ә белем җыярга дәртләнә. Вәдүт тә эшли-эшли унберенчене тәмамлады ич. Күр дә тор, әнкәй, КамАЗны да әнә шундый яшьләр менә дигән итеп төзеп бирәчәкләр.

Зөһрәбану түти, башка вакыт булса, мондый гына сүзгә биш җавап табар иде табуын. Килен — бүген генә бусага атлап кергән кеше. Аның белән тәмсезләнмәскә тырышты, үзен тыеп торды. Шулай да, Рәйхан авызын томаладым монын дип уйламасын өчен, дәшми дә калмады.

— Монда килеп өерелгән инсафсызларны үз күзегез белән күргәч, ниндилекләренә иман китерерсез әле. Гавам алдында көпә-көндез кочаклашып йөрүчеләрне дә, җен-пәри кыяфәтенә кереп биючеләрен дә күрерсез. Юк инде, оят дигәнең, итагать-әдәп дигәнең бетеп бара. Кызлары егет өстенә атланырга тора хәзер, тәүбә, тәүбә...

Морзахан абзый да, бәлки, хатыны сүзенә эченнән кул куйгандыр, чөнки төзелештәге яшьләрнең беришесе чамасыз кыю кыланганны ул да хупламый. Әмма мондый сәгатьтә шул яшь-җилбәзәкләр турында тел талдырып утыруны кирәксез тапты, сүз агышын икенче якка борып җибәрергә булды һәм Зөһрәбану түтигә:

— Ашыңны карар идең, әнкәсе. Чәйле — җәяүле, ашлы — аргамаклы була бит...— диде.

— Өлгертәм ашны, хәзер өлгертәм,— дип, Зөһрәбану түти каршы өйгә чыгып китте. Рәйхан да, булышырга теләп, аның артыннан кузгалды. Гөлсем, Вәдүт һәм Морзахан абзый эшкә урнашу, баланы яслегә урнаштыру шикелле мәсьәләләрне сөйләшә калдылар.

Ясле дигәне, турысын әйткәндә, картны борчып, чәнчеп тора иде. Бик күпләр зар түгә ясле белән детсад дигәндә. Бик күпләр. Үзенең туар-үсәре булмаса да, бу хакта ачынып сөйләүләр Морзахан абзыйның да колагына керә тора. Пристаньда Айдарны кулына алып сөйгәндә үк мыегына чолгап куйды инде ул бу мәшәкатьне. Белә чөнки: карчыгы ике-өч көн багар баланы, атна-ун көн карар, бик җаена килсә, ай тәрбияләр. Аннан артыгына исәп тотуы читен. Үзенең бәләкәй бала-чага белән мазаланганы булмады, киленнекен карыйм дип тә тәгәрәп төшмәс...

— Ат — адәмнең канаты, аш — адәмнең куәте, җәмәгать. Әйдәгез әле татар токмачыннан авыз итик! — Морзахан кунакларны янә табынга өндәде. Гөлсем, гел кабар урыным да юк дип, китәргә җыенган иде, Морзахан абзый ике дә сөйләтмәде, аны көчләп дигәндәй аш янына утыртты.

— Аш ашка, урыны башка, Өммегөлсем туган. Шулпа ашадың — шифа алдың, диләр иде картлар, ит ашадың — дәрт алдың. Мәгәр шулай икән, шифасыннан да, дәртеннән дә баш тартырга ярамый...

Гөлсем аларның барысын — Морзахан абзый белән Зөһрәбану түтине, Вәдүт белән Рәйханны һәм, әлбәттә инде, Айдарны — шимбә көнгә үзләренә кунакка өндәп китте.

Кич җитте. Казан концерт бирә башлады. Картлар өчен бик табигый, үтә гадәти булган бу концерт Вәдүт белән Рәйханга гаҗәеп кадерле иде. Себердә яшәгәндә татар музыкасын, татар җырларын тыңлау сирәк эләгә торган иде. Көйләрнең дә, алар өчен махсус диярсең, соңгы елларда гына иҗат ителгәннәрен һәм күңелне язгы җилдәй иркәли-назлый торганнарын тапшыралар. Берсеннән-берсе матур җырлар тыңлый торгач, Рәйхан тирән уйга чумды. Вәдүт читтән генә аңа сокланып утырды.

...Кинәт тышта Юлбарысның ярсып өргәне ишетелде. Капкада кеше бар иде. Күлмәк изүләрен чишеп, рәхәтләнеп утырган Морзахан абзый өстенә пинжәген, башына түбәтәен киеп тышка чыкты. Капка төбендә бер егет басып тора иде. Куакларга, каралты-курага җәйге төн караңгылыгы сарылып, кешенең йөзен танып булмастай сәгать җиткән иде. Хәер, бу егетне хуҗа көндез дә танымас иде.

— Морзахан Шәйхаттаров шушында торамы? — дип сорады таныш түгел кеше.— Бу аның йортымы?

— Аның йорты. Морзахан абзаң мин булам. Ни йомыш иде?

Егет дигәнебез бермәл сүзсез торды. Кирәксенгән сүзе теленә килмәде, баскан җирендә таптанып алды. Аны телгә китерергә ашыккан шикелле, хуҗа кабат кайтарып сорады.

— Йомышың ни иде, туган? Кем буласың син? Әйдә, кер. Капка аркылы сөйләшеп булмастыр бит...

— Мин — Яфиз. Яфиз Сәмитов. Горький өлкәсеннән. Шәфика малае. Син минем җизни буласың инде, Морзахан абзый. Танымыйсың, да?

Морзахан аны житәкләп дигәндәй капкадан алып керде, эттән ышыклап болдырга алып менде.

— Балдызның улы буласың, алайса? Нинди җилләр ташлады үзеңне? Ниләр майтарып йөрисең? Танымыйсың диюең — рас. Син әниең белән безгә килгән елны бот буе малай идең. Ун ел үтеп киткәндер инде ул эшкә. Әйдә, өйгә кер.

Яфиз тырышып-тырышып туфли бауларын сүтте. Кулы тыңламый идеме, шнур чияләнгән идеме, егет мышнап чыкты. Ниһаять, бер аягындагы туфлие лапылдап салынды. Икенчесен чишеп тә тормады бугай, аяктан тартып кына чыгарды. Шул мизгелгә ул чайкалып алды, түнә язып калды. Аны күзәтеп торган абзый ирексездән:

— Кунак булгансың дип әйтимме? Буыннарың йомшаган күренә,— дияргә мәҗбүр булды.

— Юлда аз-маз була инде,— дип, саксыз гына, бөтенләй гадәти эш турында әйтеп куйган кебек, җавап кайтарды егет.

— Шулай диген... Мәйлеп йөрергә иртәрәк түгелме соң әле сиңа, балакай? Ипине еламый гына бөкли беләсеңме соң әле син?..

Яфизның болай төртмәле сүзгә ачуы кабарды. Вәт авыл абзые, ә! Тапкан сәерсенер нәрсә! Кеше синең ишегеңне шакыган икән, рәхим итеп каршы ал. Утырт өстәл янына, сораш, белеш. Вәгазь укырга беркайчан да соң түгел. Тоже, жизни, понимаешь!

— Ишек менә бу якта, әйдә, балакай, әйдә!

Морзахан аны алгы өйгә чакырды. Шул секундта Яфизның башына бер ният төште: кереп тормаскамы әллә? Карты шундый, ә карчыгы ниндидер тагын? Әнинең туган апасы түгел бит ул абыстаң, апа үлгәч бу йортка килгән хатын! Тик кая барасың? Янгыр һаман пыскый. Өстәвенә, җил дә чыкты. Бөтен Чаллысында таныш бер эт тә юк. Гостиницада кул гына селтәделәр. Сиңамы соң әле, егеткәй, янәсе. Эшле кешеләрне йоклатырга да буш урын юк! Шулай булгач, жизнәң өенә керми ни хәлең бар?! Башкаең өйрәледә бер кич, боткалыда ике кичкә калган көннәр бит, Яшка, Яшка, удалая башка! Бик үк удалой булып җитмәдең, ахры, шул син...

Морзахан абзаң да күктән төшкән шикелле капкасы төбенә килеп терәлгән бу мөсафирны тануга аз гына да куанмады. Әлек-электән белә килә, сыный килә, хәтта ки чыдый да килә, Зөһрәбану түти элекке хатын ягыннан искән җилне бер дә күтәрми. Хәзер төчкерә-пошкыра башлый.

Ничарадан бичара, бүтәнчә кылыр әмәл булмагач, төнге кунак — төнлек ябуы икәнен белә торып, Морзахан абзый балдызының малаен өйгә чакырды. Ишек төбеннән кеше борган кеше — нәселенең йөзен бозган кеше. Анысын күңеле дә, вөҗданы да күтәрми аның...

## V

Кунакның кунаклыгы өченче таң атканчы гына, диләр. Вәдүтләр дә, кайтуларына дүрт-биш көн узгач, күңелне Чаллыга ныгытып беркеттеләр. Килер көннәрендә шунда торасы, шунда тормыш корасы, шунда гомер итәсе, дөнья көтәсе! Кайткан мәлне иске Чаллыны карап йөрделәр, яшүсмер чакларын искә алдылар, район үзәгенә сыланып диярлек корылган Төзүчеләр поселогында да булдылар. Вәдүтләрнең эреле-ваклы агач йортлардан торган урамы бер башы белән «Камгэсэнергострой» идарәсенең күп катлы мәһабәт бинасына барып төртелә кебек. Кырый йорттан ташпулатка кул сузымы гына ара. Ул бина исә Кама киңлекләренә карап тора, гүя һәр теплоходны каршылый һәм озатып кала, төзелешкә килүчеләрне ачык йөз белән үзенә чакыра.

Идарәгә каршы якта вахта машиналары туктый торган урын. Иске шәһәрдә һәм Төзүчеләр поселогында торучы эшчеләр сменага юнәлер алдыннан бирегә җыелалар. Күрсәткеч такталарда язулар: «РИЗ төзелешенә...», «Коючу заводына...», «Пресс-рам заводына...», «Тимерчелек заводына...», «Дизель заводы төзелешенә...», «Автомобиль җыю заводы төзелешенә...»

Әйе, автомобильләр ясый торган завод дип бер авыз сүз белән әйтелә генә шул! Чынында ничәмә-ничә завод салына бит. Газеталар да комплекс дип яза, радиосы, телевизоры да шулай дип сөйләп туя алмый. Йөз квадрат километр мәйдан били дигәч, акылы бар кеше төзелешнең колачын чамалый инде. Колачын гына түгел, төзелешнең тизлеген дә исәпләп карамый булмый. Алтмыш тугызынчы елның ноябренда беренче төркем эшче килгән, декабрь уртасында промышленность мәйданында экскаватор беренче чүмеч туфрак умырган. Монысы — эшнең башы

дигән сүз. Ә икенче очы кай тирәдә? Әнә идарә бинасы яныннан поселокка кереп барганда, аз гына арырак салынган биш катлы зур йортның түбәсенә күрше авылдан күренерлек хәрефләр белән төзүчеләр вәгъдәсе язылган: «1974 елда беренче КамАЗ автомобилен бирербез!» Мондый колачның мондый тизлек белән үрелеп баруын дөньяның күргәне юк икән бит әле!

Вәдүт белән Рәйхан, моңа тикле байтак кала һәм сала күргән кешеләр, поселокны яратып карадылар. Туган туфракта калыккан кала булгангадыр, «Юбилейный» магазинын да, «Чулпан» кинотеатрын да бик ошаттылар, төзелеп килә торган культура сараеның шәп буласын да күңел күзе белән яхшы чамаладылар, партия шәһәр комитетының яңа бинасы өлгереп килгәнен күрделәр. Күпме генә вакыт эчендә ни тикле торак, ашханәләр, ясле һәм балалар бакчасы, кибетләр салынган, юллар җәелгән. Больницаның яңа корпуслары тиздән дәваланучыларны кабул күрергә тиеш икән. Куе яшь наратлык эченә чумып утырган «Яшьлек» кинотеатры теләсә кемне гашыйк итәрлек.

Зәйгә бара торган олы юл буйлап сузылган проспектка яшьләр озак карап торды. Бишәр катлы ташпулатлар гаскәре сафының алдына баскан уникешәр этажлы йортлар, Алып батырлар төсле, бу тирәгә яңа ямь, өр-яңа күркәмлек өсти. Олы юлда исә машиналар ташкыны. Очсызкырыйсыз булып күренә торган хәрәкәт...

Рәйхан Гөлсем апасының бер көнне үзләрен каршылаганда әйткән сүзләрен искә алды. «Зәй юлы аша чыгып, берничә йортны узгач, безнең квартал башлана,— дигән иде апасы.— Мин эшли торган торак беренче йортта. Дүрт-бер дип сорарга кирәк. Дүрт дигәне кварталны, бер дип әйткәне шул кварталдагы ничәнче йорт икәнне аңлата...»

Төзүчеләр поселогына карап, тәмам күз иялэшкәч, шактый ара дип тормадылар, бер көнне төштән соң район үзәгеннән төньяк-көнчыгыштарак салына башлаган яңа каланың түбәләрен күккә тигезердәй булып калыккан ташпулатларын да карап кайттылар.

— Янар таудай булып төзелеш кайный. Озын-озак кунак булып йөрер хәл юк. Шулай да, җиң сызганып эшкә чумганчы, яңа шәһәрнең беренче йортларын күреп кайтмый ярамас,— диде Вәдүт.

Мәскәү төзүчеләре сала икән йортларны. Куллары җиңел, эшләре уң булсын! — диярга генә кала: алар салган йортларга карап сокланырлык.

Килгәндә әллә ни чекерәеп карамаганнар иде, кайту юлында ТЭЦтан яңа калага сузылган җылы үткәргеч эстакадаларны күреп тә хәйран булдылар. Борынгы әкиятләрдәге биниһая зур еланнарны искә төшереп чакрымнарга сузылган җылыуздыргычлар шәһәр читенә тикле җир өстеннән килә икән дә, кала сызыгына җитүгә, җир астына кереп, бихисап тармакларга аерыла икән. Алар белән бер машинада Иске Чаллыга кайткан бер агай сөйләп барды (күрәсең, идарәнең берәр белгечедер, вагына-төягенә кадәр белеп сөйли): шәһәр эчендә тормыш итү өчен нәрсә кирәк булса, шул гына ясала. Һава саф, урамнар киң һәм якты, иркен, яшеллек мул, йөрү җайлы булсын дип, ит-сөт комбинатлары, икмәк заводлары, автогаражлар, трамвай паркы һәм башка бик күп ярдәмче предприятиеләрне эченә алган промзона шәһәрдән читтә буласы икән.

— Төзелеш колачы белән мен тугыз йөз житмеш беренче елгы Чаллы егерме сигезенче елгы Мәскәү ул! — дип куйды агай. Әйтсәң, әйтмәсәң дә, таң калырлык бит. Ил җиң сызганып башкара торган олы төзелештә булу горурлыгын яшереп маташа торган кеше түгел иде бугай, сөйләгәнен ихлас биреп тыңлаучылар барын искәргәч, агай канатлана төште.— Мәскәү сразы гына төзелмәгән дибез, ә Чаллыны бик тиз төзергә кирәк!

Завод сафка кергәч, анда смена саен меңнәрчә кеше эшлисе икән. Күп дигәндә ярты сәгать эчендә аларны үз цехларына илтеп җиткерергә кирәк. Бу — уен эш түгел. Шуны заманча хәл итик дип озак баш

ватканнан соң, киләсе житмеш икенче елдан тиз йөрешле трамвай булдырырга карар кылганнар. Әйтик, метро поездлары төслерәк трамвай булачак.

Заводлардагы һөнәр иярәренең санына да тиз генә чыгарлык түгел икән. Юлдаш агайның әйтүенә караганда, техник белем бирү бүлеге хәзер үк бер йөз кырык сигез төрле белгечлек буенча осталар хәзерләүгә керешкән. Бүгенге төзүчеләрнең бик күбесе киләчәктә автомобильләр ясауда катнашачак эшче дигән сүз иң бу.

Вәдүт шул минутта янә бер кат техник югары уку йортына хәзерләнә башларга кирәклекне уйлап куйды. Әйбәтрәк ял итәргә, эшкә урнашырга, аннары, озын-озакка сузмыйча, китап-дәфтәрләрне янә кулга тотарга...

Рәйхан исә теге агай сөйләгәндә болай уйлап кайтты. Саннарны «коры» дип кимсетәләр кайчак. Тик менә алар хәзер генә ишеткәннәрне коры дип кыерсыта алырсыңмыни?! Тагын өч ел дигәндә гасырлар буе тын утырган Чаллы ел саен йөз мең авыр йөк машинасы, ике йөз илле мең дизель двигателе чыгара торган заводлар каласына әверелә. Мондый саннар күңелдә җыр тудыра дисәк, һич кенә дә чәчәкләп-чуклап әйтү булмас.

Өйгә көр күңел, шәп кәеф белән кайттылар. Укып-ишетеп белү бер хәл, төзелеш мәйданында үзең булып кайту — бөтенләй икенче нәрсә шул. Тик, өйгә кайтып кергәч, аптырап калдылар. Зөһрәбану түтинең чыраенда буран уйный иде. Ул чәпчеп тезеп китте:

— Үз балаларыбыз кайтып, чүкердәшеп кенә яшәрбез дигәндә, ул хәерсезне хак тәгалә кайлардан гына китереп такты соң безнең муенга! Үзе генә тыгынып ятса бер эш иде, янына тагын кемнәрдер килде. Мытыр-мытыр нәрсәләр сөйләштеләр дә аны да иңртеп чыгып киттеләр. Ант әгәре дип әйтим, хәерлегә йөрми ул йолкыш. Үлгән ябалакның башын калкытып, жизни дигән булып, берәр әшәкелек чамалый торгандыр. Эшкә урнашам, ди. Кемгә хаҗәт ул эрәмтамак! Өстендәге күлмәкыштанынннан башка бернисез эшкә килә димени кеше?! Кем алсын аны хезмәткә? Ни кора белә ул?! Ничә әйттем эткәгезгә, ир бул, тиз-тиз озат, олактыр дидем. Мәлҗерәгән дә калган бит сакаллы сабый!..

«Үз балаларыбыз кайтып, чүкердәшеп яшәрбез» дигәне чапмаган да, юынмаган да рыя иде, әлбәттә. Калганы хак иде. Менә инде дүрт төн Зөһрәбану түтине йокы алмый. Керфеккә керфек органы да юк дисәң дә, хата сүз булмас. Ызанда йоклаган куян йокысы кебек, күз йомды исә саташып уяна, куркып дерт итеп китә. Яфиз алгы өйгә кереп актарынган, имеш. Хәзинәдә бар затлы әйберләрне арыш капчыгына төяп, үзенең әшнәләренә түр тәрәзә аша озата, имеш. Ул гына да аз күренгән икән дә, келәткә кереп тәпән-тәпән балларны үз шайкасына өләшә, алай гына да күзе туймагач, ике мөгезеннән бәйләп, сыерны алып чыгарга маташа, әзтабар этләр дә иснәп тапмасын өчен, сыер аякларына чабата кидергән, чабата эченә тәмәке сипкән, имеш...

Чынында Яфиз янына кемнендер килеп китүеннән башка берни дә булганы юк югын. Зөһрәбану түти әйткәнчә, «сакаллы сабый»ның да алай мәлҗерәп төшкәне күренми. Киресенчә, өченче көн дә, кичә дә Морзахан абзый Яфиз белән тып-томат сөйләште.

— Әлегә тикле әзергә-бәзер яшәгәнсең әле син, малай актыгы. Башта әниең канат астында тернәкләнгәнсең. Балдыз минем уңмаган камыр шикелле булды, сине тезгенли белмәде. Атаң сездән баш алып олаккач, тәмам кулын салындырды. Өстәвенә, сырхау. Шуннан соң сине мәктәп-интернатка биреп бакканнар бит инде. Аннан да качкансың. Төзелешкә китәсең, янәсе, кирәкле кишер яфрагы! — диде ул, Яфизны каршысына утыртып.— Бала йоның коелып житмәгән, аракыга сузылгансың, тәмәкегә үрелгәнсең. Сине дөнья бик аз тәтәсләгән әле, би-ик аз

төтәсләгән. Аның төтене күбрәк тисә, беләсеңме, нишләр идең? Иртәгә көнең турында уйлар идең...

Кыскасы, Морзахан абзый Яфизга я укырга, я сызганып торып эшли башларга кушты. Һөнәр алырга укысаң да, бригадада эшләсәң дә, торырга җирең дә, туеныр чаман да булыр, диде. Моны Зөһрәбану түти дә аңлашып яши, билгеле. Тик аның җиде ят килмешәктән бүген ук башын аралыйсы килә.

Яфиз гына бер дә исе китмәгән кыяфәттә йөргән була. Турысын әйткәндә, Зөһрәбануның утлы карашы да, агулы сүзләре дә, Морзахан абзыйның вәгазе дә аны әйтерлек кымшандырмады. Вәдүтнең кискенлеген исә Яфиз абайламый кала алмады. Рәйхан әйткәннәр дә миен ярып керде. Бәлки, кешелекле булып, чын-чынлап кайгыртып әйтүләре барып җиткәндер.

— Һөнәр мәктәбен белешербез,— диде Рәйхан апасы.— Алай булмаса, эшкә керү юлын эзләп карарбыз. Эленке-салынкы бугалырга ярамый, Яфиз.

— Бәлки, үземнең яныма алырга җай чыгар,— диде Вәдүт тә.— Тик, кара аны, эш кешеләре тирәсендә шамакай булып йөрисе түгел. Бар бүген ук парикмахерскийга, чәчеңне кешечә рәвешкә керт. Тәмәке дигәнеңне иммәскә тырыш. Аракыны — оныт! Мин тартмыйм бит менә, бер дә тилмергәнем юк. Әткәй дә гомеренә дә төтен суырып карамаган. Күрәсең — ничек нык йөри. Алтмыш бишне тутыра бит, югыйсә...

Икәү киңәшкәч, Горький өлкәсендәге мәктәп-интернатка хат язып белешергә кирәк дигән фикергә килделәр. Ник качты икән ул аннан? Артыннан әшәке эше сузылып килмиме икән? Укырга кертә калсаң да, эш эзләсәң дә, ул тәти егетнең кичәгесен анык белү зарур иң. Ә үзе ул, сүз кичәге көненә кагылдымы, телен йота. «Ошамады. Шуңа киттем. Эшлисем килә», дигән була.

Педагог кеше өчен бер нәрсә көн төсле ачык: Яфизны язмыш кочагына ташларга ярамый. Моны Вәдүт тә яхшы аңлый. Зөһрәбану ни кадәр өнәмәсә дә, мәктәп-интернаттан хат-хәбәр алганга кадәр сабыр итәргә кирәк. Чөй өстенә тукмак дигәндәй, Яфизның кулында бердәнбер документы — туу турында таныклыгы. Укырга кертә башласаң, мәктәп белешмәсе дә юк. Интернаттан шуны да сорарга кирәк...

Шимбәдә, кич җитәрәк, Гөлсем апаларына кунакка җыена башлагач, Зөһрәбану түти әллә нигә сырхап китте. Ашказанына башта уң кулын, аннары сул кулын да басып, арткы өйдәге киң караватка барып ятты.

— Ни булды соң, нәрсә ярамады икән? — дип, Морзахан абзый чыдам гына сораштырырга керешкән иде, хатыны көтмәгәндә-уйламаганда ярсып, кабынып китте. Йортта соңгы өч-дүрт көн арасында булган үзгәрешләрдән: улы белән килене һәм оныгы кайтып төшүдән, сөйкемсез сөяк булып бәгырь итенә кадалган Яфизның икенде күләгәседәй күз алдында тирбәлүеннән, картының шул юньсезгә таштай сүз атып, аны йортыннан өреп чыгармавыннан, килене белән улының шул сөләгәй каршында хурланмыйча акыл биреп торуларыннан, иң хәтәре — шул өтекне бергә яшәтеп торырга чамалауларыннан ашказаны түгел, җаны авырта, җаны әрни иде аның.

— Нәрсә ярамаганын белеп торсам, ярамый гына дияр идем мин! Картаеп акылга туймагандай сөйлисең. Хатының бөкләнсә дә ярый, бүтәннәр генә җил-яңгыр күрмәсен! Мин бүген җан тәслим кылсам да, исенә дә кереп чыгасы юк бит синең! Җитмешкә җитмәгән әле, диярсең дә өченче хатын алып кайтырсың. Мин ничә ел бөртекләп җыйганны ул подаукалап җилгә сибәр. Кунаклар кайткач, тәмам да кукыраеп киттең...

Зөһрәбану түтинең тулышуы житкән иде инде. Иренә авыз ачар җай да калдырмыйча, эченә кату булып чыкканнарның һәммәсен тезә бирде:

— Минем бугазыма әҗәл ябышуы шулдыр бәлкем дә... Шәт, мин соңгы сулуларымдадыр... Ә син, ата күркә сыман кабарынып, Өммегөлсем кайнигәчәнә кунакка барырга җыенып торасың. Бүген авызымнан җаным чыгар булса, бәхиллегемне бирми китәм бу дөньядан. Мәңге бәхиллегем юк!..

Балалар алдында кычкырышуны килештермәгән Морзахан абзый аның саен әдәплерәк, йомшаграк, җан җылылы итеп сөйләшү ягын карады. Кайтып төшкән сәгать-минутларыннан ук «әткәй! әнкәй!» дип тәгәрәп йөргән килене алдында каты телле булырга теләми иде. Килен ни житте кеше түгел, укыган кеше, бүтәннәргә белем бирүче. Без картларга да бик итагатьле булырга охшап тора, дип уйлый иде ул. Күңеле утырып житмәс борын мәңге ябышмаслык булып куба күрмәсен, малайга да аның сүзе үтә хәзер, Вәдүт күңелен дә бездән биздерә күрмәсен. Яхшыга яхшы булып яшәүгә ни житә соң, дип тырыша иде. Тик барыбер ул дигәнчә булып бетә алмады. Зөһрәбануның тиз тула торган чуаны тишелде. Рыялыдан рәхим көтмә — шул буладыр. Туган туфракка дип ашкынып кайткан яшьләрне дә чутка сугып тормады, зәңкиләнә бирде. Хәтер калмак — бер калҗа, хәтер тапмак — мең калҗа. Кәефне җибәрүе ансат, әмма табуы мең газап икәнен дә уйлап бакмады тути.

— Нәрсә дип әле бер миңа карап каттыгыз. Барыгыз кунакка! Берегезгә дә йорт та кирәкми сезнең, чурт та кирәкми. Кабер якасындагы әнкәгез эшләр һәммәкиен. Сыеры-сарыгы кайтыр, ул карар. Казын-тавыгын ул карар. Табын янында сез карарсыз...— дип такмаклады.

Морзахан абзый эшнең төбен саф сулы кизләү төбен күреп торгандай белә бит: хикмәт шушы сәгатьтә сырхап китүендә түгел, Зөһрәбануның кунакларны исәнме-саумы дип кабул иткәннән соң, безнең кырда озак тукранмасыннар дигән исәп белән чара күрмәк булуында. Улларыда, киленнәре дә кемдә күпме кунак булырга кирәген аңласыннар, диюе аның. Үз көнегезне үзегез күрегез, еракта кояш жылы була, чакыра калсак, кунакка килгәләрсез, безләрдин сезләргә шунысы да бик житкән дигәнне төшендерергә талпынуы. Шуңа күрә йорт башы да тавышны эчтән алыбрак сүз башлады.

— Агачтагы яшерен ут кабынмыйча күренми ул, сиңа әйтәм. Телеңә чыкмаса, күңелендәгене белми калырлар да харап булырмын дидеңме әллә? Кунакка барасы булганга куркып калмаганыңны әнә сабый да белер. Минем йортта балалар булу үрсәләндерә сине. Тик аң бул: берсенә бер тәмсез сүз дә әйттермәм. Куәтемдә әле мин. Хур-рисвай булып кайткан кешеләр юк синең янына. Үз сөягем үземнән авыр түгел. Хәстәләнеп киткәнсең икән, аяныч. Терелерсең, боерган булса. Синең янында мин калам. Булышырга менә Яфиз өйдә. Яшьләр Өммегөлсемнең ничек яшәп ятканын күреп кайтсыннар. Ялдагы кешеләргә бик таман эш, кирәкле эш, фарыз шөгыль...— Шулай диде дә абзый, эчтән кыбырсып, урыныннан торып китте.

Зөһрәбану тутиның «эһ» тә «аһ!» итүләре кисәктән искән җил белән алып киткәндәй юкка чыкты шикелле. Ул, җебеннән тарткан курчак төсле, дәррәү сикереп торды да карават кырыена аякларын салындырып утырды. «Барыгыз да мондамы?» дигән кебек, картына, карават буена килеп утырган Вәдүткә, мендәр-ястыгын рәтләбрәк бирим дип баш очына килгән килененә томырылып-томырылып карады. Карашы буш иде, кысыр иде.

— Улыңа ни пачут, миңа да шул пачут.— Озын сөякчел бармагы белән башта Вәдүткә төртеп күрсәтте ул, аннары бармагын пәкегә тиңләп, күкрәк сөяген тишәргә теләгән шикелле, үзенә төртте.— Киленгә дә шул пачут булсын. Сүзем юк... Әмма дә ләкин теге зимагурны күз алдымнан юк итегез. Төннәрен саташам шуның аркасында, йокым йокы түгел. Нербам шуңа чәрдәкләнәдер минем. Бер булышлыгы да кирәкми, кул арасына керүе дә сукыр бер тиенгә дә кирәкми! Кайчандыр балды-

зын булган хатыннан яратылган җан иясен муеныма тәре итеп асарга уйламыйм. Вәдүт, сиңа әйтәм, сиңа да, килен, Өммегөлсемнәргә үзегез белән алып китегез шуны да олактырыгыз! Бульше чыраен күрмим шуның. Атагыздан булмый шуны өзеп әйтү...

Зөһрәбану түти ничек ялт итеп торган булса, шулай ук дәррәү лап итеп ятты да. Ятуы булды, тынып калуы булды. Рәйхан курка калды, әллә, чыннан да, йөрәге шартладымы кайнанасының?! Шикләнмәслек түгел, йөзеннән кан качкан иде... Тик беравыктан ыңгыраша башлады ул. Җелегенә төшеп житәрдәй бер тавыш белән сузып-сузып ыңгыраш-ты. Вәдүт, күңеленә суык җәелә башлаганын тоеп, ләм-мим сүз катмый-ча, алгы өйгә чыкты. Рәйхан да, бик күңелсезләнеп, аңа иярде. Бу минутта Яфиз гына капка төбенә китереп өйгән, бер-берсенә тимер чыбыклар белән каптырып куйган бүрәнәләр өстенә утырып тәмәке көй-рәтә иде. Ваемсызга яңгыр килде ни, боз килде ни! Арткы өйдә Зөһрә-бану түтинең боз болыты булып күкрәвенә бик исе китә аның! Ике ятып, бер керә төшенә... Вәдүт абзые начар ук булып чыкмады әле. Рәйхан апасы да. Эшкә урнаштырабыз диләр, пажалуйста. Ә хәзергә — ашау байдан, үлем ходайдан!

Өйдә ни өчендер кычкырышуларын ишетсә дә, Яфиз Зөһрәбану бай-бикәнең үзен ашатырга баш тартып үрсәләнүен аңламады...

Аның каравы, өлкәннәр уйландылар, нык уйландылар. Алгы өйгә чыгуга, Рәйхан күз яшенә буылып елап җибәрде. Юк, чәч йолкып, кара-выл салып түгел, тыныч елау белән елады. Вәдүтнең юатырга керешүен ишеткәч:

— Юатма, Вәдүт. Синең үзеңә дә җиңел түгел ич. Кайнана белән килен арасы борын-борыннан шулай булган инде ул. Монысында бер яңалык та юк,— диде һәм йон кофтасының җиңе эченә кыстырган кулъяулыгын алып, яшьләрен сөртте.— Синең белән миңа әле бүгенгә урын бар, ишеттең бит безгә «тигез пачут»! Яфиз хәле борчый мине. Аның хәле чыннан да бик мөшкел. Нишлибез?

Вәдүт, кара куе бөдрә чәче арасына бармакларын тыгып утырган килеш, үз алдына сөйләнгән шикелле генә җавап кайтарды.

— Бүген шимбә инде. Иртәгә дә ял көне. Дүшәмбедән син дә эш белешәсең, мин дә. Үзем турында сөйләшкәндә Яфиз хакында да сүз барачак. Менә шул. Аны куып чыгарудан да җиңел эш юк хәзер. Өшәке эшкә тыкшынып, барып капканчы шар сугар ул. Шуннан нәрсә? Әйләнә-тулгана монда килеп чыккан икән инде, ичмаса, без аны күздән дә, кулдан да ычкындырмаска тиешбез. Дүшәмбедә комсомол башлыклары янына да кереп карарбыз. Шәһәр комитетына дигәнем. Ә бүген, Рәйхан, без аны, чыннан да, үзебез белән бергә Гөлсем апаларга алып барыйк-мы әллә?

Рәйхан бу киңәш белән шундук килеште. Апасының нинди икәнен белә ул: үзенә булмаса да кешегә ярдәмнән баш тартачак түгел Гөлсем. Азапны тауга биргәннәр — күтәрмәгән, аннары кешегә биргәннәр — күтәргән. Инвалид апасы шундый җаннарның берсе иде. Яфизның да хәлен тиз аңлар...

Тик Яфизы юньсез бит әле аның. Үзен өйгә чакырып алып, сөйләшә башлагач, тискәреләнде дә куйды.

— Бармыйм и все! — ди.— Кияүләргә ияреп йөрергә, арбага таккан дегет чиләге түгел лә мин. Конфет суырасым да килми. Рәхмәт...

Юньсез бәндә диген инде: кызуда кызармаган, суыкта суынмаган. Вәдүтнең кәефе кырылыр дәрәҗәгә җитте.

— Беләсеңме нәрсә, чибәр егет. Үз белдегең белән сагынганда гына сабан җигеп йөрерлек булгач, бу йортка юкка килгәнсең син,— диде ул, әле моңа кадәр беркайчан да сиздермәгән кырыслык белән.— Минем янда нәзберек кыз капризлары батмаганны күңеленә киртләп куй. Мин — солдат кеше, эшче кеше. Шуңа күрә синең боргалану-сыргала-

нуларына ләббәйкә дип тора алмам. Бу — бер. Икенчедән, син бүгенгесе көнне үзеңнең әле беркем дә түгеллегеңне аңларга тиешсең. Син хәзергә нуль, беләңме? Нуль! Шул нуль алдына нииндирәк саннар язу синең үз кулыңда. Өлкәннәр әйткәнгә кәҗәләнә башласаң, син шул нуль булып калачаксың. Бар, тара чәчеңне, рәтлә күлмәк якаларыңны и марш безнең белән!

— Ә мин алтыдагы сеанска кино билеты алдым.

— Кайсы кинотеатрга инде, ягъни мәсәлән? — Вәдүт ышанып бетмәде бугай, шуңа күрә мыскыллырак итеп сорады шикелле.

— Старый центрдагысына... Күрәм, ышанмыйсың.— Яфиз башын чөеп җибәрде, җирән чәчләрен бер читкәрәк сибеп алды да, урыныннан күтәрелеп, кесәсеннән билет чыгарды.

— Пожалуйста! Син ышанмыйсың...

— Нинди фильм карыйсың соң, Яфиз? — Монысын Рәйхан апасы сорады.

— «Алтын бозау» буладырмы... Әллә «Алтын шаукымы», «Алтын зәхмәте»ме?

— Оста комбинаторны күрергә җыенасың инде. Китабын укыганың бармы соң?

— Китабын юк. Озак бит... Фильмын ике караганым бар. Мировой фильм. Карагыз, үкенмәссез...

Вәдүт белән Рәйхан елмаймыйча булдыра алмадылар. Әй, кызык соң бу үз-үзләренә чамасыз ышанган, тәмам житлегеп, дөньяның иң акыллы кешеләре булып ирештек дип уйлаучы яшүсмерләр! Күпне беләбез дип уйлыйлар алар, һәммә нәрсә хакында бик дөрес, бик тирән фикер йөртәбез дип чын күңелдән ышаналар. Фасон яраталар, поза сөяләр. Белмәгәннәрен сорыйсылары да, ябышып ятып өйрәнәселәре дә килми. Укуы авыр, күңелсез, аңа көч тә күп китә, вакыт та байтак кирәк. Куагын да утыртмыйча, төбен дә йомшартмыйча гына җимешен ашарга исәп тотканнары да бар. Яфизга да шундый шаукым кагылганы күренә. Һәрхәлдә, Рәйхан моны сизенә, тоя.

— Акча кайдан алдың соң, энем? — диде аңа Рәйхан.— Тәмәкегә дә, киногa да, кайчак артыграгына да акча кайдан аласың? Ачуланма, ачуланма. Кашларыңны да җыерма. Туганың һәм аның хатыны бу сорауны гына бирергә бик хаклыдыр. Янәшә өстәлдә кем утырганын акрынлап ачыкларга вакыт җиткәндер. Үзең бер сүз дә артык әйтергә теләмисең.

Вәдүт хатынының сүзенә куәт өстәде.

— Бик законлы сорау, Яфиз туган. Синең бюджетны нинди статьялар тәшкил итә инде?

Яфизның чын-чынлап кәефе китте. Ул җилкәләрен җыерып куйды, коңгырт-соры күзләре аның иркенә кул салырга уйлыйлар дип исәпләгән кешеләргә нәфрәт чәчә башлады, җәенке борынының калын-калын яфраклары, ерактан йөгереп килгәндәгечә, киңәеп тә, кысылып та уйнаклашты. Өйдә булмаса, черт иттереп теш арасыннан гына төкереп куярга да тартынмас иде. Түр башында бик тыныч, үз бәясен нык белеп, үзенең сөйләгәненә какшамас ышанып утырган төзүче Вәдүт ят кеше генә түгел. Әниләре бертуган кардәшләр дә ич алар. Аннан соң бу абыйсы үзенә юк акылны юмарт өләшүче түгел бугай. Эш хакында сөйләсә дә, солдат тормышына кагылса да, кешенең үз-үзен ничек тотуы хакында сүз катса да, ышанып сөйли, белеп сөйли, үзенең намуслы хезмәте һәм дөньяга карашының заманча булуы белән горурланып та сөйли. Тел тегермәне тартып кына бер читкә тибәреп калдыра торган ир-ат түгел бу! Сүзне күпкәрәк сузсаң һәм тартәгә бер дә юкка һаман тибеп матшсаң, тетмәнне тетәргә дә күп сорамас.

Яфиз мизгел эчендә шуларны уйлап алды һәм үзен тезгенләде. Ахмакларча җавап биреп кенә котылып булмасын, бу юлы үтсә дә,

киләчәктә мондый «тырпаю»ның шома үтмәслеген төшенде ул. Шулай да тавышында үпкә, рәнҗү хәтсез иде.

— Сез уйлыйсыз, берәр җирдән суккандыр дип, әйеме? Пардон, сизгер кардәшләр! Минем кесәдәге тиеннәр — гадел эшләп тапкан акча...

Вәдүт урындыкны алга-артка хәрәкәтләндереп, бер урында тирбәлеп утырган Яфиз янына килде һәм аның җилкәсенә дустанә кыяфәт белән сугып куйды.

— Әгәр эшләп тапкан тиеннәрең икән, егетсең! — диде ул. Әмма энесенең күзләренә шундый итеп текәлде. Яфиз көйдергеч карашка түзмәде, карашын читкә алды. Сынаулы карашка чыдый алмыйча баш боруын Рәйхан да искәрде. Вәдүт исә сүзен дәвам иттерде:— Әтне аягы туйдыра, кешене кулы туйдыра, дигәннәр, бабайлар, Яфиз энем. Без бу мәкальгә кешене акылы туйдыра дип тә өсти алыр идек. Заманы шундый. Беләк белән баш туйдырса — бик шәп. Тик кара аны, янап әйтүем түгел, алга карап әйтүем, кәкре куллы булсаң, муен тамырыңны бер сугуда өзәрмен. Татлы аш ачы тир белән табылганын онытма! Кайларда эшләдең акча? Сер түгелдер бит?

Яфиз, әгәр яраса, теш арасыннан сыңар сүз дә чыгармас иде. Ник дигәндә, Вәдүтнең хәзер генә үзенә әйткәннәрен ул намусына тукыну дип кабул итте. Хатыны алдында рәхимсез төпченеп үз бәясен күтәрергә тырыша, дип уйлады. Караклыкта фаш итәргә тели, нахак сүз әйтергә җыена, дип фикер йөртте. Шулай да авыз йомып утыру мөмкин дә түгел иде, ярамый да иде.

— Хөрмәтле Вәдүт Морзаханович,— дип сүз башлады ул.— Яхшы следователь булып та, акыллы педагог булып та кыланмагыз. Мин тоже малай-шалай түгел. Әллә кайчан сорыйсың бар иде. Акчаң бармы, кайдан юнәттең, дип. Ато театр тамашасы ясыйсың, иптәш. Ничек әйтәләр, трагикомедияме?.. Горький каласында, Нижний Новгородта, көнлекче йөкче булып эшләдем. Грузчик. Кул белән генә дә, баш белән генә дә түгел, бөкрең белән, җилкәң белән дә эшләп була бит әле банкнотларны... Кирәк икән, язып сораша аласың...

— Анысы яраган,— диде Вәдүт.— Эшләгәннән кеше үлми, энекәш. Инде менә иртәгә-берсекөнгә ничегрәк эшләрбез, шуны уйларга кирәк. Эшләү дә, уку да — икесе бергә! Минемчә, иң дөрес юл шушы булачак.

— Авыр, әмма синең шартларда иң дөрес юл.— Рәйхан шулай йомгак ясарга теләде төсле. Тик Вәдүтнең сүзе бетмәгән иде әле.

— Дүшәмбедә минем белән бергә кадрлар бүлегенә барабыз. Менә шул. Кат-кат әйтүләр кирәкмәс дип уйлыйм. Бүген мине командирың дип исәплә. Ә командир кушкан тикшерелми, бер сүзсез үтәлә генә. Бер сүзсез. Кинодан чыккач та Гөлсем апаларга килерсең. ГЭС поселогы, дүрт-бер. Рәйхан апаңның туганы шунда эшли дә, тора да.

— Общежитиегамы?

— Әйе. Ә син аны каян беләсең әле?

— Анда минем бер белешем урнашты. Кичә генә.

— Нинди-рәк белеш инде ул?

— Әнә теге Зухра старушка куркыткан белешем. Ул минем янымa килгәч, Зухра әби чүт үлмәде. Ә теге егет бик нормальный. Бетончы. Виктор Шмарев. Казанныкы. Теплоходта очрашкан идек.

— Бергә вермут чөмергән белешеңме?

— Син нәрсә инде, Вәдүт абый. Виктор яшь әле. Өйләнмәгән дә.

— Ярый,— дип сүзне кыскартты Вәдүт.— Сөйләштек. Тагын бер нәрсәне колагыңа тукып куям. Синең өчен бернинди дә Зухра старушка юк. Зөһрәбану апа гына бар. Ул син киерелеп утырган йортның хуҗаларыннан берсе, синең алдыңа аш китереп куйган хатын. Аңа таш белән атарга матавшма. Егетлек түгел, хайванлык булыр. Инде Викторга килсәк, мин, үз чиратымда, Шмарев белән кызыксынырмын. Һәм соңгысы: эшкә урнашу белән, әниеңә хәбәр саласың. Ул инде: «Кай-

ларда гына йөри икән балакаем?» дип ут йота булыр. Ә сина дингез тубыктан.

Бу фикерне әйткәч, Рәйхан, гөлтләп кабынып киткән учак шикелле, ниндидер бер эчке талпыну белән сүзгә янә кушылды.

— Әнидән дә кыйммәтрәк, әнидән дә кадерлерәк кеше юк, Яфиз. Бишек тирбәткән кул — якты дөнья тоткасы, энем. Аны рәнҗетү — зур хата, кыерсыту — гөнаһ. Менә әйбәтләп кенә урнаш та, абыең, син, мин — өчәүләп — хат язып салырбыз аңа. Беравык эшләгәч, бүләген, көчтәнәчен дә җибәрә алырсың бәлки. Син аның карап торган куанычы да, таянычы да ич, Яфиз энем...

— Ул минем монда киткәнне белә,— диде Яфиз коры гына. Әллә коры булырга азаплана гына идеме. Әнисе хакында сүз чыккач, тәкәбберләнеп, өреп тутырган куык төсле булырга көчәнүе кимеп тә калды шикелле, югыйсә. Ул өстәл читен сыйпаштыргалады, бер боты өстенә икенчесен куеп, киерелеп алды, ике учы белән чәчләрен рәтләп куйгандай итте, нидер әйтергә хәстәрләнде, шулай да шушы мизгелдә генә кирәк санаган сүзләре теленә килеп өлгермәде бугай.

— Яхшылык эшләү, изгелек итү чын күңелдән булса яхшы ул...— диде егет, ниһаять, тел күтәреп. Тик яхшылык табигый булырга тиеш, белдегезме? Сез дә миңа яхшылык итәргә телисез, анысы әйбәт, билгеле, тик ясалма...

Рәйхан белән Вәдүт, һич көтмәгәндә Яфизның шулай фикер йөртүен ишеткәч, бер-берсенә карашып, күз белән генә сөйләшеп алдылар. «Бу егеткәй төшеп калганнардан түгелгә охшап тора түгелме соң?!» — ди иде аларның ым кагышып алуы. Мондый темага Рәйханга әледән-әле гәп куертырга туры килгәнлектән, ул Яфизны да бер селтәнүдә кире кагып ташларга җыенмады. Чөнки үтә яхшы төшенә: болай уйлана башласа, кеше туры сукмактан чыкмый ул. Чыга алмый. Кеше башына уй кердеме, әшәкелек белән әйбәтне аерырга талпына дигән сүз.

— Әш бит Вәдүт белән миндә генә түгел, энем,— диде ул бик тыныч, бик сабыр кыяфәттә.— Хикмәт конкрет бер вакытта ярдәмгә мохтаҗ кешеләрдә. Яхшы күңеллелекне һәркем үзендә тәрбияләргә, булдырырга, үстерергә тиеш. Теплицада үстергән кебек итеп, әгәр теләсәң...

Вәдүт хатыны әйткәннәр белән тулысынча фикердәш иде.

— Менә шулай, Яфиз. Шулай! — дип печать басып куйды ул.— Рәйхан апаң хаклы.

Яфиз ул сүзләргә каршы:

— Әни өйрәтә, укытучылар өйрәтә, туганнар тоже. Урамдагы берәр әзмәвер тоже...— дип әрепләште.

— Әзмәвер сабагы пычагыма да кирәк түгел. Анысын тыңлама! — Вәдүт тагын кыза төште.— Ә менә калганнарының өйрәтергә дә, колагыңны борырга да хаклары бар.

— Акыл өйрәтү дә акыл сату...

— Уйлап сөйлә... Бер нәрсәне бел, энекәш: мөстәкыйльлек, тулы хокук бит кешегә җәмгыять каршындагы, коллектив һәм семья каршындагы бурычлар белән бергә кушып кына бирелә. Башкача була алмый... Ярый, кинодан соң сине Гөлсем апаларда көтәбез...

Тулай торакка барганда да Вәдүт белән Рәйхан телендә гел Яфиз мәсьәләсе булды.

— Кара әле син җилбәгәйне! — дип, Вәдүт торып-торып ярсынып куйды.— Аңа барсын да тап та китер, тик акыл гына өйрәтә күрмә!

Рәйхан сабыр иде.

— Шундый чагы егетнең. Яше шундый вакыт. Үзбаш уйларга, мәсьәләне үзбаш хәл кылырга омтыла. Олылар киңәшен, үзеннән күпне күргән, авызын пешерә-пешерә тормышның кайнар шулпасын эчеп, тәҗрибә туплаган кешенең акыллы сүзен иркенә тыкшыну, азатлыгын

чикләү дип саный. Ин катлаулы чоры Яфизның. Ата-анасы тигез булып, һәр яктан җитүле тәрбиядә үскән яшүсмерләрдә дә шул хәл күзгә ташлана.

## VI

Григорий Прохорович фронтташ дустына кунакка бара, ә кәефе шәптән түгел. Гөлсем апасына хәтере калган яки үпкәсе-мазары бар дип уйларга һичбер нигез юк. Утлар-сулар кичкәндә дә сер бирмәгән, шыңшу түгел, ыңгырашучыларны бөтенләй өнәмәгән бу фронтовик апасына ихтирамы аның бик зур. Сугыш тынып ничәмә-ничә ел үткәч, гел уйга да килмәгәндә, әкияттәгечә очрашканнар иде алар. КамАЗ очраштырган иде аларны. Григорий Самородкин, сугыш елларындагы «ут күз» — полк улы, озак еллар Мәскәүдә газосварщик булып эшләгәннән соң, семьясын Мәскәүдә калдырып торып, автогигант корылышына килеп төште. Бер ел була дигәндә квартир алып, хатынын һәм ике кызын да үз янына китертте. Хәзер Гөлсем апалары аларга барып йөри, болары Гөлсем апаны үз күрәләр.

Чаллыда очрашып китүләре Григорий Прохорович тулай торакка урнашырга килгәч булды. Самородкин кулындагы ордерны алгач, Гөлсем апа телсез калган иде. Аннары «ут күз» Гришаны кочаклап алып, бик озак елаган иде. Семьясын китерткәнче Григорий Гөлсем апаның тәрбиясендә яшәде. Киеме юган, өтеләгән булды. Кайнар аштан, тәмле чәйдән өзелмәде. Дуслары белән утырып алырга ниятләгән чакларда да Гөлсем апасы һич каршы килмәде, риза-бәхил булып, булыша-киңәшә торды.

Кыскасы, алар кабат очрашканга һәм апалы-энеле кебек аралашып яши башлаганга ел ярымнан артык гомер үтеп китте инде.

Гөлсем апа Григорийны кунакка хатыны белән чакырган иде. Хатыны килә алмады, чөнки бүген иртән, студентка кызы белән икәүләп, Ялтага ялга китте. Григорий Прохорович, кече кызы белән бергә, аларны аэропортка озата барды. Әнә шуннан кайтып килгәндә кырылды инде аның кәефе.

Үзе эшли торган «Теплоэнергострой-1»нең кырык икенче идарәсеннән яшь бер инженерны очратты ул. Украин егетен. Якыннан белгән кешесе түгел иде ул аның, әмма КамАЗ төзелешенә килгән яшь белгеч икәнен белә иде.

Бу инженерны ул төзелеш-монтаж идарәсендә күргәли иде. Шунысы хәтеренә кергән: егет һәрчак кәефсез, канәгатьсез була, аз гына каршы сүз ишетсә дә пырлап китә, җилле үк җәнҗал куптарудан да тартынмый иде. Күрәсең, күптән түгел генә югары уку йортын тәмамлап килгән белгеч булгандыр. Төзелеш җилләрендә җилләнеп, суларында суланып өлгергән, яшь ягыннан аңа агай тиешле кешеләргә төртмәле сүзләр, мыскыллы әйтемнәр ычкындырудан да тайчанып тормый иде.

— Кәгазь боткасына түбәгездән кереп баткансыз! Кем өстерәп чыгарыр дип өмет итәсез? Киңәшмә дә утырыш, утырыш та кычкырыш! Яшьләр хакында уйлап та карамыйсыз,— дип сүгешә иде ул идарә җитәкчеләре белән.— Участокка чыгып, күз кырыегыз белән генә карасагыз да, бот чабар идегез. Дүртенче көн бөтен бер бригада комнан аркан ишә. Аннары атна буе суган суы суырырга тиешме инде ул кешеләр, я, әйтегез?.. Ә бит эш бер-ике бюрократка бәйле. ДЭК краны ала алмыйбыз...

Шулай үрсәләнә-үрсәләнә дә, өметсезлек белән кул селтәп, бер читкә барып утыра. Озак та үтми, янә калка һәм тагын рәнҗүләрен бәйнәбәйнә түгә башлый.

— Тулай торакка ялгышып кына бер кереп чыгар идегез. Чалбар өтеләргә утюг юк, костюмыңны гардеробка эләргә элгеч таба алмассың, өстәл асларында, тумбочкаларда шешә батареясы... Парикмахерскийга керсәң, сакалың биләңә житкәнче чират көтәргә кирәк. Ашханәләрне әйтмим дә инде. Ашаганыңны оныткачы өр-яңадан чиратка басмасаң, тәпи сузарсың, билләһи!..

Григорий Прохорович аның чытык какча йөзен менә хәзер дә күреп тора шикелле. Алгарак бүлтәйгән ияк. Очлаеп торган озын борын. Нечкә бармаклар, нечкә муен. Ә табышы үткер, агачыңны, тимереңне кисеп керә торган үткер.

Аэропорт юлында кара-каршы килеп очрашкач, бер-берсенә сәлам биреп, баш кактылар. Шунда Самородкин сорый куйды:

— Сәфәр еракмы?

— Кире кайтмаска.

— Әллә безне ташлап китәсез?

— Нишлим монда? КамАЗ балчыгына батып, киләчәк буыннарга тарихи табылдык булып калыйммы? Минем яшисем килә. Дөньяның кендеге шушы Чаллыда гына түгелдер. Хушыгыз!

Григорий аңа «сау бул!» димәде. Әйтә алмады. Укымышлы качакның бу тикле эредән кылануы аны параличлагандай булды. Шулай да яшь инженер чаттан борылып, күздән югалгач, Самородкин шул инженер каршында үзен ни өчендер гаепле кебек тоя башлады. Авызыннан ана сөте кибеп житмәгән бу егет, сүз дә юк, төзелештәге кайбер житмәгән якларга миңгерәп калган. «Улым!» дип торучы әнкәсе янында түгел, кинога билет алып, персональ машинада илтеп куючы әткәсе дә янәшәсендә юк, ә? Кирәккә-кирәкмәскә кычкырып салу, урынсызга да сүгенү бар. Гозереңә колак салып житкермәү — шулай ук бик бар. Ашханәдә өйрәнең сыек чагы куесына карaганда, мөгаен, күбрәктер. Танцы залы да өлгермәгән. Күп катлы йортлар арасында катырган асфальт өстендә биергә туры килә...

Кыскасы, мондагы тормыш аның фараз иткәненә караганда катлаулырак та, аяусызрак та күренгән. Яшь инженерның үпкәсен, рәнжүен дә аңлый ала Григорий. Ник аңламасын? Үзе дә бит ул шул ук шартларда яши. Аннан яманрак шартларны да күргәне булды. Ул, фронт кичкән солдат буларак та, инде кулы сөялләнеп барган төзүче, сварщик буларак та, бер нәрсәне генә аңлый алмый һәм аңларга теләми: мондый төзелештән, алгы сызыктан ничек качмак кирәк?! Ил чигендәге дозордан да, хәрби объект янындагы посттан да качмыйлар бит! Аннан соң посар урын табарына да шикләнә ул аның. Вөжданыңнан качып котылып буламы соң? Тыныч та, рәхәт тә жир күп булыр, тик, ахыр килеп, аны канәгатьләндерерме соң? Юк, әгәр йөрәге чыннан да тынгысызлык дулап тора икән, кеше дигәнең барыбер тынычлап кала алмый. Моны Григорий Прохорович үз тәжрибәсеннән белә.

Сугышта чакта полк улы Гришаның кояшлы һәм тып-тын, хуш исле болыннарда кошлар гына сайрап торган көннәр турында күп хыялланганы булды. Шул хыялына ирешкән дә иде ул. Зөя буена урнашкан Фролово авылы — аның туган авылы шундый иде.

Алмасы-чиясе белән тирә-юньдә дан тоткан авылда үсте ул.

Я хозур иде соң шау чәчәктә утырган бакчалар! Агачлар, туйга бизәнгән яшь киленнәр кебек, ап-ак кием кигәннәр. Дөресрәге, ак ефәккә урангаиннар. Язгы җилсез көн. Кояш нурын мул сибә. Зәңгәр күктә аккош мамыгыдай кабарынкы сирәк болытлар ялкау гына тирбәлә. Һава чәчәкләрнең баллы исе белән, зөбәрҗәттәй үләннәрнең дымлы исе белән тулышкан. Җиләк-җимеш бакчасына керәсең дә бал кортларының җанга рәхәт өстәп бызылдауларын һәм шөпшәләрнең сабыр гына гүелдәүләрен ишетәсең. Шушы язгы сихәтле һаваны күкрәк киереп сулыйсың да, тирә-яктагы гүзәллекне куркытмаска теләгән кебек,

бүтән кабатланмас сихри мизгелнең рәхәтен тоеп — тып-тын каласың.

Авыл җире! Җәйнең үз матурлыгы, көзнең үз гүзәллеге, кышның шулай ук үзенә генә хас илаһи яклары бар. Тик сугышның урау юлларын узган, аннары башкалада илгә-көнгә атаклы Анатолий Коновалов бригадасында берничә ел эшләгән монтажникны авыл үзеннән җибәрми тотып кала алмады инде. Ул янә Мәскәүгә китте, аннан менә Кама буена килеп чыкты.

Үзен туганыдай күреп каршы алган Гөлсем белән исәнлек-саулык сорашып кына торганда, Вәдүт белән Рәйхан килеп керде. Танышып алдылар. Бер-берсен күрү белән үк дигәндәй ошаттылар. Эш кешеләренә хас гадәт бу.

Вәдүт исә монтажчы-сварщикларга аеруча сокланып карый. Ул һөнәргә гади белгечлек дип кенә карарга һич ярамый, ул һөнәр — бөтен бер индустриаль буын. Сварка эшенең үзе кебек үк яшь буын.

Өстәвенә, Григорий Прохорович күпне белә, күп күзәтә һәм күргәнбелгәнен хикәяләү осталыгы да бар икән. Авыл тәэсирләре дә мул аның, шәһәр тормышын да, чиратын, ашыгуын, халык күплеген, транспорт кысанлыгын матур тасвирлый. Сугыш елларын искә алса да йотылып тыңлыйсың. Сөйләшкәндә кешенең йөзенә туры карап сөйли. Күзләре яшелләнебрәк торган зәңгәр. «С» авазын ничектер үзенчә, сакауландырып әйтә, ләкин, тулаем алганда, сөйләмен ямьсез итми. Чәй янында күпме сүз сөйләнде, әмма Гөлсем апалары «кычкыртып» мактарга алынмаса, Григорий Самородкинның Дан орденының тулы кавалеры икәнлеген Рәйхан белән Вәдүт белми китәселәр икән. Хәер, полк улы булганлыгын, кырык өченче елның язында, һөнәр мәктәбенә китәм дип, фронтка кыяклаганын үзе әйтте. Яшүсмер еллар хатирәсе аңа үтә кадерле иде булса кирәк, малай чагын бик тәмләп хикәяләде.

— Кешенең яшьлеге язмышым дигән сүзне беренче тапкыр иңрәп, өзгәләнеп авызыннан чыгарганга кадәр дәвам итә, диләр. Минемчә, бик хак әйтәләр,— диде Григорий Прохорович. Үзенең кичергәннәрен шулай бәяләве булгандыр.

Ирләр очрашкач котылгысызга әйләнә торган бер сүз бар. Ул — халыкара тормыш, дөньядагы яңалыклар һәм, шуларга ялгап, һәркемнең чамасы җиткәнче күрәзәлек итүе... Әмма мондый темаларга әңгәмә ничаклы куермасын, азактан гәптәшләр барыбер үз эшләренә, шәһәр һәм поселок тормышына, туганнарының һәм якыннарының ничек көн итүләренә әйләнеп кайта. Бу мәҗлестә дә шулай килеп чыкты.

Григорий Прохорович иртән аэропорт юлында очраткан яшь инженер турында сөйләгән иде. Вәдүт Яфиз турында ялгап китте. Рәйхан да бу хакта Самородкин белән фикерләшүне кулай күрде. Төзелештә абруйлы кеше икән бит, коммунист кеше, үз эшенең бер дигән остасы, әйтсен әле ни уйлаганын.

— Монда килергә тиеш дисез. Күрик, карыйк, сөйләшик. Әгәр күңеле ятардай булса, буыннары нык булса, мин аны үземнең бригадага ала алам. Бездә андый ике-өч егет бар. Дөрес, алар инде дүртенче айларын өйрәнәләр, шушы көннәрдә разрядка имтихан тотарга тиешләр. Әйе, сүзегезгә караганда, мәшәкатьле егет булырга охшый. Шулай да бер нәрсәне әйтим: безнең һөнәргә бер гашыйк булган кеше гомеренең азагына кадәр чигенми...

Сәгать унынчыга авышты. Унынчы яртьы булды. Ун тулды. Яфиз килмәде дә килмәде. Кунаклар кузгаласы иттеләр. Саубуллашып таралышканчы дип, Вәдүт белән Гөлсем апасы Виктор Шмарев яши торган бүлмәгә сугылып чыгарга булдылар. Гөлсем дә бүтәннәргә кушылып борчыла башлаган иде шикелле. Мәҗлес вакытында бит урталары алсуланып киткән иде аның. Башына бик матур фикер килгән мизгелдәгечә, кашлары чөенкеләнгән иде. Яфизның башбаштаклыгын вакыйк-

ларына кадәр ишеткәч, вәгъдә биреп тә, өлкәннәрне тәмам төп башына утыртуына инде тәмам ышангач, пошынды ул, күенде. Ияк очындагы ямавы тагын да аксылланды.

Һәммәсе кыерсытылган кебек булдылар.

Яфиз танышым дип атаган Шмарев яши торган бүлмәдә дә юк иде. Виктор дигәне үзе дә өйдә кунмаган булып чыкты.

Яфиз ул төнне Морзахан абзый йортында да йокламады. Якшәмбедә дә күзгә-башка чалынмады.

* * *

Ә дүшәмбе көнне...

Дүшәмбе көнне төштән соң Сергачтагы мәктәп-интернатның директор урынбасары, Вәдүт белән Рәйхан язган хатны кат-кат укыгач, Чаллыга җавап язарга утырды.

«Хөрмәтле Рәйхан Кәримовна һәм Вәдүт Морзаханович! — дип башлап китте ул үзенең хатын.— Сездән килгән хат мине сискәндереп җибәрде. Мин аны җентекләп укыдым. Ахырда үземне ике хис берьюлы биләп алды. Аларның беренчесе — шатлык хисе иде. Әйе, әйе, шатлык хисе. Димәк, дидем мин үз-үземә, Яфиз Сәмитов тайгак юлда түгел. Союзны шаулаткан төзелешкә, әнисенең туганнары янына барып чыккан. Аның өчен күпме ут йотканыбызны күз алдына китерә алсагыз, минем куанычымны һичшиксез аңларсыз. Сигезенче класста укыганда, Яңа ел алдыннан юкка чыкты бит ул укучыбыз. Туган авылына да барып карадык, күрше районнардан да белештек, өлкә шәһәреннән дә эзләдек. Таба гына алмадык. Күпмедер вакыт узгач, әнисе янына кайтып киткәнлеге мәгълүм булды. Әнисе янына бардык (мин үзем бардым), бик җай белән сөйләштем. Дөньяда нәрсәдәндер коты алынган кеше шикелле, апа атлы-юллы сынар сүз дә әйтә алмады. Белә торып та авыз ачарга теләмәдеме, әллә чынын да берни дә белми идеме, моны ачыклый алмадым. «Кайтып киткән иде шул» — бар хәбәре шул булды. Нииндидер гөнаһ кылганы өчен эзләп килгәннәр дип уйлавы булдымы икән? Анысын да тәгаен расный алмыйм.

Гаеп-гөнаһ дигәндә, безнең коллектив Яфиз Сәмитовны турыдантуры нииндидер җинаятьтә гаепли алмый. Тыңлаусыз иде, үз сүзле иде, баш бирергә яратмый иде. Яшенә карата буйга-сынга да зур һәм тотрыклы булгангадыр, яшьтәшләренә өстәнрәк карау гадәте дә бар иде. Еш кына ул аларны «Салагалар!» дип тә хурлый иде. Без моны һәрчак исенә төшерә тордык, ләкин ул үзен кисәтүне бик авыр күтәрә иде.

Көннәрнең берендә тимер юл станциясендә райпотребсоюз складыкешеләре аракы әрҗәләреннән шешәләр югалуын абайлап, аны бер төркем яшүсмерләргә сылтарга, шул яраксыз кәсептә Сәмитов та катнашкан дип расларга җыендылар. Моның белән тиешле кешеләр шөгыльләнде, тик Яфизның андый эшкә катнашканлыгын расламадылар һәм тикшерүчегә чакыртып та тинтерәтмәделәр. Мине биләгән икенче бер хис хакында. Ул — көенеч хисе. Димәк, безнең коллектив Сәмитовны аякка бастыра алмады булып чыга. Димәк, без дә, аның әнисе һәм үз авылларындагы мәктәп укытучылары кебек үк, нәрсәнедер абайлап житкермәгәнбез, үз вакытында тиешле профилактик чара күрмәгәнбез булып чыга. Гаять үкенечле хәл бу. Мин, егерме елдан артык эшләүче педагог буларак, моны бик аңлыйм һәм, туп-туры әйтим, Яфиз мәсьәләсендә үземне дә җаваплы саныйм. Минем уемча, аның мәктәп-интернаттан китүенә төп сәбәп — малайлык мәхәббәте булды...»

Директор урынбасарының үтә тәфсилләп язган хатыннан Яфизның Лия исемле кызга күзе төшүе, ләкин кызыйдан җылы сүз ишетә алмавы, азакта аларның бик нык үпкәләшүләре беленде. Ничек булса була:

Яфиз мәктәп-интернат бусагасыннан бүтән атлап керми. Холыксызлыгы белән сынаткач, кире борылмый. Борыла алмый, акылы-фигыле кушмый.

«...Эш үткәч, Лия дә суынды да, соң иде инде,— дип дәвам иткән мәктәп-интернатның директор урынбасары.— Сәмитовның юкка чыгуы барыбызны да утлы табага бастырды. Педагогик «ЧП»га әверелде. Укытучы-тәрбиячеләр коллективы да, тәрбияләнүчеләр дә авыр кичерделәр ул хәлне. Мәктәп җитәкчеләренең башыннан сыйпамадылар, үзегез аңлыйсыз. Лия беркөн хат җибәргән иде (ул хәзер Горький шәһәрендә автозавод каршындагы профессиональ-техник училищеда укый), теге чактагы пырдымсызлыгы өчен үкенә, Яфизның кайдалыгын белмәдегезме? дип тә читләтеп кенә кызыксынган.

Хөрмәтле Рәйхан Кәримовна һәм Вәдүт Морзаханович! Ихлас күңелдән үтенү белән гозерләп сорыйм, сез инде, зинһар, Яфизны күзегездән ычкындырмагыз. Туганнарын тыңламый булмас. Эшче ир-ат тирәлегендә ул үзен, бик ихтимал, үзгәчә тотар. Тиң итеп, егет итеп сөйләшсәгез, яхшырак булыр иде.

Мин сезгә аның җиденче классны тәмамлагандагы еллык билгеләре турында белешмә җибәрәм. Характеристикасының да кирәк булуы мөмкин. Әнисенә хәбәр итикме, әллә сез язарсызмы? Һәрхәлдә, минем бу хатымны бөтенләй җавапсыз калдырмассыз дип өметләнәм».

Морзахан абзый улының да, килененең дә эшкә әйбәт урнашуларына сөенде. Шәһәр мәгариф бүлегендә Рәйханны бик әйбәт каршылаганнар. Эш турында иркенләп сөйләшкәннәр. Мөдир бик җайлы кеше икән, иплән сорашкан, яшен, стажын белешкән, торак ягы белән кызыксынган, баласына урын турында да сораштырган. Документларын караган, Урайдан алып кайткан характеристикаларга күз салган. Сүз азагында болай дигән:

— Көндезге мәктәптә бездә дә урын юк, иптәш Шәйхаттарова. Хикмәт менә нәрсәдә. Соңгы ике елда гына да берничә яңа урта мәктәп ачсак та, укытучы кадрлар белән бик яхшы тәэмин ителгәнбез... Һич мохтаҗлык тоймыйбыз. Ник дигәндә,— бөтен Союз удар төзелеше булгач, бихисап инженер-техник работниклар килде. Байтак иптәшләрнең хатыннары укытучылар. Берсенең дә өйдә генә кул кушырып утырасы килми. Беләсез, педагоглар көне-төне эшләргә күнеккән халык... Кичке мәктәптә, тагын эшче-яшьләр арасына барам дисәгез, монда бер вариант тәкъдим итә алам. Үзәктәге сменалы мәктәптән математика укытучысы декретка чыкты. Менә шушы көннәрдә генә башлана аның ул ялы. Кем белсен, бу уку елында эшкә башлап та тормас. Хәзер рәсми рәвештә андый хокук та бирелә, беләсездер. Әгәр шунда эшләргә риза икәнсез, бигрәк тә тәҗрибәгез дә булгач, мин сезне икеләнмичә шунда җибәрәм...

Рәйхан, ризалашып, эшкә билгеләү кәгазе алырга иртәгә киләсен әйтеп кайтты. Ире моны хуп күрде. Эшли торсын әле. Алдагысын күз күрер...

Вәдүтнең эшкә урнашуы өчен һич кенә дә борчылыр җир юк иде. Аны дүрт куллап кабул иткәннәр. Ул ДЭКта, ягъни дизель-электр краннда эшләячәк — двигательләр заводы мәйданчыгында, шул пәһлеван заводка нигез салуда. Күңелне алгысытканы шул: анда хәзер субайны бораулап коярга керешкәннәр. Яңа ысул, алдынгы алым!

— Бик мәгъкуль, бик хуп! — диде Морзахан абзый, килене белән улы кайтып сөйләгәннәрне бик бирелеп тыңлагач.— Хәерле сәгатьтә булсын! Шулай бит, бәләкәй улым, ә? — Ул җилтерәтеп Айдарны күтәреп алды.— Пар күгәрченнәр кебек гөрләшеп яшәргә насыйп булсын диген, улым, әйе бит?! Исәнлек-саулык белән, җан тынычлыгы белән!

Карт күңеленнән улы белән киленнең хезмәтләреннән ямь табып, уртак куаныч-шатлык белән эшләп йөрүләрен уйлады. Иртән җыеныл

эшкә китүче булганда, кичке күлемдә менә кайталар, менә кайталар дип көтәр кешең булганда,— ул үзе бер бәйрәм ләбаса. Югыйсә, иртән торсаң да ике бөртек бөрлегән, кич ятсаң да ике ярма ясмык. Туйдыра ла ул ялгызлык адәм җанын!

## VII

Идарәнең кадрлар бүлегенә кергәндә, Григорий Прохорович Яфизга чак кына сабыр итәргә, шушы тирәдә генә йөреп торырга кушты. Үзе хакында барачак сүзне тыңлап тормаганы хәерле егетнең, дип уйлады ул.

Кадрлар бүлеге начальнигы, колгадай озын буйлы, шул озынлыгы аркасында азрак бөкре чыгарып йөрүчән, житез хәрәкәтле, ачык чырайлы кеше, Самородкинны бик күңелле каршылады.

— Син дә безнең ишекнең кай якка ачылуын онытмагансың икән әле, Григорий Прохорович, ә? Нинди җилләр ташлады үзеңне? Иртүк нилэр майтарырга йөрисең? Исәнме! — диде ул, урыныннан торып ишек катына килде һәм монтажчылар бригадирына кул сузды.

— Исәнме, исәнме, иптәш Чукайло! — Григорий озын агайның кулын кысты.— Хәерле иртә телим. Каләмегез тутыкмасын! Ә ишекнең кай тарафка ачылуын бер белдемме, онытмыйм инде мин. Еш килеп йөрергә, үзең беләсең, кадрлар мәсьәләсе монда хәл кылынса да, заводлар язмышы, кала киләчәге тегендә, безнең якларда хәл ителә бит... Вакыт тыгыз, туган, вакыт... Әйләнеп карарга да өлгермисең, атна үткән дә киткән...

— Анысы да хак, Григорий Прохорович... Гозерең бар идеме?

Икесе дә түрдәге өстәлнең ике ягына утырдылар. Самородкин киң козыреклы кепкасын салып куйды һәм буынтыклы юан бармаклары белән өстәл читенә суккалап, үзе генә белгән көйне тыпырдатып алган булды. Аннары начальникның йөзенә туры карап, елмайгандай итте. «С» авазын үзенчә бераз сакаурак итеп:

— Слушай, иптәш Чукайло,— дип сүз башлады.— Минем фронтташ дусның ерак бер туганы, бер ташбаш Чаллыга килеп төште. Уналты тулар-тулмас үзенә. Мәктәп-интернаттан табан ялтыраткан. Автозавод төзешмәкче. Монтажник булам ди дә вәссәлам!..

Григорий Прохорович, кирәк чакта, сүзе үтемлерәк һәм ышандырырлыграк чыксын өчен, буяу сала, кершән яга да белә икән!

— Ә син әйтерләр аңа, Прохорович, башта борын астыңны сөрт, укып бак, безнең һөнәрне үзләштерә алсаң, сыртыңны сынап карарга минем бригадага килерсең, диярләр. Уналты да тулар-тулмас борын монтажчылыкка нәфсесен суза икән, ә. Һе, малай-шалай кем булам димәс ул! Мин тора торган унике катлы йортның һәр этажы саен икешәр-өчәр булачак Гагарин. Аларның арты кызганга карап йөри башласаң... Белеме ничә класс? Кая әле, күз кырыем белән генә карыйм әле шуның табелена. Укуын дәвам итәр иде ул малай...

Кадрлар бүлеге башлыгы, документлар сорап, Самородкинга кул сузды. Тегесе шундук кистереп җавап бирергә ашыкты.

— Укуы урта кул инде, билгеле. Тик менә ул шул хәтле ашыккан, жиденчене бетергәнгә белешмә дә алып тормаган. Үзе болай сигезенчедә ярты ел укыган малай. Сораттык, документлары бүген-иртәгә синең кулда булачак, иптәш Чукайло. Хәзергә янында бердәнбер мандаты — туу турындагы таныклыгы.

Начальникның аяз йөзе сүрелә төште. Аның бөтен торышы, килешкилбәте: «Үзең мактаулы бригадир. Фронт батыры. Житди кеше ләбаса. Үзең, дивана агай төсле, кулында документлары да булмаган балачаганы монтажчылар бригадасына алырга йөрисең. Әллә чыннан да

бераз кыйшайдыңмы? — ди иде. Григорий Прохорович монтажчы эшенең четрекләрен бик белә, шулай да үзенекен тукырга ашыга.

— Малай дип, бала-чага дип сөйләшсәк тә, ул полный самай хәзер, са-ма-а-ай! — Самородкинның «самай» дигәне бик кызык яңгырады. Әйтерсең лә ул үзенең телендәге бераз сакаулыгын сиздерер өчен юри шул сүзне сайлаган иде.— Таза гәүдәле, сукса җенеңне өзәрлек егет. Ашат та эшләт кенә! Спортсмен. Штанга буенча мастерлыкка җыена...

Шулай дип җилле генә җилгәреп җибәргәч, Григорий Прохоровичның үзенә дә күлке булып китте. «Гомеремдә бу тикле борчак сипкәнем юк иде, каян телемә килеп тора! Бригададагы егетләр моны белсәләр, «Да, безнең батя кулы белән чуртан тота икән», диярләр иде. Алдавын алда, тик чамасын чамала»,— дип куйды эченнән.

— Хәзерге егетләрнең бер ишесе я штанга күтәрә, өздереп эшләргә дигәндә, әнә, әткәй эшләсен! Кыскасы, уналтыны да тутырмаган килеш, хәтта бөтен документларны җырлап торса да, эшкә алып булмый аны, Григорий Прохорович. Укысын. Һөнәр училищесына керсен.

Самородкин сүз тезгенен ычкындырмаска итте.

— Әйтергә ансат: укысын! Нәрсә ашасын, нәрсә кисен, кайда торсын? Менә бит хикмәт кай тирәдә, иптәш Чукайло! Буй җиткән егет хәзер бот буе малайлар белән һөнәр училищесында утырмый шул инде. Каны кайный аның, беләкләре эш сорый...

Начальник бер генә минутка тынып калды, күзләрен өстәлендәге калын пыяла астында яткан кәгазьләргә текәде. Шунда, кәкре-бөкре хәрефләр арасында мәсьәләне хәл итү сере яшеренгән идемени! Аннары башын күтәрде, күзләрен ачалак-йомалак китереп торды да:

— Хәзер кайдарак торып тора әле ул спортсмен? — дип сорады.

— Миңа фронтташ тиеш бер хатында. Белмисеңдер, Галя, Гөлсем Сайкина. Дүрт тә бердәге торакта комендант. Протез белән йөри. Шунда яшәп торган була. Болай яшәү турист путевкасы белән дигән сүз. Сайкинаның үз мәшәкате муеннан ашкан. Бүлмәсе дә танцы залы түгел. Синең кебек берәү сузылып ятса, түрдән бусагага хәтле диган сүз, иптәш Чукайло!

Бүлек хуҗасы тагын эндәшмәс булды. Ә Прохорович аның авызыннан сүзне тартып алырдай булып утыра бирде. Аннары түзмәде — әрсезләнеп эндәште:

— Шулай да бер чарасын күрәсе иде бит, иптәш Чукайло... Самородкин түш кесәсеннән тарак алып, сыек-сирәк чәчен тараштыргалады, болай да туры итеп аерган чәч юлын төзәткәләп куйды.

— Мин әйтәсемне әйттем, Григорий Прохорович. Булмый. Бигайбә. Хезмәт турындагы законнарны бозарга миңа бер кешенең дә хокук тоттырганы юк әле. Ә син менә шуны әйт: бригадаңдагы иң яшь монтажнигың ничәдә?

— Егермене тутыра.

Начальникка читтән рух өрделәрмени, ул җанланып китте. Озын гәүдәсен өстәл аша яртылаш бөгеп, Самородкинның йөзенә төртелер дәрәҗәдә якын килде дә, тешләре күренерлек итеп авызын ачты.

— Менә-менә-менә! Әле аны да, мөгаен, югарыга менгермисеңдер. Врачлар рөхсәт бирсә дә хәтта...

— Мин дә рөхсәт бирдем бирүен. Тик шуны аңла, иптәш Чукайло, мин бу егетне артына сугып сразы өскә менгереп җибәрергә җыенмыйм. Аңа әле аста да шөгыль житәрлек булачак.

— Юк, барыбер мин бу эшкә бара алмыйм. Хәзергә син яхшыга — мин яхшы. Алла сакласын, берәр жирдән мәтәлеп төшсә, я булмаса пешә-нитә калса, башың прокуратура буеннан, суд залыннан кайтып кермәс. Булмый. Бүтән йомышларың юк икән, саубуллашыйк, Григорий Прохорович...

Начальник өстәл аша аңа кул суздьı. Самородкин, теләр-теләмәс кенә күрешеп, ишеккә юнәлде. Ишекне каерып ачкач кына, артына борылып:

— Гаепләмә, әләкче дип уйлый күрмә, идарә начальнигының үзенә барам. Мин бит сине эш башкара ала торган ир дип уйлаган идем, иптәш Чукайло! — диде.

— Закон тәртип сорый, Григорий Прохорович. КамАЗ корылышы башбаштаклыклар мәйданы түгел!

Һич югында, соңгы җөмләсен әйтмәсен иде бу кәнсәләр сандугачы! КамАЗның нәрсә икәнен Самородкин белмиме әллә?! Шул чәнечкеле сүзләргә җене кузгалгач, бригадир да сдачасын бирми калмады.

— Инструкцияне яттан иң шәп белгән кешене, автогигант өлгергәч, беләсеңме, кая куячаклар? Тәмәке тарту урынында акыл сатып торырга...— дип усалланды. Шуннан соң, командага буйсынып кырт борылган солдат кебек, ишеккә карады һәм киң козыреклы кепкасын башына ябыштырып, эре-эре адымнар белән китеп барды. Яфиз янына килеп җитүгә, алдан ук юатып куярга теләгән төсле:

— Чиертмәде әле, энекәш. Җимен таба белмәдек бугай. Шулай да борының салынмасын. Иртәгә идарә начальнигының үзенә керәм,— дип сөйләнде.— Ә бүгенгә бар, кайтып тор. Иртәгә сәгать алтыдан да калмый монда килгән бул. Мин ТЭЦка киттем...— Аннары тирә-юньгә мазут төтене таратып, үкерә-үкерә алга үрмәләгән машинага кул изәде. Аның кабинасына кереп утыргач, башын тыгып, янә Яфизга нидер кычкырды. Егеткә аның «Яша-а-а» дигәне генә аңлашылды.

Иртәгесен идарә начальнигы белән әңгәмә дә татлыдан булмады. Иптәш Чукайло начальникка һәммәсен тармагыннан кармагына хәтле сөйләгән иде. Артыграгын да җибәрмәдеме икән әле. Ник дигәндә, идарә начальнигы комендант хатын хакында кайта-кайта сорашты, читләтеп тә сораулар бирде, туп-туры: «Ул фронтовичка кем соң сиңа, Прохорович? Аның туганы дип ник шул тикле җан атасың? Закон бозарга ярамаганлыкны син миннән ким белмисең бит!» дип тә төпчеде. Болайга киткәч, әйле-шәйле ярамаганын Самородкин тиз аңлады. Яфизның ул комендант хатынга бәйләнеше мич моржасының космостагы корабль антеннасына якынлыгы чамасында гына икәнен әйтте. Сәмитов Яфиз ник аңарда яшиме? Туганнарында, дөресрәге, җизнәсе йортында, табын такыр, ятак тар. Ник алаймы? Яфиз ул җизнәсенең вафат булган хатынының сеңлесеннән туган малай гына. Менә шул. Егеткәйне алай каккannар, болай сукканнар. Без дә янагына бер чалтыратып җибәрсәк, ике дөньяны бер савытка тутырып йөри башлаячак ул, белдегезме? Ә мин аны теләмим. Кеше булсын ул! Җимертеп эшләсен, илгә файда китерсен, үзен тулы хокуклы кеше итеп сизсен. Караңгы почмакта шикле шөгыль белән буталганчы, үзе шундыйларның кулына сугарлык булсын! Мин аны үзем белән дружинниклар командасына алып йөриячәкмен. Соңыннан үзегез дә рәхмәт әйтерсез әле...

— Ниятең изге, Григорий Прохорович. Сине бик ихтирам итәм. Ләкин... Сәмитовны эшкә алырга рөхсәт итә алмыйм. Булды, сөйләштек. Егетнең үзенә дә әйттем. Шуның белән сүзне бетерик.

— Юк, бетермик! — Самородкин урыныннан сикереп торганын тоймый да калды.— Бетермик! Җәмәгать эше булса, эшлә, дисез. Карышмыйм. Барыбыз да эшләргә тиеш. Ата-аналар комитетында членмын. Җәмәгать тәртибен сакларга булыш, дисез, булышам. Беләм, бу — барыбызның да бурыч. План давай, дисез. Ике норма биреп килмәбез. Шулай булырга тиеш. Бишьеллыкны безнең өчен читтән килеп үтәмәсләр. Мин дә менә каршыгызга килеп, бер яшүсмерне тайгак юлдан йолып калыйк, дип йөз суы түгәм, кешене кеше итик дим, бу кадәресе, нәрсә, бер минем генә эшемме? Аякларына нык баса алма-

ганнар юлдан язып китнәч, бер-беребезгә бармак белән төртә-төртә күрсәтешеп, гаепләне эзли башлыйбыз. Кем гаепле: ата-анамы, мәктәпме, коллективмы? Кайсы кайчан тәрбия итеп җиткермәгән, дибез. Шулай бит? Без үзара кычкырышып, бер-беребезгә төртешеп торган арада фәлән кешебезне төрмә тәрбияләргә кала...

— Лекция укыма, зинһар, иптәш Самородкин. Булмый дигәч, булмый. Яше җитми. Мөмкин түгел!

— Ә сугыш елында мөмкин иде бит! Яше җитми димәдек. Азмыкүпме кеше яше җиткәнен көтмичә үк фашистны кыйнаштык. Фронтта бит монтаж мәйданы гына түгел. Анда, туганкаем, өстеңә ут түкереп металл яудырып торалар. Мин менә ундүрт яшемнән ут эчендә йөрдем. «Эх, син, Самородкин! Эшне боздың, молокосос!» дигәнне ишетмәдем. Кешеләргә ышанырга да кирәк...

— Ничек, син шулай яшьли киттеңмени фронтка, Григорий Прохорович? — диде идарә начальнигы.— Менә монысын белмәгән идем. Шул тикле кешенең үткән юлын кайдан дәррәү генә белеп алмак кирәк?! Кызык, кызык! Полк улы идеңмени соң син?

Начальник әле генә булган низагны бөтенләй оныткандай булды, тыныч, йомшак тавыш белән сөйләшә башлады. Аның йөзенә гафу сорау галәмәте чыккан иде. Григорий Прохорович та кызып китүенә үкенеп куйды. Шунлыктан идарә начальнигының соравына каршы бик тыйнак кына:

— Әйе,— дип җавап кайтарды.

Истәлеккә чумып утырыр чак түгел, егетләр көтәләр. Коридорда гына Яфиз өмет өзми йөри. Шуңа күрә, Самородкин, кабат үтенүем дигән төсле, идарә начальнигына ирләрчә ялвару белән карады. Әтегесе бригадирның ялынуына чыдый алмыйчамы, я булмаса күңеленнән аның белән ризалашыпмы, кырыс кына:

— Барысы өчен дә үзем, Самородкин Григорий Прохорович, башым белән җавап бирәм, дип кулыңнан язу калдыр. Ә ул язуыңны мин менә монда, сейфка салып куям. Шунысын да истә тот, һәр ай азагында кереп, бу мәсьәләдә эш ничек баруын особо хәбәр биреп торырга мәҗбүр итәм мин сине. Яз, мин, Самородкин, уналты яше дә тулып җитмәгән Сәмитов Яфиз Әюп улын өйрәнчек итеп үзем җитәкли торган монтажчылар бригадасына алам, диген. Аның производстводагы иминлеге өчен дә, укуы өчен дә, үз-үзен тотышы өчен дә җавап бирәм, диген. Идарә начальнигы да, кадрлар бүлеге дә ни дәрәҗәдә җаваплы икәнемне нык кисәттеләр. Шуңа да карамастан, Сәмитов Яфизны бригадага кабул иттем, диген.

Григорий Прохорович әйтерсең нәкъ шуны гына көткән иде.

— Була! Кәгазь-каләм бирегез,— диде.

* * *

Аннан бирле өч-дүрт көн узды. Яфизга бригадада кызык та, куркыныч та иде. Кызык дию шуннан, монда аның өчен тау чаклы яңалык ачылды. Брезент киемнәрдән, каскадан һәм махсус ботинкалардан башлап иминлек гарантиясе дип йөртелә торган монтаж билбавына, электрод тоткасыннан алып бригадирның холкына кадәр — һәммәсе яңалык иде. Куркыныч дигәне — анысын әле Яфизның сынап караганы юк һәм тиз генә туры да килмәс — ай-һай, монтажчыларның эше хәтәр икән ич: ут көлтәсе эчендә калып эшлиләр. Бу — бер. Ә биектә эшләве! Яфиз аларны биек ярга, ярның төрле җиренә килеп кунган кошларга охшатты. Алар металлга ут белән мәңге сүтелмәслек җөй салучылар икән! Җөйләрнең вертикальләре дә, горизонтальләре дә була. Түшәм җөе дигәне иң катлаулысы, ди. Ни өчен дисәң, түшәм җөен эретеп

ябыштырып барганда, агай-эне, металл җир тарту көче белән тарты-ша-тартыша югары китәргә, тигез һәм нык ятарга тиеш. Баш өстендә җөй салуның кыенлыгын күпне күргән монтажчылар яхшы белә. Андый чакта кеше тиз арый, кайнап торган металл тамчылары еш кына аска чәчри, кулларны пешерә. Шуның өстенә җил-давыллы көнне, чатлама суыкны күз алдына китерегез.

Бу бригадада ут яңгырыннан саклануның әмәлен тапканнар табуын. Зур кисәк резинны уртасыннан тишкәннәр дә электродның тоткычын шуның аркылы чыгарганнар. Беренче карашта гап-гади җайланма кебек, ә күпме кешенең кулын саклый!

Бер сүз белән әйтсәң, шул менә: монтажчылар өчен кызык һәм авыр дигән төшенчәләр — игезәк төшенчәләр икән. Яфизга башта шуны төшендерделәр. Шуларның беренчесе икенчесе белән туры пропорциональ бәйләнештә икән.

Яфизны бригадага алып килгән көнне Григорий Прохорович үзен шушы һөнәргә өйрәткән Мәскәү бригадиры Анатолий Степанович Коновалов тормышыннан бер хәлне сөйләде. Коточкыч! Тыңлаганда йөрәк жу-у итеп китә, баш әйләнә башлаган шикелле була.

Коновалов, Запорожьеда домналарны сафка керткәндә, шундый хәлгә тарыган, саклагыч бил каешы да коткарып кала алмый икән. Мондый очрак бозланып каткан балкадан шуыша-шуыша барып ябыштырганда булган. Шуннан ул ботинкалары үкчәсендәге корыч дагаларны балкага эретеп ябыштырган. Бер урында эшен бетергәч, кискен хәрәкәтләнеп аякларын каерып ала икән дә икенче җиргә күчкәч, үзен янә ябыштырып куя икән! Григорий Прохорович, шундый гыйбрәтле хәл сөйләгәч, инде кырыкмаса кырык әйткән булуына карамастан, тагын бер кат киртләп куя: «Менә шулай, егетләр! Табигать кешене яратканда запас частьлар ясарга оныткан. Безнең хезмәттә шуны мыскка урап яшәргә кирәк!»

Яфизны бригадир үзе алып килгән егет булгач, әйбәт каршыладылар. Беренче көнне үк Рыжик дип йөртә башладылар. Григорий Прохорович: «Менә бригада улы алып килдем. Таныш булыгыз!» — дип сөйли башлагач, кайсыдыр (Яфиз хәзер аны таный да алмый инде):

— Пионерлар лагере ачабызмы әллә, батя? — дип тел шомарткан иде шомартуын, Самородкин үзе:

— Кирәксә, балалар бакчасы да ачарга мөмкин,— дип кырт кисте.— Син үзең бригадага академия бетереп килдеңме әллә? Яле, алай бик тиз борын күтәрмик. Барыбыз да әйбәтләп булышыйк Яшага. Ярдәм кирәк хәзер аңа...

## VIII

Нигез корганда гадәттә сугыла торган тимер-бетон субайлар урынына бораулап бетон салу ысулын куллану түзелеш өчен нигез астында зур чокырлар казу, миллионнарча тонна туфракны читкә ташу, аннары ул чокырларны төп кабат тутыру шикелле бинһая мәшәкатьләрдән коткара. Яңа ысул буенча алты йөз һәм мең ике йөз миллиметрлы скважиналар бораулап, аңа арматура каркаслары куела һәм бетон коела. Шушы яңалык төзү материалларына да, вакытка да зур экономия бирә, эшнең күләме дә азрак була.

Кыскасы, яңа ысул һәркемне сөендерә. Тик аның көенечләре дә чат саен сагалап тора. Шуңа күрә дә төзелеш мәйданына килгән житәкчеләргә субайчы егетләрнең гозере бер: «Бетоннан өзмәгез! Кыш житәрен истән чыгармагыз. Зәмһәрир суыкта бетон шаярганны бер дә яратмый. Егерме-утыз чакрымдагы заводтан бетон ташып кына ерып чыгарбызмы? Көзге пычракларда юл начарланып, төп башына утырып калмабызмы!» — диләр алар.

Бүген вахта машинасына төялеп кайтканда да сүз гел диярлек житенкерәмәгән яклар хакында барды.

Смена буена бик дәртләнеп эшләгән иде кебек Вәдүт. Өйгә кайтып, юынып, өс-баш алыштыргач, тамак ялгагач, бөтен гәүдәсе авыраеп киткән төсле булды, йокысы төште. Ял итеп алыргамы соң әллә, дип торганда, бабасы белән бакчада эвәрәләнгән Айдар килеп житте.

— Әтием тайт-тан! — дип куанычлы кычкырды ул һәм, аякларын аерып баскан хәлдә, кулларын чәбәкләргә керешге.

— Кил әле, Айдар, монда кил! — Вәдүт аны кул изәп үзенә чакырды.

Айдар коңгырт күзләрен ялтыратып Вәдүткә карап торды да, дәррәү кузгалып, йөгереп килде. Вәдүт аны кулына күтәрде.

— Сагындыңмы әллә, улым, мине?

— Э-э!

— Күрсәт инде алайса, сагыну ничек була ул?

Айдар Вәдүтнең муеныннан чытырдатып кочаклады һәм битеннән чуп-чуп итеп үбеп куйды. «Сулай була»,— диде аннары, эш башкарган кеше төсле.

— Вәт, маладис, Айдар. Зур үскәнсең инде. Әниең кайда соң?

— Тит-те.

— Кая китте?

— Мәт-тәп-тә тит-те.

— Шулаймыни?

— Сулай...

Вәдүт Рәйханның мәктәпкә алданрак китәсен белә иде. Беренче көннәр. Яңа мәктәптә яңа класс. Укытучылар коллективы яңа. Укучылар да. Оештыру эшләре байтак.

Морзахан абзый керде. Ул һәр бирмеш көнне, Вәдүт эштән кайтуга, гәпләшергә кереп утыра. Автозавод төзелеше хакында сүз булмый калган көн юк диярлек.

— Бүген нинди яңа хәбәрләр бар, улым? — диде ул.

— Гадәттәгечә, эткәй. Субай сугуны арттыру өчен тырышкан-тырмашкан булабыз. Көзге пычракка кадәр ашыгабыз. Яңгырлар көйләп жибәрсә, безнең Чаллы туфрагында, үзең беләсең бит, жен куәтенә ия машиналар да бер урында көпчәк әйләндерә башлыйлар.

— Анысы шулай...— Морзахан абзыйның сөйләшер сүзе ул түгеллеге сизелде. Тел очында бүтәне бар иде.— Техника куәтле лә хәзер. Жәһәннәмнән дә имин чыгар,— дигән булды алай да. Кырт кисеп кенә бүтән нәрсә хакында тыкылдап китүне килештермәде булса кирәк.

— Бүген әллә нигә арып киттем әле,— диде Вәдүт.— Үз алдыма авыраеп, салынкыланып торам...

— Явымга авышмакчы бугай, шуныкыдыр. Кортларның борчылуына караганда, яңгыр булырга тиеш...— Менә шунда Морзахан абзый сүзенең жилемен тапкан шикелле тойды.— Кортлар димәктән, шул нәрсәкәйне киңәш итим дигән идем мин синең белән, Вәдүт. Бүген шәһәр Советындагы Галәветдинне күрдем. Беләсең син аны. Әйе, әйе, Жантимер абзый улы... Шул әйтә, Октябрь бәйрәменнән соң чират сезнең йортка да житәр төсле, ди. Сүтәсе булгач сүтәрләр. Кортларны суыкта ары-бире китерер хәл юк. Әллә, мин әйтәм, совхозга барып кайтыйммы, дим. Сатыйк булмаса. Башка мал-туары өчен хафаланган юк. Суйдык и вәссәлам! Семьяга ит булыр...

— Әгәр ташпулатлар рәте килеп житә икән, йортны сүтәргә туры киләчәге хак, эткәй. Шулай булгач, бик кыен булса да, умарта кортларың белән саубуллашырга туры килер инде,— диде Вәдүт.— Теге вакытта, үзең әйткәндәй, күнелең һич тә басылмас булса, совхоз умартачыларына булышырсың, эткәй. Шәһәрдә яшәүче авыл кешесе булып карарсың...

Морзахан абзый көлемсерәп кул селтәде.

— Хәзер авылда яшәүчесе дә игенче дип әйтерлек түгел инде, улым. Печән өсте — печән өсте түгел, печән җыеп алу. Урак өсте — урак өсте түгел, урып-җыю. Элек, колхозларның беренче елларында, печән өсте җитәр иде, әзмәвердәй ирләр болынга кузгалырлар иде. Кулмәкләр тирдән сыгып куймалы булыр иде. Аннары инде ашарга утырсаң, ут уйнатыр идек. Печән өстенә дип атап сарык суелыр иде. Кем кинрәк алып чаба, кемнең адымы үрчемле дип ярышыр идек. Илаһи, кояш кыздырыр иде, кошлары сайрар иде. Кичләрен, куышларда куна калганда, берәр ут күңеле җыр башлар иде... Кая инде ул хәзер! Хәзер трактор сөрә, трактор чәчә, комбайн урып-сугып авызына гына салмый... Хатыннар өйдә ипи пешерүне оныттылар бит, бөтәнен әйткән дә юк... Ирләре ат җигә белми, валлаһи. Хәер, аты да калмады инде аның... Техника заманасында почет бал кортларына гына түгел, крестьянның гомер-гомергә күңел юанычы булган һәммә җан иясенә кимеп калды. Тамакка кабарга дигәндә, бар да кирәк. Ит-сөт дибез, бал-май дибез, күкәй дибез... Я, ярый, мин иртәгә совхозга барып кайтам, алайса, улым?

— Шулай ит, эткәй.

Вәдүтнең ял итәргә чамалаганын күреп торса да, этисе тиз генә чыгып китмәде. Тагын да нидер сорашмак-кинәшмәк була иде әле.

— Шуны әйтәм, йортны сүтәр булсалар, алдан ук килешеп, сүз беркетеп куярга кирәктер бит инде. Без — нибарыбыз биш җан, алай гына булып торыр дип кенә дә булмый, кыр тикле ике өйне дә ташлап китәсе кешеләр, ничек итәрбез икән соң? Фатирның өч бүлмәлесен, балконлысын дип сорарбыздыр бит?

Инде Вәдүт көлемсерәп куйды.

— Эткәй, турысын әйтим, минем бу турыда нигытып уйлаганым да юк бит әле. Кайттык, урнаштык, контейнерлар белән киләсе нәрсәләр килеп җитте. Алгы өйгә бик кинәнеп урнашып алдык. Әлегә бөтәнен гел уйлыйсы да килми иде. Күчәргә туры киләчәк булгач, уйлашырбыз инде... Чыннан да!

Морзахан абзый, нигәдер уңайсызланган шикелле, төзәтебрәк куйды:

— Син инде бергә-бергә яшәүгә каршы да булмассың, шәт. Киленнең ул-бу сүз әйткәне булмады, дигәнем?

— Минемчә, ул да бөтәнчәрәк уйламыйдыр, эткәй. Бергә-бергә берберебезгә таяныч дигәндәй...

— Анысы бик шулай, улым, бик шулай. Безнең яшь тә бирегә түгел, кирегә китеп бара бит инде. Исән көнең бар, сырхап китүең бар. Бер ояга оешып яшәгән хәерле...

Сүзгә шунда нокта куйдылар.

Авыраеп торуы, чыннан да, яңгыр явасыга булган икән.

Ул, янбозына төрткәндәй, кинәт уянып китте. Нигә болай булды әле бу? дип уйлана торгач, төшенде тагын. Стена сәгате кылт туктап калган икән, шуңа уянган. Әйтерсең ике сәгатькә якын шуны гына тыңлап яткан! Ә тышта шәп яңгыр явып узган. Түр бакчада куаклар юылып, чистарып калганнар, яфракларыдан әле дә булса тып-тып тамчылар коелгалый. Аяк астын шактый пычраткан.

«Рәйхан босоножкалар киеп киткәндер, мөгаен. Каршы алырга кирәк булыр, резин ботыйларын тота барыргадыр...» дип уйлап алды Вәдүт. Киенеп болдырга чыкты. Һава саф, сулышка җиңел иде. Мондый минутларда уйлар да сафланып кала шикелле. Кешеләргә ягымлы итеп, бик самими итеп эндәшәсе килә башлый, яхшылык кылу дәрте уяна. Рух күтәренкелеге шул була торгандыр...

Рәйхан да дәрескә күтәренке күңел белән керде. Үзен аягүрә торып каршылаган укучылары белән бик ачык, бик җылы исәнләште.

— Утырыгыз, иптәшләр...

Укучылар җайлап утырышкан арада класс бер гөжләп алды да тынып калды. Староста сайланган булса да, дежурныйлар үз вазифаларын тырышып үтәсәләр дә, исемлек буенча укып чыкмый булмый иде әле. Сигезенче класска төрле идарәләрдән, төрле подразделениеләрдән җыелган егетләр һәм кызлар аралашып өлгермәгәннәр, бер-берсен белеп җиткермиләр.

— Ике кеше юк, димәк. Бәлки, кичегәләр генәдер,— диде Рәйхан, классны җентекләп тикшергәч.— Дементьева Алевтина һәм Геворг Григорян юк. Сәбәпләрен ачыкларга кирәк булыр, староста иптәш.

— Ачыкларбыз.— Гөбедән чыккан тәсле тавыш белән арткы партада утырган егет җавап бирде. Экскаваторчы ул. Машинаның үзен сытардай таза.— Миннән имин котыла алмаслар, Рәйхан Кәримовна.

Бөтенесе диярлек старостага борылып карадылар.

— Син чыннан да муеннарын борырга җыенмыйсыңдыр бит? — диде кайсыдыр. Староста җитдинең аръягына чыккан кыяфәт белән гөрелдәп куйды.

— Ни сәбәпле килмәгәннәрдер бит. Тикшерермен, аннан күз күрер,— Булмәдәше турында Яфиз сүз катты.

— Григорян миннән кайтып җитмәгән иде әле, Рәйхан Кәримовна. Килердер ул, килми калмас...

Үткән дәрес темасын искә төшерергә булдылар. Җавап бирергә Рәйхан Яфиз Сәмитовны чыгарды. Уку елы башланып, геометрия дәресе ничәнче генә тапкыр уза, ә Рәйхан апасы Яфиздан менә икенче тапкыр сөйләтә инде. Әйткән иде шул тулай торакка килгән көнне: «Минем кулдан шома гына ычкына алмассың, энем. Математикага кырын каравыңны юкка чыгарырмын мин синең!» — дигән иде. Тәки сүзендә тормакчы...

Яфиз туры почмаклы өчпочмакта яклар һәм почмаклар арасындагы мөнәсәбәтләр турында ярыйсы ук шома сөйләп китте. Җавабыннан Яфиз үзе канәгать иде. Акка кара белән язганны, бөтенләй чүбек баш булмасаң, укып хәтерләргә дә, сөйләп бирергә дә мөмкин ич. Кулыңа китап алып утыргач, белеп булмый торган нәрсә юк инде ул! Тик мәсьәлә чишә башлагач, сызымнарга килеп терәлгәч, хәл мөшкелләнә. Менә хәзер дә, класста практик мәсьәләләр чишүгә керешкәч, Сәмитов үңга да карап алды, сулга да күз сирпеде. Күршеләр ничегрәк мәтәштермәкчеләр, янәсе.

— Уйла әле, уйла, Сәмитов,— диде аңа Рәйхан апасы.— Тактага чакырыласы кешенең авызына чәйнәп салганын гына көтеп утыру шәп түгел. Яле, мәсьәләне өр-яңадан бер кат укып чык...

Яфизга әйбәт тә, читен дә. Әйбәт диярлеге шул: Рәйхан Кәримовна аны бик азга гына да күздән ычкындырмый. Чамасы җитмичә, боргалана башлавын абайлап алуга, укытучы аның янына килеп җитә, өстәмә рәвештә аңлата, төшендерә. Читенлеге әйтмәсәң дә аңлашыла: якыннан белеш кеше, туганының хатыны бит ул. Аның каршында булдыксызлыгыңны күрсәтеп утыру газапның газабы инде...

Класс дәфтәрләргә текәлгән. Ара-тирә борын тартып куйган тавышлар ишетелә дә каләм кыштырдаганы колакка керә. Рәйхан Кәримовна кемнең ничегрәк эшләвен күзәтеп парталар арасында сүзсез генә йөренә. Менә ул староста утырган парта янынарак килде. «Күзе начар күрәме соң әллә бу баһадирның?» дип уйлап алды ул. Староста тәмам дәфтәренә кадалып диярлек утыра. Баксаң, калгып киткән икән!

— Йокы төштемени, Сәләхиев?

Экскаваторчы сискәнеп башын күтәрде һәм, бер мәл күзләрен әлҗемөлҗе китереп торгач, уңайсызланып җавап кайтарды:

— Ике смена рәттән эшләгән сиздерә, Рәйхан Кәримовна,— диде

ул.— Гафу итегез. Күп йоклаган — аз белер, ди. Мәсьәләне кузгаткалап карыйк әле...

Рәйхан өчен яңалык түгел инде мондый хәлләр. Эшләп укучыларны аңлый ул, ансат түгел аларга. Көз башында тагын бер хәл әле, көннәр жылы, һава әйбәт. Кышын көнозын суыкта эшләгәч, мәктәпкә килеп утыручыларга бик читен. Жылы класста изрәп кенә төшәләр. Шулай йокы-ял хисабынарак алгангадыр, белемнең дә кадерен белүчән булалар. Житди карыйлар... Яфиз булып Яфиз тәртә арасына керер төсле күренә ич әнә.

Бүген кәефе әйбәт иде Яфизның. Геометрия тикле геометриядән «дүртле» чиертсен әле. Бер дүртле генә дә түгел, рус теленнән беренче диктант та «өчле»гә бәяләнеп кайтты.

Мәктәптән чыгуга, парадный ишектән ерак та китмәделәр, староста белән янәшә атлаганда, Яфиз тәмәке көйрәтеп жибәрде. Экскаваторчы егетнең Яфизга салып карыйсы сүзе бар иде.

— Син Григорий Прохорович бригадасыннанмы? Самородкиннан, әйеме? Яфиз дигәч, бер дә ис китмәгән иде, беткәнмени дөньяда Яшкалар! Тик әле Сәмитов дип фамилияне кабатлый торгач, хәтерләдем. Штанга буенча мастерлыкка кандидат синме инде ул?

— Нинди кандидат? Син нәрсә, азрак чалышайдыңмы әллә? Кем әйтте сиңа мондый тарихи яңалыкны? Кайсының теле кычыта?..

— Маташтырма, Яшка. Мин үзем дә штангист, но мастерлыкка ерак әле миңа. Нинди үлчәүдә син? Жиңелдәме, иң жиңелдәме?

Яфизның ачуы чыга язды.

— Кара әле, староста, миемне тугылап маташма, яме? Минем гомеремдә дә андый тимер-томыр күтәреп караганым юк. Капчык ташыганым бар. Он капчыкларын да, цементныкын да. Ящик ташыганым да бар...

Староста да буш сүз һәвәскәре түгел иде, тешләгән жиреннән өзмәк булды.

— Сине мактар өчен үзем уйлап чыгарган хәбәр түгел, Яшка. Күпмегә алсам, шуңа сатам да... Мин бу сүзне кадрлар начальнигы иптәш Чукайлоның үз авызыннан ишеттем. Горькийдан килгән егет, ди, Самородкин үз бригадасына өйрәнчек итеп алыр өчен жан талашты, ди. Барыгызның да борынына чиртер әле менә, күреп торырсыз, ди. Шулай булгач, синме ул мастерлыкка кандидат, әллә бүтән Сәмитовмы?

Яфиз хәзер генә аңлап алды. Димәк, Григорий Прохорович бригадага алырга дип жан атканда, буяуларны куертып, начальникның башын катырганда әйтеп салган инде ул моны... Күңеленә шул уй килү белән, Яфиз көлеп жибәрде.

— Миф бу, староста, миф! Дөрес хәбәр түгел. Изге ялган койрыгы, мин сиңа әйтим.

Староста барыбер берни дә аңламады.

— Кит әле, тагын нинди изге ялган уйлап чыгардың? Ялган булгач, изге буламыни инде ул, дивана!

Яфиз һәммәсен рәте-чираты белән аңлатып бирде. Аннан соң да старостаның сүзе бетмәгән булып чыкты.

— Гайбәтең киткән, инде гадәтеңә кереп китсен. Пәр әйдә штанга секциясенә. Башлап жибәрик әле. Мәктәптән спорт залында шөгыльләнергә мөмкин. Монда физрук — во кеше! — Староста уң кулының баш бармагын тырпайтты.— Егетләрне генә жый. Барысын эшлибез, ди.

— Көчкә килмәсме икән соң миңа? Эшлә дә, укы да, тимер дә күтәр! Ай-һай, парень, ерып чыга алмам мин аны...

Староста сүзен бирмәс кеше булып чыкты.

— Спортның кайчан эшкә яисә укуга комачау иткәне бар, я, әйт,— дип, классташын үгетли башлады.

Яфиз ризалашты. Кайтырга кузгалдылар. Сәмитов тагын папирос кабызган иде, куерып барган караңгылык эченнән каршыларына Вәдүт килеп чыкты.

— Исәннәрме, егетләр! Дәресләр беттеме?

— Исәнмесез!

— Исәнме, абый! — Яфиз сәламне алды алуын, тик койрыгы пешкән мәче хәлендә калды. Алай итте, болай итте, сиздермәскә тырышып, папиросын аяк астына салды.

— Миннән яхшы түгел дип кенә яшерә-яшерә тартырга итәсең әле һаман, Яфиз, ә? Син шуны аңла, зыяны үзеңә ләбаса, туган!

Староста шуны гына көткән идемени!

— Мин дә әйтим дип тора идем әле. Без аның белән штанга секциясенә язылырга булдык. Спортчыга тәмәке тартырга ярамый...

Яфиз үзен җайсыз тоя, тик бирешәсе килми иде. Абыйсының да, экскаваторчы егетнең дә хак әйтүләрен аңлый ул, тик, кеше үгете үтсыта дигән бер исәр кебек, чигенәсе килми иде.

— Агитаторларга мохтаҗлык юк безнең заманда! — дип, сүзне уенга борды. — Лекция тыңладык, уйланырбыз...

Алар кайтып киттеләр. Вәдүт мәктәпкә керде.

Рәйхан белән Вәдүт култыклашып кайтырга кузгалганда, күктә яшь ай урагы чалкан ята иде инде. Аяк астының пычраклыгына исең китмәсә, төн менә дигән булып шәһәр өстенә күгелҗем бөркәнчеген япкан иде. Кайдадыр еракта, заводлар корылган мәйданда, мотор гөрелтесе тынмый, тимер юл тармагындагы дежур паровоз өзек-өзек гудоклар белән нидер сөйли, төзелеш краннары башындагы электр лампалары, караңгылык диңгезендә йөзгән төн кошлары сыман, әле бер якка, әле икенче тарафка салмак кына хәрәкәтләнәләр иде.

Рәйхан Вәдүткә елышып атлады. Каршы алырга килгәне өчен дә, хәлләрен сорашуы, кәефен белешүе өчен дә һәм бер сәбәпсез — бары тик үзенең сөеклесе, ире булганы өчен дә Рәйхан күңелендә аңа олы рәхмәт хисе ургый иде. Тик аны сүзләр белән әйтеп булмастыр кебек. Әйтеп булса да, телләнеп әйтмәскә кирәктер шикелле. Иң зарур, иң төгәл сүзе табылмаса, ул тойгы вакланыр, төссезләнер сыман...

Дәрестән чыккан укытучылар бер Рәйханга, бер Вәдүткә карап куйдылар бугай. Һәрхәлдә, Рәйхан шулай аңлады. Карасыннар шул, күрсеннәр! Аның Вәдүте менә дигән, андыйларны эзләргә кирәк әле!

Төн кочагында янәшә атлау бәхетен дә әлегәчә татымаган бер ләззәт белән тойды ул. Уз урамнарына борылгач, үтә-сүтә йөрүчеләр, каршыга килүчеләр кимеп калды. Берәү дә диярлек очрамады аларга, ә Рәйхан үзен шундый горур һәм нәзакәтле тотып атлады, әйтерсең лә адым саен дистәләрчә кешеләр аңа карап калалар иде...

Самовар кайнаган, әмма сүнгән, суынган иде инде. Саулыгыннан зарланып йөргән әнкәсен борчымаска уйлап, кичке чәйне Рәйхан үзе хәстәрлисе итте. Күлмәк алмаштырып, алъяпкыч бәйләп җибәрде, инде йоклап киткән Айдарның бит очыннан үбеп килде.

Рәйханның дулкынланырга, куанырга, шул ук вакытта уйланырга да тулы нигезе бар иде. Ул бу кичтә Шәйхаттаровлар гаиләсенең озакламый тагын да ишәячәген әйтте.

## IX

Сентябрьнең икенче яртысы житте. Яшьләр — эштә, Морзахан абзый умарталарын совхозга сату белән әвәрәләнеп, авыл белән район үзәге арасына тузан тәшерми йөрде. Ике ут арасында иде ул. Кортларыннан аерыласы да килми, аерылмый хәле дә юк. Зөһрәбану түти белән Айдар гына өйдә.

Капканы хат ташучы кыз дөбердәтте.

— Үлешле инде шушы бозау хәтле этегез белән! — диде ул, ачуы чыгып.— Аяк атлап керермен димә, валлаһи... Хат бар иде сезгә...

— Этне өрер өчен тоталар, үскәнем, өрер өчен. Бүген килдеңме әллә бу дөньяга?

Зөһрәбану түти конвертны дорфа гына тартып алып, капканы шапылдатып япмакчы иде, кыз аны җиңенән тартып туктатты.

— Мәшәкатьле хат бу, заказной. Тапшырганлыгыма кул куйдырып алып кайтырга тиеш мин. Менә карандаш, сырла шунда подписенне...

Хат ташучы кыз чәнти бармак буе гына карандашының очын авызына кабып төкерекләде дә Зөһрәбану түтигә сузды.

— Сал тамгаңны!

Тиз генә борылып керү ягын караган Зөһрәбану түти, кыз чәнечкеле-төртмәле кылана башлагач, киресенчә, бөтенләй ашыкмас булды, салмакланып калды.

— Ашыкма, үскәнем, ашыкма. Газиз әнкәңнән дә алай тиз тумагансың. Кай тирәгәрәк дисең әле? Мондамы? Алай... Бүтән чакта бүтән кешеләр белән сөйләшергә туры килсә, үскәнем, тамга дип, фәлән дип сайрама. Тамгалар заманы тау артында калган инде, үскәнем. Бездә хәзер халык грамотный... Менә шул...

Хат ташучы нидер әйтергә авызын ачкан иде, күз алдында капканы шартлатып япкач һәм эчтән ниндидер тимер бикне дә шудыртып куйгач, иреннәрен йомарга мәҗбүр булды.

Зөһрәбану түти, өйгә кергәч, хатны алай да әйләндерде, болай да борды. Тәрәзәгә, көн яктысына куеп үтәли дә карады. Бик калын булыр бу, әллә акчасы бармы, ходаның хикмәте, дип тә уйлап алды. Аннары, конверт тышына язылган хәрефләр өстеннән имән бармагының очын шудыра-шудыра укып китте.

«Шай-хат-таро-вой Рай-хан Ка-ри-мов-не».

— Киленгә икән ләбаса бу! — дип куйды азактан. Әйтерсең ләсинең үзенә дип биреп киткәннәр, тиктомалга үртәлә калды.— Кемнән булыр? Ниләр язалар икән? Төбендә берәр чатагы юкмы? Иблис койкысы белән язылган хат түгелме? Дөньяныкын белеп бетермәссең. Монда туган, Урайда яшәгән, Себердә кияүгә чыккан кеше бит ул килен дигәнебез. Кайда кеме булмас аның...

Түтинең күңелен вәсвәсәле кыбырсу, эчне тырнап куя торган тынгысызлык, сабырсызлык биләп алды.

— Хәерле генә кыл, ходаем! — дип укына башлады. Гүя аңа шомлы сүз ишеттерделәр!

Чоланга чыкты, тышкы ишекнең биген элеп керде. Арткы өйнең бакчага карап торган тәрәзәсе буена барып утырды. Бакчада бер генә җан иясе дә юклыгын анык белсә дә, тәрәзә пәрдәсен корып куйды. Аннары, малайны нәрсә беләндер юмалап бер читкә утыртты да, алласына тапшырып, симез конвертны ачты.

— Бәлеш! — диде үзе сизмәстән.— Капчык, капчык эчендә карчык дигәндәй, хат эчендә хат ич монда! Кәнбирт эчендә кәнбирт... Алла сакласын, ниткән хат булды бу, әй! Икесендә дә әдрисләре бар...

Беренче конверттан ук чыккан кәгазьгә татарча язылган иде. Ул кадәресен Зөһрә бану түти сукалап-тырмалап дигән шикелле ермачлап чыкты. Аңгармаган урыны калмады бугай.

«Рәйхан апа,— дип язылган иде анда.— Сиңа, Вәдүт абыйга һәм Айдарчикка күптин-күп итеп Урай сәламы юллыйм. Бәхет, уңыш телим. Исәнлек, таза сәламәтлек гомерлек юлдашларыгыз булсын!

Эшкә урнашкач та язган хатыгызны алган идем. Бик шатландым. Галәмәт тә зур төзелешле җирдә яшисез инде сез хәзер. Бәхетле булыгыз, тату яшәгез инде.

Үзем шунда ук эшлим. Мәктәптә әйтердәй үзгәрешләр юк. Синең урынга быел гына пединститут бетереп чыккан бер егетне җибәрделәр.

Моннан бер-ике көн генә элек Свердловскидан менә шушы хат килеп төште. Үзеңә җибәрәм.

Бүтән хәбәрләрем юк. Вакыт тапсаң, каршы яз. Сиңа иң матур теләкләр белән: Зәлифә».

Нигә икәнен аңлатуы кыен, әмма Зәлифә дигән хатын-кыз хаты Зөһрәбану түтинең ачуын кабартты.

— Иләкнекен чиләккә озата торучы бер бәндә инде бу! Арадашчы! — дигән фикердә иде ул.— Бер гөнаһың да гөнаһ, мең гөнаһың да гөнаһ. Монысын да ачыйм әле...

Эчтәге кечерәк конверттагы хат русча язылган, җитмәсә, язуы да кара савытында коенып чыккан чебен йөргән төслерәк. Кыскасы, Зөһрәбану түти кулыннан килә торган эш түгел иде моны укып аңлау. Укымый калырга да ярамый иде. Түтинең кыбырсуы шул дәрәҗәгә җитте, ул тирә-күршедә ярдәм кулы сузарлык кемнәр барын исәпли башлады. Каршы күршенең кызы укытучы кеше, керәшен Гәрдәлесендә укыта, тиздән илаһи-уптым күчерәсе авылда. Ну, аңа тел ачарга ярамый. Күпне белеп, туры Тукай булып йөри торган чәчби. Салиха Сабирасы шытырдатып укып бирер иде инде, сүз дә юк, аңа сүз кушарга гарьлек. Бер көннәрне поселоктагы гастрономда тиз-тиз генә конфет алыйм дип әрсезләнгәндә, чиратсыз үрмәләмә әле, Зөһрәбану түти, эшкә чыгып чабасың юк, дип каршы төшкәч, сүзгә килделәр.

Җәмилә Җәүһәриясенә суз кушып карасаң, ничегрәк барып чыгар? Таш кисәсе түгел, укып бирер. Тик теле теш артында тормый инде бер дә. Сертотмас үрдәк белән тиң. Таң атканын да көтмәс, Зөһрә карчык өйдәгеләрдән яшереп хат укытып йөри дип, бөтен Чаллыга хәбәр салыр.

Шулай үз урамнары буйлап өй борынча кеше эзләп барганда, кылт итеп бер уй килде. Гыйльменисада Байтирәк кызы тора бит, ашханәдә эшли. Өйдә булса, шуны гына дәшеп керим дә, укып бирсен әле шушы гөнаһ шомлыгы хатны...

Тырышкан таба инде, Байтирәк кызы укыды да, тәрҗемәләп тә бирде. Хат Раяга язылган (анысы Рәйхан инде, Рәйхан). Хатын-кыз язган. Свердловскидан. Рәйханның кияүгә чыкканын белми язган. Шулай аңлашыла. Тик хикмәт андамыни! Юкәдә икән чикләвек диярлеге аннары китә. «Ялгышып, буталып, инде килеп иң азакта үз гомерен үзе чикләгән туганым Вадим өчен әле дә булса күңелем әрни. Аның төсе булып якты дөнья йөзендә калган бердәнбер җан иясе — улы. Бик борчу дип санамасаң, мин, чираттагы ялымны алгач, сентябрь соңында яисә октябрь башында сезнең янга барып кайтыр идем. Айдарны бик күрәсем килә»,— дигән сүзләр бар иде хатта.

Зөһрәбануга шуннан артыгы кирәкми иде. Изге тамыры бар диярсең, эчендә бер шик йөртә иде ул йөртүен, ләкин белмәгәнен кемгә дә әйтә алмый иде бит. Менә инде хәзер барчасы ап-ачык. «Аталары кайтсын да, сакаллы сабыйның күзләрен ачыйм әле. «Шәйхаттаровлар нәселен дәвам итүче иң бәләкәй улым!» дип, җиде яттан, дип дошманыннан туган малайны сикертә икән бит ваемсыз карт... Менә белер моннан соң, Вәдүтнең дә кемлеген таныр. Килененең дә нинди кош икәнен белеп торыр...» — дип очынды.

Морзахан абзый, ишекне ныгытып ябып, чышын-пышын сөйләгән хәбәрне башта гел аңламый торды. Тырыша торгач, хатын төшендереп бирде үзенә. Хатларны да сузган иде, карт алмады.

— Кеше хатын ачып уку закон каршында зур хилаф икәнен белмисеңмени син? Кычкырып торган хилафе канун эш кылгансың. Ник тыкшындың яшьләр эшенә? Башың белән җавап бирәсеңне көт тә тор! — дип, Морзахан абзый зурдан купмакчы иде дә, Зөһрәбануның

илерә-котыра чәрелди башлавыннан, Айдарның беренче ирдән икәнлеге дөньяга фаш ителүеннән сагаеп, ачуын эчкә йотарга мәҗбүр булды.

— Ник кенә дип кеше ашына катык каттың икән син, тик тормас бәндә?! — ди-ди, кат-кат үрсәләнде ул.— Нигә кирәк иде гаиләдәге тынычлыкны җимерергә? Җаны теләгән — елан ите ашаган. Үзләре көн итсе. Әле, менәтерә, күгәрченнәр төсле гөрләшеп яшиләр иде...

— Күпләргә гөлдерәгән күгәрчен инде ул синең яшь киленең! Мине нәнкә итәргә ниятләгән идегез, әйеме? Шушы минутта соңгы сүземне әйтим: җилдән туган бала карап ятасым юк. Менә үзләре кайтсыннар да, бир хатларын, әйт сүзеңне!

Яшьләр хат килгәнгә дә, андагы хәбәрләргә дә аптырамады, билгеле. Алар өчен бернинди дә сер юк иде. Шулай да Зөһрәбану түтинең чама җуеп әрсезләнүе Вәдүтне чыгырыннан чыгара язды.

— Кем бирде сиңа мондый хокукны? — дип кычкырды ул әнкәсенә.— Ниткән башбаштаклык бу, әнкәй?

Зөһрәбануны дөрләтмә генә инде. Күзенә ак-кара күренмәде, үз гаебе турында уйлап та карамыйча, киленне битәрләргә кереште.

— Күңеле саф хатын баласын итәк астына яшереп чыкмый ул. Әйтеп чыга. Гавамнан да яшереп тормый. Ә сез, монда кайтып, ата-анагызга хәтле төп башына утыртмак булып йөрисез. Без капчыкта ятмый шул. Кырык елдан соң да беленә ул кыңгыр эш! Малаегызны теләсәгез кая куегыз, әйттем, шул менә: карамыйм. Бик кадерле булса, әнә аксак апасы баксын!

Җир газабы кичереп утырган Морзахан абзый теш кысып кына уздыра алмады. Урыныннан сикереп торды да, яшенә карата артык җитез хәрәкәтләнеп, Зөһрәбану каршысына килде.

— Өммегөлсем исеме белән авыз чайкыйсы булма! Бүтән ишетмим штубы! Бүгенге көнгә имин тормышыңны саклашып калган кеше ул. Өрмәгән җиргә дә утыртмыйсы иде аларны. Юк, тиешенчә булышып булмый, дөньяның һәр көнне бер мәшәкате чыгып тора. Айдарны үзем карашырмын. Сабыйга, нарасыйга кырын карарга бераүгә дә юл куеп тормам. Шуны аң бул. Ә хәзер һәммәбез үз урыннарыбызга таралыйк та бу тәмсезләнүләр булмады дип чутлыйк әле...

Морзахан абзый килен һәм улы белән кайнана арасында укмашып каткан бу бозны болай гына эремәсен дә, бөтенләй дә эремәү ихтималын да аңлап тора иде, югыйсә, ләкин бүгенгә башка чарасы юклыктан шулай диде.

Вәдүт чиктән тыш борчылган Рәйханны төне буе үгетләп, тынычландырып чыкты.

* * *

Атнасына ике ял көне дигәнең бик шәп нәрсә бит ул! Акча алгач, Яфиз Горькийга барып килде. Самолетта юл нәрсә!

Тулган айдай балкып, канатланып килде егет! Көне буе йөзеннән елмаю китмәде. Кичен тулай торакка Григорий Прохорович килгәндә дә кәефе әйбәт кенә түгел, бик әйбәт иде аның. Бригадирның ишек шакуына:

— Керегез, кер. Рәхим итегез! — дип кычкырды.

Самородкин, бүлмәдә кемнәр барын да тәгаен белмәстән, шаярып сөйләнә башлады.

— Пароль дә сорамыйча «мөмкин!» дисез, егетләр. Әгәр ишегегезне хатын-кыз җенесеннән берәрсе какса?..

Бүлмәдә өч кеше яшәсә дә, өченче иптәшләре юк иде. Григорян белән Яфиз Самородкинның нәрсәгә киная ташлаганын шундук аңлап алдылар. Вахтер өстәле янында ат башы кадәр хәрефләр белән «Бүтән

женестәге гражданнар тулай торакка кертелми» дигән белдерү язып эленгән, бригадирның шуны өнәмәве иде.

— Кызлар безнең янга комендантның мәете аша гына уза алырлар инде, Григорий Прохорович,— диде Яфиз.

Геворг аңа ялгап:

— Ә кешене берәү дә юк-бар өчен генә теге дөньяга озатырга теләми, понимаете,— дип куйды.— Шулай булгач, безнең этажга хатын-кыз кавымыннан булган җан иясенең менеп җитүе гамәлгә ашардай эш түгел...

Григорий Прохорович Яфизга гына төбәп әйтәсе итте:

— Лия килә калса, эшләр хөрти икән, алайса...

Ләкин Лияне Геворг Григорян әллә кайчаннан бирле ишетеп белә икән инде. Самородкинның авызыннан шул исем ишетелүгә, такылдарга ук кереште. Ул сөйләп кенә калмый, йөзе-чырае белән дә, аяк-куллары белән дә сүзләренә дәрт өстәргә тырыша иде.

— Панимаете, Лия килсә, Яшка җиденче кат күккә менеп тә гостиница табачак. Лия димәгән сулышы юк аның, иптәш бригадир. Шул кыз хәсрәтеннән сарыга гына түгел, җирәнгә сапты инде безнең бүлмәдәшебез...— Геворг рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Үз мәзәге үзенә ошый иде, ахры.

Яфиз да җавапсыз кала торганнардан түгел бит.

— Син менә, Сильвам, Сильвам ди торгач, кара күмергә әйләндең инде. Көл булып җилгә очасың гына калды. Җирәндә өмет бар әле, ул ялкынлап тора!

Егетләр чәй өлгерттеләр һәм бригадирны өстәл янына чакырдылар. Григорий Прохорович бик теләп, кинәнеп утырды табынга.

— Яле, Яша, чын татарча итеп куп-куе чәй яса әле миңа,— диде ул.— Беләсең бит: утәли Мәскәү күренеп торган чәйне мин чутка кертмим.

— Була ул, Григорий Прохорович!

— Грузин чәен татарча куе итеп ясап, Әрмәнстаннан килгән җимешләр белән эчегез әле, бригадир,— диде Геворг һәм абыйсы җибәргән күчтәнәчләрне почтадан алып кайткан әрҗәсе белән үк күтәреп килде.

Чәйдән соң телләр тагын да ачыла төшкәндәй булды. Григорий Прохорович егетләрнең буш вакытларны ничегрәк үткәрүләрен сораштырды, нәрсә укулары белән кызыксынды. Түрдәге киштәгә куелган дәреслекләрне һәм матур әдәбият китапларын караштыргалаганда, аның күзе былтыргы, ягъни житмешенче елны чыккан «Америка» журналына төште. Бу сан тулысынча Америка яшьләре тормышына багышланган иде.

— Карап туймассың! — диде Геворг, журналны мактап.— Кәгазе нинди, рәсемнәре! Ә кызлары бер кашык су белән йотарлык, иптәш бригадир! Кара әле, кара, дарагуй... Мин моны Ереваннан ук алып килгән идем...

Яфиз да бүлмәдәшенең фикерен куәтләгәндәй итте.

— Шәп бит, Григорий Прохорович? — диде ул.— Карамас җиреннән карарсың...

Самородкин журналны кулына алды һәм өстәл янына утырып актара башлады. Геворг, кош тоткан төсле, куанычлы кыяфәттә бригадирның артына килеп басты. Яфиз исә Григорий Прохоровичның янәшәсенә килеп утырды. Шәп рәсемнәр килеп чыккан саен егетләр тел шартлатып, авыз чапылдатып куйдылар.

— Әй-йе! — дип куйды Григорий Прохорович, журналны япкач.— Әйтерең бармы, шә-әп!

Шулай диде дә, башта Геворгка, аннары Яфизга карап алды.

— Кат-кат карыйсыз инде, ә? Кат-кат укыйсыз дамы? Тик бер нәр-

сэгә игътибар иткәнегез булдымы икән, егетләр? Менә ничә битле журнал, әмма бер генә урында да мин «Вьетнам» дигән сүзне күрмәдем. Юк, күрмәдем...

Инде егетләр бер-берсенә карашып алды.

— Чыннан да! — Яфиз маңгаена шап итеп сугып куйды.— Ничек искәрмәдек без шуны, әй!

— Кызык бу, әкәмәт кызык, дарагуй! — диде Геворг та.

— Шул-шул менә.— Григорий Прохорович журналны кулына тотып, нәрсәнедер тураклаган шикелле хәрәкәтләр ясап, сөйләп китте.— Елмаеп торган егетләр бар, чибәр-чибәр кызлар бар. Кием-салымнары шәп, алкалары, йөзекләре, беләзекләре әйбәт, машиналарда гына элдертәләр, табигатьнең сокландыгыч почмакларында ял итәләр, шәрабның бер дигәнен генә эчәләр... Оҗмах та оҗмах, боларның тормышы да оҗмах... Ә «Вьетнам» дигән сүз дә юк. Я, кайсыбыз белми, Америка яшьләрен генә түгел, бөтен дөньяны борчый бит бу проблема. Негрларны кыру хакында да ярты җөмлә дә юк. Чит илләрдәге хәрби базалар да телгә алынмый... Менә шулай ялтыравык кәгазьгә төреп тоттырмакчы алар безгә агуны!

Егетләр читенсенеп калдылар.

— Бу кадәресен уйлап та карамадык инде без,— диде Яфиз, гаепле кеше сыман.— Шәпме? Шәп! — дибез бит әле...

— Менә дарагуй! Мин әле мәктәпкә алып барып күрсәтмәкче идем,— дип өстәп куйды Геворг.

— Ипәшләр белән дә карарга мөмкин. Хикмәт анда түгел бит.— Григорий Прохорович сабырлана төште.— Хикмәт нинди күз белән карауда, егетләр. Кем сөйләвен, кем язуын белеп карарга кирәк.

Әңгәмә вакытында Григорий Прохорович күптән чамалап килгән, ләкин бүген аермачык булып алдына баскан бер бурычны төшенде. Аларга, утны-суны кичкән, хезмәт учагында чүкелеп чыккан кешеләргә, яшьләр арасында күбрәк булырга кирәк. Әлегә бу төзелештә өлкәннәрнең яшь буын белән бәйләнешы күбрәк производствога кагылган мәсьәләләр буенча гына. Тәҗрибәле агайларны һәм дәрте ташып торган, ләкин шул дәрткә дәва табып җиткерә белмәүче яшьләрне технологик җепләр бәйләми кала алмый, ә менә гаять нечкә, нәфис рухи җепләр бәйләнеше җитәрлек түгел дә түгел... Ярты мәңнән артык егетнең хезмәттән соңгы тормышын, тәрбиясен комендант белән тәрбияче җилкәсенә генә салып калдыру дөресмени соң инде? Тулай торакта яшәүчеләр һәммәсе янып торган яшьләр. Үзләреннән-үзләре эзли торган чаклары, дөньяны олы кешеләрчә ачып азапланган вакытлары. Шушы дәвердә тупланачак әхлакый капитал аларның бөтен киләчәген хәл кылуда битараф калмаячак ич...

Яфиз Григорий Прохоровичны озата чыкты. Урамда кызык бер күренеш: көн яктысы инде сүнгән, караңгылыкны чакырып, әңгер-меңгер назлана, киң урамның як-ягына сузаеп баскан металл баганалар башындагы электр утлары тирә-юньне нурга чумдырырга теләп, бар көчләренә тырышалар иде.

Гөлсем комендант булып эшли торган тулай торакка җитәрәк, Григорий Прохорович Вәдүт белән Рәйханны күреп алды.

— Әнә сезнекеләр дә килә. Шәйхаттаровлар. Карасана, урам тутырып киләләр. Кече Шәйхаттаровны да калдырмаганнар бу юлы,— диде.

Тегеләр дә Яфиз белән дустанә сөйләшеп килүче Григорий Прохоровичны күреп елмайдылар.

Тик алар эчендә нинди ут янганын әйтүе кыен иде.

Чаллы — Казан.
1972 ел.

## Роберт Әхмәтҗанов

# ГОМЕР УЧАГЫ

## Кыр атлары

Менә бара! — бер кайгысыз кеше:
башын кыңгыр салган!
Үз иркендә — чиксез киңлекләрдә
бүген ул югалган...
Тәгәрмәчләр бераз сыкрап бара,
күк чәчәктә — дегет.
Арба бара — офык артлы офык...
юлы чиксез кебек!..

Ат пошкыра: яшел арыш исе
керә танау ярып!
Кытыклана күзләр: «Яле, бәндәм,
кара бер тугарып,
Бер кайда да түгел,— шушы төштә! —
туктыйк, арылган гел...
Йөрелмәгән юлмы?! Син дә йокла
бишек-арбаңда бер.
Кыр тургаен тыңла: вәт кыңгырау! —
безнекеннән шәбрәк!..
Мин дә яшел дулкыннарда йөзеп
килим әле әзрәк!

Ат дигәч тә, шушы туфрактан бит
безнең нәсел-нәсәп!
Без беренче булып сөргән кырлар...
дөнья тарттык яшьнәп!..
Инде тимер көндәш йөри анда.
Килсен әйдә, килсен,—
Безнең азыкка дип килми бит ул!
Яратмыйм тик... исен!
Кырлар иркен! Бу кырларны хәзер
сөрә диләр атом.
Аңа карап һич тә чыкмас әле
«ат» дип яман атым!..»

# Ак поэма

Тәрәзә каршында
әни бәйли
сүтә-сүтә
кояш йомгагын.
Аннан керешә
айның көмеш йомгагына,
җепләрнең ул сайлап иң агын...

Инәләре — нурлар!

Ак өлгедән күзләп урамны,
бәйли —
бураннарда — кушып буранны!
кушып
кояштан килгән хәбәрләрне,
кушып — яшьлек истәлекләрен,
су буйларын,
җылы, якты көннәрен,
кошлар җырын,
яшел шавын
агачларның;

челләдә —
арыш сабаклары зеңләвен!

*

Ак инәсе белән
җеп күзенә
чалып ала җәйнең
карлыгачларын!..

*

Тәрәзәдән карый инде көз.
Ак инәңә, әни, ничә күз?
Инәләрең синең чалып ала
һаман бер сүз:
«Ана, түз!»
«Сагын, көт,—
ак инәңдә ничә күз —
шуның чаклы еллар тез!»

...Тезә ул...
(ана — түзә ул!)

...Инде кыш та...
ап-ак — тышта!

Кушып бәйли
ак карларның яктылыгын,
хыялларның алдагысын, көтелгәнен...
карый-карый
күкләр тәрәшендә
ап-ак йондай
тузгак карлар тетелгәнен...
кушып бәйли
кардан да ак өметләрен!

Бәйли әни.
Әни бәйли,
шулай
безнең тамырларны туган җиргә
ныграк бәйли!..

Ак өлге каршында
карый-карый
җилнең, песи кебек,
кыш йомгагы белән уйнавын...

Шулай
бәйли әни
айлар, еллар...
сүтә-сүтә
гомере йомгагын!..

●

Юк,
берни дә аермаган безне,
төнге ачык тәрәзәдән
ерак шәһәрләрнең тавышы килә,
ак йолдызлар яна җемелдәшеп,
әйтерсең лә
галәм ярына яккан учаклар!..

Юк, берни дә аермаган безне,—
бал исләре аңкып торган көзне,
алмагачның яшел итәгенә
яшереп башларын,
черем итә балалары,
бәгырь алмалары!..
Яфрак җыры иңли безнең араларны...

Юк, берни дә аермаган безне:
капламаган стеналар,
йолдыз астындагы этажлар...
юк, берни дә аермаган (без бит
шушы җир һәм
искән җилләр аша тоташлар!).

Чакрымнар аша искә алдың,—
рәхәт булып китте, җилкендем,
аякларым тоймый җирне!
Менә син оныттың,— күңелем буш,
ташлап чыккан
йорт шикелле!..

Юк, берни дә аермаган безне,—
кагыла бар да: иткән изгелегең
(хыянәтең булса — бигрәк тә!).
Тотам сине — синең кыска дулкын
бәгыремә кагыла, йөрәккә...

Юк, берни дә аермаган безне —
мәкер-ялган кабырчыкларына
әкәм-төкәм булып керсәк тә,
башны ашереп мендәр асларына,
аллы-гөлле төшләр күрсәк тә —
юк, берни дә аермаган безне...
Чынбарлыктан аермаган!..

●

Идел ага.
Кайсы култыктандыр
минем елгам килеп керә аңа
тын гына...

Язмышларны алып ага Идел!
Ярларында
сары моңдай сары ком гына.

Идел куенында агинешем —
өлешемә тигән көмешем!
Нәни елгам белә үзенең эшен —
агып ята якты көн өчен!
Ил дәрьясы — Идел өсләрендә
дулкыннары уйный көлешеп!..

Суларына ятып җыр тибрәнгән,
ярларында — учак утлары...
Кайсы борылыштадыр аваз бирә
бала чагым пароходлары!..

Идел куенында — агинеш мин,
офыклардан агып килешем.
Ак инеш мин Илем куенында,
туган туфрак моңы җырымда!

## Җил тегермәннәре

**1**

Күңелемдә сызылып бик еш кына
ага башлый тоных кына инеш...
Тау битенә яккан учаклар
мин кайтканны көтеп яна, имеш.

Баш очымнан, ак болытлар сыман,
еллар агыла, агыла еллар!..
...Су буенда — тургай көтүләре!
Кырда — томан:
вак яңгырлар, сары камыллар...

Су буенда тургай көтүләре
таудан-тауга оча, таудан-тауга...

Бу яңгырлы-җилле көзге таңда
ямансурак язны көтүләре!..

Су буенда тургай көтүләре
таудан-тауга оча — чыр да чу!
Күлмәк ябыша тәнгә... Мин — бер чәчәк!..
Көзге болыннарым — манма су!

Ә тегермән көзге яңгырларда,
гигант тургай төсле кагынып,
җилгә каршы тора! Камылларны,
көзне көтеп алган сагынып!..

Җил булмаса, безгә тегермәнче
сызгырырга кушты бергәләп.
И сызгырдык! Чыгыр әйләндердек,
салам чөйдек, җилне билгеләп!..

2

Агач коштай син талпындың озак
яңгырларда, карап еракка.
Очып киткән кошлар артыннан...
Тынып торды агач канатларың
алсуланып шәфәкъ-ялкында.

Талпындың син, агач күкрәгеңдә
дүрт йөрәктәй типте дүрт ташың!
Талпынасың! Очып китмисең тик...
Ятим итәрмен дип куркамсың
бу кырларны — дөнья уртасын?!.

Алтын көздә сине аяз күккә
чакырып очты биек аккошлар...
Очтың — җирдә! Вакыт буйлап очтың,
көздән очтың! Кичтең ак кышлар...
Очтың — җирдә! Очтың — заман буйлап!
Кар-яңгырлар кичеп — елларга!
Шушы кырда яңа чорга очтың,
җырга очтың! Легендаларга!
Сугыш янгыннары аша очтың,
какты сине афәт давылы...
Бар көчеңә — дүрт канатка очтың!
Калдырмадың ләкин авылны!..

Минем бабай уйлап тапкан сине,
мәңгелекнең бөек чыгырын!
Гомер двигателе! Якташларны
яздан көзгә имин чыгарып,

син... кузгалдың бер көн... Очып киттең!
Тарихыңны җиргә багышлап,
очтың җирдән... Сине якты җырына
ияртteләр бугай аккошлар!..

Безнең якның урманнары сагына,
иңри әле имән, өрәңге:
шул урманнан иде канатларың!
Сагына таулар: шуннан — йөрәгең...
Төштә күрәм: һаман әйләнәсең,
канат шәүләләрең — сукмакта...
Казык йолдыз яннарыннан кайчак
чыгыр тавышың килә колакка!
Алып менсен синең истәлекне
галәмнәргә очкан кораблар.
Төшләремдә күрәм: әйләнәләр
Ай җилендә синең канатлар!..

3

...Күңелемдә никтер бик еш кына
әйләнәләр агач тегермәннәр,
Җирнең канатлары шикелле,
талпыналар җирдән — күккә,
күктән — җиргә!

Шәүләләре — басу сукмагында,
шәүләләре — минем йөздә...
Әйләнәләр иске тегермәннәр —
күңелемдә...

Ерак көздә!..

## Борынгы нигездә

1

Көн каршында
җилләр укый
ташка уйган сүзләрне;
бер сүзе тора көй булып:
«нигезләрне, нигезләрне!..»

Печәне чабып алынган,—
буй-буй ята әрем-кура...
«нигезләрне, нигезләрне...»
һәр ташыннан хәлен сора!

...Тургай,
дога укыгандай,
ап-ак болыт каршысында
тибрәп тора,
тибрәп тора!..

2

Җирдә чиллә.
Агачларда
яшел алкыш тынган.
Юлда — тузан.
Корылыктан
карлыккан каргалар оча
баш очыннан...

Җәйге чиллә!
күләгәдә
актан киенгән карт
утыра гомер җебенең
очын-очка ялгап...
утыра төйнәлгәнен — чишеп,
чуалганын — сүтеп...
Җыена. Хәстәрле йөгән,
бөек сәфәр көтеп...

3

Күкләрем — җитен кырыдай,
арасында — көнбагыш!
Безнең дә болытлар белән
тарихка китеп барыш,
тарихка китеп барыш!

Мәңгелек бөек күкләрдән
китәбез төялешеп.
Китәбез төялешеп!
Каршылагыз яңаларны,
тормагыз сөялешеп лә,
тормагыз сөялешеп!

Серелгән кырларга инә
кояшның ярты ягы,
кояшның ялкын ягы!
...Алсу кырларда гомерем
бер җырга артты тагы да,
бер җырга артты тагы!

●

Гомернең бөек учагы
шартлап яна, яна кызып.
Шәү күмерләр ахәкланса,
Яшәү рәхәт, кызык!

Җылынырга була әле
ялкынына кулны сузып;
калгып кына, көн каршында
яна тотенсез ут!

Тамчылап утка төшә —
яна йөрәк шәмең сызып...
Учак яна... Кичелә бара
күренмәгән Сызык:

тып-тын гына баш очыннан
Кояш бара узып!

Гөлшәһидә

# МИНЕМ КАЛА АЛУЫМ

ПОВЕСТЬ

## 1



— Йә, булдыңмы, кызым? — диде эти.

— Булдым,— дидем мин.

Капка төбенә колхозның йөк машинасы килеп туктаган иде. Эти шофер янына кереп утырды. Мин машина ящигына күтәрелдем дә сарыклар янына чүмәштем. Сарыкларны заготскотка илтәләр, ә мин үз гомеремдә беренче мәртәбә калага барам.

Сыер-сарык рәсемнәре белән тулы чемоданымны, төшеп калмасын дип, култыгыма кыстым.

Машина, ачулы гөрелдәп, кузгалып китте.

Безне озата чыккан әнинең, кабинадан кубып, миңа кул болгаганын гына күреп калдым. Машина гөрелтесе аның ни әйткәнен ишеттермәде.

«Сау бул, Күлбай!» — дидем мин күңелемнән.

Йорт түбәләрендәге сыерчык оялары, тупыл очлары безнең яннан йөгереп уза башладылар.

Озакламый юл тузаны аларны да күмде.

Бәэлдәп кычкырган сарыклар, кулыма чытырдатып кыскан чемоданым белән мин япа-ялгызым торып калдым.

Безнең авылдан олы кешеләр байтак чыккан. Җәен, сабан туйлары вакытында, Күлбайга профессор Нурмөхәммәт абай [1] кайта. Ак чечүнчә костюмнан, көмеш язулы кәкре таякка таянып, Бояр урманына бара, инде биш-алты ел буылмый асраганлыктан төбе кара көйгән тегермән буасын карап йөри. Зират рәшәткәсенә таянып тора. Ике-өч көн буена шулай дәшми-тынмый йөри дә сүзсез генә китеп бара. Нәрсә ошамый икән соң аңар? Әгәр мин авылга аның шае олы кеше булып кайта

---

[1] Әгерже ягында абыйны «абай» дип сөйләшәләр. Автор.

алсаммы? И җуләр! Мин иптәш кызларым Сания белән Фәүзияне ияртеп дөньясын айкар идем. Юк, мин Кулбайны сүзсезлегем белән аптыратмас идем.

Безнең авылдан художник чыкмаган шул әле.

Машина Бояр урманына барып керде. Юл яңгырдан соң каешланып калган. Мине озатырга чыккан каеннар машина җиленнән җилфердәшә. Күңелне үкенү хисе биләп ала. Нишләп мин каеннарга күбрәк игътибар итмәдем икән? Алар әнә нинди аклар. Ничек йөгерешеп уйныйлар.

Шулай да безнең яклар каеннарыннан бигрәк карагайлы урманнары белән дан алган. Шишкин безнең як наратларын бөтен дөньяга таныткан. Без нарат урманнары уртасыннан бик озак бардык. Ачык кырга килеп чыккан чакларда да ерак-ерак зәңгәр урманнар миңа гел юлдаш булып тордылар.

— Син исәнме әле, кызым? — диде әти, машина Әгерҗенең тимер юл стансасына килеп туктагач.

— Исән,— дидем мин, чүмәшеп утырудан оешкан аякларымны язып, урыннмнан күтәрелдем.

Аннары без чират торып билет алдык.

Поезд әти белән мине урманнар аркылы таш калага алып китте. Безнең якның казылмалы юлларыннан сарыклар белән бергә дыңгырдап чапкан чакта миңа моңсу иде. Казан поездының тыныч вагонына кереп утыргач, бигрәк тә моңсу булып китте. Моны әти дә сизде.

— Нәрсә, кызым, ашап алабызмы? — диде, минем моңсу уйларымны таратырга теләп.

— Ю-уук, ашасы килмәй минем!

Безнең йортта төчеләнеп сөйләшү гадәте юк. Шуңадырмы — әти мине башкача кыстап тормады. Атналар буена урман эшендә йөреп ул бик арган иде, бераздан ул буш вагонның бер утыргычына сузылды да шундук йоклап та китте.

Мин тәрәзә каршысыча килеп бастым. Күз алдымнан тагын каеннар йөгерешә башлады. Алар Әгерҗе юлындагы, Бояр урманындагы каеннар белән кушылып, җемелдәп торган аксыл чуарлыкка әйләнделәр, сабакташ дусларымны, каз куып йөргән болыннарымны, каен җиләгенә барган кояшлы аланнарны искә төшерделәр.

Мин тавышсыз гына җылап алдым. Җылаудан туктый алмам да, вагонга станса саен күбрәк тула барган кешеләр миннән: «Җебегән кыз, Казанга барырга чыккан, таш калада яшәргә дип килә, ә үзе — әстагафирулла! — күз яшен дә тыя алмый, моннан нинди художник чыксын!» — дип көләрләр кебек тоелды. Тәрәзә буендагы почмакка сыенып, күземне йомдым.

Әкрен генә башымнан сыйпауга, күземне ачсам, каршымда әти басып тора:

— Тор, кызым, тор...

— Килеп тә җиттекмени?! — дидем мин, тәрәзәдән күренгән зур кызыл бинага карап. Аның түбәсенә кеше биеклеге хәрефләр белән «Казан» дип язылган иде.

Әти үзе белән Нурмөхәммәт абайларның йорт адресын алган икән, ләкин без аларның кай яктарак торганнарын белми идек. Адресны икәүләп кат-кат укыдык та умарта күче кебек мыж килеп торган кешеләрдән: «Новаторлар» урамын ничек табарга була?» — дип сораша башладык. Ун гына кешедән сорамаганбыздыр, берсе-бер белми.

Ак эшләпәле татар карты без күрсәткән адресны укыгач башын кырынрак салып уйланып торды да урам уртасында ташлап китәргә теләмичә:

— Ә сез машина белән барыгыз,— диде.

— Ю-уук! — дип авылча кырт кына кисмәкче идем, эти мине бүлдерде:

— Тик кенә тор!

— Әнә шунда чаттан борылгач та такси тукталышы бар,— диде ак эшләпәле бабай,— ул сезне, балакайлар, җаныгыз теләгән төшкә илтеп куяр.

Мин мәзәк итеп кеткелдәп куйдым. Әти дә балакай, мин дә балакай! Әти тагын коры гына:

— Тик тор! — диде.

Мине беренче мәртәбә көлүемнән тыйдылар. Миңа тагын моңсу булып китте. Этешә-төртешә шакмаклы машинага утырып китүчеләр янында чират торганда да, ярты сәгать буе таш йортлы урамнардан чапкан чакта да авыз ачып бер сүз дәшмәдем.

Нурмөхәммәт абайларга килеп кергәч кенә күңелем әзрәк бушанып алды; кара күн белән тышланган ишекнең уң ягындагы баян төймәсе кебек кенә ай төймәгә китереп басуга, кайдадыр еракта, урман эченнән килгән кебек кенә булып, кыңгырау зыңлаганы ишетелде, аннары ишек ачылды.

Бусага төбендә — Гөлҗиһан түтәй. Зәңгәр халатының изүен каптыра-каптыра, ул безгә төбәлеп карады да:

— Әнекәйгенәм! Вафа, син түгелме соң? — дип, ике кулын сузып, күрешергә килә башлады.

— Мин дә бар әле монда! — дидем мин, алга чәчрәп чыгып.

Гөлҗиһан түтәй шаккатты. Мине җилкәмнән кочып алып, башымны күкрәгенә кысты.

— Я рабби, урамда очрап, кыйнап китсә дә танымассың! Нәҗия апаем да шундый булдымы?! И дөньялар! Әтисе, әтисе дим! Карале, безгә кемнәр килде?!

Ул арада алгы бүлмәгә Нурмөхәммәт абай үзе дә килеп чыкты. Чал чәчле, күзлекле. Кара костюмнан.

— Нигә шулхәтле тавышланасыз? Ут чыккан мәллә? — дигән булды. Ләкин шундук битенә елмаю җәелде.

— Нәҗүк килгәнмени безгә? Әтисенә ияреп килгәнмени? Каяле, карыйк әле,— дип сөйләнә-сөйләнә, ул әти белән икебезне — ике «балакайны» берьюлы кочаклап алды.

Минем кадерле чемоданымны, юл капчыгын алгы бүлмәдә калдырып, түргә уздык. Юк икән әле, узмадык. Бөтен идәнне тутырып җәелгән затлы келәмгә басарга куркып эти белән икәү ишек төбендә туктап калдык. Әти хәтта аягындагы ак йон оекбашка карап куйды.

— Узыгыз, уз, тартынып тормагыз,— дип, Нурмөхәммәт абай тагын безнең янга килеп житте. Ул хәзер Кулбайның суы кипкән буалары тирәсендәге кебек сүзсез түгел иде, гөлдер-гөлдер килеп өзлексез сөйләнеп тора иде.

Гөлҗиһан түти чәй кайнатып, табын әзерләгәнче, ул безгә бүлмәләрен күрсәтеп йөрде. Аның үзе эшли торган кечерәк кенә бүлмә идәненнән түшәмгә хәтле китап белән тулган иде. Ал-ла! Безнең авыл китапханәсендә аның тикле китап бармы икән әле?

— Нишлисез бу хәтле китап белән? — дип сорады минем әти.

— Укыйбыз,— диде Нурмөхәммәт абай.

Аларның квартирында дүрт бүлмә бар, ләкин алар әллә ни зур бүлмәләр түгел. Кайсы китап белән, кайсы көзгедәй ялтырап торган кием шкафлары белән тулган иде.

Гөлҗиһан түтәй өстәл янында минем әни турында, авылдагы хәлләр турында сорашып утырды. Нурмөхәммәт абай авыл картларын сораш-

ты, янгырлар бармы? диде, буаны әле һаман бумаган килеш тоталармы? диде.
Әти уңайсызланып кына:
— Сарык фермасы салалар, халыкның вакыты юк,— диде, акланырга теләп. Моңарчы моңсу гына елмаеп утырган Нурмөхәммәт абый:
— Сарыкларга абзар кирәк, билгеле,— дип әкрен генә әйтеп куйды, ә үзенең чал чәчле башы кыегаеп, иреннәре турсаеп китте.
Аннары без сөйләшми генә чәй эчтек.
Чәй эчеп бетергәч, эш тә калмады.
Хәзер без нинди йомыш белән килүебезне әйтеп бирергә тиеш идек. Мин йөрәгем кубып чыгар дәрәҗәгә житеп, шул сүз башлануны көттем. Хәзер профессор абый минем рәсемнәрне карарга һәм чыраен сытып кына:
— Юк белән йөрисез,— дип әйтергә тиеш.
Әти сүзне авылча ерактан урап, профессорга юкә чөй кыстырып, баллап-шикәрләп әйтте:
— Безнең өчен, Нурмөхәммәт абый, бөтен Татарстанында синнән дә олырак кеше юк, әлбиттә. Үзең укымышлы, үзең авылдаш. Барыбыз бергә өстәл янына утырып бер киңәштек тә сина килүдән дә кулайракны тапмадык. Әйтсә Нурмөхәммәт абый әйтеп бирер, инде ул да: юк, апайлар, кысыр хәсрәт белән йөрмәгез, дип әйтеп әйтә торган булса, сала капчыкларын аркага асарбыз да беркемгә бер сүз әйтмиенчә кайтып та китәрбез.
— Яле, апайлар, тыңлап карыйк, нинди йомыш икән ул? — диде Нурмөхәммәт абый, кинәт житдиләнеп.
Мин инде атылып чыгып чемоданымны таратып ташларга әзер идем, әти әле һаман эшне суза бирде.
— Кызны укырга китердем бит әле мин, Нурмөхәммәт абый. Монда, әлбиттә, синең киңәштән башка берни дә кырып булмас, бәлки, ул синең дә кулыңнан килми торган эштер, әммәдәки, ни хәл итик, синең сүзең, синең бер киңәшең безнең өчен су кебек кирәк.
Бигрәк озак сөйли инде бу әти. «Әлбиттә», «әммәдәки», «бәлки», имеш. Өйдә шулай сөйләшсә, көлә-көлә эчебез катар иде инде безнең.
— Нажия... ничәнчене бетерде? — диде Нурмөхәммәт абый.
— Сигезне.
— Техникумга кертергә иттегезмени?
— Шулайрак иде шул.
— Кая?
Әти жавап бирмәде, миңа таба ым гына какты. Мин йомран житезлеге белән торып, бәләкәй чемоданны китердем, әти аны, иң затлы әйберне тоткандай, иплэп кенә ачты һәм менә... минем өч еллык хыялым профессор абыйга фаш булды.
Ул тагын да житдиләнә төште. Күзлеген маңгай өстенә күтәреп, минем ватман кәгазенә, дәфтәр кәгазенә, сары катыргыларга төшергән рәсемнәремне күздән үткәрә башлады. Мин йөрәгем өшеп төшәр дәрәжәгә житеп, аның хөкемен көттем.
Минем әти нинди сабыр кеше, ул булып ул түземсезләнеп:
— Ничек соң, Нурмөхәммәт абый? — диде.
— Рәсем училищесынамыни?..— диде, ниһаять, профессор, үзе көлемсери биреп минем бер рәсемгә карап тора башлады. Рәсемдә кызыл күлмәкле өч яшьлек кыз — минем сеңелем Руфия ясалган, ап-ак зур ата каз аның күлмәк итәгеннән каптырып алган да хәзер икәү жан-фәрманга тартышалар иде. Профессор абыйның минем рәсемнәргә бер сүз дә әйтми торуы, минем үлеп тә сүз ишетергә теләвем әнә шул рәсемдәге тартышны хәтерләтә иде. Профессор абый әти белән безне бик озак азаплаганнан соң:

— Ала-а-ай...— дип кенә куйды.

Минем язмышым тагын кыл өстендә асылынып калды.

— Нишләргә киңәш итәсез, Нурмөхәммәт абай? — диде эти.

— Сез, Вафа туган, Нажия белән икәүләп рәсем училищесына барып кайтыгыз, кабул итү комиссиясенә рәсемнәрегезне, документларыгызны күрсәтегез, калганын соңыннан сөйләшербез,— диде.

Рәсем училищесының гранит баскычларыннан әчкә ут йотып күтәрелдек. Ишекләрдәге язуларны укып йөри торгач, «Кабул итү комиссиясе» дигәнен дә эзләп таптык. Анда эш гадирәк булып чыкты. Минем язмышымны ике кеше хәл итте дә куйды.

Берсе — илле яшьләр чамасындагы түгәрәк йөзле, иреннәреннән елмаю китми торган бер апа. Гөлҗиһан түтәй кебек көйләп кенә, моңлы итеп кенә сөйләшә.

— Рәсем мәктәбендә укыдыгызмы?

— Ю-оук!! — дидем мин.

— Юк бит ул бездә, туганнар. Каян аласың аны. Булса кана...— дип өзгәләнә башлады эти.— Кызның теләге хәтәр дә зур инде. Әллә ниткән уку йортлары бар, югыйсә. Кәттәләре бар уку йортларының. Кермим ди бит!

Икенчесе — чәче җилкәсенә төшкән ир кеше — кәмит күргәндәй көлемсерәп миңа карап тора. Беләм мин аның нигә шулай караганын. Мин сирәк очрый торган экземпляр! Табигать миңа кап-кара чәч биргән дә аны ике толым итеп ак бантик белән үреп куйган. Маңгай астына ук зәп-зәңгәр ике күз төрткән. Алай да аз тоелган табигатькә: минем битемә учлап кара сипкел сипкән. Шуннан соң минем биттәге күз явыныы алырдай төсләрдән үзе үк куркып калган, күз тияр бит моңар дип уйлаган һәм... бармак очы белән минем борыныма китереп баскан. Чөенке борынлы, сипкелле, күк әчү ташы кебек зәңгәр күзле, шомырт кара чәчле кыз бу озын чәчле ирнең ушын алды, ул миннән күзләрен алмый карый, ләкин мин тоям, ул миңа җылы сүз әйтмәячәк.

— Нәрсәдер бер нәрсә борынлап килә монда, Фаина Ахметовна,— диде Озын чәч.— Нәрсә борынлаганын аермачык әйтү кыен. Әгәр без аны ышандырсак, юк, бу җинаять, аның әзерлеге юк, элементар белеме юк, аңа әзерлек узарга кирәк.

— Кайда?

— Рәсем мәктәбендә.

Эти кара коелды да төште. Ә мин үземне җиденче күк катында итеп сиздем. «Нәрсәдер борынлый». Күкәй эчендә чеби бар. Пи-пи-пип! Ура! Бу Озын чәч минем сәләтемне таныды. Ул, мөгаен, художниктыр! Юкса, аны монда рәсемнәр карарга кем куйсын иде.

Без Нурмөхәммәт абайларга кайттык. Минем күк әчү ташы күзләрем җемелди булыр. Кара ясмык сипкелләрем, тавык чебиләре кебек, битем буйлап таралып киткәндер — профессор абай мине күрүгә кояш кебек елмайды.

— Әллә борчак пештеме? — диде.

— Юк шул,— диде эти.

— Бар шул! — дидем мин.— Алар миннән берни дә чыкмый, димәделәр. Әзерлеге юк кына, диделәр.

— Әһә! — дип эләктереп алды Нурмөхәммәт абай.— Әзерлеге юк диделәрме? Бик хуп. Әзерлеген әзерләргә кирәк инде аның алай булгач.

— Ничек итеп? — диде эти, гаҗиз калып.— Бездә бит аның рәсем мәктәбе хәттаки Әгерҗесендә дә юк. Авылда берәр рәсем укытучысы, белемле укытучы булса икән. Мәктәптә пумаланы ничек буяуга манарга икәнен буяучы Гомәр өйрәтеп йөри бит.

Беразга тын калдык. Нурмөхәммәт абай чал чәчләрен сыпыргалап, күзлеген кул яулыгы белән сөрткәләп, бераз тик кенә утырды. Тик кенә

утырмады, уйланып утырды. Аннары ул Гөлҗиһан түтәйне чакырып китерде.

— Энисе,— диде,— сиңа сүзем бар,— диде.— Нәҗүкнең сәләтен таныганнар бит.

— Шулаймыни?! — дип, бите-башы белән елмайды Гөлҗиһан түтәй.— Шулай булыр дип уйлаганием аны. Күңелем үк сизенгән ие. И-и, апаем, алай булгач булды инде бу.

— Юк әле, булмады,— диде Нурмөхәммәт абай,— алай тиз генә булмый ул, энисе.— Нәҗүкне әзерләргә кирәк.

— Кая әзерләргә?

— Рәсем училищесына.

— Ничек итеп?

— Безнең малай укыган рәсем мәктәбе кирәк аңа.

Гөлҗиһан түтәй эшне аңлап алды.

Уллары Рөстәмнең инде дүрт-биш ел элек рәсем мәктәбендә йөргән чактагы рәсемнәрен алып килде, без аларны барыбыз җыйнаулашып бик озак карадык.

Аларның бәлки аңар бик әллә ни исләре дә китмәгәндер, әмма мин ул рәсемнәргә киләчәгемә карагандай карадым, миннән өч кенә яшькә олы малай нинди ләр оста китереп ясаган! Мәктәп диләр шул аны!

— Алай булгач, тәвәккәлләдек! — диде Гөлҗиһан түтәй,— Нәҗияне рәсем мәктәбенә илтеп бирик.

— Э фатир, ә яшәве? — диде әти.

— Үзебездә торыр,— диде Гөлҗиһан түтәй.— Авыл балалары — эштән курыкмаучан була, идәнемне юышыр, аш-суымны пешерешер.

Нурмөхәммәт абайдан без андый сүзне көткән идек, ник дисәң — ул безнең авылдаш, әмма шул сүзне Гөлҗиһан түтәй үзе башлап әйткәч, зерә дә рәхәт булып китте.

Рәсем мәктәбенә дә мине Гөлҗиһан түтәй үзе алып барды. Әти белән Нурмөхәммәт абай үз гәпләрен гәпләшеп калдылар. Бер генә дә белмәгәне юк икән бу Гөлҗиһан түтәйнең! Күгәрчен күк гөрли менә: кызны бик сәләтле дип әйткәннәр, әйбәт художник чыгар, дигәннәр, тик менә теге ни... сезнең мәктәптә берәр ел укысын, дигәннәр. Торыр урыны юк дип кайгыра күрмәгез, Нурмөхәммәт үзебездә тотарга булды, бәк тә тәртипле, бәк тә уңган бала...

Рәсем мәктәбе директоры Натягунин абай минем рәсемнәремне, җилгәргеч кебек, бармак очыннан гына уздырып, бер минут эчендә селтәп чыкты. Берсенә дә озаклап туктап тормады. Хәер, ул бер рәсемгә тукталды. Ихтыярсыз үзем дә рәсемгә төбәлдем һәм аркамнан кайнар су чымырдап йөгергәнен тойдым. Минем рәсемнәр арасына Рөстәмнең бер рәсеме ияреп килгән иде. Әгәр хәзер: «Монысын кем ясады?» — дип таптыра башласа... Таптырып кына калса бер хәл, алдашып йөрүчеләр кирәкми миңа дип, бөтенләй куып чыгарса... Йа ходай, рәхмәт төшкере, узды, дәшмәде, мине кызганды бугай. Шул минуттан башлап, озын буйлы, пеләш башлы бу кешене мин укытучым итеп таныдым.

— Ярар,— диде ул Гөлҗиһан түтәйгә,— сезнең хакка риза булам. Нурмөхәммәт Садриевич та, сез дә мәктәпнең йомышын кире какмадыгыз. Сентябрьнең беренче көнендә дәресләр башлана. Дәрес өчен кирәкле бар нәрсәне әзерләп килсен. Торуы сездән, өйрәнүе бездән. Тырышлыгы үзеннән,— диде.

Мин, тере тиен тоткандай, баскан җиремне тоймыйча, урамга атылып чыктым. Урамда кояш, урамда машиналар, урамда — умарта күче — кешеләр — болар барысы минем туганнарым, минем дусларым, миңа изгелек теләүчеләр.

Керүен керсәм, укыйм инде мин аны. Укымыйммы соң! Без ике көн буе Казан урамнарында йөреп, буяулар, пумалалар, төсле карандаш-

лар жыйдык. Күргән берсен ала торгач, алар минем бер чемодан булды. Мин шул тамаша байлыгым булуга сөенеп бетә алмадым. Тик Рөстәм минем барлык шатлыгымны алып ташлады. Без жыйган байлыкка ул мыскыл итеп кенә карап алды да:

— Не пойдет! — диде,— мин сиңа, Надюша, үзем табып бирермен.

Шул сүз белән тынычланып без өйгә кайтып киттек.



## 2

Минем әле бер генә мәртәбә дә вакытның шулай озак үткәнен тойганым юк иде. Сабакташ кызларым белән урманга жиләккә, балтырганга бару, бакча чүбе утау, бәрәңге төбенә өю, яшелчә бакчасына су сибү, атнага бер килә торган киноны карау, көтү куу, көтү каршылау белән жәйге ялларның узганы сизелми дә кала торган иде.

Быел әллә нишләдем. Иртә торсам, кичне житкерә алмыйм, кичкә керсәм, таң аттыра алмый аптырап бетәм. Жиде күл болынына олылар кичке уенга барганны карарга йөри торган идек, быел нигәдер анда да күңел тартмый.

Зөфәр, мактанчык, минем белән сигезне бетергән, ветеринар малае, жәен моторлы велосипед алып жибәргән. Элек тә бәйләнеп жаныма тия торган иде, ике көннең берендә, кич життеме — тәрәзә буена килеп туктый да моторын тырылдатырга тотына:

— Әй, кала кызы, әбиеңә сәлам, атаң-анаң кайтканчы чыгып кал, Салагыш болынынннан әйләндереп апкайтам.

Зөфәрне мин ике ел инде дус итеп йөрим. Ләкин бу юлы мин аңар сер бирмәскә булдым.

— Алдыңа кара, тырылдавыгыңны каула! Подумаешь, иске арба эләктергән дә әллә кем булган!

«Подумаешь»ны калада булып кайтканны күрсәтер өчен юри өстәп әйттем.

— Әй, кала кызы, назлы Нәжүк! Художник булам дигәч тә бик борыныңны чөймә! Жылап безнең янга кайтасың булмасын! Әбиеңә сәлам! — дип, Зөфәр-мактанчык мопедын тырылдатып китеп барды.

Чынлап торып үпкәләде, ахрысы, кара чутыр! Бер көн килми, ике көн килми, минем эч поша, эч поша, ичмасам, тизрәк Казанына барыр көне дә житми бит әле аның. Уты-ялы бер көн дигәндәй, барысына күл селтәп китеп барыр идең. Мәктәбенә бер кереп алсам, көне-төне рәсем ясар идем, күрсәтер идем мин ул Зөфәр-мактанчыкка күрмәгәнен! Шулай да күңелем тыныч түгел, рәсем мәктәбендә мине алырбыз, диделәр дә бит, әгәр ул тулып китсә, яки миннән дә өлгеррәк берәрсе минем урынны эләктереп куйса... күрерсең күрмәгәнеңне! Зөфәр-мактанчыкның авызы колагына житәр, борыныңны чөеп йөргән идең, синнән дә әллә кем чыкмады дип, тагын мыскыллый башлар.

Житсә тизрәк житсен иде инде сентябре дә.

Килсә килсен иде инде китәр көне.

Минем ашкынуым шул кадәр көчле булган булса кирәк, моны эти белән әни дә сизеп алдылар. Алар миңа башка еллардагыга караганда ягымлырак дәшәләр, тиң итеп сөйләшәләр, гомумән, мине уңай яктан гына сыпырырга тырышалар иде.

Бер килә башласа кеттереп тормый, китәр көн ул арада килеп тә житте. Әнкәй миңа урын-жир әйберләре әзерләде, мин еллар буе жыйган буяу пумалаларымны, картон кәгазьләремне ныгытып төреп, иске обой һәм синтетик клеенка белән чорнап, сүс киндерә белән бәйләп куйдым.

Мине бу юлы Казанга әни озата барырга булды. Әтинең урманда эше күп иде. Шулай да ул мин китәсе көнне эшеннән бүленеп кайтты һәм мине озаткан чагында, нечкәреп-нитеп тормыйча:

— Әйбәт укы, кызый, йөзгә кызыллык китерәсе булма,— диде.

Мин әтидән кече яшемнән үк шаян сүзгә өйрәнгән идем:

— Ә-әй, ел буе укып та керерлек булмасам, өйгә кайтып та тормыйм мин, Иделгә төшәм дә үләм! — дидем.

Әти минем «шуткыны» шундук эләктереп алды:

— Акча әрәм итеп, профессорны тинтерәтеп ел буе азапланып та йөрмә, алайса, баргач та төшеп куй суга,— диде.

Мин, олылар белән тиешле-тиешсез шаяртуның урынсыз икәнен абайлап алып, авызымны ачтым да күземне йомдым.

Казанда минем белән уен-муен сөйләшеп тормадылар. Шатырдатып бер рамкага китереп кыстылар. Чыдасаң чыда, чыдамасаң юк!

Рәсем мәктәбе укытучысы Натягунин абай мине беренче сентябрь көнне үз кабинетына чакырып алды.

— Әти-әниең бармы? — диде.

— Бар,— дидем.

— Сине бер ел туйдырырлык хәлләре бармы?

— Әти — урманчы, әни — укытучы.

— Квартир ягың ничек?

— Профессор Галикәев абайларга урнаштым.

— Бик шәп, Ханнанова. Нурмөхәммәт Садриевичның малае Рөстәм бездә рәсем мәктәбе бетерде. Сәләтле егет, мин әйтер идем, ифрат сәләтле, әмма ялкау. Сәләтле балаларның күбесе кебек, ялкау. Мин профессор белән сөйләшермен, Рөстәм синең өйдәге укытучың булыр, барлык эшеңне тикшереп барыр.

«Бик кирәге барые»,— дип уйладым мин эчемнән, әмма авыз ачып бер сүз дә әйтмәдем, баш селкеп риза икәнемне генә белдердем. Шуннан соң Натягунин абай минем башка вазифаларымны аңлатып бирде. Мин рәсем мәктәбен беренче класстан башлап түгел, өченче класстан башлап алып китәргә, баштагы ике классны шул ук Нурмөхәммәт абайның төпчек кызы Зөһрәдән өйрәнергә тиеш булып чыктым. «Ничек? — дидем мин гаҗәпләнеп.— Зөһрә бит әле быел бишенче класста гына укый, аның рәсем мәктәбенә барып та караганы юк бит». Натягунин абай анысын да гади генә аңлатып бирде: Галикәева, әгәр бик беләсен килсә, рәсем мәктәбенең беренче классына җәй көне гариза биргән һәм рәсемнәре белән конкурстан иң җиңел узучы булган икән.

Шулай итеп мин беренче-икенче классны үземнән өч яшькә кече Зөһрә белән, өченче-дүртенче классны үземнән өч яшькә олы, өстәвенә КИСИ студенты, хәрефләп таратып әйтсәң, Казанның инженер-төзүчеләр институты студенты, булачак архитектор Рөстәм Галикәев белән узарга тиеш булып чыктым.

Ярар, карап карыйк, дип әйтте ди сукыр, аксак ничек атлап китәр икән, дип әйтте ди. Бу сүзләрне кәефе шәп чакларда минем әти әйтергә ярата иде. Мин, әнә шул шаян сүзнең төбендә зур гына мәгънә ятканны аңлаган сыман булып, кала алырга тотындым.

Дөресен әйткәндә, кала алу миңа беренче көнне авыр газаптан башка берни дә китермәде.

Сигез малай, ике кыз рәсем дәресенә кереп утырдык. Малайлар рамга тарттырган кәгазь алып килгәннәр иде. Минем кулда андый кәгазьнең булмавы малайларда сәерсенү, минем үземдә уңайсызлану тудырды. Шулай да мин бирешмәскә булдым. Бер табак ватман кәгаземне алдыма җәеп салып, укытучының әмерен көтә башладым. Натягунин абай өстәлгә кызыл балчыктан мичтә кыздырып ясалган озын

муенлы сөт чүлмәге, аның янына жыерчыкланып торган кызыл бәрхет материя, материя өстенә пычак белән кабыгы юныла башлаган сап-сары шалкан куйды да эшнең тәртибен аңлатып чыгып китте.

Мин малайларга күз төшердем. Алар сөңге кебек озын, инә кебек очлы итеп юнган карандашларын бармак очы белән генә тотып, тиз-тиз сыза башладылар.

Имәнгә балта чабалармыни!

«Менә сиңа мәктәп узу!» дигән фикер яшен тизлеге белән күңелемнән узды.

Ә мин нишлим? Карандашны сындырып чыгарырлык итеп очлаган төшеннән кысып тотканмын. Минем рәсемем тоташ сызыклардан түгел, әбиләр йөгергән кебек, вак-вак юыртып барудан жыела. Шуңа күрә алардан профессиональ художник түгел, һәвәскәр художник хисе кала торгандыр. Әнә ни өчен Натягунин абай минем рәсемнәр янына эләккән Рөстәм Галикәев рәсеменә карап торды.

Минем кала алуым карандаш тота белүдән башланырга тиеш.

Һәм мин карандашны башка малайлар тоткан төсле, очламаган башыннан чеметеп тотып, әле генә үзем «юырттырып» чыккан чүлмәк рәсемен аркылы сызыклар белән юкка чыгарып ташладым.

Мин кече яшьтән китап укырга ярата идем. Келт итеп бер мәзәк исемә төште. Ходай тәгалә үзе бар иткән барлык җан иясеннән юлбарысны яратмаган һәм аны аркылы сызыклар белән сызып ташлаган. Мин үземне әнә шундый хәлдә итеп сиздем. Һәм гүя моңарчы ясаганнарымны сызып ташладым.

Натягунин абай безнең класска әйләнеп кергәндә мин әле һаман шул эш белән мәшгуль идем. Мин аның озын буе белән сәер генә мышнап артымда басып торганын тойдым һәм «яхшы!» дигән бер генә сүзен ишеттем. Шул сүздән сигез малайның сигезе дә шаркылдап көлеп җибәрделәр.

Натягунин абай аларны ни өчендер тыймады.

Ике сәгать узгач, дәрес бетте. Малайлар һәм бердәнбер кыз Светлана да кайтып китте. Мин укытучым янында беренче кинәшкә калдым. Сүзне ул мине мактаудан башлады. Син башлы кызый, нәрсәнең нәрсәгә кирәген аңлый аласың, мин синең белән эшләргә ризамын, диде. Керфек төпләремнең кымыржып, рәхәт җылынып торуын сиздем. Шуннан соң ул бүтән бер сүз дә әйтмәде, ике «подрамник» алып килде (укытучы авызыннан мин яңа сүзләр ишетә башладым), ике табак ватман алып килде, үзе ни эшләсә, миңа да шуны кабатларга кушты. Миңа ул Нажия дип дәшә белми, Надя дип әйтергә рөхсәт сорады, мин риза булдым.

Кәгазьне без подрамникка тарттырдык, сулап киптердек, ул типтигез булып тартылып калды, сәер ялтыравы бетте, карандаш та, буяу да тигез төшәрлек хәлгә килде.

Шуннан соң без Натягунин абай белән ике сәгать буена чүлмәк ясадык. Мин аның карандаш йөртүен үземә үрнәк итеп күчермәкче булдым. Ләкин минем алай әйбәт чыкмады. Чыкмавының сәбәбен укытучым һич иренми аңлатып барды.

Һәрнәрсәне художниклар бөтенгә һәм кисәккә бүлеп карыйлар да пропорция чыгаралар икән. Чүлмәкнең биеклеге һәм киңлеге, чүлмәкнең авызы һәм корсагы, чүлмәк үзе, аның янындагы шалкан, алар бербересенә мөнәсәбәттә нинди зурлыкта икәнен юл уңаенда аңлата барды, кәгазьгә сызыклар сызып, ул сызыклар арасында пропорция китереп чыгарды.

— Ә нигә художниклар сызыкларга бүлеп тормыйлар, карандашны тоталар да ясый да башлыйлар? — дип сорарга батырчылык иттем.

— Алар, Надя, пропорцияне, син хэреф ятлаган кебек, күнелдән ятлаганнар инде, күз чамасы дип атала ул.

«Күз чамасы» — глазомер. Әйбәт сүз. Хәзер мин карандаш тота белү өстенә әйберләрнең пропорциясен күз чамасы белән чамалап ала белергә тиешмен.

Чүлмәкне кәгазьгә төшергән чакта мин «фактура» дигән сүз отып алдым. Укытучым миңа пыяланың бер төрле, агачның бөтенләй икенче төрле, чүлмәкнең өченче төрле ялтыраганын, ягъни кояш нурын, яктылыкны аларның төрлечә чагылдырганын аңлатып бирде.

«Аһ, менә ни өчен минем чүлмәгем дөрес килеп чыкмый икән?!» — дип күңелемә беркетеп куйдым.

Калганын минем башым сыйдырырлык түгел иде инде. Укытучым мине өйгә кайтарып жибәрде. Шул ук көнне мин әти белән әнигә хат язып жибәрдем.

«Иске чүлмәкне ваттык. Яңасын ясыйсы бар!» — дидем.

3

Минем каладагы көннәрем берсеннән-берсе тыгызрак, мәшәкатьлерәк булып, тулып-ташып уза башлады. Мин иң әүвәл рәсем мәктәбенең китапханәсенә ташландым. С. Чуйковның «Башлап тотынучы художникка» дигән китабын табып алдым.

Татарча да андый китап эзләп караган идем — табып булмады. Якупов белән Фәттахов минем художник булып чыгуымны теләмиләр, ахры.

«Ярар, дидем мин, сукыр күреп торсын әле аксакның ничек йөргәнен». Бер утыруда башлап тотынучы художникның башына җиттем. Әллә Натягунин абый аңлатканнардан артык әйбер юк иде, әллә үзем аңлап җитмәдем, бу китап мине бигүк канәгатьләндермәде. Передвижниклар дип аталган унтугызынчы гасыр художниклары турындагы истәлекләрне табып, роман укыган кебек, йотып кына җибәрдем.

Киттем чыгып музейларга. Кремль янындагы музейга өч көн рәттән йөрдем. Аннары сынлы сәнгать музеена әйләнеп кайттым. Күңелдә берүк вакытта ашкынулы да, куркыныч та уйлар уянды. Күңелдә шик туды. Рәсем сәнгате бик олы, бик дәү, минем аңар гомердә дә көчем җитмәс кебек тоела башлады.

Әгәр мин гел шуларны гына уйлап йөрсәм, вәсвәсәләнеп тә бетәр идем, ярый әле, рәсем мәктәбе бар. Ярый әле, Натягунин абый бар. Алар мине янә дә урындыкка, озын муенлы чүлмәк белән йоп-йомры сары шалкан сурәтен ясарга утырттылар. Мин тагын үземнең артымдагы бакыр башлы Баринның миннән көлгәнен, аңар ияреп башкаларның хихылдашканын ишеттем.

«Ну, погоди, заяц!» — дидем мин, телевизордагы бүрене искә төшереп. Бу минем шәһәр культурасын сеңдерә баруым дип атала иде. Һәм мин моны үчлегеп, үҗәтләнеп әйттем. Моны әйтергә минем нигезем дә бар иде. Миннән шаркылдап көлеп утыручы бакыр баш Баринның әле сигезенчене бетерәсе бар, ел буе ул китаптан хәреф чүпләргә тиеш, ә мин инде сигезне бетергән, минем ике кулыма бер эш, рәсем ясау да музейга йөрү. Шулар янына мин урысны да сатып җибәрерлек итеп урысча өйрәнергә тиеш.

Мин бик үтенеп сорагач, профессор Нурмөхәммәт абый минем белән гел урысча гына сөйләшергә булды. Шулай да ул минем саф татарча сөйләшә белүемә кызыгып китеп, үзе дә татарча сөйләшә башлый иде.

Без вакыт-вакыт өчәү җыелабыз — Зөһрә, әтисе, мин. Нурмөхәммәт абай Зөһрә белән минем рәсемнәрне карый, я ирен кырые белән генә елмаеп утыра, я башын кырын салып уйга кала. Мактауга ул саран, без аның йөзенә карап кына рәсемебез ошыймы-юкмы икәнен чамалый идек. Нурмөхәммәт абай биология профессоры, ул бүгенге заманда иксезчиксез ачышлары булачак фән — биология дип саный, диңгезләр, океаннар дөньясына кереп китеп, сәгатьләр буена безне авызына каратып тота ала иде.

Ул Зөһрә белән миндә романтика дип аталган, хыяллана белү дөньясы уятты һәм безнең гыйльми фантастик китаплар белән мавыгып китүебезгә дә сәбәпче булды.

Үземне сыендырган бу семьяның төрле кешесе белән бик төрле мөнәсәбәт урнашты минем. Профессор абай миңа өмет баглый, сиздерми генә мине әйдәкләп бара. Гөлҗиһан түтәй белән без күбрәк кухняда очрашабыз. Бер җирдән бер квартир тапмастай бер вакытта үзләренә сыендырганнары өчен күңелемнән бик рәхмәт әйтеп, мин аның барлык эшләренә булышам. Атнага бер мәртәбә идәнне юып чыгарам, миннән күрмәкче Зөһрә дә шул эшне эшли. Иртәле-кичен, ашап-эчкәннән соң, мин, җиң сызганып, савыт-саба юып ташлыйм. Кранны борып җибәрү белән кайнар су агып тора торган квартирда савыт-саба юу уен гына бит ул! Зөһрә белән без рәсем мәктәбенә, музейга, киногa барабыз, берберебезгә рәсемнәребезне күрсәтешәбез. Болары һәрберсе үз нәүбәтендә гади генә бара.

Ә менә Рөстәм белән эшләр катлаулырак.

Рөстәм — әллә ниткән сәер егет. Ул минем калада барлыгымны, минем кала алырга махсус килүемне сизми. Ул гомумән мине танымый. Институтына китә, институтыннан кайта, аның янына, үзе төсле үк җилкә чокырына хәтле төшереп чәч үстергән берничә егет җыела, алар магнитофон ленталары әйләндерәләр, үзләре «такта» дип исем биргән бик матур һәм, әйтүләренә караганда, бик кыйбат гитара чиертәләр.

Нурмөхәммәт абай белән Гөлҗиһан түтәй эштән кайтыр чак җиткәч, «озын чәчлеләр» өйдән чыгып китәләр. Кайчан алар дәрес әзерлиләр, кайчан укырга вакыт табалар — һич белерлек түгел.

Шуларның барысы өстенә Рөстәм мине санга сукмый, бала-чага итеп, өстән карап сөйләшә. Төсе-бите, буе-сыны белән коеп куйган чибәр егет булса да, мин аны бакырбаш Бари белән янәшә куям. Әмма үземнең гел менә аңа омтылганымны сизәм, аның мәнсезлеге, мине танымавы күңелемне өшетеп гасабиландыра һәм мин: «Ну, погоди, заяц!» — дим.

Көнне куып төн килә. Таң атканны түземсезләнеп көтеп алам. Авылдан ук килгән гадәт. Әтәчләр кычкыра, көтүче быргысы уйный башладымы — авылда йокы юк.

Көтүне мин куа торган идем. Күршебез — балта остасы Гыйлфан абзый — мине күрә дә мыек астыннан гына елмаеп:

— Малайларым юк, үземә генә килен итеп алырыем шушы Вафаның Нәҗиясен,— дип, мине битләремә ут кабардай итеп кызарта иде.

Менә хәзер дә ул минем күз алдымда. Гөлҗиһан түтәй, Зөһрә һәм мин өчебез бер бүлмәдә йоклыйбыз. Дөресе — алар икәү сабый кебек изрәп йоклыйлар. Мин күзләремне ачып ятам. Эшлисе эшем дә юк кебек, йокым да килми, торып йөрергә дә уңайсызланам. Ни дисәң дә үз өең түгел. Песи-песи генә басып, ванныйга чыгам, шыпырт кына юынам. Казанга килгәч, Рөстәм белән бергә универмагтан барып алган этюдникымны күтәреп (Рөстәмнең миңа эшләгән бердәнбер яхшылыгы!) урамга чыгам.

Сары тәңкә белән күмелгән көзге агачлар минем күңелемдә әллә ниткән сагышлар уятып, тагын күршебез Гыйлфан абзыйны искә төше-

рәләр. Авылда чакта мине ут кебек кызарткан сүзләр хәзер әллә ниткән серле дә, якты-ягымлы да булып китә. Мин күңелемә Гыйлфан абзыйның мыеклы йөзен китерәм, рәсем мәктәбендә өйрәткәнчә, аны шакмакларга бүлеп, пропорция ясыйм һәм... әнә шул шакмаклар эчен каш-күз, авыз-борын белән тутырам һәм... үзем дә исем китеп туктап калам. Шакмаклар эченнән миңа мыеклы Гыйлфан абзый түгел, авылда мине үчекләп йөргән Зөфәр-мактанчык килеп чыга. Мин хәтта аның мопеды тырылдавын ишетәм, ул да булмый, такси машинасының сигналыннан читкә тайпылып калам.

«Болай иртә каян килгән такси бу?» — дип уйлап бетерергә дә өлгермим, таксидан шагыйрьләр чәче кебек зур кара бөдрә чәчле егет белән җилкәләренә көлтә булып сибелгән сары чәчле кыз төшә. Егетнең Рөстәм икәнен танып, аларга таба аркам белән борылам, ә үземнең аяк буыннарым хәлсезләнеп китә, йөрәгем беренче мәртәбә каты гына чәнчешеп куя.

Кызның чыркылдап көлгәне, Рөстәмнең аңа кушылып «го-го-го» килгәне ишетелә, мин шул көлүләрне ишетмәс өчен, этюднигымны кысып тотып, тимер юл платформасына таба тыр-тыр йөгерәм. Тимер юл каян килеп чыкты дисезме? Мин әйтмәдеммени әле: Нурмөхәммәт абыйлар Казанның иң матур бер почмагында яшиләр. Халык аны «Новаторлар урамы» дип түгел, «Куба» дип кенә йөртә. Моның хикмәте бар. Новаторлар урамы ул ярым утрау — ике ягында алма бакчалары шаулап үскән чокыр, өченче ягыннан тимер юл, аннан да ары Казанка елгасы ярып уза. Ярым утрау булгангамы — тимер юлчылар аны «Куба» дип яратып әйтәләр.

— «Кубада» яшим,— дип горурланалар.

— Безнең «Кубага» да килеп чык әле бер,— дип поездлар йөртүче дусларын кунакка чакыралар.

Беренче мәртәбә килеп төшкәч, ул минем дә исемне китәргән иде. Алма бакчаларын, тимер юлчыларның бик пөхтә итеп үстергән аллеяларын, бакча эчендәге зәңгәр-яшел-сары йортларын, авыл умарталыгына охшатып, шәһәрдә яшим, авылда торам дип сөенгән идем...

Тимер юл буендагы тау кырыена килеп утырам. Этюднигымны ачып куям. Сары толымнарын асылындырып уйга талган ялгыз каенны рәсемгә төшерә башлыйм. Художниклар телендә рәсем ясауны никтер язу дип йөртәләр. Якупов яңа картина язган, диләр. Башта бу миңа бик сәер тоелган иде. Инде ияләнеп киләм. Ихтимал, ясау дигәнгә караганда «язу» дип әйтү дөресрәктер. Кем әйтә менә бу каен кызын ясыйм дип. Язам мин аны. Кичен, мин мәктәптән кайткан чагында, ул башка агачлар фонында күзгә артык ташланмый йөргән, кечкенә уенга чыккан кызый кебек иде. Әйе, әйе, мин аны күңелемә шулай дип язып куйдым. Менә хәзер ул иптәшләреннән аерылып алга чыккан, иртәнге нурларда коена, үзенең дөньяда бар икәнен, күңелендә тойгы уянганын сизә, аның качып-посып түгел, бөтен матурлыгы белән күренеп йөрисе, күзгә ташланасы, бәхетле буласы килә. Мин аны күңелемә шулай дип язам. Мәктәптә алган төшенчәләрем килеп кушыла: непрерывность линий дип өйрәтә мине Натягунин абый, башта мин аны өзелми торган сызык дип үзем өчен гадиләштереп тәрҗемә итеп аңлаган идем, хәзер мин аны үзем өчен: бер сулыш белән язу дип аңладым. Шулай аңлау күңел күземне ачып җибәрде. Димәк, художник булу өчен әле рәсем ясый белү генә җитми, әйберләрне җанландыра, аларга мәгънә сала белү дә кирәк икән. Бер сулыш белән кабул итәргә кирәк икән аларны.

Бу минем өчен ачыш иде.

Мин, үземне, тирә-юнемне, артымда бер көтү җыелып торган малайларны бөлештермичә, каен кызын ясадым да ясадым. Буяуларны буташтырдым, буяуны мин су белән түгел, күңелемдәге тойгылар белән куш-

тым, каен кызы кәгазьгә төшә барган саен мине дулкынландыра, мин үземдә әллә ниткән бер җиңеллек, күтәренкелек тоям, әйтерсең миңа канатлар үскән һәм мин озакламый әнә шул канатларымда очып, әнә теге ерак урманнарга барып төшәрмен, урманнар артында тагын урманнар булыр, күлләр булыр, Кама, Иделләр булыр, минем туган якларым, минем сабакташларым булыр.

Алар мине сагындылар микән инде?

Әй сагындым да соң мин аларны!

Шаулап пассажир поезды узып китте. Кул болгадым. Вагоннарын санадым. Күзем төште: «Казан — Киров» поезды. Минем туган якларыма, Әгерҗе буйларына кайта.

— Сәлам әйтегез, вагоннар! Сәлам әйтегез, машинистлар! «Куба ярым атавында» яшәүче Нәҗия Ханнановадан сәлам әйтегез!



## 4

Минем тормышымда бар нәрсә үз җае белән бара хәзер. Көненә мин алты сәгать, сигез сәгать, ун сәгать рәсем ясый алам. Минем каен кызымны Натягунин абый мактады. «Тагын шундый берничә композициян булса, художество училищесы укытучыларына да күрсәтеп карарбыз»,— диде. Бер ай буена ул миннән өметләнеп яңа бер «каен кызы» көтте. Мин Казанка буендагы карт өянкене дә, яшен суккан имәнне дә язып карадым.

Башны кыңгыр сала Натягунин абый, дәшми.

Ул аптырауда. Ни өчен мин бер мәртәбә шәп итеп композиция ясадым да шуның артыннан ук шундый ук әйбәтне ясый алмыйм? Һе! Мин үзем дә аңламыйм аны, сизенәм генә.

Күрәсең, кешенең тормышында күтәрелеш минутлары була. Барысы бер төсле булып, елга суы төсле бер көйгә агып киткән көннәр арасыннан берсе, су өстенә сикереп чыккан көмеш чабактай, хәтердә торып кала.

Каен кызын ясаган көнем минем шундый иде.

Мин гадәти шуклыгымнан, тилемсәләнүемнән арынып, моңсуланып калдым. Үсмер кызый чорымның узуы, балигъ булу дигәннәре шушы микәнни инде?

Рөстәм бер айдан соң иртән, мин этюдникгымны күтәреп Казанка буена чыккан чакта, тагын сары чәчле кызы белән кайтты. Мин шул көнне үземнең автопортретымны яздым. Мин табигать биргән кыяфәтемнән туйганчы көлдем. Күзләремне шакмак чаклы итеп ясадым. Битемә борчак-борчак итеп бөрәм-бөрәм сипкел тезеп чыктым. Почык борынны бит уртасына тырпайтып куйдым да юка иреннәремә мыскыллы елмаю өстәдем. Бу минем Рөстәмнән үземчә үч алуым иде.

Натягунин абый миннән яңа бер «удача» таләп итеп алҗыткан заман иде, үземчә шаяртып автопортретны күрсәттем.

Укытучым авызын ачты да ябарга онытып шаккатты да калды. Күпмедер вакыт шулай карап торганнан соң:

— Здорово! Наденька, здорово! — диде, җилкәмнән кочып алды, тыр-тыр юыртып укытучылар бүлмәсенә кереп китте.

Минем кәефем бик яман иде ул көнне. Рөстәмнән үч алырга дип ясаган портретымның үз максатына ирешмәве минем мыскылчан-үчлекле булуымны арттыра төшкән иде. Шул мәлне кул астына бакырбаш Бари килеп эләкте. Үз артыннан бер дистә малай ияртеп, әле һаман миннән көләргә җай эзли, әмма минем класста хәтәр бер үҗәтлек белән эшләп барган эшләрем аңар көләрлек рәт бирми иде шул инде. Ә көләсе килә бакырбаш Баринең. Минем коридорга килеп чыгуым булды, бакырбаш Бари, иләк чаклы авызын ерып:

— Банан кила, Банан! — диде.

Минем Ханнанова дигән фамилиямне боза, янәсе!

Аның тирәсенә җыелган берничә малай мәзәк көтеп, көләргә әзерләнеп торалар иде.

Барлык ихтыяр көчемне җыеп, каршысына килдем дә, рус малайлары да аңласын дип, русчалатып ярып салдым:

— Ты что, влюбился что-ли в меня?!

Барием кып-кызыл булып кызарды, малайлар шаркылдап көлеп җибәрделәр.

Ә мин әйләнеп тә карамыйча мәктәптән чыгып киттем.

Өйдә мине күңелсезлек көтә иде. Дөресе — күңелсезлек миңа түгел, Нурмөхәммәт абайлар өенә килгән. Миңа ишек ачарга чыккан Гөлҗиһан түтәйнең күзләре яшьле иде.

— Нәрсә булды, түтәй? — дидем мин, куркынып кулларымны күкрәгемә кушырдым.

— И-и, апаем, әйтмә инде: Рөстәм институтын ташлап чыккан...

— Кит аннан! Нишләп? — дип кенә әйтә алдым.

— Кем белгән хәзерге яшьләрне, туклыктан сикерәләр, майларына чыдый алмыйлар, минем белән әтисе кебек, җир тырмашып белем алырга туры килсә, белерләр иде дә кадерен, юк шул, юк...— диде ул рәнҗегән тавыш белән.

Мин хатын-кызлар бүлмәсенә кереп киттем. Күрше бүлмәдә Гөлҗиһан түтәйнең күз яше белән Рөстәмне үгетләве ишетелеп торды, җан кыйнагыч, бер төсле тонык ялварудан соң Нурмөхәммәт абайның салмак калын тавышы ишетелде:

— Бетермә, әнисе, үзеңне. Һәркем үз ялгышы аркылы дөреслеккә килә. Берәр ел заводта эшләп карасын, күз күрер тагын,— диде.

Шуннан соң өйдә тынлык урнашты. Минем күңелем Гөлҗиһан түтәй яклы иде. Кызгандым мин аны. Рөстәмнең шулай кылануын аңламадым. Кешеләр институтка керергә тырышалар-тырмашалар, икешәр-өчәр ел рәттән имтихан бирәләр. Ә ул менә дигән итеп имтиханнарын тапшырып кергән, менә дигән итеп укып бара иде. Акылы юк икән. Төзелеш институты, булачак архитектор! Минем аркамнан чымырдап салкын су йөгереп төште. Әйтерсең мине художество училищесыннан куып чыгардылар.

Бер атна чамасы күңелсез генә яшәдек. Рөстәмгә соңга калып йөрүне тыйдылар. Хәер, ул үзе дә институттан чыкканнан соң төн урталарында яки таң алдыннан кайтуын ташлады. Ул бездән ерак түгел генә бер заводка слесарь булып урнашты, иртән эш сумкасын күтәреп китә, кичен шул ук сумканы күтәреп кайта. Аягында хәзер модельле туфли түгел, кирза итек, башында зур фуражка була, аның «шагыйрь чәчләре» хәзер сәер булып кепка астыннан бүселеп чыгып торалар.

Рәсем кануннары буенча кешенең гәүдәсе сигезгә бүленә. Башы аның сигездән бер өлешен тәшкил итә. Бу буй җиткән егетләрдә шулай. Малайларның башы алтыдан бер өлешен алып тора. Иң төгәл пропорция буй җиткән егетләрдә. Минем өчен төгәллекнең, матурлыкның үрнәге булып саналган Рөстәмнең башы, слесарь булып урнашкач, пропорциядән чыгып, кинәт зураеп китте. Нәфис-нәзакәтле архитектор егеттән ул хәзер зур кепкасы һәм кирза итекләре белән төптәй нык эшче егеткә охшап калды. Ләкин ул шушы хәлендә дә минем өчен кадерле иде. Элек ул минем өчен буй җитмәс бер биеклектә иде. Архитектор! Затлы кием. Электр гитарасы. Сары чәчле мадонна! Битниклар җырлый торган җырлар. Әйтерең бармы? Һо-һо-һо! Хәзер ул минем белән бер тигез дип әйтерлек. Ул кирза итек кия, мин — авылдан әни посылка итеп җибәргән кара киез итек. Ләкин шулай да уйлап карарга кирәк әле. Миңа тышкы кыяфәтемне үзгәртү кирәк түгелме? Озакламый мин пас-

порт алам, миңа уналты тула. Тырпаеп торган ике бантик нигә миңа? Кистереп ташлатабыз да ирләр прическасы ясыйбыз. Бу булдымы — бер. Яка төпләре кыршыла башлаган кышкы пальто киеп йөрим мин, шуның өстеннән мамык шәл (сусәрә башлаган шәл әле, житмәсә!) бәйләп йөрим. Әллә минем этиләр миңа затлы шапка гына алырдай кешеләр түгелме? Әллә ниткән салам сыйрак торна ботлар ялтыр лаклы гусар итекләре киеп йөриләр. Әллә минем эти белән әни миңа гусар итеге генә алып бирерлек түгелләрме? Ниемә дип калага килдем һәм кала алам дип сөйләнеп йөрим. Киез итекне салып атабыз, гусар итеге киеп жибәрәбез: гәүдә тартыла, корсак эчкә керә, түш алга чыга. Әллә-лә-лә-лә! Трал-ля-ля-ля! Шапканың биеген, ачыграк төслесен чәпәп куябыз башка. Аннан ары килеп иренне болай нечкә итеп йөртмибез, помада белән бантиклы-кып-кызыл ирен ясыйбыз. Менә шуннан соң Рөстәмнең күзе төшми карасын безгә! Мин үзем тудырган хыялыма канәгать булып, шаян-тылакыйлыгым ташып чыгып сикергәләп, атынгалап йөри башладым. Ярый әле, өйдә Зөһрәдән башка берәү дә юк иде. Зөһрә азартка бирелә белә торган нечкә табигатьле, кайнар тойгылы кыз! Ул минем кыланышларымнан эче катып көлә, ә мин тиле диган саен тиганәк буе арттырам. Шифоньердан Гөлжиһан түтәйнең тутый кош кауры кап-тырган эшләпәсен табып алдым, аякка кадак укчәле туфли эләктердем, беләккә ридикюль асып, билләрне боргалап киттем, мин сиңа әйтим!

Аннары Зөһрә белән кочаклаштык та күздән яшь чыкканчы көлдек, бер-беребезне бөтереп вальс әйләндек, музыка уйнаттык.

Гөлжиһан түтәй кайтканда арып хәлдән тайган, тынып калган идек. Ул безнең сәер тын булуыбызга маңгай астыннан гына карапкалды да кухня ягына кереп китте. Озакламый аннан кире чыкты. Хатын-кызлар бүлмәсенә керде. Нурмөхәммәт абай бүлмәсен урады. Күренеп тора: үзенә урын таба алмый, әйтер сүзе бар Гөлжиһан түтәйнең.

Ахырда түзмәде. Зөһрәне икмәк алып керү сылтавы белән кибеткә жибәрде дә, авыр сулап, яныма килеп утырды:

— И-и, апакаем, белдем бит мин тегене...— диде, астыртын эш йөртүче кебек пышылдап.

— Нәрсәне белдегез, Гөлжиһан түтәй?

— Рөстәмнең нигә институт ташлаганын белдем.

— Нигә?

— Теге сары чәче ташлаган икән бит аны.

— Кайсы? — дидем мин ашыгып, шулай чәчрәп тотынуыма үзем үк уңайсызланып калдым.

— Шул инде, таксиларга утыртып йөри иде бит. Әтисенә әйтмиенчә яшереп килдем. Шул гына житте улымның башына. Беләсенме, апаем, ул бит аңа сихерләнгән иде. Ә теге нишләгән диген?

— Нишләгән?

— Рөстәмнең иптәш егете белән Алтайга качкан.

— Кит аннан? — дидем гажәпләнеп, ә күңелемдә сөенеч канат какты.

Гөлжиһан түтәй әле һаман да сагышлы тавыш белән Алтайга качкан «Сары чәчне» сөйли иде, мин инде күңелемнән Рөстәмгә күренү-планнарын кора идем.

Ләкин минем планнарым комга корылган булып чыкты.

Әтиләр минем шәһәрчә киенү нияте белән акча сорап язган хатыма ике генә сүз белән: «Акча юк», дип жавап бирделәр. Әти берничә ел инде алты почмаклы яңа өй салырга йөри иде. Ниһаять, ул шул эшенә тотынган, димәк ки, бер тиен дә акча арттыра алмый.

Кече-кечедән мин борын салып йөри торган кыз түгел.

Үз кул көчем белән табарга булдым акчаны.

Минем белән бергә рәсем мәктәбендә укучы Светлананың әнисе — врач кеше. Светланага ияреп аларга барган чакта, зарланып әйтеп

куймасынмы? Аларга төнге дежурга вешалкага кеше кирәк икән. Айлыгы алтмыш сум. Бирәү белән дә киңәшеп тормадым, тоттым да кердем шул эшкә.

Төне буе вешалка саклыйм, авырулар янына керүчеләргә халат бирәм. Буш вакытларда кулда ватман да карандаш. Нянкаларның берәм-берәм рәсемнәрен ясап чыктым. Ошаталар, күләләр, үз итәләр, китте эшләр хутка! Бер ай эшләгән идем — шалт алтмыш тәңкә кулга. Сорочи базарына чыгып гусар итеген алып та кайттым. Парикмахерда ярты көн утырып ирләр прическасы ясаттым.

Гусар итеген киеп, ирләр прическасы ясалган башны текә тотып, ишектән чыгып бара идем, слесарь Рөстәмнең ике күзе ут булды. Сер бирмәдем, эре генә чыгып та киттем.

Икенче булып Нурмөхәммәт абайны өнсез иттем. Гөлҗиһан түтәйнең генә ушын алып булмады.

— И-и, балакаем, эрәм иткәнсең чәчеңне...— диде ул әкрен генә, сагышлы-тигез тавышы белән.

Бик ихлас күңелдән әйткәнгәме, Гөлҗиһан түтәйнең сүзләре күңелемне кузгатты. Әллә ничек менә шунда үземә-үзем кызганыч булып киттем. Итекләрне салып аттым да мендәргә капланып тавышсыз гына балавыз сыктым.

«Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың»,— дип әйтергә ярата минем әти. Шәһәрдә торгач шәһәрчә киенми хәлең юк, акча тотып итек алгач, аны чыгарып ташлап булмый, үземне-үзем мыскыллап көлсәм көләм, киям итекне!

Шулай да бик озак кия алмадым, атна-ун көн дигәндә аяктан салкын тидереп, тамагым шешеп, урын өстенә аудым.

Һәм шуңа сөендем.

Авырганда мине караучы кем булды диегез? Рөстәм. Рөстәм Галикәев! Ул больницадан врач чакырып китерде, рецептлар буенча дарулар алып кайтты. Миңа якын да килеп карамаган, мине бөтенләй танымаган егет башыма кулын куеп кайнарлыгымны үлчи. Элегрәк үлчәсә икән ул башымның кайнарлыгын! Хәзер мин кызганыч хәлдә! Ә минем кызганыч буласым килми, һәм мин аның ярдәменнән баш тартып, үземнең кызганыч хәлдә түгел икәнемне исбатларга азапланам.

Бу хәл Рөстәмдә миңа карата тагын мыскылчан караш тудыра. Ул авыру балаларга теләктәшлек белдергән тәҗрибәле врач кебегрәк көйле тавыш белән:

— Авыру Ханнанова, сезгә менә бу микстураны көненә өч мәртәбә йотарга кирәк. Кулланыр алдыннан болгатырга онытмагыз,— ди. Мин күңелемдә янә ачу кузгалганны сизәм. Бакырбаш Баридан үч алгандагы кебек, бауны бер чабуда өзеп чыгарырга теләп:

— Рөстәм Нурмухаметович! Әйтә алмассызмы, кешеләр нигә Алтайга качып китәләр икән? — дип сорыйм.

Рөстәм бер мәлгә югалып кала, ударның нык уйланып эшләнгәнен аңлагач кына, матур кара кашларын җыерып, аннан соң җиңүчән төстә елмаеп:

— О-о, җылан баласы! — ди һәм өйдән чыгып китә. Мин аны көне буе үз янымда күрмим, кич җиткәнче өйдә япа-ялгызым ятам, миндә теләгәнемә ирешә алырдай көч барлыгын сизеп, үземне-үзем дәвалый башлыйм.

Чәй содасы белән тамакны чайкарга кирәк. Бер чокыр җылы суга бер бал кашыгы сода. Ә мин аш кашыгы белән тондырам. Сода ачылыгы җаннарымны актарып китерсә дә, озаклап тамагымны чайкыйм да урыныма ятып йокы чакыра башлыйм.

Шаулап поезд килә. Мин поездга таба йөгерәм. Барып җитә алмыйм, поезд инде гудок бирә, аксыл төтеннәрен бөркеп пошкыра, мопеды

елән каяндыр Зөфәр килеп чыга, мине алдына утыртып, кузгалып иткән поезд артыннан йөгертә, поезд бездән ерагая бара, ерагая бара, ин борчылып дәшмәкче булам, поезд машинистына кычкырмакчы улам, тавышым чыкмый, мопедчы миңа таба борыла, минем башыма улын куя, мин аның Рөстәм икәнен күреп куркып калам. Ушымны җуя зам, ул да түгел, Рөстәм мине кулына күтәрә һәм шул көе «Куба» янын-агы урманлы таудан, Казанка елгасы өстеннән очып китә. Болытларга аба очабыз. Болытлар кып-кызыл. Минем битем, кулларым, бөтен әнем эсселектән яна. Янып үлүдән котым чыгып, ут суласп ятканда индидер салкын бер нәрсә башыма орына һәм мин куркынып күзлә-өмне ачам: Гөлҗиһан түтәй минем башыма салкын суга манган сөлге уеп маташа икән.

Мин аның теләктәшлек белдереп моңсу гына елмайган йөзен күрәм һәм шул елмаюдан җиңеләеп тагын күзләремне йомам...

## 5

Август, сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь. Биш ай Казанга килеп, ти-әнидән, сеңелем Руфиядән аерылып яшәвемә биш ай үтеп киткән. Рифкать абыйны искә алмыйм да инде, аның Минзәләдә педучилищеда укуына дүртенче ел; калганнарыбызның өстәл янына җыелып сөйләшә-сөйләшә чәй эчкән вакытларын зрә дә сагындым. Таң аттымы, без дүр-тәүләп тиз-тиз өй эшләрен карыйбыз да ишекне биклэп дүртебез дүрт якка китәбез. Әни мәктәпкә укытырга, Руфия белән мин күрше авылга укырга, эти велосипедына атланып урманга — лесничествога китеп бара. Кичен эти берәр агач кисәге, кәкрәеп-бөкрәеп торган тамыр алып кайта да чәй эчеп бетерәбез дигәндәрәк, өстәл яныннан кузгалганчы:

— Кызым, карале, менә бу тамыр берәр нәрсәгә охшамаганмы? Сиңа дип алып кайттым,— ди. Без дүртәүләп ул алып кайткан тамырны әйләндергәләп карый башлыйбыз, башта берни дә чыгарып булмый, аннан, әйләндергәли торгач, я сыңар аяклы торнага охшый, я шунда... Хәзер хәтерләмим инде барысын да; тик бер көнне Руфия өч җәпле кәкрерәк бер тамырны кулына алу белән: «Әти, бу Шәяхмәт бабай бит!» — дип кычкырып җибәрде, өстәлгә бастырып куюы булды, чыннан да, таякка таянган бөкрәйгән кешегә охшап калды...

Биш ай... Гөлҗиһан түтәй гусар итеге алып кигәнемне, чәчемне кис-тергәнне яратып бетермәгәнгәме — бер көнне эштән кайткач әйтте:

— Нәҗия, эшеңнән чык та укуыңны гына кара инде син, балакай,— диде.— Сиңа бит рәсем ясарга гына түгел, рус теленнән дә имтихан тотарга кирәк булыр.

Мин авырганымны әниләргә әйтеп тормадым. Декабрь беткәч, кани-кулга өйгә кайтып килермен дә эштән чыгармын, ә рәсем мәктәбенә өченче класс сменасына да, дүртенче класс сменасына да йөрермен дип уйладым.

Мин көз көне килгән генә көемә, училищега кереп китмәвемә сөенә идем. Берни белмәгән көенчә ничек укыган булыр идем, гел дә генә хәреф танымаган бала шикелле булганмын. Кулымда шул белер-белмәс ясаган рәсемнәремнән, училищега кабул итү хакындагы белдерүдән һәм сигезенче классны бетерү таныклыгыннан башка берни юк иде бит. Рәсемнән берни белмәгәнмен. Әлифбаны үтмичә уку китабына тотынган бала сыманрак булганмын икән. Менә нәрсәләр ачтым мин биш ай үтте дигәндәрәк.

Каникулда авылга кайтып өстәл янына җыелгач, сөйлим дисәң сүз-ләр бер олау җыелды. Кызык хәлләр дә булды. Сөйләми торганы, сөй-ләү түгел, әле үземнең дә белергә теләмәгәнем — Рөстәмне уйлавым иде.

Ә бөтен класс белән ду-у килеп көлешкән хәл менә болай булды. Гөлҗиһан түтәй мәче ярата икән. Ташкүмер кебек елкылдап торган кап-кара мәчеләре бар. Рөстәм дә, Зөһрә дә аны «Мурка, Мурка» дип кенә торалар. Гөлҗиһан түтәй Муркага дип я балык, я бавыр алып кайта. Муркасын Мурка да бит, тик шул Мурка ел саен өч-дүрт бала китерә, шуларны кая куярга белмиләр икән аннары. Ә инде Нурмөхәммәт абай алардан кая качып котылырга белмәгән шикелле тоелды миңа. Мин аларда торган чакта да Мурканың дүрт баласы бар иде. Берсен мин, Светлана сорагач, куеныма кыстырып рәсем мәктәбенә алып киттем. Светлана мәктәпкә соңгарак калып килде. Дәрес башланды инде, этюдникларыбыз янына утырдык — Светлана юк. Пумала манарга дип әзерләгән сулы савытларыбызны этюдник янына куеп эшкә башладык дигәндә генә, мәче баласы куенымнан чыгып качты. Кирәгемне бирә укытучы, дип, котым очып торганда, Наталья Карповна: — Ой, какой хорошенький котеночек! Кис, кис, кис! — дип, песи баласын тотарга иелде. Тоттырамы соң ул алай гына! Чапты китте урындыклар астына.— «Вот тут!» — «Нет, вот он где!» — дия-дия, барлык укучы песи баласын тота башлады. Этюдниклар ауды, сулар түгелде. Ахырда бер малай тотып укытучы кулына бирде. Гөлҗиһан түтәй генә сәер кеше түгел, безнең Наталья Карповна да песи ярата икән, мине ачуланып та карамады. Өйдә әле тагын өч песи баласы бар. Төне буе чабышалар, диваннарны тырнап, ертып бетерәләр. Нурмөхәммәт абайны кызгандым. Өчесен дә рюкзакка тотып салдым да илттем дә бирдем ветлечебницага. Рөстәм шуны белгәч: — Вот, дает! — диде. Ул да ярата иде бит песи балаларын. Мин аның алдында тагын юньсез кеше булып калдым. Кызык-кызганыч хәлләрнең берсе менә шул иде инде. Әтигә сөйләсәң:

— Әллә сезнең бүтән эшегез юкмы? — дияр иде.

...Казан — Киров поездына утырып авылга кайттым. Арча, Кукмара, Можга стансаларын мин икенче тапкыр күреп үтәм. Җир өсте ап-ак, дулкын-дулкын булып кар ята. Каен урманнары төтен сыман сизелерсизелмәс кенә булып калган. Нинди буяуларны, нинди төсләрне бергә кушып чыгарып була икән шушы төтен сыман күксел-зәңгәрсу төсне? Әз генә кызгылт сыман да әле ул. Ә чыршылар чиксез аклык белән янәшәдә кап-кара күренә икән. Тәрәзәдән күземне алмый алты сәгать буе карап кайттым. Әгерҗегә колхоздан трактор килгән иде, шуңа утырып күрше авылга, аннан тәпи-тәпи үзебезнең Күлбайга кайттым. Кар шыгырдаганын сагынганмын. Баскан саен шундый рәхәт итеп, үз итеп шыгырдый кар!

Безнекеләр өйдә иде. Яңа ел алды бит!

— Сорап кайттыңмы? — диде әти күрешеп бетүгә.

— Алдан җибәрделәр. Җиз комган, бер кием чабата алып килергә куштылар,— дидем мин.

— Чабата калыбы белән шөшлесе дә кирәк түгелме? — диде әти.

Ул безнең шундый инде — әллә чынлап, әллә уйнап әйтә, аныкын аңламассың.

## 6

Чыннан да мин авырганымны энеләргә әйтмәдем. Аларны борчыйсым килмәде. Шулай да авылга кайтып килгәч, хәлемнең бигүк шәп түгеллеген үзем генә белеп йөрдем. Гәүдәм минем сау-сәламәт, рухым сәламәт түгел иде. Рөстәмгә карата кылган дорфалыгым мине бик үкендерә, шуңа күрәдер инде мин гадәттәгечә шат күңелле, мыскылчан табигатьле Нәҗүктән сөмсерләре коелган, башын муенына тыгып йөри торган Нәҗия балакайга әйләнеп бара идем. Дөньяда бар нәрсәдән

өстен күргән, минем яшәү дөньям булган рәсемнән дә күңелем сүрелеп бара һәм бу мине куркыта иде.

Мине бу халәтемнән Казанга килгән бер күргәзмә коткарды. Бу — унҗиде яшендә һәлак булган художник кыз Надя Рушева күргәзмәсе иде.

Газетадан шул хакта укуга мин Сынлы сәнгать музеена чаптым.

Музейда әле минем беркайчан да шул хәтле күп кеше һәм шул хәтле дә зур тынлык күргәнем юк иде. Иөзләгән кешенең, гүя сүз куешкандай, барысы берьюлы тын калулары үзе үк рухи бер халәт тудыра һәм сине нииндидер зур бер нәрсәне кабул итәргә әзерли. Күргәзмәнең башланган өлешен күрсәткән зур кара укка буйсынып, эчке бүлмәгә уздым. Анда унике яшьлек Надяның рәсемнәре куелган. Мин үзем өчен шундук бер нәрсәне ачыкладым. Надя унике яшендә чагында рәсемнәрен миннән артык ясый алмаган. Бу хәл миңа үземә-үзем ышанырга ирек бирә. Шул ук вакытта Надя Рушеваның исеме мине дулкынландыра. Без адашлар булып чыктык.

Надя Рушеваның укытучысы, киңәш биреп торучысы академик Ватагин булган. Айга бер мәртәбә ул аның янына калын бер папка күтәреп килгән. Укытучың академик булу — уен эш түгел, әлбәттә! Ләкин үзең тырышмасаң — юк. Натягунин кул астында мин инде ярты ел эшлим. «Аксакның атлап киткәнен сукыр карап торыр» дәрәҗәдән котылдым. Акварель белән эшли беләм. Фломастер да минем кулга буйсына. Ә менә темпера, монотипия, офорт дигән төшенчәләрне мин әле китаплардан укып кына белә идем. Тотынырга, тотынырга, бернигә карап тормаска! Мин шулай фикер йөрттем. Бу уйлар беренче залны караганда, Надяның бала чак рәсемнәрен күргәндә тудылар.

Икенче залда мин үземне оныттым, Надяның рәсемнәренә йотылдым. Уналты яшендә Надя Рушева «Сугыш һәм тынычлык» романын иллюстрацияләгән. Мин әле ул романны Нурмөхәммәт абайларга килгәч кенә укып чыктым. Анда да күп өлешен аңлап җиткермәдем. Надя мине таң калдырды.

Надя пушкиниана тудырган. Пушкинны ул үз күңеленнән үткәргән. һәм шул Пушкин миңа моңарчы мин күргән бик зур художникларның портретларыннан якынрак булып тоелды. Аның балаларча очлаеп килгән авызы, ак болыт кебек җиңел бөдрәләре (башкаларда аның бөдрәләре кара болыт!) миңе үзенә тартты. Шунда мин Надяның кыюлыгын күрдем. Мин үз-үземә үпкәчел бер сорау куйдым: ник мин Тукай портретын язмыйм? Ник миңа моны берәү дә киңәш итми? Ник мин үзем өзелеп яраткан шагыйрем зәңгәр күзле Такташны шундый ук җиңеллек белән, тоташ бер сызык, ягъни бер сулыш белән язмыйм? Надя Рушева мәхәббәт һәм усаллык аллаларын ясаган. Бездә андый аллалар юк, мине авылда андый төшенчәләргә берәү дә өйрәтмәде, ләкин бит дөньяда Галиябану белән Хәлил бар, Йосыф белән Зөләйха бар, Сак белән Сок бар. Аларны кече яшемнән беләм. Мин үз алдыма тагын бер сорау куйдым: Надя Рушева җиңеллек, матурлык дөньясына, хыял дөньясына ничек шулай кереп китә алган? Әтисе аның музыкант, әнисе биюче, бабасы художник булган. Әзерлек дигән нәрсә, күрәсең, рәсем мәктәбе белән генә чикләнми, матурлыкны аңлау буыннан-буынга килә. Надя музыка дөньясында яши, биюләр дөньясында яши. Надя унбиш яшендә Варшаваны күреп кайта. Мин унбиш яшемдә беренче мәртәбә Әгерҗедән чыгып киттем. Мин унбиш яшемдә сәнгать турындагы беренче китапларны укый башладым. Минем әле эшләмәгән эшем, куып җитәсе нәрсәләрем — таулар! Мин чынлап торып зур эш белән шөгыльләнәсе урында Рөстәм Галикәевкә үпкәләп йөрим. Ул мине сангә сукмый, ул мине танымый, янәсе. Нишләп ул мине танысын, ул минем буем җитмәс биеклектә бит инде, ул гитара уйный, баян уйный, ул

6*

бөтен дөнья музыкасын магнитофон ленталарына язып ала. Ул әтисенең китапханәсен күптән укып чыккан, хәзер иң кирәкләрен китапханәләрдән алып укый. Хәзер мин аны куа чыгарга, өзлексез куарга, аның яшендә аны узып, үземнең артымнан йөгертерлек итәргә тиешмен...

Уй-хыялларымнан арынып, мин Надяның автопортреты янына туктыйм һәм сискәнеп китәм. Бу бит — минем автопортретым. Менә ни өчен Натягунин абый мине беренче мәртәбә мактаган икән. Мин дә бит вакытның күпмедер мизгелендә Надя ирешкән югарылыкта булганмын, рухи халәтемне ватманга төшерә алганмын. Бу хәл миңа тагын канатлар куя һәм мин Надя Рушева турындагы язмаларны укый башлыйм.

Академик Ватагин әйтә:

«Мин Надя Рушеваның бер ел эчендә гадәттән тыш сәләтенең үсеш күрү бәхетенә ирештем, шуның өчен җаваплылыкны үз өстемә алдым. Мин аның, художник буларак, көнләп түгел, сәгатьләп үсүен күрдем. Аның рәсемнәре «балалар иҗаты» булудан күптән инде узып киткән, әмма олы яшьтәге художниклар арасында да аңардагы җиңеллек, композицияне тою, образларның үткенлеге, дөньяны аныңча кабул итә белүләре белән бик азлары гына ярыша алалар».

Надя Рушеваның күргәзмәсе хакында йөзләрчә кеше дулкынланып, таң калып язган. «Надя безнең күңелебезгә бетмәс-төкәнмәс шатлык китерде»,— ди алар. Ә менә художниклар аның иҗатына бәя биргәндә аның пропорцияләренең дөреслегенә, рәсемнәренең нәфис һәм җиңеллегенә, барыннан да бигрәк аның геройларының матур күңелле булуына сокланалар. Аның хәтта убырлы карчыклары белән шүрәлеләре дә изге күңелле, диләр.

Надя акварель, темпера, монотипия, офорт белән эшләү күнекмәләрен бик тиз үзләштергән, шуларда үскән, әмма каләм яки төсле фломастер белән бер мәртәбә сызып җибәргән сызык, төзәтүсез, әзерлексез сызган сызык аның төп үзенчәлеге булып калган. Күчеш чорында да ул төшенкелеккә бирелмәгән, хыял дөньясы белән яшәп калган, һаман камилләшә барганда, унҗиде яшендә... миенә кан савудан үлеп киткән.

Күргәзмәгә килгәндә мин Надя Рушеваның үлгәнен алдан ук белеп килсәм дә, ул калдырган ун мең рәсемне караганда шундый мавыгып киттем, соңгы хәбәр миңа яшен суккандай тәэсир итте.

Бугазыма килеп бөялгән күз яшен йотып, музейдан чыктым. Адашыма беркайчан да хыянәт итмәскә, ул эшләп бетермәгән эшне дәвам итәргә күңелемнән ант иттем.

## 7

Дөньяга яз килде.

Җилләр суык булса да, өшеткеч түгел. Казанка бозы өстенә күтәрелгән болганчык шадра сулар, художник күзлегеннән, төсләр гаммасыннан караганда бер тиенгә торгысыз булса да, кай ягы беләндер күңелне җилкетә!

Үзебезнең тулып ташыган Кама суын, күкселләнеп утырган урманнарны искә төшереп, ямансулап, өйгә бер хат яздым да билне буып соңгы штурмга тотындым.

Бу — минем Кышкы Сарайны алуга булган соңгы һөҗүмем. Бу — минем адашым Надя Рушевага биргән антымны үтәргә тотынуым. Барлык көчемне җыеп, алга-артка каранмаска, гел алга гына барырга тиешмен мин. Укытучым Натягунин миңа шулай диде. Надя күргәзмәсеннән кайткач, мин аны тагын бер рәсемем белән сөендердем. Мин аңар профессор Галикәевнең, ягъни мине үзләренә сыендырган Нурмөхәммәт абыйның портретын фломастер белән ясап бирдем. Мин аны күптәннән хыялланып йөргәнемчә бер сулыш белән, тоташ бер сызык белән ясарга

тырыштым. Аның өчен мин аны атна буена күзәтеп йөрдем. Нурмөхәммәт абый белән якшәмбе көненә сүз берләшеп куйдым һәм без тып-тын, ып-аулак өйдә икәү генә калдык. Профессор миңа позировать итте. Бу эшнең җаваплылыгын аңлап мин бик каушаган идем, күңелемдә өермә булып олы тойгылар айкала иде, шуңадырмы — фломастерны минем кулым түгел, күңелем йөртте.

Портретны мин егерме минутта сызып аттым. Бу минем өчен бик аз вакыт кебек тоелды, әмма мин аны бүтәнчә «эшкәртергә» теләмәдем, чөнки ул чакта кирәксез сызыклар артачак, минем аны бозып ташлавым мөмкин иде.

Ни булса — ул! дидем дә, тәвәккәлләп, портретны Нурмөхәммәт абыйның үзенә күрсәттем. Ул башын кырын салды. Беркайчан да чәчрәп көлмәгән, ашыкмый-кабаланмый торган, олы сымак чырайлы профессор кинәт балалар кебек кулларын чәбәкләп, тезеп китте:

— Әнекәй генәем! Нәҗүк! Художник бит син, апаем! Ну, брат! Ну, брат! Менә нәрсәгә илтә тырышлык! Гафу ит — коры бер тырышлык белән генә пычагым да кырып булмый. Призвание! Синдә чынлап торып художник җаны. Керергә кирәк училищега. Мәтәлеп-кадалып булса да керергә! Телисеңме, мин сиңа булышам? Бүген үк барып училище директоры белән сөйләшәм. Юк, директор белән түгел, Художниклар союзы председателе белән сөйләшәм. Телисеңме?

— Ю-уук! — дидем мин үҗәтләнеп.— Керсәм мин үзем керәм!

Минем нык күңелле булуым аны шатландырды. Ул, беренче мәртәбә күргәндәй, минем кистерелгән кыска чәчемә, шәһәрчә «мини» күлмәгемә карап алды:

— Үзгәргәнсең бит син, Нәҗүк! — диде.

— Нигә, абый, шуның өчен килдем дә бит инде калага! — дидем.

Ул рәхәтләнеп бер көлде.

Әнә шул көннән башлап профессор Галикәев минем һәр адымымны күзәтеп-барлап торды. Аның киңәше белән мин төнге дежурлыктан чыктым. Ул кичләрен кимендә бер сәгать вакытын минем белән бергә рус теле дәресләрен кабатлауга бирде. Ул моны вазифа итеп түгел, кызык табып, рәхәтләнеп эшли иде. Апрель буена — төп-төгәл утыз көн — без грамматика кагыйдәләрен өйрәндек. Өйрәнеп тә карадык соң! Җиде төн уртасында уятып сорасыннар — без теләсә кайсы кагыйдәне уйлап-нитеп тормастан әйтеп бирер дәрәҗәгә җиттек.

Май аен тоташы белән диктант язып үткәрдек.

Рәсемне инде әйтеп тә тормыйм. Рәсемне мин мәктәптә дә, өйдә дә, утырып та, баскан килеш тә, утырып-басып торырлык хәл калмагач, корсак өстенә ятып та ясый идем.

Кайчагында Нурмөхәммәт абый минем зал ягында идәндә корсак өстенә ятып рәсем ясаганны күрә дә аяк очларына басып кына уза башлый. Мин шуны сизеп — ялт! — сикереп торам. Икебез дә рәхәтләнеп бер көләбез. Аннары ул башын кырынрак салып минем рәсемнәремне күздән үткәрә һәм авыр гына бер көрсенеп куя. Баштарак сәерсендерә иде мине бу көрсенү, бераздан аңладым, ул да минем өчен янып-көеп йөри икән.

Минем өчен «янып-көеп» йөрүче кеше — минем укытучым Натягулин. Баштарак ул моны миңа сиздермәгән иде. Училищега гариза бирер көннәр якынлашкан саен миңа игъбарын арттыра барды. Мин атна-уң көн эчендә калын бер папка булып җыелган рәсемнәремне күтәреп аңа илтәм. Рәсемнәремне ул хәзер бармак очыннан гына үткәрми, һәркайсын җентекләп карый, кайда фактура ачылмаган, кайда шәүлә-күләгә дөрес салынмаган — ике-өч сүз белән генә аңлата. Минем укытучым аз сүзле.

— Да-а,— дип сузып кына әйтеп куя ул. Мин аннары сабыр гына

аның аңлатмасын көтәм.— Да-а... Рәсемне жиндек без. Композиция да безгә буйсынды. Шулай да, Ханнанова, живописьта без аксыйбыз.

Син аксыйсың, диме, без аксыйбыз, ди. Бу сүзләрдә мин аның минем язмышыма никадәрле җаваплы каравын сизәм. Минем аны борчыйсым килми, мин үлепләр дә аның ышанычын акларга телим. Ничек акларга соң аны? Ничек итеп имтиханда каушап калмаска?

Уку елы бетәр алдыннан мин атна буе училищега йөрдем. Укытучым шулай кушты. Училищеның атмосферасына өйрәнә тор, диде.

Йөрдем мин, өйрәндем. Әммәдәки (әти әйтмешли), мине тагын бер хәл чыгырымнан чыгарып ташлый язды.

Мин училищега документларым белән бергә иң яхшы дип тапкан рәсемнәремне тапшырып кайткан көнне урамда... кемне очраттым дип беләсез? Сары чәчне! Җилкәсенә чишелгән көлтә булып сибелгән Сары чәчне очраттым мин.

Ул минем күңел ныклыгымны җимерде. Мин үземне дөньяда иң бәхетсез кеше итеп тойдым.

«Их,— дидем мин,— имансыз кызый,— дидем,— мин имтиханнарымны тапшырып бетергәнче генә кайтмый торсаң ни булган?!» — дидем.

Мин тагын сөмсерләрем коелып йөри башладым. Моны укытучым Натягунин да, Нурмөхәммәт абай белән Гөлҗиһан түтәй дә сизделәр, ләкин мин аларның кәеф-хәтер сорашуларына әйле-шәйле генә җавап бирдем.

Мин Рөстәмнең мөнәсәбәтен көттем. Ул соңгы көннәрдә минем белән гади генә исәнләшеп йөри. Ул инде мине күрмәмешкә салына алмый, әмма минем «этлегемне» гафу да итә алмый иде әле.

Минем уемча, Сары чәчнең кайтуы аны үзгәртергә тиеш. Беренче имтиханга мин аның Сары чәчкә мөнәсәбәтен ачыкламаган килеш барып кердем. Без гипстан койган орнамент сынын ясарга тиеш идек. Күңелемдә ярсу булгандырмы — иплап-җайлап тормадым, сөңгедәй очлаган карандашымны озын итеп тотып, орнаментны бер сулыш белән ясарга тотындым. Имтихан комиссиясеннән өч-дүрт кеше минем янга килеп китте.

Бу юньлегә микән?

Каяндыр килеп чыккан укытучым Натягунинны күргәч кенә минем эчемә җылы керде.

— Нормально. Бик ашыкма, вакытың күп әле,— диде ул.

Никадәр ышаныч бирен китте ул миңа.

— Йә, Нәҗүк, эшләрең кай тирәдә? — дип каршылады мине Нурмөхәммәт абай.

— Ясадым шикелле,— дидем.

Имтиханда бер урынга өч кеше идек. Икенче көнне фамилияләр тезгән тактадан, ашыгып-кабаланып, үз фамилиямне карап чыктым. Юк! Йөрәгем жу итте.

Аһ, монысы бит керми калганнар исемлеге.

Бакырбаш Бари белән Светлананы шул тактада күреп бик гаҗәпләндем. Алар бит рәсем мәктәбендә дүрт ел укыганнар иде.

Тагын ике көннән композициядән имтихан бирдек. Мин «Хезмәт» дигән темага йорт салучыларны ясадым.

Теләп-яратып ясасам да, укытучым күренмәү мине каушатты. Өч сәгать чамасы газаплангач, ниһаять, Натягунин абай күренеп, минем йорт салучыларыма елмаеп сәлам биреп китте.

Тагын бер көннән ике имтиханның да билгесен әйттеләр. Минекеләр — дүртле. Бу — югары билге, бишлене бирәүгә дә куймыйлар. «Бишле алу» — житлеккән художник булу дигән сүз икән.

Живописьтан мин өчле эләктердем һәм кара кайгыга калдым.

«Кышкы Сарайны алуны дәвам итәбез!» — диде Натягунин абай, мине тынычландырып кайтарып җибәрде.
Шул кичне Гөлҗиһан түтәй минем белән эч серен бүлеште.
— И дөньялар! — дип, көйле-сагышлы тавышы белән сүз башлады ул.— Теге адәм тәганәсе тагын кайткан бит...
Мин белмәмешкә салышып:
— Кемне әйтәсез? — дидем.
— Соң, Рөстәм мавыгып йөргән кызны инде...
— Кайтса соң?! — дидем мин.— Аннан сезгә ни зыян?
— Менә бөтен бәла дә шунда шул, апаем. Рөстәмнең кайтканын, минем өйдә юкны гына сагалап торган, йөзен ертып килеп җиткән, затсыз.
— Кит аннан! — дидем мин, гаҗәпләнгән булып. Ә үзем эшләрнең ничек беткәнен беләсем килеп сабырсызлана башладым. Әле һаман баш чайкап утырган Гөлҗиһан түтәйдән сүзне сулышым белән тартып алырдай булдым.
— Ярый әле,— диде Гөлҗиһан түтәй, озак кына утыргач.— Соң булса да малай акылына килде.
— Нишләде? — дидем мин, үз-үземне белештермичә.
— Куып чыгарды.
— Алай ярыймыни? — дигән булдым, ә үземнең җаным тагын бер мәртәбә канат какты.
— Бик тә ярый...— диде Гөлҗиһан түтәй сабыр гына.— Шул кирәк хыянәтьчеләргә.
Рус телен мин бишлегә, язманы дүртлегә тапшырдым. Кара-каршы сөйләшү вакытында мин биргән җаваплар комиссиягә ошаган булса кирәк, алар миңа туп-туры әйттеләр:
— Рәсем училищесы студенты булуың белән котлыйбыз! — диделәр.
Мин баскан җиремне тоймас хәлдә йөгереп өйгә кайттым. Шул хәбәрне түкми-чәчми Галикәевләргә тапшырдым.
Алар барысы да өйдә иде.
Зөһрә мине кочаклап үпте. Гөлҗиһан түтәй аркамнан сөйде. Ир-ат тыенкырак кыланды.
Нурмөхәммәт абай миңа чын художниклар йөртә торган чемодан чаклы этюдник бүләк итте.
— Нажия Вафовна, син җиңүче, син кала алучы. Күлбайга мин сине үз машинамда озата кайтам,— диде.
Бер читтәрәк басып торган Рөстәм:
— Әти, мин дә Күлбайга кайтыйм әле,— диде.
— Син нишлисең анда? — диде Нурмөхәммәт абай.
— Авылда этюдлар ясар идем...— һәм үзе теләктәшлек эзләп мөлдерәп миңа карады.

1971—1972.

## Фатих Хөсни

# БЕЗ ЯШЬ ИДЕК...

ПОВЕСТЬ

I



Мин элек-электән үк бәләкәй гәүдәле, чандыр, үтәли күренердәй юка булдым. Шуңа күрә әни мине әледән-әле: «Каз канаты син, берәрсе каерып алып китмәсә ярый», дип үчекли торган иде. Әллә аның шул сүзләре колакларына кереп калган, соныннан иптәш кызларым миңа «Канат», «Канат Миңлегөл» дип кушамат тактылар. Шулай да әни мәрхүмнең юраганы юш килмәде, берәүдән дә канатымны каертмадым. Бусы болай, сүз арасына кысылган сүз генә, мактанчык икән бу дип уйлый күрмәгез.

Хәзер сөйләргә җыенган сүзләрем дә әллә ни үсеп киткәннән түгел, ничек бар — шулай калдым, кешеләр йөргән ишектән үк йөрим. Шулай да ул көннәрдән бирле күп гомер узды, чәчкә чал керә башлады, узган ел әллә зурлап, әллә үсәрдәй чакта үсмәгәнне берьюлы үстереп җибәрергә теләп, «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән исем дә биреп куйдылар, әйе, буйга әллә ни үсмәсәм дә, узгандагы хәл-әхвәлләрне, баштан кичкәннәрне бәяләргә өйрәндем шикелле. Бигрәк тә алар арасыннан яшьлек җүләрлеге белән эшләп ташланган тилемиле эшләрне, ничектер, моңсу сагыну белән искә алырга яратам — картая башлау галәмәтедер, бәлки...

Әйтеп узганымча, мин бәләкәйдән үк кечкенә гәүдәле идем, ә менә 1942 елда әтинең фронтта үлеп калу хәбәрен ишеткәч, бөтенләй куырылып төштем. Ул кайгылы хәбәр берьюлы минем иңнәремне басып, болай да юка гәүдәмне җиргә индергән кебек булды. Сугыш еллары — сагыш еллары, бер безнең баштан гына кичмәгән, бөтенесен сөйләүне кирәк тапмыйм. Аннары тагын, без әни белән ике генә бөртек идек, кеше күргәнне күрдек, ничек булса да җирнең өстендә калганбыз, җирнең астына китәргә ашыкмаганбыз. Шулай да ул вакыттан истә калган ике хәлне көлемсерәп искә төшермичә үтә алмыйм.

Моның беренчесе — минем энинең осталыгыннан килгәндерме, барлы-юклы тавык-чебешләребезнең бәрәкәтле булуыннандырмы, һәрхәлдә, байлыгыбыз ташып торганнан түгел: минем әни бәләкәй генә бер тавыктан сигез аш пешерә, хәтерегезгә сеңсен өчен кабатлап әйтәм, сигез тапкыр итле аш пешерә торган иде. Берәр канаттан иң элек ике аш, ике бот — ике аш, менә булды дүрт, санын тип-тигез өч кисәккә бүлеп өч аш итә, эченнән-башыннан тагы бер аш: менә булды сигез. Ни хикмәттер, ашап туйгысыз тәмле була иде аның ул ашлары. Соныннан, институтта укыганда ишетеп белдем: электә, Грибоедов заманында, «Каз — ахмак яралган кош, бер кешегә күп, ике кешегә җитми!» дип әйтә торган булганнар. Ә минем әни, җаным, бәләкәй генә бер тавыктан сигез көн рәттәм сигез аш пешерә...

Әни катнашында башыбыздан кичкән икенче бер аянычлы хәл. Бер көнне бу колхоз эшенә киеп йөри торган сырма бушлатына, сырманың эчке ягына зур итеп кесә салырга керешге. Мин моны башта абайламыйча тордым: кесәме соң бу, әллә җылырак булсын өчен эчтән тагын бер кат астар ябыштырамы? Кесә булып чыкты. «Нигә кирәк андый зур кесә?» — дип сорадым әнидән. Җавап бирмәде. Утырган урыныннан дәррәү сикереп торды да кече якка кереп китте. Соныннан белдем: аның шул үз исәбе үзендә булган икән. Ләкин, мәрхүмәкәем, ул бу исәбендә бер тавыктан сигез аш пешерә белү кебек осталык күрсәтә алмады. Бер көнне колхоз ындырында ашлык тазарткан җиреннән әлеге шул кесәсенә бодай тутырып алып кайткан бу, ләкин барып чыкмады, шундук артыннан колхоз председателе Ярулла абзый протезлы аягы белән шакы-шокы килеп тә керде. Теле белән түгел, шул протезлы аягы белән шакылдатып әйткән төсле булды ул, минем күңелгә нишләптер шулай сеңеп калган.

— Син, Халисә түти, икенче болай эшли торган булма, җәме,— диде, әнинең кесәсен дә бушатырга өлгермәгән сырмасын чөйдән алып,— тормышыгызның җинел түгеллеген беләм, мәгәр без монда ничек тә түзәрбез, бодайны әрәм-шәрәмсез генә фронтовикларга җибәрик.

Шулай диде дә, сырманы янадан элеккеге урынына — чөйгә элеп, китеп барды. Каты бәрелгән булса, минем әнинең дә авызында теле бар, бер тавыктан сигез аш пешерә белгәнне Хабул Ярулласына гына җавапны тапкан булыр иде. Җавап биреп тормады, Ярулла абзый киткәч, утырып бер елады да, кесәгә тутырып алып кайткан бодаен әтинең иске киез эшләпәсенә бушатып, мине колхоз ындырына — илтеп кайтырга җибәрде. И шундагы гарьләнүләрем! И шундагы әнине кызгануым! Икенче көнне әни сырманың эчке ягына ябыштырган шомлы зур кесәне юри минем күз алдымда, юри үзен-үзе үчекли-үчекли сүтеп атты.

## II

Шул арада мин урта мәктәпне бетереп, башыма әллә ни зур белем тәмәсәм дә, тормышның уен түгел икәнлегенә төшенеп алдым. Бөтен авырлыкны әни җилкәсенә калдырып, укуны дәвам иттерү, институтка китү турында уйлап та карамадым. Яшь булсам да, минем дә җилкәм бар, нужаны уртак күтәрәсем килде. Әни укуымны дәвам иттерүемне теләп чапаланса да, мин тешләп өзгәндәй иттем:

— Институт юлына киртә тотмаслар, бер-ике ел соңыннан да качмас, бу авыр елларда синең үзеңне генә калдырасым юк,— дидем.

Һәм сүзем белән эшем арасына салкын йөгерергә ирек бирмәстән, район үзәгенә киттем. Ниятем болай: җае туры килсә, нинди дә булса район учреждениеләренең берсенә секретарьмы, хисапчымы булып эшкә урнашу, алай барып чыкмаса, ронога кереп, берәр мәктәпкә укытучы итеп җибәрүләрен сорау. Беренче ниятем барып чыкмады, район уч-

рендениеләрендә минем эше күзгә чебешләр кайнап тора, өреп тутырган апайларың да бетәсе түгел. Күзәтә йөрдем: берьюлы өчәр эш башкара кайберләре. Телефоннан да сөйләшә, күзгә чыгарып ирене дә кызарта, шундук тагы минем кебек ишек төбенә кереп баскан чуракәй үрдәкләргә чак кына сабыр итеп торырга кушып, ишарә ясарга да өлгерә. Сугыш чоры, уйнап йөрүче түгелдер, дип уйлап та карамый. Хәер, андыйларны күргәч минем дә җенем кузгалып-кузгалып куя иде. Ронога чиратым җиткәч җебеп тормадым.

— Менә килдем,— дидем чатылдатып. Әйтерсең чакыру буенча килгән.— Урта белемне тулысы белән алдым, югарысын тутырырга хәзергә капчыгым әзер түгел, капчык әзерләгәнче әнигә булышырга кирәк, мине кая булса да эшкә җибәрегез. Укытучы итепме, китапханәчеме, берәр клубкамы шунда — кайсын булса да ерып чыгармын дип уйлыйм.

Соңыннан абайлап алдым, чыш-пышрак килеп чыкты, клуб эшләре ронога карамый бит, ләгънәт. Әмма болай куырып әйткәч, бигрәк тә минем тасраеп карап торуымны мәзәксенеп булса кирәк, андагылар минем бу «чыш-пыш»ны сизеп алырга өлгерми калдылар. Ахрысы, аларга минем — әнисе шәленә төренеп килгән япь-яшь кызның шулай чәчрәп торуы ошады булса кирәк.

— Укытучы итеп алыр идем алуын да,— дип көлемсерәп сүз башлады роно мөдире,— укучыларың арасына кереп югалып калмассыңмы икән соң?

Сизеп торам: бу моны минем бәләкәйлегемә ишарәләп әйтә. Буйдамыни эш, йөрәктә, теләктә — ә минем эшләп карарга теләк тау чаклы иде.

— Калмам, абый, бу чаклысын ышандырып әйтә алам,— дидем өзеп. Өзелеп җиткәнлегенә-җитмәгәнлегенә үзем бик ышанып бетмичә, авыз эчемдә бутка пешеребрәк, шундук өстәп куярга да ашыктым: — Ышанмасагыз, Таллы күл авылы качкан җирдә түгел, мәктәп директорыннан характеристика соратып алыгыз, бөтен фәннәрдән отличнога укыдым, аттестатым отлично. Кирәк икән, үзегез экзамен алыгыз, бернидән дә курыкмыйм.

Әнисе шәленә төренеп килгән япь-яшь кызның шулай чатылдап торуы да ошады булса кирәк, аннары тагы сугыш чоры, ир-ат укытучылар фронтка киткән, мәктәп кадрлары җитешми торган чак — йомшамыйча булдыра алмадылар.

— Ярый, без монда уйлашырбыз, хәзергә кайтып торыгыз, сеңелем,— диде мөдир, бу юлы инде сизелеп торган җитдилек белән. Аннары тагын өметләндергеч җылылык белән өстәп тә куясы итте: — Кирәк тапсак әгәр, сузмабыз, үзебез хәбәр итәрбез.

Нужа калач ашата, диләр безнең авылда: кирәк тапмаслар иде, мәктәпләрдә укытучылар җитешми, борын төбендә беренче сентябрь, икеме-өчме көннән мине ронога чакыртып алдылар. Имтихан ук тоттырмасалар да, шулай да нык кына сораштылар, методкабинетка җибәреп, анда да сораштылар, өйрәткәләделәр, өстәвенә, бер кочак кәгазь: программалар, методик кулланмалар тоттырдылар һәм, шулай итеп, буйга аршын ярым, белгә үлчәве дә табылмаслык уналты яшьлек «Канатны» — мине, бәхеткә каршы, үз авылыбыздан унбиш километрдагы Алмалы урта мәктәбенең башлангыч классларына укытучы итеп билгеләделәр.

— Үз авылыгыз мәктәбендә, әниең янында ук калдырырга да мөмкин булыр иде дә,— дип сузып куйды соңыннан мөдир, ничек тә безнең семьяның хәленә керергә тырышып булса кирәк,— беренчедән, сезнең мәктәптә әлегә укытучылар мәсьәләсе алай үткен тормый, ул чаклысын үзегез дә беләсездер. Икенчедән... икенчедән, педагогика нормасына бик үк сыеп бетмәс кебек. Баласытып, үз ишләре итеп караулары бар укучыларның.

Бусы тагы шул: минем бәләкәйлегемә ишарә, әйтеп кенә бетермәде. Хәер, мин алай нечкәртеп тормадым, Алмалы мәктәбе икән — Алмалы мәктәбе, эш кайда да бер.

Әмма әни өчен бу һич кенә дә барыбер түгел иде. Мине шатландырып кайтарган бу хәбәр әнине, мескенемне, ике ут уртасында калдырды. Бердән, кызының укытучы булып китүен, әлбәттә, дәрәҗә саный. Шуның өстенә, акча күреп өйрәнмәгән авыл хатынын акчасы да кызыктыра, ирсез-атсыз калган өйдә кирәк-ярак төпсез кое кебек. Икенчедән, кызыннан да аерыласы килми, бөтенләй япа-ялгызы калачак бит, бичаракаем. Бу турыдан ничек тә тынычландырырга — юатырга тырышам әнине. Алмалы — олы юл өстендәге авыл, килә-китә йөрүче өзелеп тормас, ял көннәренә каршы гел үзем дә кайта-кита йөрермен, мин әйтәм. Барып, эшне җайга салып, фатир якларын рәтләсәм, бер-авык үзең дә торып-торып китәрсең, дим.

Соңыннан, тел белән әйтүеннән дә бигрәк, сүз аркасындагы уфылдауларыннан чамалап алдым — хәзер инде мин дә төрле яклап уйлый башлаган идем. Өйдә ялгыз гына калудан курку түгел, хәтта кызының ничек урнашуы, укыта алуы-алмавы да түгел — бу чаклысында ул миңа ышана иде булса кирәк — төрлесен уйлап өйрәнгән йорт башы кешене, барыннан да элек укытучы булачак кызын, ничек киендереп озату мәсьәләсе борчыган, имеш.

— Шәлебез яна, анысы инде битенә кызыллык китерер дип уйламыйм,— шулай дип сүз башлады бу бер көнне. Үзенең кеше арасына ябынып чыга торган бердәнбер мамык шәлен ул инде күңеленнән минеке — укытучы кызыныкы итеп куйган, имеш.— Пәлтәң искерә төшкән. Хәер, өстән мамык шәл белән каплабрак йөрсәң, аның искелеге күренмәсен дә, ди. Материалы затлы материал, атаң мәрхүм Казаннан үзе алып кайткан ие, авыр туфрагы җинел булсын.

— Әй, юк өчен баш ватмасана, әни,— дип чәчрәп чыктым мин, әнинең күзләре яшьләнә башлаганны тыныч кына күтәрә алмыйча.

— Син гел шулай инде, Миңлегөл, җиңел уйлыйсың. Эленке-салынкы йөрү безнең иште прастуй кешегә ярый ул, ә син бит — алла ярдәм бирсен — укытучы дип аталасың, кеше күзе алдында булачаксың.

Бераз битен-күзен сөрткәләгәннән соң, ничектер әл-хәл алгандай булып, ул икенче борчуын — бу юлы аны иң аптыратканын булса кирәк,— әйтеп салды:

— Аяк киемнәреңнең бер дә рәте-коты юк. Гел генә киез итектән йөри алмассың бит. Биек үкчәле берәр туфли сымак нәрсә булсын ие. Биек үкчәле аяк киеме кешене кеше алдында ничектер күтәребрәк тә күрсәтүчән...

Бичара әни! Җуләрем әни! Газизем әни! Әйтеп кенә бетермәде, тел төбендәгесе, күңелендәгесе миңа шундук житте: ул минем буйга бәләкәй булганлыгым өчен борчыла, ул мине кеше күзе алдында ничектер үстеребрәк күрсәтергә тырыша иде булса кирәк. Моны ул озакламыйча гамәле белән үк күрсәтте. Мин Алмалыга килеп тә өлгермәдем, кайдан акча юнәтептер — шик юк, кешедән әҗәткә алып булса кирәк — миңа биек үкчәле ялтыравыклы туфли сатып алып кайтты. Яңгырлы көзгә, карлы-буранлы кышка каршы, авыл җирендә — ялтыравыклы туфли! Тагын бер мәртәбә: җуләрем әни!

## III

Алмалыга баргач, ялгыз карчык Хәтирә апада уздырган беренче көннәрем, авылны, әнине юксынуларым турында җәелеп торуны кирәк тапмыйм. Болай үзе әйбәт кеше булса да, Хәтирә апа әни түгел

инде. Бусагасын атлап беренче керү белән, бергә утырып беренче чәй эчү вакытында ул, әти-әнием, кайда укуым, ничек тормыш итәрг уйлавым турында бик җентекләп сорашты да, ялгыз үзе генә калган әниемнең хәленә кергәндәй итеп, яулык почмагы белән яшьләнгә күзләрен сөртеп алганнан соң ук, тизрәк үз хәленә күчте:

— Бер нияләнгәч, ялгыз баш та торасың икән, әле сине кертүем д ялгызлыктан аптыраганнан түгел, утыны өчен дип эшләнгән эш, утынын бирербез диделәр,— һәм шунда ук һич суынырга ирек куй мыйча, әйтеп тә салды: — Кара әле, кызым, кем диден әле исемеңне Гөлйөзем диденме?

— Гөлйөзем түгел, Миңлегөл, апа.

— Ә, әйе, Миңлегөл шул, бик матур исем, ходай бәхетеңне тул итсен. Син инде, Миңлегөл җаным, ул ягын, зинһар, үзең кайгырт йөр. Колхоз салам бирми, кышын утынсыз да калсак, алла сакласын таракан урынына аяклы-очлы катып үләрбез.

Һәм аның бу турыда көн саен бер искә төшерми калганы булмады кай көннәрдә икешәр-өчәр кабатларга да иренми иде — гөнаһысын керер хәлем юк.

Мәктәптә ничек? Менә хәзер, аннан бирле егерме-егерме биш е вакыт узгач, берьюлы капыл гына әйтә дә алмам. Таркалып калу д булгандыр, үзең әлеге шул укыта торган балаларыңнан чак кына кал ку, арада уйнарга кергән күрше кызына караган кебек караучылары да булды шикелле — андыйлары турында соңыннан. Мәгәр, тулаем алганда, мәктәп коллективы үз итеп каршылады. Берьюлы берүзем ике класс беркеттеләр, берсендә әле класс җитәкчесе дә. Беренч класс белән эшем ярыйсы башланды — методик кулланмаларны да жи тәрлек ятлаган идем, ул хакта әдәби китаплар да укылмаган түгел ронодан да кат-кат тукып җибәрделәр, барыннан да бигрәк, балал рымны үзем яраттым, менә хәзер дә күз алдымда җемелдәшеп уты ралар төсле: сабыйлар, эчкерсезләр, кулларына урын тапмыйлар, күңелләре алдан әзерләп куелган гөл туфрагы кебек: орлык кын сип, шытып чыгарга тора.

Бераз башкачарак килеп чыкты икенче класс белән. Болары инд азмы-күпме этләшкәннәр, узган ел икенче бер укытучыны күрергә өл гергәннәр, сине аның белән чагыштырып карыйлардыр кебек тоела кеп-кечкенә башлары белән парта арасына сыймаган кебек кыла налар, үзара этешеп-төртешкәләп куялар, ачуланып кычкырасым кил ләкин белэм: методик кулланмаларда кычкыру күздә тотылмаган Дөрес, күзләре боларныкы да җемелди, тик бу җемелдәүдә чак-ча кына мыскыл да бар сымак: «Кара әле, кара! Үзе безнең чаклы гына ә үзе безне укытырга килгән!»

Методик кулланмаларым, завуч, директор биргән киңәшләрем бо ларга карата да, әлбәттә, бар иде, ә мин тоттым да үземч тәвәккәлләдем.

— Туктагыз, китапларыгызга, дәфтәрләрегезгә кагылмыйчарак то рыгыз, балалар, минем сезгә әйтәсе сүзем бар,— дидем, күзләрен туп-туры карап. Кайчагында кешегә карый белеп карау да бик зу нәрсә икән, ә мин аларны яратып, яхшылык теләп, бәхетле булула рын, үсеп кеше булуларын теләп карадым ул минутта. Күзем бел генә түгел, ничектер, җаным белән инәлеп карадым. Дөрес, хәзерг материалистик фән безне җан юк дип өйрәтә, ә мин, кем ничек уй лый — шулай уйласын, ул вакыттагы хәлемне яшермим, җаным бел карадым.

— Әйтеп торуның кирәге дә юк, сез, балалар, беләсез, менә икенч ел Гитлер Германиясе белән безнең Советлар иле арасында сугыш бара,— дип дәвам иттем мин, тавышымны мөмкин хәтле нык тотарг тырышып.— Мин беләм, ул сугышта сезнең дә күбегезнең әтиләрегез

абыйларыгыз катнаша торгандыр. Минем үземнең, мәсәлән, сугышта этием үлеп калды.

Бик читен булды миңа балалар алдында бу сүзләрне әйтү, елап җибәрмичә әйтү. Ләкин мин әйттем, күңелем шулай кушты, мин алардан, алар миннән бер нәрсәне дә яшермәскә тиешлекне сизә идем. Һәм аннары беренче сүз итеп тормышның уен түгел икәнлеген әйтергә кирәклекне дә сизә идем.

— ...Шулай, балалар, авыр чор кичерә безнең халкыбыз. Бәланең күзенә курыкмыйча карап әйтик. Курыкмыйча һәм яшермичә сөйләшик: сугышта безнең күп кенә яхшы кешеләребезнең үлеп калуы, корбан булуы мөмкин. Аларның урыннары буш кала булып чыга бит бу килештән. Аларның урыннары буш калмасын өчен, тормыш, әйтик, безнең колхоз тормышы, өй тормышыбыз, шәһәр җирендә завод-фабрикалар тормышы сүнеп калмасын дисәк, сезнең белән безгә нишләргә кирәк? Әлбәттә, көчебездән килгәнчә колхоз эшенә, өй эшләренә дә булышырга кирәк. Ләкин иң кирәге, сезнең белән бездән иң сорала торганы: безгә бик нык тырышып укырга, укырга кирәк. Ленин бабай да яшьләргә карата укырга, укырга, укырга дигән. Мин сезгә озак сөйләргә җыенмыйм, ләкин мин сезгә иң кирәген баштан ук кисәтеп әйтмичә дә кала алмыйм. Уку, белем алу, ил өчен, халык өчен, этиәниләребез өчен файдалы кеше булып җитешү уен эш түгел. Сүз бирәсезме, балалар, шулай тырышып укырга, яхшы кешеләр, файдалы кешеләр булып чыгарга? Чын-ихластан сүз бирәсезме? Сүз бирерлек булсагыз, балалар, мин сезнең белән — сезнең укытучыгыз булып калам, әгәр шулай эшләмәстәй булсак, бушка вакыт әрәм итмик, авылда минем япа-ялгыз әнием калды, елап калды, бичаракаем, мин иртәгә ук әнием янына, колхозда эшләргә китәм. Сезнең җавапны көтәм, балалар.

Методик кулланмаларда мондый кереш искә алынгандырмы-юктырмы, мин ул турыда уйлап тормадым, мин үз сүземне әйттем, күңел җылылыгымны салып, фронтта үлеп калган этиемне искә алып, әйтмичә кала алмаганлыктан әйттем.

Чын күңелдән әйтелгән бу сүзләр балалар күңеленә дә хуш килде булса кирәк, барысы да беравыздан бөтен классны яңгыратып:

— Укыйбыз, тырышабыз, китмә, апа! — дип кычкырдылар. Аннары тагы мондый бер хәл дә булды: дәресләр беткәч, укучылар таралгач, мин әйберләремне җыештырып азапланганда, бөтерчек хәтле генә бер кызчык, ишеккә кысылгандай, курка-ояла гына килеп керде дә, сүзен ничек башларга белмичә борынын тарткалап бер мәл торганнан соң, туп-туры күзләремә карап:

— Оныттым, син ни атлы әле, апа? — дип сорап куйды. Кызчык бик җитди, бик уйчан иде бу минутта, аның белән рәсми корылык мөмкин түгел кебек тоелды.

— «Нәнә апа» дип эндәшсәң, сиңа шул бик җиткән, үскәнем,— дидем, бала күңелендә нәрсә кайнаганны тизрәк беләсем килеп.— Ник ул чаклы кызыксындың, акыллым?

— Минем эти дә сугышта,— диде ул, бу юлы инде бик алай күзгә ук карамыйча. Аның тавышы калтыранып куйды,— шундук сизеп алдым, ул елап җибәрүдән үзен көчкә генә тыеп тора иде.— күптән инде сугышта. Без язабыз да язабыз, ә этидән хат килми дә килми. Син язып карасаң, килмәс не микән, Нәнә апа?

Бала кинәт йөзе белән минем итәгемә капланды һәм шундый ук кинәтлек белән, хәтта минем ни дип җавап биргәнемне дә көтмичә, чабып чыгып китте. Көтмәсә көтмәс, мин, әлбәттә, ул кызның этисенә хатны язачакмын, берсенә җавап килмәсә, икенчене, өченчене язачакмын, татарчасына җавап булмаса, русча, частенә, командирына язачакмын, ләкин хәзергә мин бер нәрсәдән бик канәгать калдым:

күнелендә уянган шундый саф өметен бала миңа ышанып әйтә икән, димәк, мин аның күңеленә ачкыч тапканмын. Бүген берсенә, иртәгә икенчесенә һәм аннары барысына да. «Димәк, синең бәләкәй буйлы кызың, биек үкчәле туфли кимәсә дә, укытучы була ала, әни», дип куйдым мин, күңелемнән әни белән бәхәскә кергәндәй.

## IV

Ул кызчык Сәлимә атлы булып чыкты. Мин озакка сузмыйча аларның өйләренә үк бардым. Сәлимәнең әнисе, апалары белән дә таныштым, бергәләп елап та алдык. Хатны булдыра алганча килештереп, элек әтиләренең үзенә, аннары кыр почтасы номеры буенча рус телендә командованиесе исеменә яздым. Бер аларга гына да түгел, үзем кирәк дип тапкан берничә баланың өйләренә барырга, әтиәниләре белән сөйләшергә өлгердем. Җыеп кына әйткәндә, эшемә иләшә барам шикелле. Укучыларым да көннән-көн ачыла, үз итә баралар. Кызык бит ул кеше дигәнең. Шул бер җайга салына барган көенә көн артыннан көнне санап кына торасы иде, югыйсә. Юк шул, үз башына әкәмәт уйлап чыгарырга кирәк кешегә. Берәү бер ишарә ясамаган хәлдә, тора торгач минем, ничектер, кинәт үсәсем, зуррак булып күренәсем килде, бер дә бер көнне мәктәпкә барганда газетка төреп әлеге туфлиләремне алып киттем. Янәсе, класста һәм укытучылар бүлмәсенә үтешли шуны кияргә. Дөресен генә әйткәндә, бөтенләй үк сәбәпсез дә түгел иде бугай. Минем класс алдыннан үтеп икенче катка — үз классларына йөрүче 10 нчы класс малайлары анда-санда ачык ишектән, ишек ачык булмаса юри ачып, кәмит караган кебек миңа карап узалар, арада кайбер йөгәнсезрәкләре телләрен чыгарып, үчекләп китәргә дә күп алмый. Сугыш алдындагы тыгрык елларда буйга сузылганнар, ә акыллары үсмәгән, бәлки, бүген дә башларына сугыш чукмары төшеп өлгермәгәндер, әллә төшеп тә яшьлек тилелеге белән сизмиләрме? Чандыр булсалар да гәүдәләләр, баскычтан атлап түгел, мәтәлә-кадала чабалар, шул ук вакытта борын да чөйгән булалар үзләренчә: янәсе, бик исләре китми, бүген укучы, иртәгә койрык сыртта: кирәк табалар икән, хет фронтка җибәрсеннәр. Әллә сизмимме? Миннән — буе-сыны ягыннан алардан чебешрәк бер кызның укытучы булып килүеннән — авыз ермакчылар. Ә минем алардан көлдерәсем килми, аларның мине баласытып караулары минем җенемне чыгара, күрсәтермен әле мин сезгә апагызның кем бакчасында үскәнлеген. Шулай бәхәсләшәм эчемнән генә. Шулай да, алда әйткәнемчә, көннәрдән бер көнне минем никтер кинәт үсеп китәсем, зуррак булып күренәсем килде. Аннары, үзегез беләсез, әни сүзен дә аяк астына салып булмый, әни әйтте ич: биек үкчәле аяк киеме кешене эрерәк-үстеребрәк күрсәтә, диде. Кыскасы, бәйрәм дә түгел, вечер-фәлән дә юк көнне мәктәптә кем биек үкчәле туфлидән шыгырт-шыгырт басып йөри? Башлангыч класслар укытучысы «Канат Миңлегөл» шыгырт-шыгырт басып йөри.

Ай-һай ла, шулай гына булсачы! Мин моны хәзер, ул вакыттан бирле күп сулар акканнан соң, үземнән-үзем көлеп шулай кыландырган булам. Шыгырдамаган кайда, гомердә бер шундый биек үкчәләргә менеп бас та тиз генә шыгырдап кит, имеш. Кыскасы, ник алып килдем, ник кидем дигән көнгә төштем мин ул көнне. Басып тора алмыйм, атлап китеп булмый, очлы башы аяк бармакларымны бөрештереп китерде, соңга калып чыккан чирләшкә каз бәбкәсе сыман, атлаган саен артка чүгеп-чүгеп китәм. Укучыларымны әйтәм, ни беркатлы, дөньянын хәйлә-мәкерен белмәс җан иләре, алар булып алар сизеп алдылар. Малайлары, әкәмәт күргәндәй, утырган урыннарыннан калка

төшеп, кызыксынып, көлемсерәп карап торалар. Кызлары исә, нечкәрәк күңелле халык, апаларының мөшкел хәлен ничек тә аңламакчылар — тәнәфес араларында яныма килеп сырпаланалар.

— Нәнә апа, аягың авырта мәллә синең бүген? — ди беришесе, чын-ихластан минем бәламне уртаклашып.

— Әй, Нәнә апа, җаным, матур да соң аягыңа кигәнең. Әни миңа да шундыйны апкайта,— дип, куанычларын, хыялларын бүлешәләр иде.

Ә теге унынчы класс күсәкләре, мин чалыш-чолыш атлап укытучылар бүлмәсенә үткәнне күреп, үзара пырхылдашып ук калдылар. Аллам сакласын, күңелләренә: «Үсәргә тырышкан бу саескан, атлый белмәсә дә» дигән мыскыллы уй килмәдеме икән?

Ахырында түзмәдем, бер тәнәфес вакытында ул дөмеккере туфлиләрне укытучылар бүлмәсендә салып калдырып, оекчан гына йөри башладым — менә кайда икән дөнья рәхәте! Чөйкәләсе дә юк, аяк бармаклары да иркендә. Салып калдырдым, ләкин — бәла аяк астында диләр — салып калдырган урыннан таба алмадым. Чистый бер тамаша купты ул көнне әлеге шул ләгънәт төшкән туфлиләр аркасында. Укытучылардан берсеннән дә шикләнмим — мөмкинме, укытучы булган кешенең кулы шундый әшәке булырмы! Ләкин, шунысы эчне пошыра, укытучыларның берсе дә дәрес беткәннән соң да өенә кайтып китәргә ашыкмый. Бөтенесенең дә төсенә чыккан, телдән калганнар. Билгеле инде, миннән шикләнмәгәйләре дип, һәркайсы үзеннән шикләнә. Шулай бит андый чакта: чын карак табылганчы бөтенең бер очтан карак булып күренәсең. Кайсыдыр берсе: «ЧП бу, мәктәп тормышында булмый торган хәл, тиз генә педсовет җыярга, сөйләшергә кирәк»,— дип куйды. Икенче берәве: «Табылмаса, акча салышып Сәрьяновага шундый ук туфли сатып алып бирик, коллектив өстендә тап калмасын!» — дип карады. Ләкин мәктәп директоры Гаффаров абый мондый тәкъдимнәрне уртаклашып та, кире кагып та бер сүз дә әйтмәде. Ул сүзсез һәм, газеталарда була торган баш мәкалә кебек, житди иде бу минутта. Аннары, бер нәрсә дә булмаган кебек, әкрен генә әйтте:

— Башлангыч классларны, дәресләре беткән булса, хәзер үк кайтарып җибәрегез, балаларны юк-бар уенга катнаштырырга ярамый. Эшләре беткән укытучылар шулай ук кайтып китә алалар,— диде.

Директорыбыз тыныч һәм, димәк, безгә караганда зирәгрәк тә иде булса кирәк. Мине бигрәк тә шунысы шаккатырды: үз коллективын, кайда нинди шуклык, кайда нинди елан мөгезе яшеренеп ятканын чамалап йөргән, имеш. Тавыш-гауга басылгач, өстән 10 нчы класс малайларын — әлеге теге миннән көлеп калган күсәкләрне чакыртып төшерде — кызларын түгел, малайларын гына. Бөтенесе уникé малай икән, уникесе берьюлы солдатлар кебек Гаффаров абый алдына килеп бастылар. Дәшми-нитми басып торалар, ә күз карашларында ниндидер яшертен хәйлә бар: берсенә-берсе астан гына карашып алалар, авыз читләрендә мутлык та кунаклап калган кебек. Директорыбыз, үз чиратында, шулай ук дәшми-тынмый гына тегеләргә бераз карап торды. Аннары тавышын һич күтәрмичә әйтте:

— Сәрьянованың туфлиләрен кайда яшердегез! Эт китертеп, мәктәп дирекциясен расходка батырганчы, тизрәк чыгарып бирегез,— диде.

Шунда янә бер кат төшендем: баш та бар икән безнең директор абыйда. Әгәр, әйтик, акырып-бакырып тотынса, белмим, кузгата алыр идеме икән бу уникé ташбашны. Үен сүз кыстырып, дусларча бер дәшүе булды, тегеләр беравыздан пырхылдашып көлеп җибәрделәр. Хәтта арадан бер башсызы директор хәтле директорга каршы сүз әйтүдән дә тыелып кала алмады.

— Йөри алмый ич ул туфлидән, азапланмасын дигәндер инде кем дә булса.

Хәзер инде мәсьәлә барыбыз өчен дә ачыкланды: бу этлек — шул уынчы класс кусәкләренең эше. Директорыбыз, сүзне артык куерт-мыйча, китеп барды. Укытучылар да таралыша башладылар. Бер заман әлеге уникe герой калды да мин калдым басып. Ә туфлине табып биргән кеше әлегә юк. Басып тора торгач, ардылармы дип әйтимме, бәлки, тамаклары да ачкандыр, ишек ягына таба караштыргалый башладылар болар.

— Мин кул белән кагылган кеше түгел, кулы белән кагылган кеше алып та бирсен,— диде берсе өзеп кенә. Һәм тиз-тиз атлап ишеккә юнәлде.

— Мин дә,— диде икенчесе, китәргә кузгалып.

— Мин дә,— диде өченчесе.

— Ә мин подавно,— диде дүртенчесе, русча белгәнлеген күрсәтергә тырышкандай.

Шулай китә-китә, Тукайның «суга дип киткән бүреләр»е кебек, нәкъ унбере китте дә барды. Каршымда бер малай гына торып калды да, мин үзем калдым. Торабыз шулай бер-беребезгә карашып. Чандыр озын малай. Чәче җиту. Борын тирәсендә чак-чак кына беленә торган ике-өч кенә сипкел дә бар. Маңгае киң. Шул киң маңгаен кая куярга белмәгәндәй, йөзен читкә бора. Күзләрендә көлү чаткысы да бар кебек, оялган да төсле. Өстендә олылар иңеннән төшкәнлеге әллә кайдан күренеп торган сипләнгән тужурка — бәлки, аның әтисе дә... Ничек каты бәрелмәк кирәк шундый малайга.

— Үзең болай ярыйсы егет күренәсең, значок та тагып алгансың,— дидем мин, күкрәгендәге «ГТО» значогына ымлап.

— Уйлама, апа, яшерүче мин дип,— диде бу, туфлине минем үз классымнан, үз өстәлемнең иң аскы ящигыннан, ящикның да иң түреннән алып биреп. «Апа» дигәндә ул, нишләптер, кызарып калды. Хәер, буйга миннән озын егеттән «апа» дигән сүзне ишетү минем үземә дә бик үк җайлы түгел иде.

## V

Фатир хуҗам Хәтирә апа мине гел йөдәтеп калмаган, күрәсең, мактәп администрациясенең дә бусагасын таптаган, колхоз идарәсендә дә булган — бәлки, бер генә тапкыр да түгелдер. Чана юлы төшү белән безгә ике үгез җигелгән киң табанлы, киң үрәчәле чанага төяп куптән түгел генә киселгән зур-зур имән яркалары китереп бушаттылар. Әйтергә генә ансат «бушаттылар» дип. Китерүчеләре дә хатын-кызлар иде, мине инде үзегез беләсез — апаның озын бишмәтен киеп чыгу да әллә ни көч өстәмәде, Хәтирә апа үзе, «маша-алла, бар икән бәрәкәт!» дип, учына төкереп тотынса да, карчык кешедән ни чыкканын үзегез чамалыйсыздыр. Бар күк көчләрен туплап, әлеге шул ике колхозчы хатын, мышкылдады. Кыскасы, ул чи яркаларны бушата-бушата, тәмам чиләнеп беттек. Соңыннан, өелеп яткан яркаларга карап, олаучы хатыннар үзләре дә, бичаралар, аптырап калдылар.

— Бушатуын бушаттык инде, Хәерниса малай, төявен ничек төядек икән бу галәмәтне, икәүдән-икәү генә бит,— диде берсе, үзенә-үзе соклanып.

Һәм алар, Хәтирә апаның: «Берәр чынаяк чәй эчеп, җылынып китегез»,— дип, өйгә чакыруын ишетмәмешкә үк салышып, үгезләрен куалый-куалый чыгып киттеләр. Ишегалды уртасында карда өелеп әлеге чи яркалар калды, үзенең «маша-алла»сы белән Хәтирә апа һәм озын бишмәт итәгенә уралып мин басып калдым. Шундук, бер-беребезгә әйтеп бетермәсәк тә, Хәтирә апада да, миндә дә бер сорау: «Инде моны ничек кистерәбез? Ничек эш итәбез?» дигән сорау иде.

Уйламаган яктан җае килеп чыкты. Шуннан соңгы беренче ял көнне үк, үзе белән тагын ике малай ияртеп, теге көнне минем яшерелгән туфлиемне табып биргән малай килеп керде. Мин хәзер аның исемен белә идем инде, Фоат атлы иде ул. Җиңел кыска бушлаттан, култыгына пычкы-балта кыстырып килгән Фоатны бу килүендә «малай» дип әйтү дә әллә ничек, ул егет сымак күренә иде.

— Минлегөл апа, утыныгызны кисеп китәргә дип килдек, сорагыз Хәтирә ападан: өюен кая өяргә куша? — диде ул, «апа» дип эндәшкән чакта бу юлы да бераз кызаргандай итеп. Хәтирә апаны чакырып торырга да кирәк булмады, ул, үзенең «машалла»сы белән, баскыч төбенә чыгып баскан иде инде.

Малайларда теге вакыттагы шуклыкның әсәре дә юк, эшкә чынлап тотындылар, чынлап эшләделәр — төш авышканчы кисеп, ярып, лапаска ташып, әрдәнәләп өеп тә куйдылар. Соңыннан Хәтирә апа үзенең әлеге дә баягы «берәр чынаяк кайнар чәе» белән бик өтәләнсә дә, яшь җилкенчәкнең синең чәеңә исе китәмени,— әлбәттә, кермәделәр. Мин Фоатка яңадан «апа» дип эндәшергә һәм кызарырга урын калдырмас өчен, аларны үстерергә тырышып:

— Шәп килеп чыкты бу, егетләр. Кайдан башыгызга килде? — дип, үзем сүз куштым.

— Башка килә ул, директор абый кушса,— дип, туры карамаска тырышып кына җавап кайтарды Фоат. Теге икесе, авызларына су капкандай, дәшми калдылар. Теге вакытта, миңа карата этлек эшләп, туфлиемне яшереп куйганда, алар чагыштыргысыз әтәчләр, телләренә салынган нәрсәләр күренгәннәр иде миңа. Бу юлгы тыйнаклыкның сәбәбе булган: директор кушмаганны директор кушты дип мәтәштерүләре өчен шулай әчләреннән тынганнар икән. Соңыннан белдем: директорның монда һич катнашы юк, имеш. Моны белгәч миндә тагын да башваткычрак бер сорау кузгалды: «Ник болай кыланган булулары соң аларның? Һаман мине бәләкәйсетеп, үзенең кулыннан килмәс, акча биреп кистерә алмас» дип мыскыллауларь түгелдер ич? Тагы бер уй килде тиле күңелгә. Теге вакытта, класс алдындагы площадкада икәүдән-икәү генә калган чакта яшергән җирдән Фоат минем туфлиемне алып биргән чакта да кузгалып куйган иде ул уй. Карап алды ич шунда. Моңаеп, инәлеп, гафу үтенгәндәй, «Мине аңла инде, аңларга тырыш инде!» дигәндәй томырылып карап алды ич! Тфү, тфү, карчыклар әйтмешли, аллам сакласын, андый юк-бар уйны башка китерергә ярыймы соң? Мөмкинме соң? Сугыш вакытында. Калаларыңны берсе артыннан икенчесен Гитлерга калдырып торган чагында. Комсомолка башың белән... Кыскасы, миңа утынсыз вакытта, өебез салкын вакытта, Хәтирә апа: «Утын! Утын!» дип колак итемне кимереп торганда рәхәтрәк булган икән. Менә инде утын килде. Утынны кисеп, ярып, өеп киттеләр, Хәтирә апаның тавышы тынды. Ә күңелем элеккедән дә яманрак урыныннан купты.

Мин мәктәптәге эшләремне бетереп кайттым да, кичке караңгылыктан, әлегә өйгә ут алынмаудан файдаланып, караватыма йөз түбән капландым һәм үзем дә сизмәстән үксеп елап җибәргәнмен. Әтинең үлгән хәбәре килгәннән бирле шундый елак бер кызга әйләнә барам— үземне-үзем сөймим бу гадәтем өчен. Әмма бүгенге елавым, ничектер, рәхәт, сәбәбе ачык булмаган, кояшлы яңгыр кебек якты бер елау иде.

— Нәрсә булды тагын? — дип, шундук Хәтирә апа яныма килеп җитте. Ул үзе болай йомшак күңелле булса да, вакыты белән балавыз сыккаларга яратса да, кеше елаганны өнәп үк бетерми иде.

— Өң җылы, утының туралган, паеңа тигән ризыгың килеп тора, бер дә юктан мендәр чылатып, таптың елап ятуны! — дип тезеп китте ул, «утының туралган» дигән сүзләре белән мине тагын да үчекли төшкәндәй.

— Әнине сагындым, шуңа елыйм,— дип ялганларга мәҗбүр булдым, аңардан ничек тә котылырга тырышып.

Кайдан белим ди мин аның шундый беркатлы икәнлеген! Минем шул сүзләремне чынга алып, Хәтирә апа, шомлык, кем артыннандыр Таллы күлгә, минем әнигә хәбәр салдырган. Ике көннән тубыктан кар ерып, күтәренеп, әни килеп житте. Кулындагы төенчеген күргә үк күнелем шомланып куйган иде, тикмәгә шомланмаган икән. Ул карт җүләре, «ашарыңа, ягарыңа ал» дип мин кайтарган беренче зарплата акчама минем үземә шәһәрдәгечә модалап тегелгән пальто сатып алып килгән.

— Алдым инде кибеттә күренгәч. Икенче әллә кайта, әллә юк,— дип акланырга маташты, мин ачулана башлагач.

Ул вакытта, комсомол кешегә алай уйлау килешмидер, дип күңелемә китерергә дә курыккан идем, соңга калып булса да хәзер әйтәм. Гаҗәпләнеп, сокланып, күзләремә бәреп чыккан сөенеч яшеннән кинәнеп, менә хәзер әйтәм: ходаем-аллам, каты бәлаләр җибәрдең кешеләр башына, сугыш кырында әти-абыйларыбыз үлеп калды, тылда тамаклары туяр-туймас килеш ат урынына җигелеп эшлиләр, бер караганда, күнелләр ташка әйләнгәндер кебек күренә иде, юк, әйләнмәгән, кешеләрнең күнелләрендә яхшылык орлыгы гел шытып, гел үсеп торган. Шул яхшы күнелле кешеләр мин бала кошны да урап алган булганнар, канатымны каерырга ирек бирмәгәннәр.

## VI

Бер көнне иртән мәктәп ду купты. Мин «пәри туе»ның үзенә үк барып өлгерә алмадым, мактаныр хәлем юк, мин алай иртә йөрүчеләрдән түгел — элек тә түгел идем, хәзер дә үрле-кырлы йөгерүчеләрдән түгел. Бәлки, соңгарак калып йөрүем бу очракта файдага да булгандыр әле. Ник дисән, минем исемне болай да житәрлек селкеделәр ул көнне. Минем исемне, аннары әлеге дә баягы шул унынчы класс сугыш чукмарларын. Дөрес, бу юлы «спектакль»гә ул классның барлык унике герое да катнашмаган, өчесен генә почмакка бастырдык. Шул өченең бере — теге көнне яшергән жирдән минем туфлиемне табып биргән, аннары әле күптән түгел генә килеп утынымны кисеп-өеп киткән Фоат иде. Яшерми әйтәм, миңа бу җәнҗалга Фоатны тарттырып йөрүләре ошамады, күнелемнең кайсыдыр бер почмагында ул малай ышыклану урыны таба башлаган иде инде. Әмма нишлисең, җәнҗалның уртасында шул герой үзе торгач.

Соңыннан барысы да мәгълүм булды. Фоат кына түгел, үзем килеп житмәсәм дә, мин дә вакыйганың герое булганмын, имеш. Эш моннан гыйбарәт: әлеге шул шайтанлыклары белән дан казанган унынчы класс малайларыннан берсе консерва тартмасына салып буяу, кесәгә генә сыярлык пумаласын тыгып килгән дә минем класс ишегенә:

«Нәнә апа! Безнең класска куч! Имтихансыз алабыз» дип язып куйган. Соңыннан тагын бер эндәш галәмәте өстәмәкче икән дә, аңысына өлгерә алмый калган, бу кулы кычытучы художникның җилкәсеннән Фоат кайтарып алган. Киткән җәнҗал. Юк, җәнҗал түгел, башта әле сорау-җавап кичәсе: /

— Синең нишләвең бу, киермә танау?

— Ә синең ни катнашың бар... каланча башындагы җиз кыңгырау?..

Соңгысын ук әйтмәгән булса, бәлки, эш ул чаклы кызмаган да булыр иде, кайчагында юктан гына да бозылышып китәсең ич. Иван Иваныч белән Иван Никифоровичны ал, Гоголь китабының геройла-

рын, олы яшьтәге алпавытлар, агаем, «Гусак» дигән бер сүздән гомерлек дошманнарга әверелеп китмиләрмени. Фоат дигәнем шул, болай үзе акыллы егет күренсә дә, «Каланча» дигәнне бер дә күтәрә алмый, имеш.

— Юк, син әйт, кемне мыскыл итүең бу? — ди, инде тегенең изүеннән үк эләктереп алып.

— Сине түгел, юкка әтәчләнмә,— ди салкын гына художник, бу юлы бераз шиңә төшеп. Хәтта, эшнең зурга китүеннән шүрләп булса кирәк, үзе язганны үзе кырып бетерергә әзер икәнлеген сиздереп, кесәсеннән пәкесен үк чыгара. Ә Фоатның исә эшне болай гына калдырасы килми. Күрәсең, «Каланча» дигәнгә үтә дә җене чыккан булгандыр, бәрәнге шулпасында торып көннән-көн күккә сузыла баруы өчен ул гаепләмени!

— Юк, син пәке белән түгел,— ди Фоат, теге малайның кулыннан тартып алып,— кулың белән язгансың, тешең белән кыр.

Әйтүе була, теге өндәмә авторының башын ишектәге язуга таба сыгып төшерүе була. Әйтеп тормасаң да билгеле: тегенең дә кул бар. Китә бәргәләшү. Ул арада кулы тик тормаган «художник»ның ике эшнәсе килеп җитә. Китә әүмәкләшү. Кыскасы шул: укытучылар килгәндә класс ишеге төбендә җан-фәрман сугыш, ә ишекнең үзендә әлеге шул: «Нәнә апа!..» дип башлана торган өндәмә лозунг. Майлы буяу белән язылганны тиз генә бетереп буламы соң: көннең-көн буена торды бу язу. Мин, әлбәттә, белмәмешкә салышкан булдым, янәсе, миңа кагылмый. Кагылмыймы соң! Хурланам да, куркам да. Хурланам: ник болай бәләкәй калдым икән мин? Бөтенесенә Гитлер төртеп гаепле. Әтинең сугышта үлеп калуы өчен дә, ашарга такы-токы булуы өчен дә. Куркам — балаларны «Нәнә апа» дип эндәшергә өйрәткәнем өчен Гаффаров абыйдан шелтә эләкмәсә ярый. Югыйсә, тамчы гына да гөнаһым юк, килгән мәлне Сәлимә атлы укучыма гына әйткән идем, әтисеннән хат килмәгәнлеге өчен борчылып, кызчыкны үз күреп, якын итеп кенә әйткән идем, шуннан шул китте башланып. Башта мин моны үз классларымда гына калыр, читкә чыкмас дип уйлаган идем. Чыкмас, бар... Дәресләр беткәнче ишектә янып торды «Нәнә апа».

Бактың исә Гаффаров абый юри бетертмәгән икән ул язуны. Дәресләрдән соң, укучыларны өйләренә кайтарып җибәргәч, ашыгыч рәвештә педсовет җыелды. Укытучылар һәм класс ишеге төбендә сугыш кыры ясаган өч малай чакыртылган.

— Әйтегез әле, зинһар,— дип әкрен генә башлады Гаффаров абый,— директор башым белән белми йөргәнмен: кем ул бездә «Нәнә апа»?

Ул бу сорауны кемгә булса да атап түгел, барыбызга да берьюлы куйды, һәм аның бөтен авырлыгы да шунда: беребез дә җавап бирергә ашыкмый идек. Мин дә, әлбәттә, «Мин ул!» дип чәчрәп чыкмадым. Ах алла, нәнә икәнлегем күренеп тора лабаса, укытучылар арасында иң бәләкәе мин. Хәтта Фоат кебек буйга сузылган укучыларга да үрелеп карарга мәҗбүрмен.

Аннары Гаффаров абый күзләрен бер читтә басып торучы өч «геройга» — өч сугыш чукмарына күчерде.

— Я, егетләр, алайса, инде сезне тыңлап карыйк: ничек аңлатабыз бүген иртәнчәк купкан канлы вакыйганы? Әтиләребез һәм абыйларыбыз сугыш кырында явыз дошман белән кырылышып сугышып ятканда, без монда, җылыда, класс ишеге төбендә өелешеп сугышып ятабызмы? Яхшылап укып, тизрәк кеше булып, чын кеше-гражданин булып чыгасы урында. Я, әйтегез, нинди бүләсе малыгыз бар иде?

Өчесе тын, авызларына су капкандай, сүзсез тордылар. Дөресен әйткәндә, беребезгә дә җиңел түгел иде. Хәтсез дәвам иткән авыр

тынлыктан соң, Гаффаров абый, арада шыксыз рәвештә калкып торганлыгы өчендер инде, Фоатка төбәлде.

— Отличник укучыбыз, менә-менә мәктәпне бетереп чыгасың, я, алайса, Фоат, син җавап бир: кайсыгыз башлады сугышны? Нәрсә бүлә алмаудан китте?

— Мин башладым,— дип, авыз эченнән мыгырданып куйды Фоат. Күренеп тора: аңа чынлыкны әйтү ансат түгел, әмма укытучылары алдында, директор абый алдында ялганлый да алмый иде. Бөтен бите белән, колакларына чаклы кызарып тагын бераз торганнан соң, акланырга да тырышкандай, ярсып та тагы берничә сүзне ярып салды:

— Ә ул кешене мыскыл итмәсен. Ник мыскыл итә?

Кем? Кемне мыскыл итә? Нәрсә өчен мыскыл итә? Күпме генә сораштырып азапланмасыннар, аның авызыннан бүтән бер сүз дә ала алмадылар. Бүтәннәре дә авыз эчләрендә бутка пешерүдән узмады. Аның каравы, укытучылар үзләре ялындырып тормадылар: бер-берсезгә акыл сатарга, бигрәк тә кемне булса да тәртипкә чакырырга дигәндә, без инде тәмам остарып җиткән идек. Шөкер, ул гадәтебезне хәзер дә онытып бетергәнебез юк.

Гаффаров абый нишләтсен, малайлар үзара якалашкан дип ул да якалашырга тотынмас бит. Теге өч малайга, өчесенә бер тигез көч куеп, ишектәге «өндәмәне» бетерергә кушты. Әлбәттә, үгет-нәсихәт, тәртипкә чакыру сүзләрен ул да җәлләп тормады.

Өч малай дигәнебез — директор кабинетындагылары гына өч булган икән, калган тугызы «Нәрсә булыр? Ни белән бетәр?» дип, иптәшләрен кайгыртып, өйләренә кайтып китмичә көтеп торганнар, имеш. Чын буяу белән язылган ул уен сүзләрне кырырга тотынгач, алар бөтенесе дә берочтан эшләделәр, тел ачып уртәшүче булмады — белмим, әллә татулашудан, әллә алда тагын бер бәргәләшү өчен көч җыюлары шулай булды?

## VII

Тагын ни булды? Берни дә булмады. Көн артыннан көн уза торды. Тамак кайгысы, әни кайгысы, ә барыннан да олырагы; туган ил кайгысы, икенче фронт ачылганны, сукыр Гитлерның тизрәк дөмегүен көтү баштан китми иде. Шул ук вакытта авылга әле теге йортка, әле бу йортка этиләренең, я абыйларының үлгән хәбәре кайта торды. Андый хәбәрләр алынганнан соң өйдә ни тамашалар купканын мин инде беләм — эти хәбәрен баштан кичергән кеше. Хәзер исә икенче кабат укучыларым аша кичерәм: өйгә андый авыр хәбәр алынганнан соң укучы кинәт үзгәрә, элек бер-ике көн мәктәптә бөтенләй күренми. Күренгәч, аптырап каласың: бала я миңгерәгән, әйткәнне ишетми, ишеткәнен аңламый, я балага хас булмаганча җитдиләнгән. Тора торгач дәрескә бөтенләй кагылышы булмаган әкәмәт сораулар биреп куя. Шуларның барысы өстенә тагын комсомол нагрузкасы дигәне дә бар. Колхозда агитатор, стена газетасы, бригадаларда «Яшен» чыгарырга кирәк. Уйласам, хәзер дә исем китә: үзең чит авылдан килгән бәп-бәләкәй кыз, кайгыдан, тормыш мәшәкатеннән күзләре чыккан олы яшьтәге апаларны юатырга, дәртләндерергә азапланган буласың. «Нәнә апа» дигән кушаматка инде күнегеп беттем — мәктәптә булсын, урамда булсын, бөтен җирдә «Нәнә апа» да «Нәнә апа».Олы яшьтәге хатыннардан, хәтта карчыклардан да «Нәнә апа» дип эндәшүне ишеткәч, башта уңайсызланган вакытларым да була иде. Булса соң, шундый юк-бар нәрсәдән кылчыкланып тору заманымы!

Тагын ни булды? Ә, әйтергә онытып торам икән, бәла өстенә бәла: тирә-юньдә котырган этләр күбәйде. Моны сугыш җиреннән качып

килгән бүреләр таратудан да күрделәр, ризык җитмәү аркасында этләрнең юньле-юньсез нәрсәгә ташланулары белән дә аңлатып маташтылар, мәгәр иң аңлашыла торган шул: халык телендә өстәмә шом куерганнан-куера барды. Фәлән авылда фәлән кешенең кызы котырган эт тешләгәннән соң кырык көн үрсәләнеп яткан да, докторларның төрлечә чара күрүләренә дә карамастан, имештер, телен аркылы тешләп барыбер үлгән. Икенче бер авылда — андый чакта авылын ачык кына әйтмиләр, бу үзе үк шомны куертырга бер сәбәп булып төшә — имештер, бер котырган этне кабер актарып торган җирендә бәреп үтергәннәр. Бу имеш-мимеш хәбәрләр, әлбәттә, мәктәпне дә урап узмый, бигрәк тә менә малайлар ташлана, һәрхәлдә, аларны андый йогышлы «романтика»дан аерып алып китапка кадаклау укытучыдан өстәмә көч-осталык сарыф итүне сорый иде. Шундый чакта киенү-ясану турында кем уйласын, ди? Әни алып килгән модалы пальто җәймәгә төрелгән килеш чөйдә тик эленеп тора, иске бишмәтем өстеннән шәлем белән уранам да йөри бирәм. Ә шулай да вакыт-вакыт киясем килә модалы пальтоны. Үзем дә белмим, ни өчендер авыл урамыннан бер кеше дә үтмәгәнчә башны югары тотып, карлы юлдан шыгырт-шыгырт атлап бер үтеп китәсем килә. Бигрәк тә Фоатлар өе тәрәзәсе каршыннан шулай үтәр идем. Укытучы апасы белән әле тегеләй, әле болай әкәмәт корып маташмасын, бәләкәй дигәч тә, әллә минем эчемдә җаным юкмы!

Фоат дигәннән, тагын бер оятлы итте ул мине — этисе пинҗәгеннән иңбашы тертәеп чыккан малай. Читен булса да барысына да күнегеп, фатир хуҗам Хәтирә апаның ике сүзнең берендә «машалла!» дип кыстыруын ишетмәскә өйрәнеп, иң истә калырлыгы, классларымны тулаем «яхшы» билгесенә сөйрәп алып килгәндә, яз галәмәте шулай котырттымы, әллә «инде мәктәпне бетерәм, минем койрыкны тиз генә тота алмаслар» дип этәчләнүе булдымы, беребез «А» хәтле, икенчебез «Ә» хәтле дә түгел, тагын очраштык без моның белән. Әле кайда диген? Яланда, үзәннән шаулап кар суы агып яткан бер урында.

Болай ашык-пошык әйткәннән генә аңламассыз, аннары тагын минем ул хәлне ашык-пошык кына сөйлисем дә килми. Болай булды хәл: безнең Алмалы авылындагы «Мулланур» колхозы, үз симәнәсе җитәрлек булмаганлыктан, симәнәлек бодай сорап, күрше «Авангард» колхозына барып егылган. Ничек, кайчан, нәрсә белән түләргә сүз куешканнардыр, ул чаклысы безгә кагылмады, колхоз председателе Басыйрова апа үзе белә булыр. Без белгәне: бер көнне ул безнең мәктәп дирекциясенә гозер белән килгән.

— Җигәргә ярардай барлык аяклы малны ялга куйдык, районнан шулай кушылды, зинһар дип әйтәм, кул арасына керә күрегез, иртәгә якшәмбе өмәсе оештырырга ие исәп, кадәре-хәлчә сез дә кешеләр белән булыша алмассызмы? — диган бу.

Безнең Гаффаров абый ике әйттерә торган кешеме соң! Бигрәк тә шундый авыр язда. Комсомол оешмасы безнең мәктәптә иде ул вакытта, колхозныкылар да шунда йөри, без моны «якшәмбе өмәсе» дип түгел, «комсомол өмәсе» дип атадык. Шундук ашъяулык хәтле игъланы эленде, кыстатып тору юк иде ул чагында, иртәгесен иртүк билләребезне буып, һәрберсе үз өеннән капчыгын алып, төркем-төркем булып киттек «Авангард» ягына.

Ә «Авангард» дигәннәре безгә әйткәндә генә «күршедә генә» икән. Чынында безнең «Мулланур»дан нәкъ унике километр ераклыкта булып чыкты. Язгы ала карда, купшак-юеш юлда, берәр пот бодай күтәреп, бата-чума кайта башлагач, бу унике километр, ачуым да килмәгәе, егерме ике километрга җитте. Һәрхәлдә, баргандагы уенкөлке тавышлары ишетелмәс булды, төркемнәр дә таралышып бетте — хәллерәкләр сер сынатмыйча алдан киттеләр, ял итә-итә калып, кой-

рыкта сөйрәлүчеләр дә артканнан-арта барды. Тагы шунысы бар: ял иткән саен жилкәдәге капчык жиңеләйми, авырайганнан-авырая гына бара кебек тоела иде. Бу чаклысын мин һич арттырусыз әйтәм, ник дисәң, шул койрыкта сөйрәлүчеләрнең берсе мин идем. Югыйсә, әйтмәделәр түгел, әйттеләр: «Сезгә, наный, потны ук тутырып житкермәсәк тә үпкәләмәссез, пот ул, искечә әйткәндә, кы-ры-к кадак», диделәр, «кырык»ны трубадан сузган кебек сузып. Мин моны минем бәләкәйлегемнән көләләрдер дип кабул иттем, озак сузарга ирек бирмәдем:

— Кешегә күпме, миңа шул хәтле булсын, ашаганда кешедән ким ашамыйм,— дидем, кимсетеп караулары өчен юри тупасланып.

Алганда шулай чатылдатып сөйләшсәм дә, кайта-кайта басты: укытучы дип тормый, пот дигәнең чынлап та кырык кадак икән шул! Әле алай гына булса! Житмәсә, ярты юлны узгач, аяк болай да чалышчолышрак атлый башлаган бер вакытта, рәхмәт төшкересе, юри сузып салганнар диярсең, бер үзәнсү жирнең ерганагыннан шаулап кар суы агып ята. Алдыма карыйм — алдагылар киткәннәр, кычкырып ишеттерәсем юк, аннары, аллам сакласын, кычкыраммы соң мин сер биреп. Арттан килүче шулай ук күренми, әллә иң артта калган кеше мин инде. Ялан уртасында үземне болай ялгыз хис итү, бер яктан, куркытты да — шунда, әйтик, үзәннән генә бер ач бүре килеп чыкса! Сугыш чоры, исең китмәсен, бүреләрне дә сыйлап кына тормый торганнардыр. Икенче яктан, бу ялгызлыгым өчен шатланып та бетә алмыйм: ни булса — шул, тәвәккәлләгән — таш йоткан.

Шулай дидем дә, бар көчемне туплап һәм, әлбәттә, өлешемә тигән бодай капчыгын алгарак суза төшеп, ыргыл, Миңлегөл, ерганакның аргы ягына. Узган эшкә салават, яшереп тормыйча әйтәм: таш ук йотуын йотмадым, әмма ташу суын байтак кына йотарга туры килде — өске киемнәремнең манма булып чылануын әйтеп тә тормыйм инде. Беләм, ыргылуын шәп ыргылган шикелле идем, нишләмәк кирәк, ерганак мин чамалаганга караганда киңрәк булып чыккан лабаса! Шунысына шөкер: капчыгымны шулай да ярга ыргытып өлгергәнмен.

Шунда шул, язгы судан ничек кирәк алай мүкәләп чыгып, капчыгым тирәсендә кагынгалап, мәгәр капчыкка кабат кагылырга курыккандай шәбәреп торганда — кирәк бит кешенең шундый ким-хур чагын эзләп йөрергә! — жир астыннан калкып чыккан кебек, әлеге шул Фоат дигән каланча-малай килеп басмасынмы!

— Кагылма, мин үзем,— дип кычкырдым, малай эзләүсез-сораусыз минем капчыгымны күтәреп ала башлагач. Мәктәпне бетерәсе елы, ай ярым, ике айдан ул инде оядан очачак, бәлки шуңа күрәдер, Фоат бу юлы үзен егетләрчә, хәтта эре итеп тота иде.

— Син өшемичә үзеңне алып кайта алсаң, рәхмәт әйт инде, Миңлегөл,— диде ул, нишләптер бу юлы исемем белән атап. Миңа рәхәт булып китте, капчыгымны кеше күтәргәч, жиңел булып калганлыгын әйтеп тә тормыйм инде.

Кайта-кайта күреп алдым, Фоатның үз «социалистик милке» биштәрләп тагылган килеш жилкәсендә бара, имеш.

— Син нишләп соң болай, Фоат? — дидем мин, әллә аптыраганнан, әллә куанычымнан,— син бит алдан киткән идең.

— Китсәм соң. Киткән юлдан кире килеп тә була ич,— диде ул, артына әйләнеп карамыйча гына.

Ул үз йөген дә, минекен дә күтәргән килеш, бер дә исе китмәгәндәй, тиз-тиз атлый бирә, мин буш килеш тә аның артыннан көчкә-көчкә генә элгәшә идем. Шунда, ялан уртасында, язгы кояш астында күңелемнең кайсыдыр яшертен бер почмагы белән сиздем — ояла-ояла сиздем: буйга сузылган ул малайга мин жаным-тәнем белән гашыйк идем.

— Ичмасам, үз капчыгыңны кайда булса да калдырып торган бу-

лыр идең,— әлбәттә, аптыраганнан, сүз югыннан сүз булсынга әйтелде бу. Берсүзсез аның артыннан тырык-тырык кайту, ничектер, уңайсыз иде.

— Калдырсаң, ия чыгар капчыкка. Колхозның чәчүлек орлыгы дип тормаслар.

Ул моны һаман да шулай, миңа борылып карамыйча гына әйтте. Ахрысы, шәбәргән көемдә миңа карамаска, оялтмаска тырыша иде булса кирәк. Кем белгән, бәлки, үзенең шулай миннән оялып кайтуыдыр, шуңа күрә мине ничек тә житкермәскә тырышып тыр-тыр йөгерүе булгандыр? Ничек кенә димик, булды шундый бер көн, кояшлы бер көн!

## VIII

«Нәнә апа» гына булсам да, эшемә ярадым шикелле, үкчәңне ялтырат, дип әйтүче булмады, ә мин ияләшә башлаган эшемнән китәргә жыенмый да идем. Икенче кышны да шул Алмалы мәктәбендә ук калдым. Быел инде эшләр башкачарак, жырлап бардык, жырлап кайттык дип үк әйтмәс идем, шулай да узган елгы тамашалар күпмады, өйдә энине дә карап — утынын әзерләп, елына күрә жылы шулпасын булдырып килдем, барыбызны да тернәкләндергәне: фронтта да эшләр ярыйсы бара башлаган иде. Сталинград тирәсендәге жиңүләр бер канатландырса, киткән шәһәрләребезнең янадан үзебезгә кайтуы турында Совинформбюро, көн саен булмаса да, әледән-әле житкереп тора иде. Ростов, Воронеж, Харьков — боларына инде укучыларым белән кызыл кәгазьдән флажоклар ясап ябыштырып куйдык, әйтерсең аларны үзебез сугышып алган. Тагын шул ягы кызык: бу хәбәрләрне күп вакытта мәктәпкә балалар алып килә, үзем ишеткән-тыңлаган булсам да, алардан ишеткән атлы булып күренергә тырышам. Китә сораштыру, география белән, шәһәрләр һәм чикләр белән кызыксыну. Башлангыч классларда география аерым дәрес булып кермәсә дә, өлкән класс укучылары арасында сүз чыга калса, минекеләр дә кушылып китәргә әзер, тик минекеләрне бик үк кушылдырмыйлар. Сүзләре колагыма кереп кала кайчагында: «Бар әле, кысылма... иренеңнән сөтең кипмәгән», дип кенә жибәрәләр минекеләргә. Ә минекеләр, олыракларга үч итеп, юри күбрәкне белергә, сорашырга, сугышны олыракларга караганда алданрак туктатырга жыеналар. Әллә нихәтле кызыл флажоклары тора запаста, бүтәнен әйткән дә юк, үзара акча жыешып, өр-яңа Европа картасы сатып алдылар — үзләре хужа картага, дәрес башланганчы алдан ук килеп гел шуның тирәсендә кайнашалар. Кыскасы, эшләр жайга салынып бара. Шулай да, нилектәндер, вакыт-вакыт күңелемнең бушап калганлыгын сизәм, мәктәптә ниндидер бер тавыш житмәгән кебек. Теге жәнжаллы класс малайлары юк быел. Бик теңкәмә тигәннәр иде тиюен, әллә, адәм көлкесе, шуларны юксынам микән?

Фоатның бөтенләй күзгә-башка чалынганы юк, мәктәпне онытты малай. Аерып үзе турында гына сораштыруны күңелем күтәрми — кеше әллә ни уйлар. Әмма инде мәктәпне бетергән ул егетләрне телгә ала башласалар, Фоат турындагы сүзләргә аеруча колагым тора. Жәй көне аны, үзенең тәкатьсез калып соравы буенча, шоферлар курсына жибәргән булганнар. Укып чыккан егет. Хәзер кесәсендә шоферлык правасы бар, ди. Тик машинасы юкка гына нишләргә белми йөри, ди.

Хәер, ник көям әле мин аның өчен ул хәтле: булды ни машинасы, булмады ни... Үземнең эшләрем бара, укучыларымның шөгыле шулай ук муеннан: яшь тешләре белән белем гранитын һәм дәреслек почмакларын кимерепме кимерәләр, анның тагы үзләре сатып алган Европа картасы тирәсендә сугышны ничек тә тизрәк туктату юлларын тикше-

рәләр. Эшләр шулай җайлы торгач, мин дә быел киенебрәк йөрергә булдым: узган ел әни алып китергән модалы пальтоның өстенә япкан җәймәсен алдым, аның якасына ошаганрак малахай бүрек сатып алып кидем, мәктәп белән фатир арасында йөргәндә генә аяк өшерлек түгел, җәелгән киез итекне мич башына ыргытып, аякка биек үкчәле, яннан биш-алты төймә тезелгән, җылы эчле драп галош алып кидем — әйтеп карасыннар хәзер «Нәни апа» дип. Соңыннан ишеттерделәр үземә: укытучылар арасыннан көнләшүчеләр дә булган, «Миңлегөлнең аның йөрәгендә ялкын булса да, тәпиенә салкын» дип әйткәннәр, ди, кемнәрдер. Авызына теле сыймаган кеше сөйли бирсен, Миңлегөл әлегә үз тәпиләренә үзе хуҗа. Шулай да менә бу биек үкчәле драп галошларымны, модалы яңа пальтомны, егетләрчә кыңгыр салынган малахаемны киеп мәктәпкә үтеп барышлый, ялгыш кына булса да, теге... кесәсенә шоферлык правосы алып тыккан машинасыз шоферның күзенә бер чалынасы иде, чукынчык!

Булмады, ул турыда хәтта башка китерү дә харам икән миңа. Уйламаган-көтмәгән, әбиләр әйтмешли, тузга язмаган бер бәла килеп чыкты. Болай булды, дип сөйләп китсәм, кайда да булса ялган кысылыр, сүземне экияткә юрарсыз дип куркам. Ничек булганын, бәлки, мин тулысы белән сөйләп тә бетерә алмам, ник дисәң, куркудан үземнең дә өнемне югалткан минутларым булган, бигрәк кинәт, бигрәк уйламаганда килеп чыкты ул бәла.

Кыскасы, уку елына колактан чумып барганда, аянычлы ягы тагы шунда: кышкы каникуллар алдыннан минем бер укучым дәрескә килдекиттелерәк йөри башлады. Килгәндә килә, килмәгәндә эзен дә күрсәтми. Болай да дәресләреннән бик ыргылып бармый торган бу йөгәнсез малай куркыта куйды мине. Бер көнне кич, ашагач-эчкәч, малайның олы-карылары өйдә чакны туры китерергә тырышып, киттем мин боларга. Әмма миңа аларның бусагаларын атларга туры килмәде. Кече капканы ачып ишегалдына атлавым булды, капка белән өйалды ишеге арасына тарттырылган юан тимер чыбыкта, боҗрага эләктерелгән чылбырда үзенә тапшырылган шул мәйданны этке хас бирелгәнлек белән саклаучы бозау чаклы овчарканың миңа ташлануы булды. Укытучы, үгет-нәсихәт белән килгән кеше, заманына күрә ярыйсы гына киенгән, шулай да бу очракта мин чынлап та «Нәнә апа» булып калганмын, дөнья бетереп чырылдап кычкырып җибәргәнмен. Чырылдамассың бар, өстеңә бүре чаклы дәү эт ташлансын да... Җитмәсә тагы, котырган этләр турындагы шомлы хәбәрләр әле теге, әле бу яктан ишетелеп торганда.

Тагы нәрсә булганын аңышып өлгермәдем, куркудан өнем алынган, өйдәгеләр чыгып этне миннән аерганда, үгетләргә килгән Миңлегөлегез бөтенләй телсез, төссез һәм өнсез калган булган. Өнгә килгәннән соң да мин, әлбәттә, бер сүз дә — ачуланып та, өркетеп тә — бер сүз дә әйтә алмадым, сүз әйтерлек хәлдә түгел идем. Эт, каһәр төшкере, яңа алынганлыгы, актык акчама алынганлыгы белән һич исәпләшеп тормастан, минем әлеге биек үкчәле драп галошларымның берсен бишалты төймәсе белән берьюлы умырып алган һәм кереп утыргач сиздем: чәлтер сөягемә хәтле үткәзеп аягымны да умырган — үкчәмә таба җылы кан ага иде.

Мине алар ике култыгымнан алып Хәтирә апаларга хәтле озатып куйдылар, ләкин мин төнгә каршы Хәтирә апа янында гына калырга теләмәдем. Күрәсең, куркуым үтә дә үзәккә үткән булгандыр, мин шул кичне, шул минутта ук әни янына — Таллы күлгә озатуларын сорадым. «Сорадым» дип кенә әйтү йомшак булыр, үз гомеремдә беренче мәртәбә тавыш күтәреп, катгый рәвештә таләп иттем: ни күрсәм дә әни янында, аның күзләренә карап...

Бик үк тиз булмаса да, заманына күрә шулай да озак көттермичә,

чанага күп итеп коры печән салып һәм, кемнеке булгандыр, тире толып куеп, атны китереп тә җиткерделәр. Миңа шул ат белән район больницасына гына китәргә кирәк булган, югыйсә. Күрәсең, минем әнине яратуым, шушы җәрәхәтләнгән килеш әнидән үземне җәлләтергә теләвем үтә көчле булгандыр — соңыннан мин бу адымымны ярату дип түгел, тилелек, яшьлек тилелеге дип атадым, әле дә шулай дип кабул итәм.

Әни мине җәлләп кенә калмады. Хорафатларга ышанучан карчык үзе дә ду купты, минем күңелгә дә шом салды. Китте үзара юраулар. Китте күрше хатыннары белән колактан-колакка пышылдашулар. Китте әллә кайдагы шомлы хәлләрне искә төшерүләр... Шуның да өстенә тагы, имештер, котырган эт тешләгән кешенең шул вакытта өстендә булган барлык киемнәрен янган утка атып яндырырга кирәк икән, шунсыз, янәсе, кеше терелми. Һәм башкалар, һәм әллә ниләр...

Мин бу сүзләрнең җеп очы кая таба сузылачагын ул чагында абайлап та өлгермәдем, хәер, миндә әйбер кайгысы калмаган да иде. Мондый шомлы пышылдашулардан, хәтәр юраулардан төн чыкканчы тәмам туеп, иртәгесен иртүк үз колхозыбыздан район больницасына озаттырдым. Ә күрше хатыннарының пышылдашулары, юраулары, әллә кайчандагы хәлләрне искә төшерүләре минем йомшак күңелле һәм, өстәвенә, чын-чынлап коты алынган әнине өркетү өчен җитә калган. Мин район больницасында чагында әни, беркатлы, кызын, имештер, котырып үлүдән ничек тә коткарып калу нияте белән минем эт тешләгән чакта өстемдә булган киемнәрне — әлеге теге модалы пальтомны, егетләрчәрәк күрсәтә торган җылы малахаемны, берсе аерылган булса да, икенчесе әлегә бөтен калган галошларымны утка атмакчы булып, утынны бер дә җәлләмичә, мич ягып җибәргән. Мичнең кыза төшүен көтеп тора икән... була бит дөньяда өзеләм дип торган гомернең дә өзелми калган чаклары. Минем югары оч Зөфәр абый — әни белән бертуган Хәмдия апаның малае — килеп кермәсенме! Сугышта аягы яраланып кайтканнан соң, колхозда ветсанитар булып эшли ул, муенына гел сумка асып йөри, сумкасында кайчыдыр, пычактыр, марлядыр, төрле порошоклардыр тулып ята, үзеннән һәрвакыт хлор исе аңкыр. Бик тә тәвәккәл кеше Зөфәр абый, аллага, җен-париләргә ышанмый, муенындагы сумкасы, сумкасындагы пычаклары, порошоклары исән булса, бертөрле дә чирне якын җибәрмәслегенә чын-ихластан ышанган. Болай үзе әнине бик хөрмәт итсә дә, аның хорафатчыл булуын, коткыга тиз бирелүен бер дә өнәми. Шуның аркасында алар арасында еш кына җил-давыл да купкалап ала иде.

...Әйе, мичнең кыза төшкәнен генә көтеп торганда килеп керә әлеге шул Зөфәр абый. Теге дә бу. Хәл ничек тә, хәл шундый. Җәлт әнинең нишләргә җыенуын сизеп ала бу — башлы кеше шул. И шундук аның кулыннан менә-менә янган мичкә атылырга торган төенне тартып алмасынмы.

— Нишләвең бу, тиле Дәү апа?! — дип кычкырып җибәрә әнигә.— Шундый затлы малны әрәм итәргәме? Ычкына башладың мәллә? Бир үземә, миндә хлоры да, карболкасы да житәрлек. Җен-пәри, чир-зәхмәт исен сизеп ун километрдан борылып кача. Терелеп кайтсын менә Миңлегөлең, үзем кулына китереп бирермен. Түльке ни, Дәү апа... яртыны кую шарты белән...

Шулай янмыйча кала киемнәрем!

## IX

Ә үзем — дөресен әйтим — чак кына янмыйча калдым! Куркуым да тирәнгә киткән булгандыр, әни бичараның күрше хатыннары белән бергәләп пышылдашулары, юраулары, тирә-юньдә котырган этләр

күбәюе турындагы имеш-мимеш хәбәрләр, котырып үлгән кызны искә төшерүләр дә эзсез калмады бугай, тагын шунысын да әйтергә кирәк, мин үзем дә ул чагында әле бала гына идем, эчке шомлануларым белән бергә ничек җил очырып алып китмәгән! Башланды йокысыз төннәр, йокы аралаш кычкырып җибәрүләр, тора торгач әнине сагынып, өйне сагынып елап җибәрүләр, тәмам тамактан калдым, биргән ризыкларыннан нафталин исе килгән төсле тоела иде. Иң курыкканым — үлем, мин үлсәм, әни кем белән кала, Хәтирә апаның малаена кем хат язар, хәтта, тилерә башлау түгел диген, өйдә калган песиебезгә хәтле кызгана башладым — әни колакка сагаеп бара, ишек төбенә килеп мыяулап торганда, ул мәхлукны кем ишек ачып кертер... Әйтеп үк бетермим, күңелемнән уйларга да оялам, ә шулай да бәйләнчек бер сорауның күңелдән киткәне юк: алай-болай булсам, хәлемне белергә Фоат килерме икән?

Әлбәттә, район больницасында гына мине аякка бастыра алмадылар, анда яткан көннәремдә тилерә үк башламасам да, шуны бик ачык шәйләдем: врачлар тыштагы авыруны белсәләр белә торгандыр, ә эчтәге авыруны, күңелнең өзлексез шомлануын пычагымны да белмиләр икән. Ахыр килеп, мине бер сестрага һәм үзем укыта торган мәктәпнең завхозы Кыям абыйга тагып Казанга — психотричкага озаттылар.

Андагы хәл-әхвәлләрне барысын да искә ала китсәң, алла сакласын, котырмас җиреңнән котырырсың. Иң кызыгы бигрәк тә шунда: анда миннән дә битәр, мине талаган эт белән кызыксынудан тотындылар: янәсе, котырган этме, әллә котырган эт түгелме? Әйтерсең аның котырган яки котырмаган булуына карап кына мине тиз генә борып кайтарачаклар. Ахрысы, мин чынлап та бераз «тегеләерәк китә» башлаган идем түгелме икән, шунда шул, йокысыз төннәр, өзлексез баш авырту, әнине сагыну, укучыларымны, мәктәпне күз алдына китерү белән берлектә, әллә кайдан гына әлеге шул мичкә атыла язып калган пальтом һәм башыма бик тә ипле малахаем искә төшеп тинтерәтә иде. Мине китерә килгән Кыям абзыйга рәхмәт, бер генә түгел, мең мәртәбә рәхмәт: өзеп әйтте, «Башымны кисмәгә бирәм, Сәгыйрьләрнең этләре котырган эт түгел, көне-төне чылбырда — бәйдә торып, ишегалдыннан беркая чыкмыйча, нишләп котырсын ди ул?! Әйт син әнә безнең читавыт Галәвине. Котырса ул котырыр ие, көне-төне ирсез хатыннар артыннан чаба». Мин җор сүзгә бөтенләй үк томана кеше түгел, ул чагында да аңлый идем. Кыям абзыйның гадәтенчә уен-көлке кыстырып әйткән бу сүзләренә әллә ни шаккатмадым, ләкин, дөресен әйтим, аның бу шук сүзләреннән ниндидер бер сулыш кагылгандай булды миңа: «Әнә бит... исе дә китми Кыям абзыйның, уенга әйләндерде дә куйды минем чирне... Бәлки, чынлап та, врачлар гына бүрәнә аша бүре күрә торганнардыр». Тагы шунысы өчен дә рәхмәт Кыям абзыйга. Киткән чакта минем үземне генә бер читкә алып барып әйтте. Бу әйтүендә бер дә шуклык кыстырмыйча, чын-ихластан әйтте, тавышыннан ук ишетергә мөмкин иде: «Син, кызым Миңлегөл, тамчы да борчылма, врачлар әйткәнен тыңла, биргән даруларын эч, иллә-мәгәр, кот очарлык чирем бар дип гупчи да уйлама, үзеңне нык тот, терелгәчсең, алла боерса»,— диде. Аның, гади бер авыл агаеның, минем этигә дә абзый була алырлык олы яшьтәге кешенең шулай ышандырып, шундый ихлас күңелдән әйтүе мине яхшы ук терелтеп җибәргәндәй булды.

Кыям абзыйның «башын кисмәгә биреп» әйтүе генә врачларны, әлбәттә, ышандырмады. Котырган этләр күбәю аркасында аларның бу эштә җитди тәҗрибәләре бар иде булса кирәк. Соңыннан мине тешләгән этнең канын алдырып, анализ нәтиҗәсен дә китерттеләр. Мине төрле-төрле дарулар белән дәваларга тотындылар, көненә берничә

төрле укол кадыйлар, тәнгә каршы йоклата торган дарулар бирәләр, көндезләрен, вакытларын жәлләмичә, озаклап-озаклап сөйләшеп утыралар, әни турында сорашалар, әтине искә төшертәләр, сөйләтәләр, янәсе,ниндирәк кеше иде әтиең? Урта буйлымы, зур гәүдәлеме, киткәндә сиңа нәрсә диде? Күтәргә куштымы? Мин, әлбәттә, артык сөйли алмыйм, яшемә тыгылам. Аларга, күрәсең, артыгы кирәк тә түгел. Ак чәчле өлкән врач зур кулларын минем иңбашыма сала, текәлеп күзләремә карап тора, озаклап карап тора, аннары тынычланырга, кереп ятарга кушып, китеп бара... Башкасын әйткән дә юк, бер вакыт мине бөтенләй балага әйләндереп, чылатылган жылы одеаллар белән билләп яткыра башладылар. Шундый рәхәт, шундый изрәтә, башны бер читкә алып куялар диярсең, дөнья гаме оча: булганы да, булачагы да. Эреп йоклап китүеңне үзең дә сизми каласың.

Мине беренче отделение дигәннәренә салганнар иде, янәсе, бусы иң жиңеле. Дөрес, монда күбесе минем кебек сынау үтүчеләр ята. Шулай да әйтмәс идем курортта яттым дип. Утырган жирдән баш селкеп утыручылар, үзе белән үзе мыдыр-мыдыр сөйләнүчеләр, караватлар арасындагы юлдан бертуктаусыз йөренеп торучылар монда да юк түгел иде. Тәрәзә рамнарының тимердән булуы, ишекләрнең кергәнчыккан арты «шарт!» итеп бикләнеп калуы үзе генә дә күңелгә шом салырга житәрлек. Күңелнең шом керердәй урыны калган булса, әлбәттә. Төнлә саташып кычкырып жибәрүләрне, торып, караватында үзалдына елап утыручыларны әйткән дә юк инде.

Боларына түзәргә дә була, күнегеп тә килә идем инде, бер дә бер көнне сакалы биленә житкән бер агай гашыйк булды үземә.

— Котырган эт тешләсә, аның бәласе егерме тәүлек. Егерме тәүлек үткәнче котырмасаң, аннары шабаш,— дип сөйләнә башлады бу, прогулкага чыккан жирдән яныма килеп.— Аннары котылдым диең. Аннары, үзең каршы килмәсәң, мин сине хатын итеп апкитәм. Минем болай бер чирем дә юк, колхоз прсидәтеле мине үчлек белән китереп тыкты.

— Мин бит бәләкәй, минем кай жирем сиңа ошый соң? — дип, юри ирештерәм тегене. Каты бәрелсәң, ярамый — «чирем юк» дип торуы үзе үк күрсәтә, чире ничек кенә әле! Минем шулай йомшак сөйләшүне ишетеп бу, бичара адәм баласы, бөтенләй эреп китә. Кырынмаган йөзе тоташ жәелә, башын кая куярга белмәгәндәй, читкә борыла. Аннары, балалар кебек кызарып, курка-курка гына әйтә, һаман шулай читкә борылган килеш әйтә:

— Миңа синең борының ошый,— ди пышылдап. Анысына башы житә, гыйшкын аңлатканны кешегә ишеттерергә теләми.

Прогулкадан керешли, көзгегә күз төшерәм — чынлап та, минем борыным шулай кеше күзе төшәрлек матурмыни соң! Еларсың да, көләрсең дә. Әллә, ходаем, бу жиңеләя башлаган кешеләр арасында ятып чын-чынлап жиңеләеп барам инде. Ахырында үземнән үзем көлеп мондыйрак нәтижә чыгарып куям: «Котырсам, егерме тәүлек тулганчы тизрәк котырып калырга иде, юкса, теге Сакалбайның хатын итеп алып китүе бар... Белмәссең бу бикле ишекләр артындагы дөньяның!»

Көн артыннан көн уза, мине әлегә чыгарабыз дигәннәре ишетелми, врачлар сөендерүен сөендерәләр, эшең яхшыга бара, дигән булалар, ләкин үзем сизәм: үз борыным белән үзем тикмәгә генә мавыкмый торганмындыр.

Һич көтмәгәндә, шифаның да шифасы булып минем янга Фоат килеп чыкты. Әйтүенә караганда, колхоз председателе Басыйрова апаны Казанга ниндидер киңәшмәгә алып килгән. Кирәк-яракларны да карыйсы бар, әле берәр көн торырбыз, дигән була. Якшәмбе көнне очрашырга мөмкин икәнлекне алдан белеп, сорашып килгән. Янымда

утыра, үзе рәтләп бер сүз дә сөйләми. Сорасаң, җавап бирә, үзе башлап бер сүз кушмый. Колакларына чаклы кызарган.

— Нәрсә соң бу кулыңда әвәләгәнең? — дим, кулындагы бәләкәй генә төенчеккә ишарәләп. Бичаракаем, үзе нәрсә алып килгәнен, ник алып килгәнен дә оныткан.

— Ә... мин аны колхоз базарында алган идем, әчтәрхан чикләвеге... Мә, сиңа күчтәнәч...

Моны биргәндә ул шул хәтле уңайсызланды, теле тотлыкты бичараның, шулай да сузды. Ничек алмыйсың инде шундый күчтәнәчне! Ничек терелмисең инде шундый күчтәнәчтән соң!

Ул көнне әллә ни сөйләшә алмаган идек, икенче көнне, очрашу рөхсәт ителмәгән көнне, колагым ялгыш ишетә, саташам дип торам, безнең палатаның тәрәзәсе каршына килеп баскан, кычкыра бу:

— Миң-н-ңлегөл! Бу — мин. Тәрәзәгә кил. Күрен бер,— дип кычкыра.

Ике кат тәрәзә аша, тимер рамнар аша нәрсә сөйләшәсең, күренүен, әлбәттә, күрендем. Берсүзсез күзгә-күз карашып тордык, озак карашып тордык. Тәрәзә аша булгангамы, бүген ул үзен кыюрак тота иде. Һәм кичәгегә караганда чибәррәк тә түгел идеме икән әле? «Бала-чага булма, Миңлегөл. Сөйләш врачларың белән. Терелгән инде син, кайт авылга!» — дидем мин үземә-үзем. Шикләнмичә әйттем, өздереп әйттем. Фоатның рәттән ике көн минем янга килүе, чынлап та, мине тәмам терелтте, куркуларымны, шөбһәләремне кул белән сыпырып ташлаган кебек булды.

## X

Мин Казанда дәваланып яткан арада Фоат монда бер яхшы эш, бер тилелек эшләп ташларга өлгергән икән! Яхшы дигәнем шул: күрше колхозның бер ташландык машинасы тирәсендә ун көн буена, шунда куна-төнә мәш килеп казынганнан соң, ничек кирәк алай рәткә кертеп, тәки аякка бастырган. Күрәсең, праволы, ләкин машинасыз шофер булып йөрү туйдырган егетне. Теге вакытта минем янга килгәндә ул моны әйтмәгән иде, шайтан, бактың исә ул килүе дә баштук Басыйрова апа белән булмаган, шул корама әрҗәсенә запчастьләр эзләп йөргән. Ә кем белә, бәлки, запчасть дигәне дә сылтау гына булгандыр әле, юри мине күрү өчен килгәндер. Яшермим, шулай уйлау минем үземә рәхәтрәк тоела иде.

Больницадан кайтып, атна-ун көн узганнан соң гына мин моның безнең урамнан узганын күреп калдым: машинасы болай, калтыр-колтыррак булса да, йөри... тәгәри дигән сүзем. Калтыр-колтырына түзәр дә идең — анысын инде ишетми дә башлаганнар — әмма начар бер гадәте бар: ун метрдан ун метрга кай җире беләндер бер дөпелдәп куя. Авыл кешеләре көләргә оста бит, сугыш чоры, авызыбыздан бәрәңгебез күренә дип тормыйлар. Янәсе, метрына хәтле санаганнар — нәкъ ун метрга бер мәртәбә, артык та түгел, ким дә түгел. Аннары «дөпелдәп» кенә дә түгел, ат кебек йөрәк кага, имеш.

— Әнә китте Тажи Фоатының йөрәк кага торган айгыры, безгә дә чабата башларын бора башларга вакыттыр,— дип сөйләнеп калалар, имеш, машина узып киткәнен күрсәләр. Машинаның болай «йөрәк кагуына» Фоат үзе дә әрнеми булмагандыр, әлбәттә. Бер дә бер көнне моның бер очы килеп чыкты, ләкин анысы турында соңыннан. Аңа хәтле мин юкта эшләгән тилелеген сөйләргә булдым ич әле мин — әйтеп керешкәнне онытмагансыздыр дип уйлыйм.

Сез тагы Фоатның үз авызыннан ишеткәнне житкерә бу дип уйлый күрмәгез — Фоаттан андый серне алырсың, бар. Аннары тагы ул

эшне кеше саен селкеп йөрү Фоатның үзе өчен дә файдалы булмас иде — Сәгыйрьнекеләр бик тә уч саклаучан астыртын кешеләр. Моны миңа безнең мәктәпнең завхозы, әлеге мине Казанга — психотричкага озатышкан Кыям абзый сөйләде һәм соңыннан бик нык кисәтте.

— Иллә, вәгъдә алтын... авызың тишек булмасын, кызым, якын итеп кенә сөйләвем... Сине дә, кайнишне дә якын иткәннән,— диде, күз алдымда имән бармагын бик нык селкеп. Ачуым да бер килмәгәе, әле дә күз алдымда тора аның ул кара тырнаклы имән бармагы.

Бактың исә, Кыям абзый дигәнебез Фоатка җизнә тиешле кеше, имеш. Аннары тагы бер фактны белеп китегез: Фоатка җизнә туры килә торган шул кеше, әлеге Кыям абзыйны әйтәм, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дигән караштан чыгып, буш вакытларында мылтык күтәреп сунарга да йөргәли, имеш. Нинди дә булса җәнлек тотып яки атып кайтканын күргән-белгән кеше юк икән юклыкка да, әмма сунарчы дигән аты чыккан. Рас сунарчы, димәк, мылтыгы бар инде моның.

Килгән бер көнне Фоат моңарга, башын иеп кенә бусагадан атлаган. Башын ими хәле юк, йомышы төшкән җизнәсенә, аның мылтыгын сорарга дип килгән.

— Мине ишегалдына апчыгып әйтте йомышын. «Биреп тор, җизни бәгырем, мылтыгыңны, гомердә онытмам бу изгелегеңне», ди. Җыламый гына егет. Значится, нәрсәдер бар шүрлегендә.

Шулай сөйләп китте Кыям абзый. Әйтерсең шикләнүе бүген дә басылмаган, тавышын кысып кына сөйли. Бермәл ирен нәрен чәпелдәтеп торганнан соң (шундый гадәте бар Кыям абзыйның!), янә ялгап алып китте бу үзе белгәнчә:

— Бирүен бирдем, бирми булмый, чыбык очы ботак кына булса да, җизни тиешле кеше. Әмма күңел шикләнә: «Ни кыйратмакчы бу егет мылтык белән», дим эчемнән. Мылтык бит, уен түгел, үзең беләсең. Берәр нәмәстәкәй була-нитә калса, алла сакласын, кем ответ тотарга тиеш мылтык өчен? Кыям-каракаш ответ тотарга тиеш.

Үзем капканы ачып озатып калдым егетне, үзем күздән ычкындырды юк. Караңгы булса да, күләгәсен шәйләп артыннан барам. Бу атлый мыштым гына, мин аңардан да мыштымрак. Барабыз шулай Агылый белән Тагылыйдай җепкә тезелеп. Барды-барды да бу, Сәгыйрьнекеләр турына җиткәч шып туктады. Мин дә, кәнишны, шып! Торды бу, байтак торды, әмма башы түгәрәк икән, туп-туры капкага барып сугылмады. Туп-туры капкага сугылса, бәлә нәрсә булачагын. Тегеләр дүрт аяклы дәҗҗал «хап» итәчәк бит моны, мылтыгың бар дип тормас, знамо шулай.

Но минем кайниш тә башлы малай булып чыкты — хет алды, хет арты, әйтми булдыра алмыйм. Тегеләрнең тыкрык буенда, келәт белән койма арасында кысылып кына үтәрлек бер аралык бар, имеш. Күрәсең, көндездән үк чамалап йөргән иблис. Шуннан, әлеге шул аралыктан, «ыжт!» бу ишегалды ягына. Күләгәсе дә калмады минем күз алдымда, тик калдым басып. Кеше очраса әллә ни уйлар, Кыям хәтле Кыям, завхоз башы белән, урам уртасында янган баганадай басып торсын әле. Хәер, озак баш ватарга туры килмәде, кайниш маладис икән, гөрес бу берне. Этнең тик чинаган тавышы гына ишетелеп калды. Тегеләр алай-болай иткәнче, шылт бу шуып кергән аралыгыннан и сыптыр тыкрыктан су буена... Әйтәм ич, генпланны алдан ук сызган булган бу. Ә мин урамнан өй якка таба, миңа су буйлап чабуның хаҗәте юк, этка аткан кеше мин түгел. Иллә-мәгәр, шунысы өчен куандым: мылтык шәп икән, малай, яшерен-батырын түгел, ни күтәреп йөреп, үземнең атып караган юк ие. Янә килеп шунысын да әйтми булмый: кайниш тә куллы егет икән — хет алды, хет арты. Тәки алды бит синең үчне, кеше чаклы кешегә ташланмасын, знамо шулай кирәк.

Иртәгесен бөтен авыл ду купты: имештер, Сәгыйрьнекеләрнең этләрен атканнар. Китте төрлечә юрау:

— Ат каракларының эше бу, тикмә түгел,— ди беришесе.

— Хуҗалыкта ат бармыни хәзер, иске тормышыңа барасың,— дип тегенең авызын томалый икенчесе.

— Таптыгыз сүз: эт җәллләп торган буласыз — дөнья котырган эт белән тулган бер чакта. Тегендә әнә, фронт якларында, кешеләр кырыла, шуны әйтегез сез.

Моныкы да дөрес, билгеле. Иллә-мәгәр, этне атарга да кул кирәк бит, малай. Ат та и шундук эзеңне дә җуя бел. Кайниш егет икән, ничу, магарич куярсың моның өчен. Икенче көнне, тоже караңгы капкач, килгән бу, мылтыкны китерә килгән. Җизнәсен ирештергән була:

— Починкага, тугымга барышлый кыстыра барган идем, берәр куян очрамасмы дип.

— Очрамадымыни? — дигән булам, бу юлы инде мин аны ирештереп.

— Очрады,— ди бу, җизнәсе күзенә текәлеп карарга кыймыйча гына,— атмый икән лә синең бу мылтыгың.

Ул туры карамаса, мин туры карыйм моңа, көлеп җибәрәсе, но көлмим, көлмәскә тырышам. Аннары зур яңалык турында хәбәр итәргә җыенган бер кыяфәт белән сорыйм:

— Ә син ишеттеңме соң әле?

— Нәрсәне?

— Нәрсәне булсын, Сәгыйрьнекеләрнең этләрен атканнар. Кичә төнлә.

— Кит әле! — ди бу, дуамал исе киткән кешедәй кыланып,— теге укытучы Сәрьянованы тешләгән этнеме?

Илла мут та соң егет, чыгара каһәр, килештереп чыгара, артист кына буласы. Йөрәк кагып йөри торган иске әрҗәдә шофер булып этләнгәнче.

Ә мин, үз чиратымда, нәкъ шундый мәгънәдәге сүзләрне күңелемнән Кыям абзыйның үзенә әйтәм: и хәйләкәр-хәтәр кеше дә син, Кыям абзый җаным! Күзләреңнән күреп торам: кайнишеңне ничек тә миңа матур итеп, яхшы яктан күрсәтмәкче буласың. Кирәк микән мондый тырышлык? Ялгышмасам, без аның белән бер-беребезне болай да белә башладык кебек инде. Дөрес, шофер булып эшли башлаганнан бирле, Казанда ике тапкыр күрешкәнне искә алмаганда, аның миңа күренгәне юк, ничектер, юри күренмәскә тырышкан кебек йөри. Бәлки, миңа гына шулай тоеладыр, күп уйлаганныкы. Ә белүен, аллага шөкер, беләбез, беләбез, Кыям абзый җаным! Мут түгел синең кайнишең, киресенчә, мутлыкны-хәйләне белми торган, чын йөрәкле, хәтта бераз тилемсәрәк егет. Мин аны нәкъ әнә шул тилемсәлеге өчен яратам да.

## XI

Фоатның мин юкта эшләгән бер тилелеге турында сөйлә дәм инде. Бу тилелекнең кем өчен, ни өчен эшләнгәнлеген бер кем дә, хәтта мылтыгын биреп торган Кыям җизнәсе дә юньләп абайламый калды шикелле. Ә мин шундук абайлап алдым: барысы да шушы кулга йокмас бәләкәй Миңлегөл өчен эшләнде, әллә белмимме. Кешегә бу турыда, әлбәттә, ләм-мим, ә үземне-үзем буташтырырга кирәк тапмыйм. Сәбәпләре бар шулай уйларга. Узган ел мәктәптә чакта ук белдерә башлады сәбәпләрен. Унынчы классның унике башкисәреннән унбере авызына су кабып калганда, яшергән җирдән минем туфлиемне алып бирүе шулай уйларга сәбәп түгелмени? Тора торгач, беркем кушмыйча, минем утынымны кисеп, ярып, өеп китүләре әллә мине уйландырмады дип белә-

сезме? Аннары тагы күрше «Авангард» колхозыннан симәнә алып кайтканда борылып килеп мине каршы алуы, йөгемне күтәреп кайтуы... Аннары килеп, мин Казанда психотричкада ятканда ике мәртәбә килеп хәлемне белүе. Күчтәнәч итеп китергән әчтәрхан чикләвеген әйтеп тә тормыйм инде, яртысы кортлы булып чыкты чикләвегенең, яшь кеше, чикләвек бакчасында үсмәгән, ала белеп алгандыр дисезмени! Ә менә мин кайтканнан соң күзгә-башка чалынмый йөрүләрен башта һич кенә дә аңламадым. Кешегә-карага ишеттермичә генә әйтсәм әйтим: минем аны күрәсем, чынлап торып бер сөйләшәсе килгән минутларым бик күп була, ничек юксынуымны үзем генә белә идем. Әйтсәм, тагы шул чаклысын да әйтим — узган эшкә салават: минем чын-чынлап тилерә башлавым эт тешләгәннән түгел, хәтта психотричкада ятканда сакалы биленә житкән абзыйның минем борыныма гашыйк булып, мине үзенә хатынлыкка алып китәргә жыенуыннан куркып та түгел, минем чын-чынлап тилерә язуым больницадан терелеп кайткач, Алмалыга кайткач, Фоатны өзелеп күрәсем килеп тә, ул кире беткәннең миңа күренмичә йөрүеннән соң булды. Нилэр генә уйлап бетермәдем мин аның турында!

Соңыннан аңлап алдым: аның күзгә-башка күренми йөрүенең шулай ук бер сәбәбе булган икән. Бер караганда, аңлашыла да. «Йөрәк кагып йөри торган машина» бит, машинасыннан бөтенесе авыз ерып көләргә тора. Димәк, ул, мөгаен, уйлагандыр: бүтән кешеләр көлгәнне, Миңлегөл, янәсе, көләчәк тә көләчәк. Ә егетнең горурлыгы көчле. Үзеннән көлгәнне күтәрә алмый. Менә шушы хәл аны, хәзер инде үзен кызганып «бичара» дим, соңгы иң зур тилелеккә, безнең ике ара мөнәсәбәтебездәге саф хисләрне чәлпәрәмә китерерлек дуамал тилелеккә алып барган да булса кирәк. Әгәр моны «тилелек» дип кенә әйтергә яраса?

Ә эш болай тора: көннәрдән бер көнне Алмалы авылыннан унбиш километрдагы Астанково станциясенә — комбикорм алырга барган жиреннән безнең бу шофер егетебез, үзенең теге «йөрәк кага торган» машинасын калдырып, икенче бер автомашинага утырып кайта. Яңалыкка бусы да әллә ни яңа машина түгел — үзегез чамалый торгансыздыр: рәтлерәк машиналар фронтта иде ул елларда. Шулай да бусының «йөрәк какканы» ишетелми, бортлары да ул хәтле кырылмаган-сугылмаган, радиатор дигәне дә гөжләп тора, имеш. Мактана алмыйм, мин үзем машина мәсьәләсендә сукыр кеше, машинаны ирләр эше дип карыйм, ул чагында да шулай иде, хәзер дә ул карашымны үзгәрткәнем юк. Соңыннан зур жәнжал белән беткән бу машина бәхетсезлеген миңа ахырдан житкезделәр. Ә безнең Басыйрова апаны Канат Миңлегөл рәтенә куя алмассың — сугыш башланганнан бирле колхоз председателе булып йөреп, утны судан, хәрамны хәләлдән аерырга өйрәнгән кеше. Кыйшык эш барын сизсә, тешләгән жиреннән өзә, характеры шундый.

Фоат станциядән кайтып, амбарлар алдына килеп туктау белән, исәнме юк, саумы юк, төяп кайткан бәрәкәте өчен дә куанырга ашыкмый, кеше аты тирәсендә бөтерелгән чегән кебек, машина тирәсендә әйләнгәләргә тотына бу. Бер әйләнә, ике әйләнә, аннары кабинада посып утыручы Фоат каршына килеп туктый.

— Ну-ка, егет, төш әле тәхетеңнән,— ди коры гына. Ачуланганын да сиздерми, тавышын да күтәрми, хәтта күзләрен дә күтәреп карамый. Аның белән очрашкалаган кешеләр беләләр, без укытучыларга әллә ни еш очрашырга туры килмәсә дә, без дә беләбез: күтәрелеп карамыйча гына эндәштеме Басыйрова апаң, бетте инде, рәхим-шәфкать көтмә. Төшерә шофер егетне машинадан, биетә башлый шофер егетне машина тирәли әйләндереп. Бер әйләндерә, ике әйләндерә, бортына суккалап карый, радиаторны сыпырып уза һәм кинәт Фоатның

күзенә керердәй булып тукталып кала. Һәм куя сорау, без кебек үтәли тишеп керә торган сорау куя:

— Бу кем машинасы?

Фоат бичара нишләсен, бер агара, бер күгәрә, ык-мык, шулай да сүзсез калмый, авыз эченнән генә мыгырдана.

— Ни... Таһирә апа, нишләп әле мондый сорау: номерына кара — дип сүз башлый аптырагач.

— Номерын күрәм. Номеры безнеке,— ди Басыйрова апа, бу юлы инде тавышын яхшы ук күтәрә төшеп,— ә машина безнеке түгел.

Фоатка артык сузарга бирми, мәсьәләне кабыргасы белән куя:

— Машина безнеке түгел. Бүген үк үзеңнекен апкайт, кешенекен илтеп бир. Моңа тиклем безнең колхозның урланган малны җыйганы булмады, моннан соң да андый эшкә юл куелмас.

— Урланган түгел, честное слово,— дип тилмереп карый Фоат, Басыйрова апаны ничек тә йомшартмакчы булып,— килешеп эшләнгән эш. Мин үз кесәмнән чыгарып өстәү бирдем, хәләл акчамны, панимаешь. Шоферын сыйладым.

Безнең Басыйрова апаны мөгрәп кенә йомшартырсың, бар. Сөйләп торырга да бирми тегеңә.

— «Хәләл» дигән булып авызыңнан чыгарасы булма, әйткәнне тыңла: бүген үк илтеп куй, үзебезнекен бүген үк апкайт.

Һәм шуның белән китә үк башлый. Аңлашыла, озын сүзгә урын юк: приказ үтәлгән булырга тиеш, приказны тикшереп тору юк. Урта мәктәп бетергән, аннары Алабугада шоферлар курсы үткән һәм, гомумән, яхшы ата-ана баласы Фоат әллә моны аңламый дисезме. Аңлый, бик аңлый, әмма эшләнәсе дуамаллык инде эшләнгән. Күзендә яшь бичараның — тилелек эшләгән икәнен белсәм дә «бичара» дим; чөнки сизәм: барысы да минем аркада эшләнгән эш. Күрәсең, «йөрәк кага торган» машинага утырып йөрүне артык күтәрә алмаган, минем күзгә башка чалынмаска тырышып йөрүе дә шуннан булгандыр әле байгышның.

Миңа тагын шунысын җиткерделәр: Басыйрова апа артыннан тагылып барган Фоат, кеше күзеннән ераклаша төшкәч, председательнең каршына чыгып аны туктаткан. Бу юлы инде һич тә мөгрәп тормыйча, тегенең үзе кебек кистереп әйткән:

— Машинаны беркая да илтә алмыйм, Таһирә апа,— дигән өзеп,— үзем эшләдем, җавабын үзем бирермен. Килеп алыштырганчы торсын.

— Ихтимал, килеп алыштырганчы без аннан файдалана да торырбыз? — ди Басыйрова апа, сабый бала хәлендә калган шоферыннан мыскыллы көлеп. Аптыраганнан инде бу көлүе, бер үк вакытта шоферы да кызганыч. Белеп-күреп торды ич: үз тырышлыгы белән җыйды теге «йөрәк кага торганын да». Белеп үк бетермәгәнен Фоат үзе әйтә, бу юлы инде һич мәлҗеп тормыйча, ачыктан-ачык әйтеп бирә:

— Мин аны кая илтергә икәнен белмим, Таһирә апа, мин аны станциядә алыштырдым. Үзара сөйләшеп, килешеп алыштырдык. ГАИ кешеләре килеп, эшнең очына чыкканчы торсын.

Ни булса шул: машинаны колхозда калдыралар, ләкин берәүне дә утыртмыйлар, ачкычын Басырова апа үз кесәсенә алып тыга. Шуннан соң шофер егетнең хәле җиңеләйде, ул Миңлегөлләр урамында җәяүләп булса да гел бөтерелеп йөрергә тотынды, дип уйлыйсызмы? Шулай булмаган кайда! Шуннан соң Фоатны, тиле күркәне, авылда гомумән күрүче булмаган, миңа ишеттерүләренә караганда, ул урамга бөтенләй чыкмас булган.

Әле ярый, башка кешеләр үз урыннарында сизгер утырганнар икән, егетнең өйдәге «тоткынлыгы» озакка сузылмады, «ГАИ» кешеләренең булышлыгы белән, Фоат алыштырып алып кайткан машинаның иясе табылды, «йөрәк кага торган» иске әрҗә яңадан «Мулланур» колхозы-

на кайтып утырды. Ә Фоатның, тиле Фоатның, башсыз Фоатның, бу сүзләрне кешегә ишеттермичә әйтәм, үземә-үзем генә әйтәм, әчемнән елый-елый әйтәм: минем Фоатымның эше судка китте.

## XII

Суд юлына киртә тотылмаган, киткән эш кире дә кайта ала икән. Кыскасы, әкәмәт бер эш булып чыкты бу. Колхоз кырыннан бер кисә борчак алып кайткан кешеләрне судка биреп, икешәр-өчәр елга утырта торган рәхимсез сугыш елларында автомашина хәтле автомашина белән «алыш-биреш» уйнауны кайсы статья белән карарга да белмәгәннәр, имеш.

Ул чагында кеше белергә өлгерми калды, мәгәр, монда Басыйрова апаның да кулы уйнамаган түгел. Җибәрүен җибәргәннәр эшне судка, ләкин икенче көнне үк Басыйрова апа, кеше-карага күренмичә генә, судья каршына үзе килеп баскан.

— Шулаен шулай инде, кем, Асия Хәкимовна иптәш, эш сезнең кулда. Дөрес законын, шәт, үзегез табарсыз,— дип башлаган ул сүзне, дипломатларча килештереп,— иллә, как колхоз председателе, әйтмичә булдыра алмыйм: егете бик тырыш, колхоз өчен үлеп тора. И чынлаб- рак уйлап баксаң, шуннан килеп чыга да: колхоз өчен, колхозны ничек тә адәм күзенә күрсәтерлек итәр өчен эшләнгән дуамаллык бит бу. Хәер, законны сез миңа караганда күбрәк беләсез, үзегез табарсыз тагы.

Бөтен кызыгы да шунда: законын таба алмый аптыраганнар, имеш. Көне-сәгате белән хәбәре авылга кайтып җитте: ул чагындагы уголовный кодекста автомашина алып китү яки алыштырып китү төшенчәсе бөтенләй искә үк алынмаган булган. Авыл халкы, сугыш чоры дип тормый, көләргә ярата. Моны да кәмит итеп чыгардылар. Актаралар, актаралар икән закон китабын, Фоат эшләгән әкәмәткә чак кына килеп ябыша торган законны һич кенә дә тапмыйлар икән. Тәмам тирләп чыкканнар закон эзләүчеләр. Ахырда берсе, закон яллаган кешеләрнең иң зурысы булса кирәк, кычкырган ачуланып.

— Американмыни бездә, кайдан чыккан эш, ди, ул машина алып китү. Килешсеннәр үзара, колхоз правлениесе, комсомол оешмасы карасын. Кыскасы, Фоатның автомашинаны юктан бар итеп, үз кулы белән җыеп аякка бастыруын, колхоз өчен җир тырмашып чабып йөрүен, унсигез яшькә җитмәгән малайлыгын, ахыр килеп, бу әкәмәт тамашаны да үзе өчен түгел, колхоз өчен эшләгәнлеген искә алып, алыштырып кайткан машинасын кире үз урынына илтергә, үзенекен алып кайтырга һәм шуннан соң аның «эше»н авылда колхозчылар белән карарга дип кире кайтардылар.

Чынлап уйлаганда, монысы Фоат өчен районда, калай түбәле өйдә урнашкан судтан, төрмәгә утыртуларыннан читенрәк булып чыкты булса кирәк. Беләм дип үк әйтеп бетермәсәм дә, белә башлаган идем инде мин ул егетне. Сырты сынса да сынатмас, кырын сүзне күтәрмәс, күзгә чәчрәп кермәсә дә, чәчрәгән телчән кешеләр алдында сүзен бирмәс... Үз тырышлыгы белән машина роленә утырганнан бирле бераз борынын да күтәргән, шуларның барысы өстенә тагын, шул ук Алмалыда күзе төшеп йөргән кызы, ягъни мин бар. Әллә уйламыймы бу турыда? Әле ничек кенә уйлый. Шунда, әйтик, бөтен авыл күз алдына чыгып бас та эшләгән башсызлыгың турында җавап бир, имеш!

Иң элек аның машинасын алыштырып, янадан үзенен «йөрәк кага» торган машинасына утырып авылга кайтып керүе бер тамаша булды. Сыгылып төшмәгәндер дисәм ме монда аның тәкәббер башы? Җитмәсә, шул күпербашы очының яхшыдан яман туган бала-чагаларын әйт, күбе-

се минем шәкертләрем, юри әзерләгән дип уйлар кеше, алла сакласын. Фоат үзенең «йөрәк кагучы» машинасына утырып авылга кайтып кергәндә, басу капкасы төбенә җыелып:

Язган булса яз кайта,
Яз кайтмаса, көз кайта,
Абый үзе югалта да,
Абый үзе апкайта,—

дип такмаклап тормасыннармы!

Әле ярый бөтен авыл күз алдына ук чыгарып бастырырга өлгерми калдылар. Бу яктан, турысын әйтергә кирәк, янә шул Басыйрова апаның башы житте. Элек «Менә иртәгә!», «Менә фәлән эш беткәч!» — дип сузып йөртте-йөртте дә көннәрдән бер көнне эшне комсомол оешмасына китереп аударды. Ул чагында комсомол оешмасының төп үзәге безнең мәктәптә, секретаре безнең укытучылардан, барлы-юклы канцеляриясе мәктәптә саклана, җыелышлары мәктәптә уза иде. Шулай булгач, Басыйрова апа чатылдатып куйды мәсьәләне:

— Сезнең мәктәпнең җимеше, комсомолда сездә тора, сез тикшерегез элек,— диде дә «эш»не калдырды да китте.

Әле дә булса күз алдымда: өске катта, физика кабинетында үтте җыелыш. Комсомоллар — мәктәпнекеләр дә, колхознықылар да — бөтенесе килгән, алай гына түгел, ябык ишекнең теге ягында кызыксынып йөрүчеләр дә юк түгел иде. Сүз алып сөйләүчеләрнең, урыннан төртмәле реплика биреп утыручыларның бөтенесен дә хәтерләмим, әмма бер нәрсә хәтеремдә ачык уелып калган: яшьләр кызу канлы, арада эндәшмәе ясарга торучылар да булды, Фоат гадәттәгечә баш имәс бер кеше булып кала бирде.

— Ике шофер үзара килешеп, сөйләшеп эшләнгән эш. Үзем өчен түгел, «Мулланур» колхозы өчен. Монда мин бернинди дә гаеп күрмим,— дип барды ул. Шул сүзләрне кабатлаган арада, бүтәннәргә сиздермәскә тырышып, «Шулай бит, Миңлегөл? Ник әйтмисең, шулай бит?» дигән кебек, минем якка да күз ташлап ала иде. Соңыннан булса да гаебемне искә алмыйча кала алмыйм: мин бер сүз дә әйтмәдем ул җыелышта. Миңа иптәшләремнеке дә дөрес, Фоатныкы да дөрес кебек күренде. Кыскасы, нәкъ менә шул җыелышта, нәкъ менә үземнең бәләкәй түгеллегемне, әйтәсе сүземне һич нидән курыкмыйча әйтә алуымны күрсәтәсе бер урында, минем бәләкәй булып, кешеләр күзенә күренмичәрәк каласым килде. Ә вакыт бик кырыс, яшьләр кызу канлы, арада калай әтәчләр дә бар иде.

Җинаять кодексында статьясы да табылмаган эш дип тормадылар, статьясын таптылар: сугыш чоры, диделәр. Колхоз милке белән шаяру, диделәр. Хәтта арада: «Комсомол башы белән Фоат взятка бирүгә хәтле барып житкән. Ничек кулы барган шул эшкә?» — дип әтәчләнүчеләр дә булды. Мин бәләкәй булырга тырышып, эндәшми калдым — һич гафу итәсем юк шул вакыттагы эндәшми калуымны. Кыскасы, шул: Фоатны комсомолдан чыгарырга дип карар кабул ителде. Фоатның башы әйләнгәндер дә әйләнгәндер, минем башым әйләнде ул минутта, тәкъдимне яклап кулым күтәрелдеме, юкмы? — һич әйтә алмыйм.

Ә Фоат, болай үзе аз сүзле булса да, киткәндә әйтәсе сүзен әйтә китте:

— Комсомол билетын миннән тиз генә ала алмассыз, ул минем кесәмдә түгел, ул минем йөрәгемдә,— диде. Кем уйлаган гади бер авыл егете шулай әйтә алыр дип. Ә менә әйтте, чын әгәр, нәкъ шулай диде.

Икенче көнне Фоатыбыз Алмалыда юк, кая киткәнен хәтта өйдәгеләренә дә белдермичә, авылдан чыгып киткән иде. Берничә елдан соң, инде сугыш беткәч, өйдәгеләренә кыска гына хат язып, авылдан киткәч,

үзенең Казанда хәрби заводта эшләгәнлеген, бер үк вакытта ДОСААФ буенча аэроклубка йөреп, очарга өйрәнгәнлеген, сугышның соңгы елында очучы булып сугышта катнашканлыгын, бүләкләнгәнлеген, аннары гражданский авиациягә күчеп, Одесса белән Ерак Көнчыгыш арасында очканлыгын, бер молдаван кызына өйләнеп, Одессада төпләнеп калуын, бер ир балалары булуын хәбәр иткән икән дип яшеттем.

Ун елдан артык вакыт узгач, илленче елларның азагына таба, һич уйламаганда, миңа бер хаты килеп төште. Хаты, нәкъ үзе кебек, аз сүзле һәм сизелер-сизелмәс кенә үпкә белдереп язылган хат иде. Хатын, юлын-юлга, сүзен-сүзгә дигәндәй, хәтта, нәкъ ул язганча, тыныш галәмәтләрен дә урынлы-урынсыз куеп, тулысы белән китерәм:

«Миңлегөл! Син исән булсаң, мин исән. Кайда икәнлегемне сорама, җир белән күк арасында — күп вакыт күктә уза. Но бер үпкә бар сиңа, малай. Теге вакытта автомашина алыштырып җенләнеп йөргәнне онытмагансыңдыр ич — шуны тикшергәндә, мәктәптә узган комсомол собраниесендә әгәр син бер сүз әйткән булсаң, мин бит малай күк белән җир арасында асылып калачак кеше түгел идем, җирдә — Алмалыда иде минем урыным. Синең белән бергә булырга тиеш иде. Мин сине өзелеп, үлеп китәрдәй булып яратадыр идем, ә шунда бер сүзең житмәде. Хәер, үземдә дә гаеп, үзем дә карга булып йөрдем, әйтәсе сүземне вакытында әйтә алмадым.

Зарланмыйм, минем хәзерге тормышым да ярыйсы — хатын, балачага и так далее... Но синең белән без бәхетлерәк булган булыр идек — синең белән безнең язмыш уртак булыр иде, ә болай түшәк уртак, юрган уртак и на этом точка.

Соңга калып тәүбәгә килгән бу, дип уйлама. Впрочем, тәүбәгә килергә без икебез дә соңга калдык бугай инде.

Онытылган Алмалы малае Фоат».

Хаты менә шул, ә уйландыруы күп булды. Уйлануын әле һаман да уйланам, кайта-кайта уйланам. Нилэр генә булмый кеше тормышында! Шатлыгы да, борчулары да, кавышулар да, аерылышулар да. Әлбәттә, тилелекләр дә була. Бигрәк тә яшь чакта. Андый тилелек Фоат ягыннан да булды, дөнья булгач миннән дә ычкынгалады бугай. Ләкин теге вакытта, комсомол җыелышында Фоат эшен тикшергәндә, күңелемдә булганны әйтмичә калуым, бәләкәй булырга тырышып, посып калуым — бусы инде тилелек кенә түгел, бусы обывательлек, әкәм-төкәмлек. Соңга калып булса да хәзер әйтәм, педагог буларак, акыл биреп әйтәм: яшь егетләр, яшь кызлар! Мәхәббәтегезне яклый белегез, саклый белегез, кирәк икән, аның өчен көрәшә белегез. Минеке кебек соңыннан гомерлек үкенече калырдай булмасын. Дөрес, хәзерге тормышымнан мин дә зарланмыйм — көн артыннан көн, ел артыннан ел уза, эшем бара... Ә тегеләй... аның белән булганда... Хәзер инде үз хөкемемнән башка бернинди хөкем дә юк, булуы мөмкин дә түгел, ә шулай да әйтми кала алмыйм: ярата идем бит мин аны, ярата идем!

1971—72.

**Флорид Әгъзәмов,**
тарих фәннәре кандидаты

# ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ— ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Совет кешесенең рухи йезен иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең яңа тибы тудырган һәм СССР халыкларының иң яхшы традицияләре белән камилләшкән сыйфатлар билгели. Мондый кешене партия үстерде. Һәм партия бу эштә культура һәм сәнгать чараларыннан нык файдаланды һәм файдалана.

Безнең заманда әдәбиятның тормышыбыздагы вазифасы көннән-көн җаваплырак төс ала. КПССның XXIV съездында Л. И. Брежнев бик хаклы рәвештә болай дип әйтте: «Җәмгыятебез коммунизм төзү юлыннан алга барган саен совет кешесенең дөньяга карашларын, рухи культурасын формалаштыруда әдәбиятның һәм сәнгатьнең роле һаман арта бара»[1]. Сүз монда, беренче чиратта, совет кешеләрендә интернационализм хисе тәрбияләү турында бара. Чөнки интернационализм — совет кешесенең дөньяга карашының, аның әхлагының һәм рухи культурасының да аерылгысыз бер сыйфаты.

Әдәбият хезмәт ияләрен интернационализм принципларында тәрбияләүдә, аларның рухи бердәмлеген ныгытуда уңышлы катнашсын өчен, аның үзенең интернациональ характерда булуы, барлык башка милләт кешеләренә аңлаешлы һәм якын булуы шарт. Күп милләтле совет әдәбияты исә — нәкъ менә шундый әдәбият. Бу — әдәбият чагылдыра торган чынбарлыкның интернациональләшә баруы, әдәби геройның чын интернационалист булуы, әдәбиятларның бер үк идеологиягә, бер үк иҗат методына — социалистик реализмга нигезләнүе, аларның бер-берсен баетышулары һәм бер-берсенә якыная барулары белән аңлатыла.

## Бай хәзинә

Революциягә кадәр дә милләтләр һәм халыклар, материаль кыйммәтләр белән беррәттән, рухи байлыклар алмашып яшәгәннәр. Аларның культура тормышы да интернациональләшә барган. Бу — милли мөнәсәбәтләр үсешендә объектив закончалык. К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин бу процессның капитализм шартларында ук җәелә баруын әйттеләр.

Капитализм чорында милли культураларның бер-берсенә якынаюы юлында кискен каршылыклар, күп кенә киртәләр ятса да, демократик әдәбиятлар барыбер бер-берсен «табыша» алганнар. Язмыш, өмет-хыяллар уртаклыгы, бөек рус халкы җитәкчелегендә илбасарларга һәм сыйнфый дошманнарга каршы бергәләп көрәшү — Россиядә яшәгән халыклар арасындагы әдәби элемтәләрнең нигезе менә шул. Халык

[1] КПССның XXIV съезды материаллары. Казан. 1971. 86 бит.

мәнфәгатьләренең уртаклыгыннан көч алып килгән әдәби бәйләнешләр Россиядәге азатлык хәрәкәте тарихының төп өч этабының дәвамчанлыгы белән билгеләнә, дип, М. И. Фетисов бик дөрес күрсәтә[1]. Әгәр азатлык хәрәкәтенең беренче этабында бу элемтәләрнең алшартлары тудырылса, революцион демократлар эшчәнлегенең күтәрелеше чорында алар инде шактый киңәя, ә өченче — пролетар этапта әдәби хезмәттәшлек тагын да ныгый төшә. Соңгы этапта пролетар әдәбиятлар көч җыя башлыйлар, марксистик-ленинчыл тәгълимат җирлегендә аларның идея-эстетик принциплары формалаша. Алар исә, буржуаз әдәбиятларга капма-каршы буларак, асылы белән үк интернациональ рухта була. Чөнки барлык милләт эшчеләренең максатлары, яшәү шартлары, идеаллары уртак, дошманнары бер. Һәм шушы уртаклык пролетариатның рухи культурасында, әдәбиятында тирән чагылыш таба.

Интернациональ демократик һәм пролетар әдәбиятлар, аларның хезмәттәшлеге бүгенге буын кешеләрендә дуслык-туганлык хисләре тәрбияләү өчен бай рухи азык бирә. Бу рухи байлыкны тәрбия эшендә тиешенчә файдаланмасак, без үзебезне бик кыйммәтле хәзинәдән мәхрүм иткән булыр идек.

Совет кешеләре рухи культура мирасы белән: архитектура һәйкәлләре, рәсем сәнгате, әдәбият тарихы һ. б. белән көннән-көн күбрәк кызыксыналар. Бу — аларның милли үзаңының, эстетик ихтыяҗларының, гомумән, белем һәм культура дәрәҗәсенең үсүен күрсәтә. Совет кешеләренең әлеге табигый ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерергә омтылу — изге бер бурыч.

Моннан әдәби мирасның интернациональ традицияләрен, үткәндәге әдәби элемтәләрне, әдәбиятлар дуслыгын тагын да җентеклерәк өйрәнү һәм эзлеклерәк пропагандалау зарурлыгы килеп чыга. Бу җәһәттән безнең әдәбият тарихы якты сәхифәләргә бик бай. Профессор И. Нуруллин бик хаклы әйткәнчә, дөнья әдәбияты материгындагы бер өлкә буларак, татар әдәбияты күршеләре белән даими аралашып яшәде, өлкәнрәк һәм «тәҗрибәлерәк» әдәбиятларның казанышларын кабул итте һәм иҗади үзләштерде, шул ук вакытта ул үзенең тәҗрибәсен уртаклашуда һич саранланмады[2].

Революциягә кадәр әдәбиятларның бер-берсенә йогынтысын, бер-берсен баетышуын тикшерү һәм пропагандалау юнәлешендә бездә эш алып барылмый түгел. Гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләрендә эшләүче галимнәребез игътибарны, беренче чиратта, рус әдәбиятының татар әдәбиятына ясаган йогынтысын өйрәнүгә юнәлделәр. Бу бик табигый. Прогрессив рус әдәбияты, аның реалистик рухы, азатлыкка чакыру пафосы демократик татар әдәбиятының үсешендә зур роль уйнады. Бу йогынтының сәбәпләрен ачарга омтылып, Г. Ибраһимов болай дип язган иде: «Русның теле бик бай, әдәби, гыйльми теле бөтенләй эшләнгән һәм матур. Рус әдәбияты дөньяның иң алдынгы әдәбиятларыннан санала. Рус мәдәнияте безгә караганда бик күп, бик күп дәрәҗәдә югары... Мең еллар буенча без бу мәдәниятка күрше яшәдек, 3—4 йөз ел инде бөтенләй моның уртасында калдык. Бу мәдәният бик күп яктан безгә остаз була килде. Безнең яңаруыбыз, безнең әдәбиятыбыз, безнең гыйлемнәребез, безнең революция хәрәкәтләребез һәммәсе бу рус мәдәниятенең бик нык тәэсире һәм мөгаллимлеге астында үстеләр...»[3]

Прогрессив рус әдәбиятының татар әдәбиятына йогынтысы гомуми сыйфатларда Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, М. Гайнуллин, Х. Госман, К. Фасеев, И. Нуруллин, Г. Халит, Й. Нигъмәтуллина һәм башкаларның хезмәтләрендә чагылыш тапты. Аерым рус әдипләренең татар язучылары иҗатына ясаган бәрәкәтле йогынтысын фәнни тикшерену эше дә уңышлы гына бара.

Татар әдәбияты шул ук вакытта башка әдәбиятларның, аерым алганда Көнчыгыш әдипләренең дә, шифалы йогынтысын кичерде. Бу хакта вакытлы матбугатта чыккан аерым мәкаләләрдән күпмедер мәгълүмат алырга мөмкин.

Безнең әдәбият, өлкән әдәбиятларның берсе буларак, үзе дә башка, бигрәк тә

---

[1] Карагыз: «Милли әдәбиятларның үзара элемтәләре һәм бер-берсенә йогынтысы» дигән китап (рус телендә). 1961 ел. 112—113 битләр.

[2] И. Нуруллин. Өлгергәнлеккә юл (рус. телендә). Казан. 1971 ел. 3 бит.

[3] Г. Ибраһимов. Кара маяклар яки ак әдәбиятлар. Мәскәү. 1924 ел. 179—180 битләр.

төрки халыкларның әдәбиятлары үсешенә уңай йогынты ясады. Ул көнчыгыштагы төрки халыкларга рус культурасын җиткерүдә күпер хезмәтен үтәде. Бу йогынты беренче чиратта, аның иң күренекле вәкилләренең (әйтик, Г. Тукай, Г. Ибраһимов) иҗатлары аша барды. Моны тугандаш халыклар галимнәренең фәнни хезмәтләреннән дә, шул шифалы йогынтыны кичергән әдипләрнең раслауларыннан да күреп була. Үзбәк язучылары Хәмзә Хакимзадә, Гафур Голәм, Әсгат Мохтар, төркмән язучысы Берды Кербабаев, казакъ әдипләре Габит Мөсрепов, Сабит Муканов һәм башкаларның татар әдәбиятының үз әдәбиятларына, үз иҗатларына ясаган уңай йогынтысы хакында тирән ихтирам белән әйткән сүзләрен китерергә булыр иде.

Хәзер революциягә кадәр булган әдәби элемтәләрне комплекслы өйрәнер вакыт җитте шикелле. Моның өчен мөмкинлекләр шактый (тупланган бай материал да, хәзерлекле кадрлар да, таяныр теоретик җирлек тә бар). Безнеңчә, прогрессив әдәбиятларның үзара бәйләнешләрен өйрәнгәндә, экономик, социаль-политик һәм идеологик шартлар белән берррәттән, түбәндәге моментларга игътибарны юнәлтү максатка ярашлы булыр иде. Сүз, беренче чиратта, ныграк үсешкә ирешкән әдәбиятларның һәм аларның күренекле вәкилләренең яшьрәк әдәбиятларга идея-эстетик йогынтысын һәрьяклап тикшерүне дәвам иттерү зарурлыгы турында бара. Икенчедән, без бай традицияле әдәбиятларда төрле милләтләргә, аларның прогрессив традицияләренә чын интернациональ караш чагылуын конкрет мисалларда тикшерүне күздә тотабыз. Һәр милләтнең алдынгы язучысы башка халыкларга зур хөрмәт белән караган, аларның тормышын дөрес гәүдәләндергән, төрле милләт вәкилләренең ягымлы образларын иҗат иткән. М. Горький иҗатындагы татар, Г. Ибраһимов әсәрләрендәге башкорт, казакъ һ. б. образларын хәтергә төшерергә мөмкин.

Бу җәһәттән башкорт күршеләрдә «Башкортстан рус әдәбиятында» дип исемләнгән биш томлык бик кызыклы бер җыентыкның дөнья күргәнлеген әйтеп үтик. Анда төрле буын рус әдипләренең башкорт халкының тормышына кагылышлы әсәрләре тупланган. Интернационализм идеяләрен пропагандалау өчен гаять бай хәзинә. Аннары әлегә хезмәт теге яки бу әдип иҗатында интернационализм идеяләренең чагылышын өйрәнүне дә җиңеләйтерә.

Өченчедән, «тәҗрибәлерәк» һәм өлкәнрәк әдәбият вәкилләре үзләренең иҗатлары белән яшьрәк әдәбиятларны үстерүгә турыдан-туры өлеш кертканнәр. Кайсы гына әдәбиятны алма, моның матур мисалларын табарга була. Мәсьәләнең бу ягын җентекләп тикшерену дә әдәби элемтәләрнең электәге картинасын тулырак күз алдына китереп бастырырга булышыр.

Әдәбиятлар тарихына мөрәҗәгать итеп, без прогрессив әдәбиятларның интернационалистик традицияләрен, аларның үзара ярдәмләшеп яшәгәнлекләрен пропагандалыйбыз, бары тик эчкерсез хезмәттәшлек кенә изелгән халыкларга үзләренең талантларын ачарга булышканлыгын, иң кыен шартларда да азатлык, чын туганлык өчен көрәш пафосы белән сугарылган рухи җәүһәрләр иҗат итәргә рухландырганлыгын исбатлыйбыз. Бу исә совет кешеләрен интернационализм рухында тәрбияләү эшенә хезмәт итә.

Ләкин узгандагы милли культураларны, аларның үзара элемтәләрен өйрәнгәндә һәм пропагандалаганда, без капитализм шартларында бу бәйләнешләрнең чикләнгән булуын һәрвакыт истә тотарга, В. И. Ленинның, һәр милли культурада ике культура бар, дигән өйрәтмәсенә таянып эш итәргә тиешбез. Үткәндәге сәламәт, демократик, кыйммәтле күренешләрне кешеләрнең бердәмлек рухында тәрбияләүгә комачаулаучы реакцион күренешләрдән аера белергә кирәк. Марксистик-ленинчыл партиялелек принцибын кулланып эш итү, әдәби күренешләргә һәм бәйләнешләргә сыйнфый караштан чыгып якын килү — узгандагы әдәбиятлар һәм аларның хезмәттәшлеге тарихын өйрәнүдә төп методологик нигез.

Әдәби мирасны һәм элемтәләрне өйрәнгәндә һәм пропагандалаганда объектив булу, милли чикләнгәнлек, милли эгоизм күренешләренә килешмәүчән караштa булу сорала. Бу очракта милли чикләнгәнлек башка әдәбиятларның «үз» әдәбиятына йогынтысын кечерәйтеп, ә «үз» әдәбиятының башкаларга тәэсирен күпертеп күрсәтергә омтылуда, бүтән халыкларның культура мирасына йөз җыерып карауда, ә «үз» халкыңныкын алардан өстен куюда һ. б. чагылырга мөмкин.

Берничә милләт яки халыкка караган әдәби мираска мөнәсәбәттә аеруча сак

булырга кирәк. Тарихи язмышларның уртаклыгы, телләр кардәшлеге, чиктәшлек һ. б. ике яки берничә халык өчен уртак әдәби әсәрләр иҗат ителүгә китергән. Әнә шундый мирасны теге яки бу халыкныкы гына итәргә омтылуның сәламәт булмаган реакция тудыруы бар. Моның мисаллары да булмады түгел. Халыклар тикле халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр турында сүз барганда шул халыклар галимнәренең киңәшләшеп эшләүләре таләп ителә.

Интернациональ дуслык тамырларын ачыклаганда һәм пропагандалаганда үткәнне идеаллаштыру, сыйнфый каршылыкларга күз йому, тарихны шомарту юлына басу объективлыкка хилафлык китерү, сыйнфыйлык принцибыннан тайпылу, берьяклылыкка сугылу булыр иде. Әгәр без шундый юлга бассак, укучыларда: революциягә кадәр дә милли әдәбиятлар тоткарлыксыз үскәннәр һәм бер-берсе белән иркенләп хезмәттәшлек иткәннәр икән, сыйныфлар һәм аларның культуралары арасында кискен идея-политик көрәше булмаган икән, дигән караш туарга мөмкин. Шуның өстенә әле КПССның ленинчыл милли политикасын фальсификацияләүче буржуаз идеологлар революциягә кадәрге әдәбиятны социалистик реализм әдәбиятына каршы куярга маташалар; беренчесен иректә, милли рухлы дип, ә икенчесен шомартылган, руслаштырылган әдәбият дип расларга тырышалар.

Революциягә кадәр демократик әдәбиятларның үсүе һәм бер-берсен баетышуы бик катлаулы, каршылыклы, чикләнгән иде. Беренчедән, изүче милләт әдәбияты изелүче милләт әдәбиятын басып китәргә тырыша иде. Патша самодержавиесе һәм буржуазия вак милләтләрнең әдәби үсешен тоткарлаучы рәсми политика үткәреп килделәр. «Россиядә, киң мәгънәсендә алганда, татарларның... үз культуралары юк һәм булуы да мөмкин түгел»,— дигән Казан губернаторы галиҗәнаб сарае камергеры М. В. Стрижевский 1912 елда [1]. Искиткеч цинизм белән әйтелгән бу җан өшеткеч сүзләрдә изүче сыйныфларның милли культураларга һәм әдәбиятларга карашы ярылып ята.

Икенчедән, һәр милләттәге хакимлек итүче буржуаз әдәбият демократик һәм пролетар әдәбиятларның үсүенә һәм бер-берсенә якынаюына аяк чалган.

Өченчедән, булган әдәбият та, В. И. Ленин сүзләре белән әйткәндә, рәхәткә туйган героиняга, эч пошудан һәм симезлектән җәфа чиккән «өстәге ун меңнәргә» хезмәт иткән [2]. Ә илнең чәчәге, аның көче һәм киләчәге булган миллионнарча, ун миллионнарча хезмәт иияләре томаналыкка һәм наданлыкка дучар ителгән иде.

Дүртенчедән, Россиядәге милли әдәбиятлар үсеш ягыннан төрле баскычта торалар иде. Берәүләрнең бөтен дөньяга танылган әдәбиятлары булса, икенчеләрендә ул халык авыз иҗаты төсендә генә яши иде. Андый әдәбиятлар арасында тулы тигез хокуклы хезмәттәшлек тә, бер-берсен баетышу да була алмый, әлбәттә.

## Үсеш чыганаклары

Бары социализм гына илебездә яшәүче барлык милләт һәм халыкларның ирекле үсеше өчен бөтен шартларны тудырды. Димәк, аларның бер-берсе белән тигез хокуклы хезмәттәшлеге өчен мөмкинлекләр булдырылды. Чөнки, Ф. Энгельс сүзләре белән әйткәндә, һәр милләтнең бәйсезлеген, тигез хокуклылыгын тәэмин итми торып, пролетарийларның интернациональ берләшүе дә, уртак максатларга ирешү өчен аңлы хезмәттәшлеге дә була алмый [3].

В. И. Ленин һәм Коммунистлар партиясе, милли мөнәсәбәтләр үсешенең объектив закончалыклары нигезендә эшләнгән милли программаны тормышка ашыра барып, экономика, политика һ. б. өлкәләрдә тамырдан революцион үзгәрешләр үткәрү белән бергә, тарихта тиңдәше булмаган культура революциясе ясауны максат итеп куйдылар.

---

[1] Г. Ахунов, М. Зариповның «И кадерле туган як» исемле китабыннан китерелә. Казан. 1971 ел. 179 бит.

[2] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә. 10 том. 34 бит.

[3] К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. Рус телендә. 22 том. 382 бит.

Культура революциясе программасын билгеләгәндә, В. И. Ленин һәм партия кешелек дөньясы гасырлар буе иҗат итеп килгән прогрессив мирасны кире кагуга кискен төстә каршы чыктылар. Эшчеләр сыйныфы, иң яхшы традицияләрне гәүдәләндерүче, кешелек тарихында иң алдынгы карашлы, иң гуманлы сыйныф буларак, барлык милләт һәм халыкларның демократик рухи хәзинәсен үз арсеналына алды. Ләкин уптым-илаһи түгел, ә һәр милли культурадан буржуаз һәм клерикалларның реакцион идеологиясе, узган заманның зарарлы традицияләрен кире кагып, әдәбият-сәнгатьнең барлык казанышларын тәнкыйть күзлегеннән үткәреп алды. В. И. Ленин күрсәткәнчә, яңа пролеткультура уйлап чыгарырга түгел, ә яшәп килгән культураның иң яхшы үрнәкләрен, традицияләрен, нәтиҗәләрен марксизм карашы һәм пролетариатның үз диктатурасы чорындагы тормыш һәм көрәш шартлары күзлегеннән үстерергә кирәк иде. Нәкъ менә рухи культура үсешенең эчке объектив законнарын (бу очракта анык чагыштырмача мөстәкыйльлеген һәм дәвамчанлыгын) шулай исәпкә алу культура революциясен уңышлы төстә җәелдереп җибәрергә мөмкинлек бирде.

Тигез хокук алган, әмма әлегә үсешнең төрле баскычларында торган милләт һәм халыкларның культурасын үстерүдә, тормышның барлык өлкәләрендәге кебек үк, аларның хезмәттәшлегенә зур исәп тотылды. Әлбәттә, ул чакта күпьяклы хезмәттәшлек турында сүз алып барырга мөмкин түгел иде. Шуңа күрә чагыштырмача алга киткән милләт һәм халыкларның, беренче чиратта бөек рус халкының, артта калганнарына ярдәмен оештыруга зур игътибар ителде. Элек изүче булып килгән милләтләрнең изелгән милләтләр хезмәт ияләренең фактагы тигезлеген булдыруга гына түгел, бәлки телен, әдәбиятын үстерүгә дә булышлык итүләрендә В. И. Ленин капитализм эпохасыннан мирас булып калган ышанмаучылыкның һәм читләшкәнлегенең барлык эзләрен бетерүнең куәтле чарасын күрде [1].

Барлык милләтләр өчен уртак интернациональ культура булдыру кискен көрәш шартларында барды. Большевиклар программасын кыйбла итеп алган культура әһелләре эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли культура һәм әдәбиятларны үстерүне яклап чыктылар, аларның интернациональ рух белән сугарылырга тиешлеген расладылар. Бөек Октябрьның берьеллык бәйрәменә багышлап язган мәкаләсендә үк Г. Ибраһимов: «Тел, әдәбият, шигырь, мәдәният — болар һәммәсе үзләренең рухларын үзгәртергә, башка милләтләргә дошманлык, милли тәгассып урынына дуслык, туганлык, кардәшлек рухы белән сугарылырга, халыкны да шул рухта тәрбия итәргә тиешледер»,— дип белдерде [2].

Революция дошманнары, буржуаз милләтчеләр исә культура һәм әдәбиятларның интернационализм юлына басуына каршы чыктылар, аларны бер-берсенә каршы куйдылар, большевикларның культура өлкәсендәге политикасына туктаусыз яла яктылар.

Шул ук вакытта партиягә миллилекне, милли үзенчәлекләрне инкарь итүчеләрнең карашларын да кире кагарга туры килде.

Социализм шартларында милли культураларның, шул исәптән әдәбиятларның, үсеш процессы уртак принципларга — партиялелек, халыкчанлык, социалистик гуманизм принципларына нигезләнде. Барлык милләт һәм халыкларның максат бердәмлеге, дөньяга караш уртаклыгы, тормыш рәвешенең охшашлыгы, чынбарлыкны чагылдыруның художество методы бер булу милли әдәбиятларның эчке бердәмлеген тәэмин итте, аларның хезмәт ияләрен туплаудагы ролен тагын да күтәрде. М. Горький, милли әдәбиятлар үсешенең беренче адымнарын анализлап, шундый нәтиҗәгә килде: «Безнең барлык республикаларның төрле милләтле, төрле телле әдәбияты Советлар иле пролетариаты, барлык илләрдәге революцион пролетариат һәм бөтен дөньядагы безгә дус әдәбиятчылар каршында бөтенлекле бер әдәбият булып тора» [3].

Ленинчыл милли политиканы эзлекле төстә тормышка ашыру нәтиҗәсендә социалистик милләтләр барлыкка килде, кыска гына вакыт эчендә совет халкының

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә. 29 том. 112 бит.
[2] Камил Фасеевның «Туганлык һәм дуслык көче» исемле китабыннан китерелә. Казан. 1966 ел. 170 бит.
[3] М. Горький. Әдәбият турында (рус телендә). 690 бит.

социаль һәм идея-политик бердәмлеге ныгып урнашты, милли кадрлар үстерелде, халыкларның эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли культурасы чәчәк атты. Элек язулары булмаган кырыктан артык халык совет чорында фәнни эшләнгән язу алды һәм хәзер аларның алга киткән әдәби телләре бар [1].

Кешелек тарихында тиңе булмаган мондый рухи яңарышның сәбәпләре нинди, чыганаклары кайда?

Беренче чиратта, әлбәттә, барлык социаль һәм милли богауларны алып аткан социалистик җәмгыятьнең милләтләр һәм халыкларның ирекле үсеше өчен, фән-техниканы, культураны алга җибәрүдә һәм аларның нәтиҗәләрен файдалануда хезмәт ияләренең актив катнашуы өчен кирәкле шартларны тәэмин итүендә. Гасырларга сузылган рәхимсез кыштан соң шәфкатьле яз килеп, моңарчы калын боз хакимлегендә булган инеш һәм елгалар ярларыннан ташып чыккан кебек, барлык милләт һәм халыкларның рухи дөньясындагы боз да челпәрәмә килде, физиклар теле белән әйтсәк, потенциаль илһам куәте кинетик куәткә әйләнде.

Совет халыкларының кыска гына вакыт эчендә рухи яктан яңадан тууларының тагын бер чыганагы тигез хокуклылык шартларында аларның бер-берсе белән материаль һәм рухи кыйммәтләр алмашып яшәвендә, дуслыгында, туганлыгында. Совет дәүләтендәге барлык милләт һәм халыкларның иҗади энергиясе, иҗат сәләтләре, талантлары туганнарча бердәмлектә генә тиңдәшсез тулылык белән ачылды. Бу — әдәбият өлкәсендә дә шулай. Һәр милли әдәбият, иң элек, яшәп килгән демократик һәм социалистик традицияләрне дәвам иттерү, баету, тирәнәйтү җирлегендә башка тугандаш әдәбиятларның казанышларын иҗади үзләштерү өчен барлык шартларга ия булды. Әдәбиятларны бер-берсеннән аерып торган элекке кирталәр алып ташланды. Милли әдәбиятларны иҗат итүчеләр һәм файдаланучылар алдынгы дөнья әдәбияты хәзинәләре сарайларына да ачкыч алдылар. Бу җәһәттән башкорт әдәбиятчысы Н. Зариповның бер матур чагыштыруы хәтергә килә. «Бердәм иҗтимагый-экономик һәм идеологик нигездә яңа культура диңгезләренең һәм күлләренең бөтен бер системасы барлыкка килде,— дип язды ул.— Алар яшәү сулышы бирә торган күп санлы каналлар ярдәмендә бер-берсенә тоташканнар. Әлеге культура диңгезләренең һәм күлләренең бердәм системасы тышкы дөньядан да аерылмаган, ул бөтен дөнья культурасының мәһабәт океаны белән киң элемтәдә тора» [2].

Социализм тудырган киң мөмкинлекләрне тулы файдалану, алга киткән әдәбиятларның тәҗрибәсен үзләштерү нәтиҗәсендә совет милләтләре һәм халыклары цивилизация тудырган иң югары культура үрләренә җиттеләр. Байтак әдәбиятлар тизләтелгән үсеш этабы үттеләр, ягъни дөнья культурасы узган юлның әйләнеч сукмакларын, зигзагларын читтә калдырдылар, чынбарлыкны чагылдыруның катлаулы һәм камил формаларын үзләштерделәр, кыскасы, сәнгатьчә фикерләүнең югары дәрәҗәсенә ирештеләр. Әдәби үсешнең мәгълүм фазаларын сикереп үткән әдәбиятлар икенче «сортлы» әдәбиятлар түгел. Алар, иң алдынгы, иң гуманлы идеяләр белән сугарылу белән берәттән, сәнгать ягыннан да камил дәрәҗәдә. Октябрьдан соң гына язма телен булдырган халыклар әдәбиятының бөтен җир шарында абруй яулавы аның иң югары эстетик таләпләргә дә җавап бирүе турында сөйли.

Безнең көннәрдә милли әдәбиятларның үсүе һәм бер-берсенә якынаюы өчен тагын да уңайлырак мөмкинлекләр тудырыла. Милли мөнәсәбәтләр үсешенең хәзерге этабында, милләт һәм халыкларның тыгызрак хезмәттәшлеге шартларында, әдәбиятларның интернациональ пафосы тагын да көчәя. Коммунистик төзелешнең киң колачы һәм коммунизм идеологиясенең яңа җиңүләре СССР халыкларының эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли культурасын баета. Милләтләрнең һәм халыкларның идея бердәмлеге көчәя, аларның культуралары якыная бара. Барлык совет милләтләре өчен уртак интернациональ культура үсә, һәр милләтнең культура хәзинәсе интернациональ характер алырлык иҗат әсәрләренә һаман күбрәк байый бара» [3].

---

[1] «Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелүнең 50 еллыгына хәзерләнү турында» КПСС Үзәк Комитеты карары. «Социалистик Татарстан» газетасы. 1972 ел. 23 февраль.

[2] «Советская Башкирия» газетасы. 1967 ел. 31 март.

[3] Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Программасы. Казан. 1961 ел. 160 бит.

Партия культура өлкәсендә милли мөнәсәбәтләрдәге объектив закончалыкка — милләтләр һәм халыкларның чәчәк атуы һәм бер-берсенә якынаюы тенденцияләренә таянып эш итә. Бу тенденцияләр бер-берсенә каршы килми генә түгел, киресенчә, бер-берсен күздә тота, берсе икенчесенә сәбәп булып тора. Теге яки бу әдәбиятның чәчәк атуы процессы милли традицияләр җирлегендә генә бара дип күзаллау ялгыш булыр иде. Чөнки милли традицияләр дигәнебез дә әле «саф» милли генә түгел һәм була да алмый. Алар интернациональ моментларын да үз эчләренә алалар. Чын милли традицияләр бер үк вакытта интернациональ булалар. Алар тормышның магистраль агышына җавап бирә торган иң алдынгы милли үзенчәлекләрне дә, тугандаш халыклар әдәбиятлары тәҗрибәсен дә, гомуми совет әдәбиятының революцион традицияләрен дә, шулай ук прогрессив дөнья әдәбияты традицияләрен дә үзләрендә гәүдәләндерә.

Аңлашыла ки, күп милләтле совет әдәбиятының үсеше һәр милли әдәбиятның казанышларына бәйле. Милли әдәбиятның үсеш дәрәҗәсе никадәр югары булса, андагы интернациональ эчтәлек шул кадәр баерак һәм башка халыкларның художество тәҗрибәсе энҗеләрен үзләштергән формасы шул кадәр камилрәк була. Милли әдәбият никадәр үскәнрәк булса, ул халык тормышын һәм омтылышын шул кадәр уңышлырак чагылдыра, димәк, башка халыкларга да якынрак, аңлаешлырак була.

Үз чиратында милли әдәбиятларның бер-берсенә якынаюы аларның тагын да чәчәк атуы өчен шарт булып тора. Милли киртәләрне кыю вату, гомум совет һәм прогрессив дөнья әдәбиятының иң яхшы традицияләрен оста файдалану, тыгыз культура хезмәттәшлеге генә милли әдәбиятларга үзләренең алдынгы традицияләрен уңышлы үстерергә, совет халкын тәшкил итүче милләтләргә һәм халыкларга лаеклы рухи җәүһәрләр тудырырга мөмкинлек бирә. Әдәбиятларның чәчәк атулары җирлегендә үзара якынаюлары, үзара якынаюлары җирлегендә чәчәк атулары тәэмин ителә. Күп милләтле совет әдәбиятының алга таба үсеш юлы шундый, коммунистик җәмгыять культурасын булдыру, совет кешеләренең рухи бердәмлеген тагын да ныгыту юлы шундый.

Милли әдәбиятларның чәчәк атуы һәм бер-берсенә якынаюы диалектик бердәмлектә икән, органик төстә бәйләнгән бу табигый ике процессны бер-берсеннән аерып карарга, бигрәк тә каршы куярга ярамый. Әгәр без әдәбиятларның чәчәк атуына, милли үзенчәлекләренә генә басым ясасак, аларның бер-берсенә якынаюын, бер-берсен баетышуын күздән ычкындырсак, һичшиксез, милли чикләнгәнлек, милли эгоизм сазлыгына төгәрәячәкбез. Милли үзенчәлекләр үзгәрми торган, катып калган категория итеп күзалланып, аларга гомерен кичергән архаик традицияләр дә кертеп каралса, эш тагын да хөртирәк.

Милли үзенчәлекләр, аларның эволюциясе белән исәпләшмәү, әдәбиятларның икенче үсеш чыганагы булган прогрессив бөтен дөнья әдәбияты традицияләренә генә басым ясау шулай ук дөрес булмас. Беренче очрак милли чикләнгәнлеккә, теге яки бу әдәбиятны бөтен дөнья художество процессыннан изоляцияләүгә алып барса, икенчесе әдәбиятны милли җирлектән аеруга, нигилизмга илтер иде. Һәм һәркайсы гомуми эшкә — хезмәт ияләрен идея-эстетик бердәмлеге рухында, дуслык-туганлык рухында тәрбия итү эшенә зыян китерер иде.

Кызганычка каршы, югарыда телгә алынган ике тенденцияне, конкретрак алганда үсешнең ике чыганагын (милли традицияләр һәм башка халыкларның художество иҗаты тәҗрибәсе), диалектик бердәмлектә карамау очраклары бар.

Теге яки бу әдәбиятка башка халыклар әдәбиятының йогынтысы турында сүз барганда, кайбер иптәшләр бу йогынты милли горурлык хисен рәнҗетә, йогынты кичергән әдәбиятның яки язучы иҗатының мөстәкыйльлеген киметә, дәрәҗәсен төшерә дип саныйлар, күрәсең. Әмма мондый шөбһәләнүләргә һич тә урын юк. Әдәбият шундый иҗат өлкәсе ки, анда — биргән ярлыланмый, алган баый гына.

Әдәби йогынтыдан куркучы кайбер иптәшләрнең: «Без үз җирлегебездә генә үсәбез», дип күкрәк сугулары бу процессның асылын аңламауларыннан да килә. Андыйлар әдәби байлыклар уртаклашуны, әдәби йогынтыны теге яки бу әдипнең икенче берәүгә охшарга тырышуы, аның иҗат чараларын үз иҗатына механик

күчерүе дип күз алдына китерәләр шикелле. Шуңа күрә дә аларның йогынты сүзеннән котлары чыга.

Кайберәүләрне милли әдәбиятларның бер-берсенә якынаюы тәшенчәсеннән куркуга төшерә торган тагын бер җитди сәбәп бар. Аерым тикшеренүчеләр бу процессны милли үзенчәлекләрнең бетә баруы белән тәңгәлләштерәләр. Милли әдәбиятларның бер-берсенә якынаюы милли үзенчәлекләрнең юкка чыгуы, унификацияләнүе исәбенә бара дигән нәтиҗә ясау теоретик яктан зарарлы, ә практик яктан безнең илдәге милли әдәбиятларның үсеш тәҗрибәсенә туры килми. Күренекле әдәбият белгече Г. Ломидзе хаклы рәвештә күрсәткәнчә, милли әдәбиятларның якынаюы процессы башка әдәбиятларның тәҗрибәсе белән баетылган милли художество иҗатының иң яхшы, тормышчан якларын үстерү һәм камилләштерү исәбенә бара[1].

Партия күп милләтле совет әдәбиятының объектив үсеш закончалыкларын дөрес аңлауга зур игътибар бирә. СССР язучыларының IV съездына КПСС Үзәк Комитеты котлавында болай диелә: «Безнең әдәбиятның принципиаль яңа сыйфаты шунда, ул Советлар Союзындагы һәр халыкның прогрессив традицияләрен үзенә туплаган күп милләтле әдәбият буларак үсә. Ленинчыл милли политиканың тантанасы, халыкларның төп интересларының уртаклыгы, аларның дуслыгы һәм туганлыгы милли әдәбиятларның чәчәк атуы өчен нигез булып тора. Ул әдәбиятларга идеаллар һәм максатлар бирлеге, традиция һәм формаларның күп төрлелеге характерлы. Илебездәге барлык халыклар әдәбиятларының туганлыгын тагын да ныгыту, аларның бер-берсен баетышуы — коммунистик җәмгыять культурасын уңышлы булдыруның объектив закончалыгы һәм мөһим шарты»[2].

## Тормыш таләбе

Милли әдәбиятларның үсеш тенденцияләрен һәм элемтәләрен тикшергәндә халыкларыбыз тормышындагы тирәнтен экономик һәм социаль-политик үзгәрешләрне исәпкә алмыйча ярамый. Әдәбиятны тормыш көзгесе дибез икән, ул әлеге үзгәрешләрне чагылдырмыйча кала алмый.

Милли мөнәсәбәтләр үсешенең хәзерге этабы исә совет милләтләре һәм халыклары тормышындагы барлык якларның тагын да интернациональләшә баруы, аларның бер-берсенә янә дә якыная төшүе белән сыйфатлана. Милләтләрнең бер-берсенә якынаюы турында сөйләгәндә, без аларның экономика һәм политика өлкәләрендәге хезмәттәшлегенең, туганнарча ярдәмләшүенең көчәюен, күп милләтле дәүләтнең ныгуын, милли культураларның бер-берсенә булган йогынтысының һәм бер-берсен баетышуының артуын, коммунистик идеологиянең һаман киңрәк катлауларның иманына әверелә баруын күздә тотабыз.

Милләтләр тормышы интернациональләшүенең үзенчәлекле күренеше — кешеләрнең яңа тарихи гомумилеге — совет халкының барлыкка килүе. Бу — яңа җәмгыять төзү дәвамында милләтләр һәм халыклар арасында, сыйныф һәм социаль төркемнәр арасында дуслык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләренең ныгып урнашуы турында сөйли. Совет халкын тәшкил иткән милләт һәм халыкларның яңа, уртак сыйфатлары бар. Бу — территория берлегендә, экономик һәм политик тормышның, максат һәм мәнфәгатьләрнең бердәмлегендә, марксистик-ленинчыл идеологиянең берлегендә, рухи дөньяның уртак билгеләрендә чагыла.

Әлеге хәл безнең әдәбиятларыбызда интернациональ теманың, халыклар дуслыгы темасының киңрәк урын ала баруына китерә. Һәр әдәбиятка, шул җөмләдән татар әдәбиятына да, хас күренеш бу.

Халык хуҗалыгының зур бурычларын бөтен ил белән бергәләп хәл итү, эре промышленность үзәкләрен күмәкләшеп төзү, табигый байлыкларны кулга-кул тотынып эшкәртү Советлар Союзы халыкларының аралашуын көчәйтә. Миграция процес-

[1] Карагыз: СССР халыклары әдәбияты һәм сәнгатенең үзара элемтәләре һәм бер-берсенә йогынтысы проблемалары (рус телендә). Мәскәү. 1968 ел. 27 бит.

[2] «Правда» газетасы. 1967 ел. 23 май.

ларының киңәюе интернациональ коллективлар барлыкка килүгә сәбәп була. Язучы үзенең әсәренә шундый коллективларны объект итеп алган икән, әсәрнең эчтәлеген дуслык-туганлык темасының, образлар системасына төрле милләт вәкилләренең килеп керүе бер дә гайре табигый түгел. Әйтик, Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар»ында, Г. Ахуновның «Хәзинә» һәм «Хуҗалар»ында, Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романында без төрле милләт вәкилләре образларын тормыш агышын дөрес гәүдәләндергән бик урынлы күренеш дип кабул итәбез. Әлбәттә, без әсәргә төрле милләт вәкилләрен кертү генә аның интернациональлеген билгели диган караштан ерак торабыз. Бу — һәр очракта язучының конкрет максатына, сурәтләү объектына бәйле.

Әмма теге яки бу әдәбиятта төрле милләт вәкилләрен гәүдәләндерү мәсьәләсе теоретик планда да, практик планда да бөтен буена алга килеп басты. Яшерен-батырын түгел, еш кына хәлләрдә әдәбиятта башка милләт вәкилләре образларын гәүдәләндерү теләгән максатка ирешми. Бу хакта А. Кешоков болай диган иде: «Еш кына язучыларга башка милләт образларын тудыруда художество тактының булмавы һәм эмоциональлекнең җитмәве комачаулык итә, шуңа күрә алар кайчак төссез, гәнаһсыз, агартылган яки, киресенчә, тупас, художество ягыннан ышандырмый, халыкның милли хисләрен күерта торган булып чыгалар»[1].

Милли әдәбиятларда интернациональ пафосның көчәя баруы турында сүзне дәвам иткәндә, чит илләр темасының, дөнья язмышы темасының киң сулыш алып яши башлавын да истә тотарга кирәк. Бу — интернационализмның офыклары киңәюдән килеп чыга. Хәзер совет патриотизмы туган илгә тирән мәхәббәт белән генә түгел, ә барлык социализм илләре халыкларына бирелгәнлек, бөтен дөнья хезмәт ияләренә пролетар теләктәшлек белән дә улчәнә. Шул сәбәпле совет язучылары, шул җөмләдән татар әдипләре, әлеге темага бик теләп мөрәҗәгать итәләр. Мисал эзләп ерак барасы юк. Аны һәр әдипнең иҗатында табарга мөмкин.

Шул рәвешле, бүгенге чынбарлыкның үсеш тенденцияләренә төшенгән язучы иҗат процессында тормышның барлык тармакларында бара торган интернациональләшү күренешләре белән, социалистик тормыш рәвешенең интернациональ характеры белән исәпләшми кала алмый, шуны үзенең әсәрләрендә гәүдәләндерми кала алмый.

Үзеннән-үзе аңлашыла, әдәбиятның җаны — кеше. Совет әдәбиятының үзәгендә дә төрле милләт кешесе тора. һәм совет әдәбиятының интернациональ рухын шушы яңа кеше — милли чикләнгәнлектән, милли эгоизмнан азат булган чын патриот һәм интернационалист совет кешесе билгеле. Совет кешесе үз милләте турында гына түгел, башка милләт һәм халыкларның мәнфәгатен дә кайгырта, үз хезмәт җимешләренең Совет Республикалары Союзына берләшкән ун миллионнарча һәм йөз миллионнарча кешеләргә тиячәген яхшы аңлый.

Совет кешеләре, ата-бабалары җиренә, туган культурасына, үз теленә, традицияләренә һәм гореф-гадәтләренә мәхәббәт, якынлык хисе саклаган хәлдә, туган ил төшенчәсен аерым милләт кысалары белән генә чикләмиләр. Алар — бер социалистик Ватан балалары. Безнең Ватаныбыз исә — Тын океаннан Балтик диңгезенә кадәр, Төньяк боз океаныннан Памир һәм Кавказга кадәр җәелгән иксез-чиксез киңлекләр алар. Совет кешесен ил хәлләре генә түгел, гомумән, планета язмышы да кызыксындыра. Ул чит илләрдәге сыйныфташ туганнарына һәрчак ярдәм кулы сузарга әзер тора. Мондый кешене Коммунистлар партиясе тәрбияләп үстерде.

Язучы рухи дөньясының гомуми сыйфатларын иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең яңа тибы тудырган һәм СССР халыкларының иң яхшы традицияләрен үзендә туплаган чын патриот һәм интернационалист совет кешесен бөтен буена сурәтли ала икән, аның күпьяклы характерын оста иҗат итә ала икән, бу образ һәр милләт кешесенә якын һәм аңлаешлы булачак, аның рухи дөньясын баетачак, акылына һәм хисләренә тәэсир итәчәк.

Ул чагында милли әдәбиятның интернациональ рухы көчәячәк, димәк, аның төрле милләт хезмәт ияләрен интернационализм принципларында тәрбияләүдә роле күтәреләчәк.

---

[1] «Литературная Россия» газетасы, 1966 ел, 6 май.

Совет әдәбиятларының бер-берсенә якынаюлары өчен мөһим объектив шартларның берсе — төрле милләт әдипләренең чынбарлыкны чагылдыруда социалистик реализм методына таянып эш итүләре. Социалистик реализм милли әдәби традицияләрне дәвам иттерү генә түгел. Социалистик реализмның барлыкка килүе әдәбиятлар арасында элемтәләрнең киңәюе, аларның бер-берсенә йогынтысының киңәюе белән сыйфатлана торган кешелек культурасы тарихында яңа чор килү белән бәйләнгән. Социалистик реализм милли әдәбиятларның тәҗрибәсенә таяна. Ләкин ул дөньяның иң төрле әдәбиятларында ныклы тамырлар җибәргән интернациональ, дөньякүләм тарихи, сыйфат ягыннан яңа бер күренеш. Г. Ломидзе хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, теге яки бу әдәбиятларда аны формалаштыруда өч көч: а) конкрет социаль тормыш шартлары, б) милли традицияләр, в) социалистик әдәбиятларның күмәк художество тәҗрибәсе һәм прогрессив бөтен дөнья әдәбиятының тәҗрибәсе катнаша [1].

Социалистик реализм күп милләтле совет әдәбиятының гомуми закончалыкларын билгели. Бу закончалыклар аның үсешендә, чынбарлыкны партиялелек, сыйнфыйлык, реализм позицияләреннән чыгып художестволы үзләштерүдә хәлиткеч роль уйныйлар.

Әдәбиятларның бер-берсенә якынаюларында совет әдипләренең дөньяга бердәм караш — марксистик-ленинчыл караш торулары гаять зур әһәмияткә ия. Алар барлык социаль күренешләргә шул караштан чыгып бәя бирәләр, дөньяны художестволы танып-белүдә марксистик-ленинчыл методологиягә таяналар. Шул җөмләдән, милли мөнәсәбәтләрнең үсешен дә фәнни нигездә аңлау язучыга үз милләте тормышын совет милләтләре семьясының бер әгъзасы тормышы итеп чагылдырырга ярдәм итә. Җәмгыятьнең интернациональләшүенә аңлы караш — милли чикләнгәнлек күренешләреннән азат булуның бер гарантиясе.

СССР төзелүгә 50 ел тулуны совет кешеләре гаять зур күтәренкелек белән билгеләп узган чакта без зур ышаныч белән әйтә алабыз: һәрбер совет язучысы үзен теге яки бу әдәбият вәкиле итеп кенә санамый, бәлки бөтен совет әдәбияты исеменнән дә «чыгыш» ясый һәм үзенең «чыгышын» барлык милләт вәкилләренә юллый.

Болар барысы совет әдәбиятларының тигез хокуклы хезмәттәшлегенең һәм бер-берсенә якынаюының объектив сәбәпләрен тәшкил итә.

Димәк, милли әдәбиятларның безнең чордагы дуслыгы-туганлыгы мәсьәләләрен тикшергәндә һәм пропагандалаганда, аларның бер-берсенә якынаюын һәм үзара баетышуын әдәби атналыклар, төрле милләт әдипләренең юбилейларын уздыру, әсәрләрне тәрҗемә итешү кебек чараларга гына кайтарып калдырырга ярамый (әлбәттә, алар әдәбиятлар дуслыгын, халыклар дуслыгын ныгытуда, һичшиксез, зур роль уйныйлар). Әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләре алдында бу катлаулы процессның асылын ачу, аның конкрет чагылышларын тирәнтен өйрәнү өлкәсендә зур бурычлар тора. КПСС Үзәк Комитеты «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында әдәбиятларның бер-берсен баетышуы һәм бер-берсенә якынаюы проблемаларының җитәрлек өйрәнелмәгән булуын күрсәтеп узды.

Безнеңчә, бу процессны өйрәнүдә уңыш китерә торган иң мөһим юл — гомум совет әдәбиятының үсеш закончалыкларын һәм шул закончалыкларның аерым әдәбиятларда ничек эш итүен тикшерү. Чөнки һәр милли әдәбият гомум совет әдәбиятының состав өлеше буларак үсә. Аның гомум совет әдәбиятына нисбәте өлешнең бөтенгә нисбәте кебек. Өлешнең сан һәм сыйфат үзгәрешләре бөтеннең сан һәм сыйфат үзгәрешләренә йогынты ясый һәм киресенчә. Әмма ассызыклап әйтергә кирәк: бөтеннең үсеш юллары өлешнең үсеш юлларын билгеләүдә хәлиткеч роль уйный.

Милли әдәбиятларның дуслыгын ныгыту, аларның интернациональ пафосын көчәйтү, аларның бер-берсен баетышуы процессына актив йогынты ясау совет халыкларын туганлык рухында тәрбия итү эшенә, аларның рухи бердәмлеген ныгытуга лаеклы өлеш кертү дигән сүз ул.

---

[1] Георгий Ломидзе. Совет әдәбиятының интернациональ пафосы (рус телендә). Мәскәү. 1967 ел. 222 бит.

## Марсель Зарипов

# ЯШЕЛ ХӘЗИНӘ

Кара син аны, без сөт тәмен онытып барабыз икән ләбаса. Мин чын мәгънәсендәге сыер сөте турында әйтәм. Ә кибет сөте... Аннан, иң әйбәт дигәндә дә, алюмин фляга яки кыш буена әчеп яткан кукуруз силосы исе килә бит.

Ленин исемендәге совхозның җәйге лагеренда безгә берәр банка яңа сауган сөт бирделәр. Күбекләре әле һаман гөбердәп торган ул сөт — менә чын сөт иде, ичмаса! Мең төрле хуш исле үлән исләре бар иде анда. Һәм мин шул минутларда, үзем дә сизмәстән, инде еракта, бик еракта калган бала чагымны, авылыбызның әйтеп кенә дә аңлатып булмаслык хуш исле үләнле һәм чәчәкле болынын, шул болында сыер көтеп йөргән вакытларымны исемә төшердем. Хәтеремдә, әнием ничек кенә ашыккан вакытларында да:

— Кара аны, малай, сыер әрем ашый күрмәсен! — дип кисәтеп куя торган иде.

Шайтан аңлаган ул сыерның холкын! Безнең болыннан да шәбрәк болын бу дөньяда, белмим, бармы икән. Яз көннәрендә болын су астында кала, аннары су китә һәм җәй урталарына ул бил тиңентен чәчәкле, сулап туймаслык хуш исле печән белән каплана торган иде. Ашау дигәндә җәһәннәм тишегенә барып керергә әзер торган сыер өчен шуннан да яхшырак азыкның булуы мөмкин дә түгел. Әмма, шулай булуга да карамастан, безнең әлеге сөңге мөгезле сыерыбыз, кызыл һәм ак калфакларын киеп ерактан ук кызыктырып торган клеверларны һәм башка шуныңише әйбәт-әйбәт үләннәрне ташлап, сукмак буйларында үскән бака яфракларын ашый һәм, җае чыкса, ачы әремне дә бик тәмләп әләктереп алырга чамалый торган иде. Ә без, малайлар, сыер саклап торабызмыни? Безгә, төрле күбәләкләр артыннан чабып, чикерткәләр тотып уйнау булсын да, тәннәребездәге тәкләр шырт шикелле булып кабарып чыкканчы, тешләребез тешкә тими башлаганчы су коену булсын!

Кич белән өйгә кайткач, әни миңа калын итеп киселгән бер телем икмәк белән бер кружка яңа сауган җылы сөт бирә иде.

— Әч, улым! Яңа сауган сөтнең шифасы зур аның. Тизрәк үсәрсең.

Күбекләнеп, гөбердәп торган ул сөт чыннан да бик тәмле була, аннан болындагы чәчәкләр исе, кыр исе һәм кояш исе килә. Гомумән, кичке авыл һавасы сөт исе белән тулган була иде, һәм мин әнием биргән әлеге бу бер кружка сөтне эчеп бетергәнемне тоймый да калам да аннан тагын салып бирүен сорый идем. Ә кайчакларда исә сөтне авызга да алырлык булмый — әрем тәме килә. Мондый көннәрдә әни дә эшнең нидә икәнлеген сизеп ала. Ләкин ачуланмый. Ризасызлыгын белдереп, тагын уенга мавыгып, сыерны оныткансың икән бит, малай актыгы, дигән сыман итеп, бер тутырып карап ала да бүтән бер сүз дә дәшми. Андый көннәрдә теге калын итеп киселгән бер телем икмәкне корылай яки сулап ашау белән генә канәгатьләнергә туры килә торган иде. Ләкин, бәхеткә каршы, андый күңелсез чаклар сирәк очрый, сыерыбызның сөте, гадәттә, эчеп туймаслык дәрәҗәдә тәмле була торган иде...

Ленин исемендәге совхоз сыерларының сөте нәкъ әнә шул мин бала чактагы үзебезнең сыер сөте шикелле хуш исле һәм искиткеч тәмле булып чыкты һәм минем күңелдә инде онытылып барган әлеге бала чак хатирәләрен яңартып җибәрде.

Ә бу совхоз җәйләвенә без — бөтен союз күләмендә үткәрелә торган зур семинарга җыелган кешеләр — ничек итеп яңача болын, ягъни сугарулы көтүлекләр ясаганны карарга дип килдек. Без бик күбәү, илебезнең төрле почмакларыннан җыйналган һәм авыл хуҗалыгын яхшы белүче кешеләр: колхоз председательләре, совхоз директорлары, район, край һәм өлкә авыл хуҗалыгы идарәләре начальниклары, «Сельхозтехника» белгечләре, мелиораторлар, галимнәр, авыл хуҗалыгы белән бәйле проектчылар, өлкә һәм союз масштабындагы партия аппаратларының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдирләре, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре белән җитәкчелек итүче өлкә комитеты секретарьлары. Ә минем ише журналист агай-эне турында әйткән дә юк инде!..

Совхозның болынын карап чыккач, минем бала чак хатирәләрем тагын бер кат яңарды. Әйе, боларның болынында да шул безнең авыл болынындагы шикелле үк мең төрле чәчәкле һәм хуш исле үләннәр үсеп утыра, монда да нәкъ андагы шикелле бал кортлары безелдәшә иде. Аерма тик шунда гына, безнең авылның болыны табигать-анабыз тарафыннан яңартылган, ә бу совхозныкын кешеләр үзләре ясаганнар. Зыяны тимәсә дә, бер тиенлек файда да китермичә тик ята торган тугайны тал-куаклардан арчып, иске агач төпләреннән чистартканнар да бик әйбәтләп сукалап-сөреп чыкканнар. Аннары шул җирне ашлаганнар, үлән орлыклары чәчкәннәр. Аерым кишәрлекләргә бүлеп, киртәләп алганнар. Шул кишәрлекләрнең һәркайсына электрокөтүче куйганнар. Моторлар, насослар көйләп, кирәк булган саен ул болынга яңгыр яудырып торганнар. Ә болынның печәне бер чирек чамасы үскәннән соң аны сыерларга ашата башлаганнар. Менә хәзер алар шул ясалма болында тиешле көннәрендә тиешле кишәрлектә рәхәтләнеп утлап йөриләр һәм потлап-потлап сөт җыялар икән. Суга да әллә кая барып йөрисе түгел: шунда ук автоэчергечләр дә куелган. Сыерларны саудыру аппаратлары да, савылган сөтне суыту пункты да шунда: яздан ук хәстәрен күреп, боз әзерләп куйганнар икән, сөтне шуның белән суыталар. Бу болынның тагын бер яхшы ягы бар: монда сөтнең тәмен ала торган ачы әрем үсми. Ә әрем үсә торган җиргә сыерлар бара алмый — электрокөтүче җибәрми.

Ләкин бу болынның безнекеннән иң зур аермасы болар гына түгел әле. Безнең болынның печәнен июнь ахырларында бер тапкыр чабып алалар иде дә шуның белән вәссәлам. Бик сирәк, яңгырлы җәйләрдә генә икенче покоска чыккалыйлар иде. Ә бу совхозда!..

Болар бер кишәрлектәге печәнне ашатып бетергәч, сыерларны икенче кишәрлеккә күчерәләр. Ә бушап калганын тырмалап һәм ашлап чыгалар да кирәгенчә «яңгыр яудыра» башлыйлар — су сиптерәләр. Җәйге эсседә мул итеп яңгыр яуганнан соң үләннең ничек котырып үсеп китүен сөйләп торуның беркемгә дә кирәге юктыр дип уйлыйм. Шулай итеп, яңгыры да, җылысы да җитәрлек булганлыктан, ике атна дигәндә әлеге кишәрлектә тагын тез тиңентен печән үсеп җитә: теләсәң — чабып ал, теләсәң — тагын сыерлар кертеп ашат. Кыскасы, бу совхозда һәр кишәрлектә бер җәйдә дүртәр тапкыр печән үстерәләр икән. Безнең якларда гына түгел, бөтен Идел буенда да булганы юк иде әле мондый хәлнең. Бу ясалма болынның без белгән табигый болыннан иң зур һәм иң әһәмиятле аермасы менә шунда!

Сизеп торам, кайберәүләрнең, тагын үлән мәсьәләсен кузгатасыңмыни, әле кайчан гына шул үләннәрнең яманатын сатып, болыннарны, үлән кырларын сөреп ташлаган идек бит, дип каш җыерып куюлары мөмкин. Әйе, андый хәлләр дә булды заманында. Ләкин бу очракта, ашыгып нәтиҗә ясаудан элек, эшнең асылын күздән кичерергә кирәк. Беренчедән, шуны истән чыгармыйк: ул чакта да бөтен болыннарны да түгел, бәлки печәнне бик аз бирә һәм башка төр культуралар (мәсәлән, кукуруз белән) һич тә ярыша алмый торган зәгыйфь үләнле болыннарны гына сөрделәр. Билгеле, һәр эштә чама кирәк. Кайбер колхозларда, болыннарны гомумән сөреп ташлап, хәтта яшь бозауларга ашатырлык та печәнсез калган очраклар да булмады түгел.

Ләкин кукурузны хаксызга кимсетергә кирәк түгел. Әле моннан ун-унбиш ел элек кенә кукурузга җаны-тәне белән каршы торган колхоз председателенә хәзер, кукуруз чәчмә, аның урынына җаның теләгән теләсә нәрсә үстер, дип әйтеп карагыз әле. Ул һич тә риза булмаячак. Терлекләргә мин нәрсә ашатыйм, диячәк ул. Аннары шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: үлән чәчүне бетерергә никадәр генә тырышмасыннар — барыбер аны бетерә алмадылар бит. Минемчә, РСФСРда болынлыклар әле хәзер дә кирәгеннән бик күп артык. Мәсәлән, табигый болынлыклар, көтүлекләр һәм печәнлекләр 86 миллион гектар мәйдан биләп тора. Бу мәйданга Татарстанныкы кадәр егерме республиканың чәчүлек җирен урнаштырып булыр иде. Ләкин нинди болыннар һәм көтүлекләр соң алар? Шул 86 миллион гектарның нибары егермедән бер өлеше генә культуралаштырылган, ә калганнары барысы да мелиорация эшләре алып баруны таләп итә торган җирләр. Югыйсә, аларның продуктлылыгы ташка үлчим генә: җәй көне терлекләрне бер ай ашатырга җитсә — бик шәп инде. Хәер, сүзне саннарга бирик әле. Безнең илдә бары тик табигый печәнлекләр генә дә кырык миллион гектар мәйдан тәшкил итеп тора. Бу, картлар әйтмешли, алла биргән хәзинә. Монда сөрәсе дә, чәчәсе дә түгел, әзер печәнне чабып алып богылга салып куясың да, шуның белән эш бетә. Әмма бөтен хикмәт шунда — богылга салырлык печәне күп булмый шул аның. 1940 елда уннарча миллион гектар болынның һәр гектарыннан 9 ар центнер, илленче елда 7,5 әр, алтмышынчы елда 6,6 шар, ә җитмешенче елда нибары 6,1 әр центнер печән җыеп алынган. Күрәсез, мактанырлык эш юк. Әгәр эшләр шәп булган булса, чәчү җирләрендә терлек азыгы үстермәсләр иде, әлбәттә. Ә бит чәчүлек җирләр безнең илебездә болай да бик чамалы — кеше башына бер гектардан да азрак төшә. Һәм ул, Бальзакның теге шигрин күне сыман, һаман кысыла, кечерәя бара. ВАСХНИЛның вице-президенты академик Панниковның һәр яктан фәнни нигезләнгән һәм «Белем» җәмгыяте тарафыннан бастырылып чыгарылган лекциясеннән бер өзек китереп үтәм: «Соңгы елларда,—

дип яза ул,— илебездә 6 миллион 880 мең гектар чәчүлек җир яткын җиргә әвереелдерелгән. Бу процесс әле хәзер дә дәвам итә. Безнең агрономиягә караган әдәбиятта бу тискәре процесска ялгыш бәя бирелә, чәчүлек җирләрне, бигрәк тә тотрыклы игенчелек зоналарындагы җирләрне, бернинди сылтау белән дә киметергә ярамый, дигән катгый кагыйдә истән чыгарыла». Шунысын да әйтергә кирәк (монда мин галимнең стилен һәм фикерен һич тә үзгәртмичә язам) табигый печәнлекләрнең һәм көтүлекләрнең продуктлылыгын күтәрүгә тиешле игътибар булмау тагын да аянычрак нәтиҗәгә, атап әйткәндә, терлек азыгы культураларын чәчүлек җирләр хисабына арттыруга китерә. Мәсәлән, соңгы егерме биш ел эчендә генә дә башаклы культуралар мәйданы Белоруссиядә 500 мең гектарга, Литвада 600 мең, Латвиядә 500 мең, Эстониядә 250 мең, Россия Федерациясенең Көнбатыш районында 1 миллион, Үзәк районында 1 миллион 300 мең, Идел — Вятка районында 700 мең гектарга кимегән.

Бу җәһәттән караганда безнең республикабызда хәлләр ничегрәк тора соң? Иң элек шуны әйтеп китәргә кирәк: ихтимал, соңгы елларда Татарстан бөтен теләсә кайсы республикага караганда да җирен күбрәк югалткандыр. Илнең энергетик могҗизасы булган Идел һәм Кама гидростанцияләре генә дә республикабызга берни белән дә каплап булмый торган зур зыян китерде: Куйбышев диңгезе астында 300 мең гектар иң уңдырышлы җирләребез калды. Ә тиздән Түбән Кама гидростанциясе сусаклагычы тагын 200 мең гектар җирне йотып алачак. Шушылар янына тагын уннарча мең гектар чәчүлек җирләрнең нефть промыселлары һәм Кама автозаводы астында калуын да исәпкә алсаң — бу инде зур, бик зур югалту дигән сүз. Дөрес, хәзергә безнең республикада җан башына 1,2 гектар җир, ягъни ил буенча алганда уртачадан артыграк туры килә. Ләкин хәзергә генә шул... Чаллы, Түбән Кама һәм Зәй шәһәрләре һаман үсә бара. Демографларның исәпләвенә караганда, алдагы елларда республикабызның халкы тагын бер миллион кешегә артырга тиеш. Шуңа күрә бездә җир «уртачадан күбрәк» дип тынычланып ятарга һич тә нигез юк.

Ә хәзер республикабызда чәчүлек җирләр ничек файдаланылуын күздән кичереп үтик. Революциядән соң республиканың чәчүлек мәйданы 1 миллион 177 мең гектарга артты. Шуның нәтиҗәсендә барлык җирнең 83 проценты сөрү мәйданына әверелдерелде. Ләкин өстәлгән 1 миллион 177 мең гектар җирнең бары тик 64 мең гектары гына иген җире ителеп, башкалары терлек азыгы культуралары үстерелә торган җирләр генә булып калды. Революциягә кадәр барлык сөрү җирләренең 96 проценты иген кыры булган булса, 1966 елда исә ул нибары 67 процентка гына калган иде инде. Моннан ярты гасыр элек терлек азыгы культуралары гомуми мәйданның нибары 0,3 процентын гына тәшкил иткән булса, хәзер ул сан йөз тапкырга диярлек артты инде. Бер караганда монда һич тә гайре табигый хәл юк: авыл җирендә терлекләр саны да бик нык артты бит. Соңгы илле ел эчендә республикабыздагы мөгезле эре терлекләр ике, дуңгызлар дүрт тапкыр, сарыклар һәм кәҗәләр саны 15 процентка арткан. Аларны ашату өчен сөрелә торган җирләрне файдалана башладылар, ә 800 мең гектарга якын табигый печәнлекләр һәм көтүлекләр терлекләргә җитәрлек азык бирә алмыйлар. Сугарыла торган культуралы көтүлекләрнең өстенлекләре бу яктан чагыштыргысыз дәрәҗәдә югары тора. Культуралы көтүлекләрдән файдаланганда, чәчүлек мәйданнарына бер дә зыян китермичә дә, кирәк кадәрле терлек азыгы үстерергә мөмкин. Алай гына да түгел, хәтта моңарчы терлек азыгы үстерүгә тотылган шактый гына җирләрне яңадан иген кыры итеп файдалана башларга шартлар туачак. Алга китебрәк булса да

шуны искәртеп үтәсем килә: күп хезмәт таләп итә, әмма аз печән бирә торган берьеллык үләннәр генә дә әлегә безнең илдә 18 миллион гектар мәйдан билән тора.

* * *

Культуралы көтүлекләрне гамәлгә ашыру мәсьәләсендә Татарстан тәҗрибәсе шактый гыйбрәтле һәм файдалы. Шуңа күрә аның белән ныклабрак танышып китүнең һич тә зыяны булмас дип уйлыйм.

Лениногорск авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Александр Алексеевич Ишелин моннан өч ел элек (ул чакта ул совхоз директоры булып эшли иде әле) авыл хуҗалыгы белгечләре группасы белән Волградка китә. Анда баруының максаты — җирне ясалма сугару чаралары белән танышу һәм, мөмкин булса, өйрәнеп кайтып, шуны үзебезнең якларда да куллана башлау. Югыйсә, эшләр шәптән түгел: районда ел саен терлекләр арта тора, ә аларны ашатырга азык җитми. Районның 27 мең гектарга якын көтүлекләре һәм печәнлекләре булуга да карамастан, терлекләргә азык җиткерә алмаганга күрә, тагын 7 мең гектар чәчүлек мәйданын яшел конвейер итеп файдаланырга туры килә: ул җирләргә арыш, кукуруз, берьеллык һәм күпьеллык үләннәр чәчеп үстерәләр дә аны июнь урталарында ук терлекләргә ашатып бетерәләр. Шунсыз юньләп сөт тә, ит тә алам димә. Әлеге 7 мең гектар яшел конвейер да һаман арта барган терлекләрне туендырырга җитми башларга мөмкин бит. Шул ук вакытта чәчүлек җирләрне дә туктаусыз кыскартып булмый. Терлек азыгы культуралары болай да һәр өч гектар җирнең берсен билән торалар. Ә бит терлек азыгыннан тыш, арыш, бодай, шикәр чөгендере, бәрәңге һәм яшелчә әйберләре дә үстереп, шәһәр халкын да туендырырга кирәк ләбаса...

Сугарулы җирләр мәсьәләсе белән шөгыльләнә торган Волгоград фәнни-тикшеренү институтында кунакларны якты йөз белән каршы алалар һәм кырларны сугаруның бөтен нечкәлекләрен бер дә иренмичә аңлатып бирәләр. Ә инде эш практик ярдәм мәсьәләсенә килеп терәлеп, әлеге сугарыла торган, ягъни культуралы көтүлекләрне ясау өчен проектлар эшләп булмасмы дип сүз купкач исә, тегеләр башларын гына чайкыйлар. Янәсе, Лениногорск районы бөтенләй башка зонада, монысы — бер. Икенчедән, институт андый вак-төяк көтүлекләр белән түгел, бәлки, эшләгәч-эшләгәч ашы да булырлык булсын дип, зур-зур мәйданнарны сугару белән генә эш итә. Ә Лениногорскида алай эшләү мөмкин түгел. Җирләр монда чокырлы-чакырлы. Көтүлекләрне дә шундый бер нәрсәгә дә ярамый торган, бөтенләй адәм башына да килмәслек ташлы-таулы урыннарда, сазлыкларда ясарга туры килә икән әле. Юк, мондый эш өчен көч түгүдән файда булмас. Мондый эш өчен төзегән проектны беренче экспертизадан ук борып кайтарачаклар. Институтның дәрәҗәсен генә төшерәчәк, имеш...

Шулай да галимнәр, кунакларның хәленә кереп, Лениногорск районына консультант җибәрәләр. Теге иптәш килә, күрә һәм байтак кына файдалы киңәшләр дә биреп китә. Әмма сугарулы көтүлекләр проектын эшләүне ул иптәш дә, институт та өстенә алмый.

Менә шул чакта нефтьчеләр батырлык күрсәтә. Тәвәккәлләп тотыналар да проектны эшләп тә бирәләр. Болай карап торырга бөтен нәрсәсе дә тәртиптә була ул проектның: сызымнары да, схемалары да һәм күпме акча тотылырга тиеш икәнлеге дә күрсәтелә. Ләкин бу проект Ишелинны куандырмый гына түгел, киресенчә, чәчләрен үрә торгыза. Хикмәт шунда, бу проект буенча 60 гектар мәйданда суга-

рулы көтүлек ясау өчен 21 километр озынлыгында тирән канаулар казырга, ул канауларга торбалар сузарга да аларны җиргә күмәргә кирәк була. Нефтьчеләрнең кагыйдәсе шундый: алар торбаларны һәрвакыт җиргә күмәргә тиеш. Нибары алтмыш гектар җиргә егерме бер километрга сузылган канауны урнаштырып карагыз әле сез?! Җирнең яртысы актарылып бетәчәк дигән сүз лэбаса бу. Ә ул җир астыннан чыккан уңдырышсыз балчык өстендә нәрсә үссен? Юк, гади су белән генә түгел, изге чишмә суын ташып сипсәң дә, берничә елсыз үлән үсәчәк түгел ул канаулар өстенә. Ә бит лениногорскилыларның максаты — бер җәйдә өч-дүрт уңыш үстерү!

Кыскасы, нефтьчеләрнең проектыннан баш тартырга туры килә. Лениногорск районы колхозларында һәм совхозларында бу эш әнә шулай абсолют нульдән башланып китә. Ә хәзер, ул көннән соң нибары өч ел үткәч, райондагы унҗиде хуҗалыкның унбишендә үзләренең сугарулы көтүлекләре бар инде. Һәм ул көтүлекләрнең Шушма, Зәй тугайларындагыларында да, кашлык җирләрендәгеләрендә дә үлән бердәй мул үсә. Чөнки аларга теләгән вакытта һәм кирәк кадәр ясалма яңгыр яудырып торалар!

Казанда үткәрелгән әлеге Бөтенсоюз семинары алды көннәрендә генә Александр Алексеевич Ишелин белән без Калинин исемендәге колхоз көтүлеге яныннан үттек.

— Әнә карагыз әле,— диде миңа Александр Алексеевич, бәләкәй генә авыл елгасы буендагы таудагы ул көтүлекне күрсәтеп.

— Судан йөз дә унбиш метр биеклектәге шул тауда шаулап печән үсеп утыра. Андагы шикелле печәннең, ихтимал, болында да булганы юктыр. Узган ел шул җирне җәенә өч тапкыр чабып, 420 центнер яшел масса алдык. Шул ук җирдән кышка сенаж салдык, печән әзерләп куйдык. Шунда ук җәй буе 429 баш сыерны ашатып йөрттек. Тагын шунысы кызык: шушы урында сугарулы көтүлек төзү өчен проект эшләп бирүләрен үтенеп, башта без үзебезнең нефть институты белгечләренә мөрәҗәгать иткән идек, авыл хуҗалыгы белгечләре эшли алмаганны без дә булдыра алмабыз дип, алар да риза булмады. Шуннан соң без, ни булса шул дип, үзебез тәвәккәлләргә булдык. Көтүлексез барыбер эш чыкмаячак дип, шефларыбызга аңлаттык та алар ярдәме белән эшкә тотындык. Елга буена биш йөз киловатт куәтле насос куйдык, аннан тау башына торбалар сузып, ясалма яңгыр яудыру җайланмасына тоташтырдык та насосны эшләтә башладык. Менә шуннан акрынлап башланып китте инде аннары.

Безнең заманда мондый нәрсәләрне генә ясау әллә ни гаҗәп хәл түгел, әлбәттә. Йөз унбиш метрлы тауга гына түгел, теләгәндә Каф таулары башына да су кудырып менгерергә булыр иде. Ләкин аның кемгә файдасы бар соң? Ә файдасыз эшне беркем дә, крестьян халкы исә бигрәк тә яратмый. Дөресен әйтергә кирәк, башта без үзебез дә бераз шикләнгән идек: 120 гектар җиргә шул тикле расход чыгарып, шул тикле хезмәт кертеп тә ул расходларны һәм түккән көчне тиз генә аклый алмасак нишләрбез? Ләкин безнең ул шикләнүләребез, шөкер, юкка булып чыкты...

Бер Калинин исемендәге колхозда гына түгел, Лениногорск районының бүтән күп кенә колхозларында һәм совхозларында да ясалма болыннарның файдалы булуын, андый болыннарны ясауга киткән чыгымнарның бик тиз аклануын инде яхшы аңлыйлар. Чөнки ул файда — күз алдында. Тагын саннарга мөрәҗәгать итик. Шул ук Лениногорск районының «Ленинский путь» колхозында, мәсәлән, сугарулы болынлыклары юк чагында нибары 385 баш сыерларын туйдырып тору мәсьәләсе дә бик кыенлык белән генә хәл ителә килгән. Ә хәзер, ясалма көтүлекләре булганнан соң, алар сыерларын

елдан-ел арттыра баралар һәм шушы бишьеллык ахырына 800 ба ка җиткерергә уйлыйлар. Монда тагын шунысын да әйтеп үтәр кирәк: бу колхозда, сыерлары һаман арта баруга да карамаста хәзер элек яшел конвейер өчен тотылган 150 гектар чәчүлек мәйда ның хаҗәте калмаган, ул җиргә башаклы культуралар чәчеп, анн 3000 центнер иген уңышы җыеп ала башлаганнар.

Яки менә «Спартак» колхозын алып карыйк. Илле гектар мә данда культуралы көтүлек эшләү өчен, бу колхозда егерме өч м акча тотканнар. Шул илле гектардан бер җәй эчендә алынган үлән сөткә әйләндереп исәпләгәндә 2012 центнер, ягъни гектарына 40 центнер сөт туры килгән. Шулай итеп, яңа болынның һәр гектар 784 сум 68 тиенлек продукция биргән. Ә бернинди дә хезмәт керте мәгән табигый көтүлекләрнең хәле ничек соң? Аларның һәр гект рыннан 5,44 центнер сөт, ягъни 106 сум 88 тиенлек продукция алы ган. Күрәсез, ясалма көтүлекләр табигый көтүлекләргә караган җиде тапкыр күбрәк продукция биргән. Ә ул көтүлекләрне ясау тотылган чыгым нибары ике ел эчендә капланган. «Капитал, хезм һәм белем кулланып эш иткәндә җирнең уңышын чиксез арттыры га мөмкин» дигән хакыйкатьне раслауның матур үрнәге менә шуш инде!

«Авыл хуҗалыгының бүтән бер тармагы да үзенә тотылган чы гымнарны культуралы көтүлекләр кебек тиз каплый алмый. Ми моны үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм». Бу — республикабызның Саб районындагы Ленин исемендәге совхоз директоры, Социалисти Хезмәт Герое Габделхак Гали улы Галиев сүзләре. Ә ул — гомер буена авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләп килүче практик. Хисапчы д булган, агроном да, район җир бүлеге начальнигы да, МТС дире торы да булып эшләгән. «Безнең шартларда,— ди иптәш Галиев,— чәчүлек җиренең һәр гектары 20—30 сум чамасы, ә культуралы көтүлекләрнең һәр гектары 200 сум табыш бирә. Файдалы».

Әйе, файдалы. Ләкин культуралы көтүлекләрнең акчадан д мөһимрәк тагын файдалы яклары бар әле. Мин һәр төрле капитал дан да кыйммәтрәк булган иң зур байлыкны — җирне күздә тоты әйтәм. Лениногорск районының сугарулы болыннар ясаган хуҗалык лары (ә ул районда барлыгы 2180 гектар болын ясалган) узган е савым сыерларын бары тик шул болыннарда гына көткәннәр. Алар ның берсе дә бер генә гектар игеннәрен дә терлеккә ашатмаган. Нә тиҗәдә элекке елларда терлек ашатырга китә торган җиде ме гектарга якын җирнең игене янга калдырылган!

Бер Лениногорск районында гына түгел, ясалма болыннар бул дыруга ирешкән барлык колхозларда һәм совхозларда бу мәсьәл менә шулай тора. Муса Җәлил исемендәге колхозда, мәсәлән, моңар чы берьеллык үләннәр чәчеп килгән 150 гектар мәйданга иген чәч башлап, аннан 2340 центнер икмәк җыеп алганнар. Ә бу — колхоз ның савым сыерларына ашатыла торган бер еллык фураж дигә сүз!

Ленин исемендәге совхоз директоры иптәш Галиев бүтәнчәрәк эш иткән: сугарулы болыннар хисабына совхоз сыерларының баш са нын ике мәртәбә диярлек арттырган. Ә бишьеллык ахырына у гектарыннан нибары 7—10 центнер гына печән бирә торган 550 гек тар табигый болыннарын сугарулы көтүлеккә әйләндерергә һәм шулай итеп, иген мәйданын арттырырга җыена. Ни әйтсәң дә, бөтен эшнең башы шул икмәккә кайтып кала бит!

Һәр районда, һәр өлкәдә, һәр республикада һәм, гомумән, бөтен илебездәге хуҗалыклар шулай эшли башласа нәрсә килеп чыгар икән? Хәзерге көндә Татарстан колхозлары һәм совхозлары савым сыерлар көтүен ашату өчен һәр җәй саен 400 мең гектар игенне

сарыф итеп киләләр. Бу — республикабыздагы барлык уҗым мәйданының яртысы дигән сүз. Әгәр барлык колхозлар һәм совхозлар да терлекләрен гел культуралы көтүлекләрдәге азык белән генә туйдыра башласалар? Болай да һаман кечерәя барган сөрү җирләренә үлән чәчүнең хаҗәте калмас иде микән? Минемчә, бик реаль булачак хәл бу.

Казанда үткәрелгән әлеге семинарда чыгыш ясап, республикабызның Министрлар Советы Председателе Гомәр Исмәгыйл улы Усманов хәзерге көндә Татарстанның 300 хуҗалыгында сугарулы көтүлек булуын, ә шушы бишьеллык ахырына аларның саны тагын да арттырылып, барлыгы 150 мең гектар мәйданны тәшкил итәргә тиешлеген әйтте. Ясалма сугарулы шул болыннардан алынган терлек азыгы хәзер 800 мең гектар табигый болыннардан алынган азыкка караганда 2,5 тапкыр артыграк булачак. Мин инде илебездә 18 миллион гектар мәйданда берьеллык үләннәр чәчелүен, ә шуннан җыеп алынган печәннең бәрәннәр белән бозаулардан артмавын искәртеп киткән идем. Тәҗрибә шуны күрсәтә: сугарулы көтүлекләрнең уңышы кырга чәчелгән үләннәрнең уңышына караганда биш мәртәбә артык була икән. Димәк, сугарулы көтүлекләр ясаганда 18 миллион гектардан аласы терлек азыгын нибары 4—5 миллион гектардан алырга мөмкин. Шәп отыш бу, кызыктыра торган отыш!

* * *

Соңгы елларда авыл хуҗалыгында иң зур игътибар яулаган нәрсә — сугарулы көтүлекләр. Бер узган ел эчендә генә дә илебездә 90 мең гектар сугарулы көтүлек булдырылды. Бу — моңарчы ясалган барлык сугарулы көтүлекләрдән чак кына кимрәк. Ә быелгы план буенча тагын 300 мең гектар көтүлек ясалырга тиеш. Бишьеллык ахырында исә колхозларда һәм совхозларда 2 миллион гектар сугарулы болын булачак. Эшлисе эшләр бик җитди, алга куелган бурыч бик җаваплы, чөнки бу эшкә беренче тапкыр тотынган өлкәләрдә, безнең Татарстандагы кебек үк, барысын да яңабаштан башлап җибәрергә туры киләчәк. Ялгышлар, кимчелекләр дә булырга мөмкин, ахыр чиктә, алар барысы да бише белән капланачак. Чөнки моңарчы бер уңыш ала торган мәйданнан дүрт уңыш җыеп алу — бу инде сезгә уен түгел!

Узган сигезенче бишьеллыкта Татарстан авыл хуҗалыгында эшләүчеләр үз алларына куелган бурычны шактый уңышлы башкарып чыктылар: бөртекле ашлыклар сату планын дүрт елда үтәделәр, ит җитештерүне — 38, сөт җитештерүне — 40, йомырка җитештерүне 56 процентка арттырдылар. Ләкин тугызынчы бишьеллыкта алар алдына тагын да зуррак бурычлар куелды. Атап әйтсәк, бу бишьеллыкта республикабыз дәүләткә сөт сатуны 31 процентка, итне — 43, йомырканы 60 процентка арттырырга тиеш.

Моның өчен иң әлек терлекләрне арттырырга кирәк иде. Минә шул чакта терлек азыгын кайдан алу мәсьәләсе бөтен кисkenлеге белән килеп басты. Нибары 5—10 центнер гына печән бирә торган әлеге 800 мең гектар табигый болынлыклардан шул тикле терлекне ашатырлык азык алу турында уйларга да ярамый. Ашлык чәчелә торган җирләргә терлек азыгы чәчүне арттыру шулай ук ярый торган эш түгел. Болай да иген кырларының өчтән бер өлешен терлек азыгы культуралары алып тора инде. Тугызынчы бишьеллыкта республикабыз дәүләткә икмәк сатуны да 2 миллион тоннага арттырырга тиеш. Шулай булгач, чәчүлек җирләрне кимету хисабына

терлек азыгы культураларын чәчүне арттыру һич мөмкин түгел. Киресенчә, ашлык чәчү мәйданын арттыру турында уйланырга кирәк иде әле.

Уйлана-эзләнә торгач, республикабыз җитәкчеләре терлек азыгын культуралы көтүлекләрдән алырга, аның өчен 150 мең гектар культуралы көтүлек ясарга, шуның 94 мең гектарын сугарыла торган көтүлек итәргә, дигән фикергә килделәр. Шулай иткәндә һәр сыерга ярты гектар болын туры килергә тиеш. Шул вакытта аңа җәй буе ашарлык азык булачак. Хәтта кышка да калачак әле.

Хәер, монда әллә ни зур ачыш юк. Тәзергә икән — төзергә инде аны. Тик шунысы мөһим: ничек, нинди ресурслар хисабына төзергә? Бөтен формасын китереп, исәп-хисап ясарга да шуны югарыга — Госпланга җибәреп: «Республикага көтүлекләр кирәк. Шуны эшләр өчен акча һәм башка төр кирәк-яраклар бирегез?» дип сорарга да була иде. Әмма, мөгаен, анда бу сорауның яртысын да канәгатьләндермәгән булырлар иде: бездәге кебек көтүлекләрне бүтән өлкәләрдә дә төзи башлаганнар, ә аларга кирәк булган су сиптерү машиналары әлегә бик аз эшләнә, мәсәлән, бу бишьеллыкның өченче елында безнең республикада гына да утыз мең гектар мәйданда сугарулы көтүлек ясалырга тиеш. Ә безнең республикага шул ел өчен нибары 50 ясалма яңгыр яудыру машинасы һәм 71 насос станциясе кайтару гына билгеләнгән. Кирәк булганның бары тик биштән бер өлеше генә дигән сүз ич бу!

Алай булгач, республика нәрсәгә ышанып шушы тикле зур программа кабул иткән соң, диючеләр булуы мөмкин. Барыннан да элек, үзебезгә, эчке резервларыбызга, шәһәр хезмәт ияләренең искиткеч зур политик аңлылыгына — аларның республикабыз авыл хуҗалыгы алдында торган бурычның мөһимлеген күреп, кулларыннан килгәнчә ярдәм итәчәкләренә ышанып тотынылган эш иде бу.

Тәвәккәл — таш ярган, ди. Башта яңа көтүлекләргә чәчәр өчен орлыкны бөртекләп дип әйтерлек җыярга туры килгән булса, бүгенге көндә республикабызның 68 хуҗалыгы чәчү орлыкларын үзләре җитештерәләр. Ясалма көтүлекләр булдыру һәм аларны сугару — бездә моңарчы күрелгән нәрсә түгел иде. Бу яңа эшкә һәркайда бик кызыксынып, тырышып өйрәнә башладылар. Партия райкомы секретарьлары, производство идарәләре башлыклары, колхоз һәм совхоз җитәкчеләре җәенә берничәшәр кат семинарларга, махсус курсларга җыелып, көтүлекләрне ничек ясау алымнарын һәм сугару чараларын өйрәнделәр. Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумында болынчы-мелиораторлар группалары оештырылды, ясалма болыннар белән эш итәргә тиешле кешеләр Казан авыл хуҗалыгы институтында махсус уку-өйрәнү уздылар. Менә шул рәвешле эш бик тиз алга китте һәм нибары өч ел дигәндә республикабызда 32 мең гектар мәйданда ясалма болын булдырылды. Чагыштыру өчен искәртеп китик: Россия Федерациясенең бүтән барлык республикаларында һәм өлкәләрендәге сугарулы көтүлекләр мәйданы нибары 200 мең гектар гына тәшкил итә.

Сугарулы көтүлекләр — республикабызда иң мөһим объектларның берсе. Шуңа күрә аңа бик зур әһәмият бирелә. Көтүлек ясарга заказ биргән хуҗалык гадәттәгечә берьюлы берничә оешма белән түгел, бәлки бер оешма белән генә эш итә. Ул оешма колхоздан яки совхоздан заказ да кабул итә, көтүлекнең проектын да сызып бирә, материалларын да юллый һәм көтүлекне эшләп, көйләп тә җибәрә. Рәхим итеп, кабул итеп ал гына!

Шул җәһәттән караганда, «Сельхозтехника» берләшмәсе республика хуҗалыклары белән аеруча тыгыз элемтәдә тора. Хәзер монда ясалма көтүлекләр өчен полиэтилин торбалар эшләп чыгара торган

махсус цех, су сиптерү станцияләре өчен арматуралар ясау цехы һәм, ясалма яңгыр яудыру өчен, ДДН-70 маркалы машиналарны җыя торган конвейер да бар. Ә сугару техникасына кирәк булган детальләрне, үзләренең төп эшләреннән аерылмыйча, Казан предприятиеләре эшләп килә: мотор төзүчеләр сугару машинасы көпшәсенең бору җайланмаларын, «Теплоконтроль» заводы редукторларын, компрессорлар заводы насосларын ясый. «Сельхозтехника»да эшләүче иптәшләрнең тагын бер бик әйбәт сыйфатын искәртеп үтәсем килә: алар туктаусыз эзләнәләр, киң караш, масштаб белән эш итәләр. Мәсәлән, әлеге шул эш өчен янып йөрүләре нәтиҗәсендә беренче карашка шактый сәер булып тоелган нәрсәләрне дә үз файдаларына эшкә җигә белә. Әйтик, металлургларның Мәскәүдәге фәнни-тикшеренү институтынданиндидер бер торба ясый торган бер яңа станны хутка җибәрә алмауларын ишетеп алалар. Стан әйбәт, тик аны үзенә алып кайтып сыный-эшләтә башлаучыны гына таба алмыйлар, шулай итеп, мәсьәләне гел суза килә икән. Ә «Сельхозтехника»да эшләүче иптәшләр моны сизенеп алу белән күп уйлап тормаганнар, Мәскәүгә барып, институт галимнәре белән очрашканнар да: «Әйдәгез, станыгызны без сынап карыйк. Безгә торбалар ясый торган мондый машина бик тә кирәк иде» дип, тегене алып та кайтканнар. Хәзер ул стан эшли башлады һәм смена саен бик кирәк булган 600 метр торба биреп килә.

Бер сан китереп үтмәкче булам: республикабызның «Сельхозтехника»сы быел хуҗалыкларда 11 мең гектар көтүлек ясарга җыена. Күпме бу яки азмы? Чагыштырып карыйк: РСФСРның бүтән барлык өлкәләрендәге колхозларында һәм совхозларында быел 23 мең гектар көтүлек ясау күздә тотыла. Ә бит Россиядә 79 өлкә...

* * *

Алда китерелеп үтелгән мисаллар һәм саннар колакка ятышлы булсалар да, мин аларны безнең республика бу өлкәдә шактый алда бара икәнен әйтеп мактаныр өчен түгел, бәлки ясалма көтүлекләр булдыруның колхозларга һәм совхозларга бик тә кирәк, бик тә файдалы икәнлеген күрсәтергә теләп китердем. Бу мәсьәлә бик җитди куелган һәм аны гамәлгә ашыру өчен күп эш алып барылса да, ил күләмендә алганда башкарасы эшләрнең күбесе әле алда. РСФСРда сугарулы көтүлекләр 200 мең гектар, дидек. Диңгездән бер тамчы гына бит бу. Сугарулы болыннарга мохтаҗлыклары зур булуга да карамастан, кайбер өлкәләрдә ул хакта кинохроникаларда күреп, популяр брошюралардан укып белүдән ары киткәннәре юк әле. Дөрес, бу зур эшкә үз көчләренә генә таянып тотыныр өчен барлык өлкәләрнең дә мөмкинлеге безнең Татарстанныкы шикелле түгел. Әйтик, Тува, Чита өлкәләрендә һәм Бурят автономияле республикасында бездәге кебек куәтле һәм бу эштә ярдәм итә алырлык индустрия юк. Әмма мәсьәлә бер индустриядә генә дә түгел булса кирәк. Югыйсә, шундый зур промышленность үзәкләре булган Украина, Ленинград өлкәләре ясалма болынлыклар мәсьәләсендә Татарстаннан артта калырлар идемени? 1975 елга Украина 94 мең, Ленинград өлкәсе 30 мең гектар сугарулы көтүлек булдырырга планлаштырганнар гына әле. Монда тырышлыкның роле бик зур. Өлкә, район һәм колхоз җитәкчеләре никадәр җитезрәк, инициативалырак булса, мәсьәләне шул кадәр тизрәк хәл итәләр. Әйтәсе килгән сүзем шул, гел өстән күрсәтмә булганны гына көтеп ятарга кирәкми. Әмма шул ук вакытта Госплан, Госснаб һәм башка шундый югары дәүләт органнары үзләре дә, гел сораганны гына көтеп тормастан, җирле резерв-

ларын исәпкә алып, бу яңа мәсьәләне тизрәк хәл итүгә күбрәк ярдәм күрсәтсеннәр иде.

Тагын бер нәрсәне аеруча басым ясап әйтеп үтәсе килә. Сугарулы көтүлекләр ясау турындагы бу бик әйбәт идеяне тиз генә тормышка ашыру артыннан куып, аның дәрәҗәсен төшермәсеннәр иде. Мин моны шуңа күрә әйтәм, чөнки бездә, кызганычка каршы, андый «бөгеп куюлар» әледән-әле булгалап тора. Хәтерегездәдер, бер вакыт торф-черемә чүлмәкләре белән ничек ду кубып йөрделәр? Ә ул бөтенләй буш, ниндидер бер институтның лабораторияләрендә тәҗрибә ясаудан бүтәнгә ярамый торган файдасыз нәрсә булып чыкты. Яки кукурузны алып карыйк. Күпме гайбәтен саттылар аның? Ә бит хикмәт кукурузда түгел, бәлки аны эшкәртү машиналарының азлыгында булып чыкты. Дөнья хәтле мәйданга чәчәләр, тиешенчә эшкәртергә көчләре җитми, шуңа күрә юньле уңыш ала алмыйлар иде. Әнә хәзер, машиналары җитәрлек булгач, председательләргә кукуруз чәчмә дип әйтеп карагыз әле сез — берсе дә риза булмаячак!

Хәтеремдә, бер вакыт һәр йөз гектар чәчү җиренә биш ана дуңгыз тоткан бер колхозның даны бик нык күтәрелеп киткән иде. Дуңгыз үрчетү әллә ни шаккатмалы эш түгел. Әмма теге колхозда, күрәсең, акыллы кешеләр эшләгән булса кирәк: алар дуңгызларны тәрбияли белгәннәр һәм әлеге биш баш ана дуңгызның һәркайсыннан икешәр тонна ит алганнар. Авыл тормышы белән таныш булган кешеләр белә: бер ана дуңгыздан ике тонна ит алу, ай-һай, шактый авыр эш ул. Зур тырышлык, күп хезмәт куярга кирәк аның өчен. Шуның өстенә, тагын дуңгызларга җитәрлек кадәр азык һәм уңайлы фермалар да кирәк.

Ләкин югарыда утыручылар мәсьәләнең ул ягына артык кереп тормыйлар, тоталар да, теге колхозны мисал итеп алып, башкаларга да шулай һәр йөз гектар чәчүлек җиргә бишәр ана дуңгыз асрарга боерык бирәләр. Ә нәтиҗәсе? Башкаларның хәлен сөйләп тормастан, үзем шаһит булган бер колхоздагы эшләр турында гына әйтеп китәм. Бер дә бер көнне бу колхозга районнан комиссия килде дә, ана дуңгызлар сайлап алып, шуларга тамга салды һәм шуларның барысы да исән булсын дип председательне кисәтеп кайтып китте.

Икенче елны әлеге колхоз председателен күреп, дуңгызларының хәлен сораша башлаган идем, ул кулын гына селекте. Ә хәл менә болай булган икән: теге ана дуңгызлар шундый ашамсак булып чыккан ки, әлеге колхозның аңарчы да такы-токы гына булган бөтен терлек азыгын ашаганнар да бетергәннәр. Шуның өстенә, колхозның дуңгыз фермасы да юньле булмаганлыктан, чучка балаларының күбесе авырый, үлә башлаган. Эшләр болайга киткәч артык түзеп тора алмаган колхоз хуҗалары, азык җитмәүдән ябыгып беткән ана дуңгызларны иткә тапшырганнар. Менә шулай итеп, бөтен ягын уйлап-үлчәп алып барганлыктан бер колхозга бик зур файда китергән эш коры энтузиазм белән генә ясканып тотынган икенче колхозга зур гына зыян китергән булып чыга. Бу сөйләгәннәрем буш сүз генә булмасын өчен, берничә сан китерәм. 1963 елда Татарстан хуҗалыкларындагы 80 000 ана дуңгыз 38 000 тонна ит биргән. Ә узган елда исә 51 000 ана дуңгыздан 62 000 тонна ит алынган. Эшләр менә шулай тора! Хикмәт башлангычның яхшы булуында гына түгел. Хикмәт шул яхшы башлангычны ничек итеп тормышка ашыра белүгә дә бик нык бәйле.

Татарстанда беренче ясалма болыннарны уңайрак урыннарда: елга тугайларында, элекке болын урыннарында һәм көтүлекләрдә ясый башладылар. Башка өлкәләр дә, мөгаен, шулай итәрләр. Ләкин күбесе алай эшли алмас: һәр колхозның кыры Идел, Кама яки Вятка буенда түгел бит. Ә вак елгалардан суны әллә ни күп алып

булмый. Бер кубометр суларын алырга ярамаган елгалар да бар: аларның суын алсаң — тирә-юньдәге табигатькә зыян киләчәк. Ләкин сугарулы көтүлекләрнең файдасы шул тикле зур, хәтта болыннарын кое яки чишмә сулары белән сугарырга туры киләчәк колхозларның председательләре дә, Куйбышев дингезе буендагы колхозларның председательләре шикелле үк, тиз арада үзләрендә ясалма көтүлек булдырырга телиләр. Ә аңа суны каян алырга соң? Хәтта Идел, Кама, Агыйдел, Вятка, Зәя, Мишә, Ык кебек зур елгаларыннан тыш та өч меңгә якын кечкенә елгалары булган безнең Татарстанда да ясалма көтүлекләр өчен су җитми бит әле. Республикадагы утыз алты районның унҗидесендә үзләренең суы юк. Ә бүтән өлкәләрдә хәл моннан да кыенрак. Алайса, ни эшләргә соң? Су юк дип, шушындый файдалы эштән баш тартыргамы? Юк, әлбәттә! Мөмкин булган җирләрдә йөзләрчә буалар буарга, катлаулы гидротехник корылмалар — плотиналар төзергә, колхозара һәм районара зур су үткәргечләр булдырырга, артезиан коелары казырга кирәк. Боларны гамәлгә ашыру — зур көч сорый торган эш. Монда, мөгаен, колхозлар һәм совхозлар бездәге шикелле үз көчләре һәм шефлары ярдәме белән генә әллә ни зур эш майтара алмаслардыр. Һәм алай эшләүнең кирәге дә ул кадәр зур түгелдер. Әгәр һәр республика, һәр өлкә үзләренең төп промышленностьларыннан калган материаллар хисабына үзләре торбалар ясый, үзләре су сиптергечләр, насос станцияләре кораштыра башласа — мөгаен, бу экономик яктан да акыллылык күрсәтү булмас, техник прогресс юлында да алга атлау булмастыр. Киресенчә, мондый ярым кустарьчылык чаралары белән эшләнгән ул материаллар автоматлаштырылган махсус зур предприятиеләрдә эшләнгән шундый ук материалларга караганда күп мәртәбә кыйммәткәрәк тә төшәр әле. Сүз җаеннан әйтү: тракторларны һәм комбайннарны алай итеп эшләмиләр ләбаса! Заман техникасы белән җиһазландырылган зур һәм махсус заводларда эшләнә ич алар.

Авыл хуҗалыгын күтәрү авыл хезмәт ияләренә генә түгел, бәлки промышленность хезмәткәрләренең, фән һәм техника эшлекләләренең тырышлыгына да бик нык бәйле икәнлеге әйтелгән иде КПССның егерме дүртенче съездында. Моны, һәркем кулыннан килгәнчә авылга ярдәм итәргә тиеш, дип берьяклы гына аңламаска кирәк. Монда сүз директив һәм план оешмаларының оста оештыру сәләтенә ия булырга тиешлеге, авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә акыллы хуҗаларча якын килергә тиешлеге хакында бара. Бәлки, мин ялгышамдыр, әмма, миңа калса, соңгы вакытларда Госплан үзе дә авыл хуҗалыгына эшли торган тармакларның мөмкинлекләрен тиешенчә искә алып бетерми шикелле тоела. Әйтик, промышленность нигезендә корылган (ягъни ел буена куяннардан үрчем алырга мөмкинлек бирә торган) куян фермаларына җиһазларны кемнәр эшли? Самолет төзүчеләр, кораб төзүчеләр эшли. Кош фабрикаларына кирәкле җиһазларны кемнәр эшли? Тагын шулар ук. Кирәк булгангa, үзләренең намуслары кушуы буенча эшлиләр. Самолетлар, кораблар эшләнә торган өлкәләрдә тавыклар ашыйлар-эчәләр, махсус урыннарда йомырка салалар. Анда тавык караучыларның эшләре җиңел: автомат-кнопкаларга басып кына идарә итәләр. Һәрбер кош караучы мең кошны уйнап кына тәрбия кыла. Ә самолетлар һәм кораблар ясамый торган өлкәләрдә исә мескен тавыклар әле һаман хан заманындагыча балчыкта тибенеп көн күрәләр.

Самолетлар һәм кораблар ясаучыларга хәзер тагын бер мәшәкать — культуралы көтүлекләр өстәлде. Һәм, рәхмәт төшкен үзләренә, алар монда да авылга ярдәм итәләр. Резервлары хисабына, үзләренең төп эшләренә зыян китермичә, әлбәттә. Ләкин бу эшкә — ясал-

ма көтүлекләр булдыруга — югарыда ныграк игътибар итеп, алдан планлаштырып эшли башлаганда хуҗалыкларның хаҗәтләрен тизрәк канәгатьләндерергә мөмкин булыр һәм нәтиҗәдә ит тә, сөт тә хәзергегә караганда шактый арта төшәр иде.

Ниһаять, тагын бер бик мөһим мәсьәлә. Культуралы көтүлекләрне ясадың, аларга су сиптердең дә шуның белән эш бетте дип уйлаучылар булса — алар нык ялгышалар. Су белән үләнне үстерергә дә, үтерергә дә мөмкин. Артык күп сипсәң дә, тиешеннән ким сипсәң дә зыяннан башка нәрсәсе булмый аның. Чама белән генә эш итәргә кирәк. Менә монда мәсьәлә галимнәргә барып терәлә инде. Алар ярдәм итәргә тиеш бу эштә. Ә бу гади нәрсә түгел. Чөнки төрле төштә җирнең үзенчәлеге төрлечә, төрле үләнгә суны төрле күләмдә сибәргә кирәк һәм башкалар һәм башкалар... Ә хәзергә әле көтүлек хуҗалары үз җирләренең «холыкларын» бик чамалы гына төсмерлиләр. Көтүлекләрне ничек һәм күпме файдалану мәсьәләсендә шулай ук әлегә ныклы бер нәтиҗәгә киленгәне юк. Гомуми фәнни күзлектән караганда, көтүлекләрдән, һәр елны өч-дүрт уңыш ала-ала, кимендә ун ел файдаланырга мөмкин дип исәпләнелә иде. Бу мәсьәлә буенча да Казанда уздырылган Бөтенсоюз семинарында сүз чыгып, үзенә күрә бәхәс сыман нәрсә булып алды. ВАСХНИЛ академигы профессор Н. Г. Андреев үзенең докладында шушы мәсьәләгә кагылып: «Культуралы сугарулы көтүлекләр 20—30 елдан алып 50 елга кадәр эшлиләр»,— диде. Ә Мәскәү тирәсендәге «Ленинский луч» колхозының председателе Ю. И. Кубарев, исә, үзләренең тәҗрибәләре белән уртаклашып, көтүлекләрдән елына дүрт кенә түгел, бәлки алты-җиде уңыш алып, нибары биш ел дәвамында гына файдалануны мәгъкульрәк күрүләрен сөйләде. Менә сезгә бер үк мәсьәләгә карата капма-каршы ике фикер. Берсе — акыллы фән сүзе, икенчесе — авторитетлы практика нәтиҗәсе. Боларның кайсына күбрәк ышанырга соң?

Әлегә фикер бердәмлеге юк, ә эш инде эксперимент дәрәҗәсеннән үтеп, чын мәгънәсендә киңәеп бара. Ясалма болын булдырырга керешкәнче колхоз председателе һәм совхоз директоры ул болынның ничә елга исәпләнүен, аннан бер җәйдә ничә тапкыр уңыш алырга мөмкин булачагын алдан белеп торырга тиешләр.

Күрәсез, фәнгә дә, техникага да һәм оештыру эшләренә дә кагыла торган проблемалар шактый күп әле. Һәм болар вак-төяк проблемалар гына да түгел. Ясалма көтүлекләрнең киләчәге әнә шул мәсьәләләрне ничек хәл итүгә кайтып калачак.

Мондый яңа көтүлекләрне төзү җиңел эш түгел. Әле моннан берничә ел элек кенә бу турыда сүз куертып торырга да туры килмәс — көч җитмәс иде. Ә хәзер эшләр башкачарак тора. Хәзер колхозларның һәм совхозларның теләсә нинди зур чыгымнарны да күтәрергә хәлләреннән килә. Тик аларга планлы төстә ярдәм күрсәтергә — көтүлекләр ясау өчен кирәк булган материаллар белән тәэмин итәргә генә кирәк. Үзешчәнлек юлы белән генә бу зур һәм бик мөһим мәсьәләне уңышлы хәл кылып булмаячак.

Бу эшкә шушылай артык зур хезмәт куеп, акча түгеп торуның файдасы булырмы соң? Һичшиксез булыр. Әгәр ясалма көтүлекләрне кирәгенчә ясый алсак, иткә дә, сөткә дә, йомыркага да бернинди кытлык булмаячак. Монысы бер. Икенчедән, илебезнең көч һәм куәт чыганагы булган игенне үстерә торган кырларның һаман кыскара баруына чик куелачак. Ниһаять, өченчедән, файдалы витаминнар урынына кукуруз силосы исе һәм алюмин фляга исе сеңеп беткән тәмсез сөт урынына бары тик болын чәчәкләре исе генә аңкыган һәм бөтен тәннәргә сихәт бирә торган тәмле сөтләр эчә башларга да вакыт бит инде безгә! Бөтен хикмәт әнә шунда. Һәм моның өчен тырышырга да ярый дип уйлыйм.

**Асия Хәсәнова**

# БАТРАК ФАТИХ КЫЗЛАРЫ

1920 елның ахыры иде. Кырымнан шатлыклы хәбәр килде: Кызыл Армия Перекопны алып, көчле давыл кебек Кырымга барып кергән һәм анда Врангель гаскәрләрен тар-мар иткән. Күптән түгел аклар кулында булган җирләрдә җимерелгән окоплар, туралып ташланган гәүдәләр, ертылган погоннар, ватылган туплар гына өелеп калган. Кырымны азат итү Кызыл Армиянең чираттагы бер уңышы гына түгел иде. Бу — ничә елларга сузылган интервенциянең һәм гражданнар сугышының тәмамлануы иде. Дөрес, кайбер урыннарда, мәсәлән, Ерак Көнчыгышта, дошманның соңгы отрядлары җир тырмашып сугышып яталар иде әле, ләкин бу отрядларның гомере санаулы икәне ачык иде инде.

Мәскәү урамнарын кар баскан. Кибет тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта кадакланган. Озак еллар ремонт күрмәгән йортлар, ватык капка, ауган коймалар, икмәк кибетләре янындагы озын-озын чиратлар башкаланың нинди хәлдә булуын ачык күрсәтә. Шуңа карамастан, эшче халыкның, солдатларның кәефе яхшы. Ничә елга сузылган сугыш бетте! Дошман тар-мар ителде бит!

Әнә шундый шатлыклы көннәрнең берсендә Партиянең Үзәк Комитетына яшь кенә бер кыз килеп керде һәм үзен иптәш Коллонтай янына кертүләрен үтенде. Кыз харап та җитди күренә: өстендә хәрби гимнастерка, аягында итекләр, башында кыңгыр салынган папаха. Әмма кызның хәрби киеме дә, кырыс кыяфәте дә секретарь хатынны гаҗәпләндермәде. Искитәрлек нәрсәсе бар? — хәзер коммунистларның күпчелеге фронтта ич. Әнә Көньяк фронтка гына да ун меңнән артык коммунист китте. Үзәк Комитет үзе дә хәрби штаб кебек: көндез дә эш, төнлә дә.

Шуңа күрә секретарь тыныч кына:

— Иптәш Коллонтайның ашыгыч эше бар, ул бүген кабул итә алмый,— диде дә телефонга тотынды. Ул каяндыр ашыгыч мәгълүматлар ала иде, ахрысы. Кыз шактый ук кычкырып:

— Ничек инде кабул итә алмый? Ул бит мине үзе чакыртты! — диде. Сүзләрен дәресләргә теләп, кесәсеннән телеграмма кәгазе чыгарды.

---

Татарстан китап нәшриятында чыгачак «Татарстан хатын-кызлары» китабыннан.

Тавыш күрше бүлмәгә дә ишетелгән, ахрысы, ишек ачылып, аннан урта яшьләрдәге хатын чыкты. Тыныч кыяфәт белән:

— Кем сорый мине? — диде.

Яшь кыз хатын кире кереп китәр дип курыкты булса кирәк, кабалана-кабалана:

— Бу — мин, Зәйтүнә Булатова. Сез мине Уральскидан телеграмма белән чакырттыгыз, иптәш Коллонтай! — диде.

Александра Михайловна Коллонтай кызны җилкәләреннән кочып бүлмәсенә алып кереп китте.

Алар елмаешып, бер мәл сүзсез генә бер-берсенә карап утырдылар. Александра Михайловнаның карашында гаҗәпләнү дә, соклану да бар иде. Кара син бу кызыйны! Моннан берничә ел гына элек чит кешегә күтәрелеп карарга да кыймаган татар кызы, атаклы Чапай дивизиясендә ирләр белән иңгә-иң торып, Совет властеның дошманнарына каршы сугыша. Аягында итек, өстендә хәрби кием булса да, үзен бик иркен тота. Күзләре ничек янып тора.

22 яшьлек Зәйтүнәнең шатлыгы эченә сыймый. Сөенмәслек тә түгел! Аның каршысында революциягә утыз ел хезмәт итүче, исеме легендага әйләнгән Коллонтай үзе утыра ич! Ул бит бик зур патша генералының кызы, диләр. Бик шәп белем алган, әллә ничә төрле тел белә, дип сөйлиләр. Егерме яшендә үк йортын, бөтен байлыгын ташлаган да халык бәхете өчен көрәшкә чыгып киткән. Төрмә дә куркытмаган аны, үлем дә. Зәйтүнә боларны эчтән генә уйласа да, Александра Михайловна яшь кызның зур ачылган күзләренә, алсуланып киткән чибәр йөзенә карапниләр кичергәнен аңлады. Бераздан ул Зәйтүнәнең үзе турында, Уральскидагы хәлләр турында сөйләвен үтенде һәм ара-тирә сораулар биргәләп, аны игътибар белән тыңлады. Акыллы, чибәр, җитез хәрәкәтле, иле өчен, халкы өчен теләсә кая китәргә әзер торган яшь коммунист (Зәйтүнә партиягә моннан бер ел элек, 1919 елда кергән икән) Александра Михайловнага ошады. Ул уйга калды. Тәмам чыгырыннан чыккан хуҗалыкны аякка бастырасы, миллионнарча кешене укырга, язарга өйрәтәсе, мәктәпләр, больницалар саласы бар. Һәркайда ышанычлы, булдыклы, тырыш кешеләр кирәк. Ул Булатовага җаваплы эш кушарга ниятләп куйган иде. Ләкин кызның үзен күргәч мәсьәләне башкачарак хәл итте.

— Син, акыллым, бик сәләтле күренәсең, сиңа укырга кирәк,— диде.

— Кайда?

— Шәрык халыклары институтында. Анда гарәп, инглиз, немец телләрен өйрәнерсең. Укып чыккач, шәрык хатын-кызлары арасында эшләрсең.

Зәйтүнәнең ризалыгын алгач, ул шунда ук институт җитәкчеләренә шалтыратты һәм Булатованы бүген үк тулай торакка урнаштыруларын үтенде. Саубуллашканда ул Зәйтүнәне якын күреп кочаклады һәм Мәскәүнең Зур опера театрына, хөкүмәт ложасына билет бирде.

Нинди опера куелгандыр, ул хәтлесе Зәйтүнәнең хәтерендә калмаган, чөнки операны аның беренче тыңлавы иде бу. Театр аны гаҗәпкә калдырды. Иң элек ул үзе кереп утырган ложаны карады. Утыргычларга кадәр алтынлап эшләнгән, ишекләргә алтын чуклы бәрхет пәрдәләр эленгән. Алан чаклы ложаның эчке бүлмәсендә зурзур көзгеләр, кәнәфиләр куелган. Моннан өч кенә ел элек Зәйтүнәне, ихтимал, бу ложага якын килгән өчен генә дә атып үтергән булырлар иде, чөнки монда Рәсәйнең хуҗасы — патша хәзрәтләре утырган бит.

Тыңлый торгач музыка Зәйтүнәнең йөрәк кылларын тибрәтте, ул туган авылы Югары Әлкине, әти-әнисен, абыйсын, апасын, сеңелләрен исенә төшерде. Бу истәлекләр татлы да, йөрәк өзгеч авыр да иде...

...1909 елның язы иде бугай. Иртәдән бирле яңгыр сибәли. Зәйтүнәнең әтисе Фатих абзыйның йөзе дә шул көн кебек болытлы. Кулы эшкә бармый: утын кисәргә дип балтасын ала да, бераздан аны ташлап, көрәк күтәреп лапаска кереп китә. Гайникамал бүген-иртәгә бала табарга тиеш. «Кем туар?» Шул сорау туктаусыз борчый аны. Фатих абзый җилкәсендә әни карчык, дүрт кыз, җәмәгате. Ике имана җирдә җиде тамак туенып ята. Тагын кыз туса, нихәл итәр ул? Капчык тотып авылдан-авылга хәер эстәп йөрергә туры килмәсме?

Фатих ага кулына алган көрәген ташлады да болдырга килеп утырды. Утырды да уйга чумды.

Бар иде Фатих аганың урта бармак шикелле егет чаклары! Югары Әлки кызларының йөрәкләре, аны күрүгә түгел, исемен ишетүгә үк дөрләп яна торган иде. Кушаматы гына ни тора: бөтен авыл аны «Матур Фатих» дип атый иде. Ә инде «Эскадрон» я булмаса «Ашказар» көйләрен сузып җибәрсә, башка егетләргә караучы да булмый иде. Кызларның күзе Фатихта гына була иде. Авылның иң бай кызлары аңа кияүгә чыгарга әзер иделәр. Әмма Фатих үзе кебек ярлы кыз Гайникамалга өйләнде. Еллар үтте, аларның бер уллары, берсеннән-берсе чибәр, берсеннән-берсе сөйкемле дүрт кызлары туды.





Фатих Булатов гаиләсе. Утырганнар — сулдан уңга: өлкән кызы Шәмсебәдәр, Фатих ага Булатов, Хәлимә, икенче рәт (сулдан уңга) Шакир, Галия, Зәйтүнә, Шәмсебәдәрнең улы Таһир, Җәрия, Зәйтүнә Булатованың ирә Шәриф Каюмов.

Лэкин бала туган саен ата-ананың йөрәге кысыла башлады. Халык «чибәр булып тума, бәхетең белән ту» дип белми әйтмәгән шул. Ике имана җирдә бу чаклы кешене ничек туйдырмак кирәк? Әле, улың читтә йөри, дип бер имана җирен тартып алырга телә̄деләр. Авыр көннәр башланды аңа: ат алу өчен сыерын сатты, бала-чага авырый башласа, атын сатып сыер алды, кыскасы, ел әйләнәсе бурычтан чыкмый иде. Кызлары үсә төшкәч, җәйләрен Фатих ага олыраклары белән күрше Самар губернасындагы Зубров дигән алпавыт җирләренә эшкә китә торган булды. Ике имана җирне Гайникамал бер үзе ура, үзе җыя. Кара көз җиткәч кенә Фатих ага, кызларын ияртеп, кайтып керә. Лэкин өч таза кешенең бер караңгыдан икенче караңгыта чаклы эшләп тапкан акчасы ярты кышка да җитми иде.

Фатих ага диндар түгел иде. Намазлар укып йөрергә вакыты да юк иде аның. Эшли дә кайтып ава. Лэкин бүген ул, аптырагач, белгән догаларын укый башлады: «И раббым, мәрхәмәтеңнән ташлама, синең кодрәтең зур. Дүрт кыз үстерәм, бусы малай булсын иде»,— дип дога кылды ул.

Әмма догасы кабул булмады. Фатих абзыйны кара кайгыга батырып, дөньяга тагын бер, бишенче кыз туды.

Аның бәхетле булуына Фатих ага ышанмады, шуңа күрәдер инде аңа Җария, ягъни кол дигән исем кушты.

Зәйтүнә ул вакытларда уникенче яшь белән бара иде. Әти-әнисенең: «Ул булсын, ул тусын», дип өзгәләнүләре, кыз тугач кара кайгыга батулары кызчыкның йөрәгенә барып кадалды. Ул башта эчтән генә әтисенә үпкәләде. «Мин туганда да шулай өзгәләнгәндер әле. Үзе тагын «кызым, кызым» дип иркәләгән була!»

Шул көннән Зәйтүнә үзен ким-хур кеше итеп сизә башлады. Әнә бит... Миңлегөл апаның ике яшь тә тулмаган улына җир бирделәр, ә Зәйтүнәгә уникенче яшь, аңа бирмиләр. Шул ким-хур кеше булганга бирмиләрдер инде... Каршы өйдә яшәүче, иргә чыкмый картайган Нурҗиһан апа еш кына кичләрен, ут алмыйча гына, кызганыч тавыш белән һаман бер көй суза:

Нигә тудым кыз булып,
Ник акмадым боз булып...

Зәйтүнәнең әнисе янына керсә дә ике сүзнең берендә:

— Кыз бала бәхетсез инде ул, ата-баба белми әйтмәгән: «Кыз үссә, өйгә кытлык, ул үссә, өйгә котлык». Юк инде, юк, үзебезгә дә бәхет юк, башкаларга да бездән бәхет юк,— ди.

Вакыт-вакыт Зәйтүнәнең бәләкәй йөрәгендә ризасызлык туа иде. Нишләп инде ул ким кеше булсын? Әнә бит ул иртәдән кичкә чаклы эшли, әнисенә гел булыша. Кечкенә сеңелесе Галияне гел ул карый. Соң, шулай булгач, нишләп ул бәхетсезлек китерсен?

Лэкин бу сорауларга җавап бирүче юк...

* * *

Менә ерак Питерда «Аврора» залпы яңгырады. Ул патша сараена гына түгел, миллионнарны изү, талау хисабына яшәүче алпавытлар, байлар дөньясына төзәп атты. Ил өстеннән шаулап Октябрь узды.

— Яшәсен Октябрь!

— Яшәсен Совет власте!

Бу сүзләр, диңгез дулкыннары кебек, җирнең бер ягыннан икенче ягына, шәһәрдән авылларга, авыллардан ерак далаларга яңгырап

үттеләр. Җир-сулар, завод-фабрикалар төп хуҗаларына — эшчеләр, крестьяннар кулына күчте.

Шәмсебәдәрләр, Зәйтүнәләр, Хәлимәләр, Галияләр һәм миллионнарча башка хезмәт иясе хатын-кызлар өчен Совет власте аеруча якын, аеруча кадерле иде. Чөнки ул хатын-кызны тулы хокуклы кеше дип бөтен дөньяга ишетелерлек итеп әйтте, аны кимсетә, хокукларын чикли торган барлык хурлыклы законнарны юк итте, хатын-кызны укытырга, белемле итәргә, җитәкче эшләргә күтәрергә кирәклеген әйтте.

Фатих абзыйга канат үскән кебек булды.

Ләкин тынычлап эшләргә мөмкин булмады. Берничә ай узуга, яшь Совет дәүләтен бишегендә үк үтерү һәм аның җирләрен, байлыкларын үзара бүлешү өчен АКШ, Англия, Франция, Япония империалистлары кораллы гаскәрләр җибәрделәр. Көнчыгыштан да, көнбатыштан да, төньяктан да, көньяктан да яшь Совет иле өстенә, саранча өерләре кебек, дошман яулары ябырылып килә башлады. Яшь Совет дәүләтенең хәле бик авырлашты. Эшчеләрне ачлык газаплый. Мәскәү һәм Петроград эшчеләренә ике көнгә бер әчмуха икмәк бирәләр. Бөтенләй иписез калган көннәр дә була.

Менә шундый авыр көннәрдә партия «Социалистик Ватан куркыныч астында» дип мөрәҗәгать иткәч, иң элек Фатих аганың улы Шакир, аннан соң кызы Зәйтүнә Булатова, шинель киеп, фронтка киттеләр. Зәйтүнә хезмәт итә торган отряд 1919 елның язында Чапаев дивизиясе белән кушылды.

Кайда гына булырга, ниләр генә эшләргә туры килмәде Чапай солдаты Зәйтүнәгә. Уральск, Богорослан, Самара, Саратов якларын ничәмә-ничә тапкыр иңләп-буйлап йөреп чыкты ул. Корал тотып сугышырга да, концертларда чыгып җырларга да, продразверстка чорында кулаклардан кычкыртып икмәк җыярга да, ярлылар комитетларын оештырырга да туры килде аңа. Айлар буе кием алыштырмый, мунча күрми, теләсә кайда кунып йөрүләрне, күз йоммаган төннәрне, ачлы-туклы үткән көннәрне кем исәпләгән...

1928 елны «Эшче» газетасының февраль санында түбәндәге мәкалә басылган иде: [1]

«...бу 1919 елның язы иде. Шәһәрне икенче кабат Сапожков бандалары чолгады. Шәһәр тагын да алка эчендә калды. Ләкин шәһәр эшчеләре, хезмәт ияләре бу тапкыр да нык тордылар, нык көрәштеләр.

Менә шуңар күрә дә элекке Уральскины Кызыл Уральский дип атадылар да.

Бу кирәк фронт окопларында, кирәк сәяси фронтта зур баһадирлык күрсәтүчеләр арасында татарлардан да байтак кына билгеле эшчеләр бар иде. Сәгыйт Үләмәев, Зәйнуллин (вафат), Хәмит Төхфәтуллин, Зәйтүнә Каюмова [2] иптәшләр әнә шул фронтларда җитешкән тимер куллы партиялеләрдән булдылар.

Урал фронтында чыга торган кызыл армеец газетасы «Кызыл шәрык»ны оештыручылар итеп югарыдагы иптәшләрне санарга кирәк».

* * *

...Пәрдә ябылып, халык бик каты кул чаба башлагач кына Зәйтүнә хатирәләрдән арынды. Уйларына чумып, ул сәхнәдә барган вакыйгаларны бөтенләй абайламый калды бит. Хәер, килер әле шун-

---

[1] «Эшче» газетасы. 1928 ел. 23 февраль. № 38.
[2] Зәйтүнә Булатова (иреннең фамилиясе белән бирелгән).

дый чаклар — Зәйтүнә ул операларны иркенләп тыңлар. Ул вакытта инде аның өстендә шинель түгел, бик матур ситса күлмәк, аягында итек урынына бик һәйбәт каюлы читек булыр.

Күп көтәсе дә калмады ич. Иртәгә үк ул шинелен салып, солдаттан студентка әйләнәчәк. Театрдан тулай торакка кайтканда гел шул турыда уйлады ул. Менә бит, Әлки кызы Мәскәүнең югары уку йортында белем алачак! Хәзергә кадәр Әлкидә мәдрәсәдән гайре башка уку йортына керә алган бер генә кеше бармы икән?!

Ләкин Зәйтүнәнең шаулы студент көннәре нибары алты ай гына дәвам итте. Совет җиренә тагын дошман кулын сузды. Бу юлы ул Урта Азиягә басмачылар кыяфәтендә бәреп керде. Зәйтүнә ике ел фронтларда булып кайткан тәҗрибәле сугышчы буларак, 1921 елның җәендә Төркстан Үзәк Комитеты карамагына китте. Ике ел Урта Азия республикаларында хезмәт итте. Басмачыларга каршы көрәштә, ерак Җиде Су өлкәсендә, Пржевальскида, Ташкентта хатын-кызлар бүлекләренең мөдире булып эшләде. Кыргызстанда чәчү кампанияләрен дә, халык санын исәпкә алу эшләрен дә алып барды. Көнетөне халык арасында булганга, ул үзбәкчә дә, кыргызча да йөгерек сөйләргә өйрәнде.

Ниһаять, 1923 елда Зәйтүнәнең үтенечен искә алып, туган ягы Татарстанга җибәрделәр.

...Ул вакытлар исенә төшсә, кайвакытта көләсе дә килә Зәйтүнә апаның. Үзбәкстаннан Татарстанга кайту олы сәяхәт булып санала иде. Поездан поездга күчеп, тәүлекләр буе вокзалларда утырып, өч атна чамасы кайтты ул.



1927 ел. Татар делегаткалары җыелышы. Уртада хатын-кызлар бүлеге мөдире Хәлимә Булатова.

* * *

Кайтып хәл алырга өлгермәде, аны эшкә җибәрделәр. Волком секретаре, Спасс канткомында хатын-кызлар бүлеге мөдире булып эшләде. Аннан аны Әлки волисполкомы председателе итеп сайладылар.

Татарстан җирендә инде туплар гөрселдәми, ә эш фронты бер дә сугыш фронтыннан ким түгел иде. Дүрт ел Зәйтүнәгә итекләрен салырга туры килмәде. Юл юк, машина юк. Аз гына яңгыр яудымы, бил тиңентен былчырак ерып йөрергә туры килә. Җигәргә ат, чәчәргә орлык, ягарга утын, өйләрне яктыртырга керосин юк. Менә шундый шартларда авыл хуҗалыгын күтәрергә кирәк иде.

Дүрт ел эшләгәч, аны Татарстан Коммунистлар университетына укырга җибәрделәр. 1931 елда аны янә партия эшенә куйдылар. Башта ул Мәскәү өлкәсендә, аннан соң Свердловскида һәм, ниһаять, яңадан Татарстанда КПССның югары оешмаларында эшләде...

...Бу утлы-давыллы еллардан соң инде күп вакытлар үтте. Без Зәйтүнә апа Булатованың җыйнак һәм матур квартирасында утырабыз. Зәйтүнә апа хәзер персональ пенсиядә, аңа 75 яшь. Сәламәтлеге шактый какшаган, әмма аңарда партия һәм революция ветераннарына хас булган сыйфат бар: ул шат күңелле, оптимист кеше. Аның белән сөйләшеп утырсаң саф чишмәдән су эчкән кебек буласың. Ләкин без аны элеккеге хезмәтләре өчен генә түгел, бүгенге көндә дә сафта булуы, туган-үскән якта эшләрнең барышы белән һәрчак кызыксынып, борчылып йөрүе, кечкенә генә уңышларга да куануы, киңәш биреп, кулдан килгән ярдәмне күрсәтергә тырышуы өчен ихтирам итәбез.

Ул «Азат хатын» журналы редакциясенең штаттан тыш хезмәткәре. Азрак буш вакыты булды исә редакциягә килә, яңалыклар белән кызыксына, редакциягә килгән берәр гаризаны алып китә. Аганалар буе йөреп тикшерә, тиешле оешмаларга шалтырата. Кирәк булса, барып та чыга. Кешеләр шатлыгына сөенеп, башкаларның борчуын күңеленә алып, аларга ярдәм кулын сузып яши ул — партия ветераны Зәйтүнә апа Булатова.

Без саргая башлаган фотоларны карап утырабыз. Мине алпавыт җирләрендә батрак булып эшләгән ярлы татар крестьяны Фатих Булатов гаиләсенең язмышы кызыксындыра. Бердәнбер улы, биш кызының һәм оныкларының язмышы ничегрәк булды икән? Бәхетләрен таптылар микән алар?..

Сигез кешедән торган гаиләнең алтысы коммунистлар партиясе сафына баскан! Икесе Совет властен кулына корал тотып саклаган. Хезмәт һәм илне саклау фронтларында күрсәткән батырлыклары өчен Фатих ага Булатов гаиләсе уналты орден һәм медаль белән бүләкләнгән!

Шакир ага Булатов — Фатих аганың бердәнбер улы, биш кыз арасында үскән бердәнбер ир бала. Гражданнар сугышы елларында да, Бөек Ватан сугышы елларында да ул совет иле дошманнары белән халык бәхете өчен дә, сеңелләренең бәхете өчен үз-үзен аямыйча сугыша.

Әлки авылы кешеләренең хәтерендә шундый вакыйга калган. 1918 елда авылга аклар килеп керә. Чехлар баш күтәргән вакыт була бу. Шунда кулак малайларының берсе Шакирның кызыл гвардиядә хезмәт итүе турында аларга әләкли. Суд бик кыска була: Кызыл Армиядә хезмәт иткән Шакир Булатовны атарга! Моны



Сулдан уңга: Шәмсебәдәр, Зәйтүнә, Хәлимә, Галия һәм Җария Булатовалар.

ишеткәч, Гайникамал биш кызын иртә дә авыл җыены каршына барып баса. Моңа кадәр ир-атка күтәрелеп карарга да кыймаган Гайникамал апага кайдан көч килгәндер. Ул балаларын кочаклап җыен алдында елап-елап сөйли: «Гомер буе ач-ялангач яшәдек, бердәнбер улымны атсагыз, безне дә атыгыз, без барыбер яши алмабыз».

Җыелган халык моны күреп тетрәнеп китә һәм бертавыштан: «Шакир Булатовны азат итәргә»,— дигән карар чыгара. Күп тә үтми, Шакир Булатов яңадан гражданнар сугышына китә.

Шакир ага Булатов — бу гаиләдә эшчеләр сыйныфы династиясенә нигез салган кеше. Ул, гражданнар сугышыннан кайткач, күп еллар буе Себер заводларында эшли, шунда Ленин партиясе сафларына керә. Аннан Татарстанга кайта һәм төрле заводларда эшләп, лаеклы ялга чыга. Гомер буе халыкка хезмәт иткән, өч сугышта катнашкан, орден һәм медальләр белән бүләкләнгән Шакир ага Булатов аз сүзле һәм тыйнак кеше. Ул улларын да үзе кебек эшчән һәм тыйнак итеп тәрбияләгән. Өч улы да завод эшчеләре. Фатих аганың төпчек кызы Җариянең улы Рөстәм дә заводта эшли.

Без бервакыт шул дүрт егет белән сөйләшеп утырган идек. «Эшегез нәрсәдән гыйбарәт?» — дип сорадым Рөстәмнән. Күрәм, сукырга сөтнең төсен аңлату кебегрәк хәлдә калды ул. Электрон-хисаплау машинасында оператор булып эшли икән. Зур китапханә туплаган. Күп кенә камилләштерү тәкъдимнәре авторы, сәнгать мәсьәләләре белән кызыксынучы Рөстәмнең кем булуына җавап табалмадым — эшчеме, әллә галимме?

Фатих аганың олы кызы Шәмсебәдәр, 1924 елда авылдан чыгып китеп, өч еллап Донбасс шахталарында эшли, аннан Казанга кайтып мех комбинатына керә.

Фатих аганың өченче кызы — алпавыт Зубров җирләрендә атасы белән бергә батрак булып эшләгән Хәлимә — апасы Зәйтүнәгә насыйп булмаганны тормышка ашыра: Мәскәүнең Көнчыгыш телләре институтын тәмамлый. Шуннан соң ул күп еллар партия эшендә була. Хәлимә Булатовага Ленинның көрәштәше, иң якын кешесе Надежда Константиновна Крупская белән берничә еллар бергә эшләргә туры килә. 1966 елда Мәскәүдә рус телендә чыккан «Крупская турында истәлекләр» исемле китапта ул болай дип яза:

«Тормышта бик күп кешеләр белән очрашырга туры килә, ләкин аларның кайберләре генә истә кала. Надежда Константиновна Крупская турында гомергә исемдә калды дип әйтү генә аз булыр — ул минем белән бергә яши. Авыр минутларда мин аның белән киңәшәм, бәхетле минутларымда мин аның белән шатлыгымны уртаклашам».



Галия Булатова.

Коммунистларга хас булганча, Хәлимә Булатова да партия кайда җибәрсә — шунда эшли: күп еллар Татарстанда, Урта Азия республикаларында, аннан соң Мәскәүдә. Бүгенге көндә ул да персональ пенсиядә.

Фатих аганың дүртенче кызы — Галия. Аның бу кызын безнең Татарстанда белмәгән кеше бар микән? Татарстанда гына түгел, Советлар Союзының башка бик күп өлкәләрендә дә аны яхшы беләләр. Ул — РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән Галия Булатова. Ничә еллар узды, әмма Галия ханым иҗат иткән образлар: Мирсәй Әмирнең Миңлекамалы, Аблиевның Шәмсекамәре, Нәкый Исәнбәтнең Рәйхан һәм Зифасы һәм тагын бик күп образлар әле булса тамашачыларның күз алдында торалар. Ул Кәрим Тинчуринның 11, Таҗи Гыйззәтнең 9, Нәкый Исәнбәтнең 11 пьесасында баш рольләрне башкара.

Атаклы рус язучысы Леонид Соболев, уенын-чынын бергә кушып, болай дип сөйләгән иде:

«Сугыштан соңгы беренче еллар булса кирәк. Мин Казанда татар театрында «Миңлекамал» спектаклен карадым. Татар телен белмәсәм дә, пьесаның эчтәлеге белән таныш идем. Баш рольдә Галия Булатова иде. Спектакль беткән, ә мин утырам да утырам икән. Килеп әйтмәсәләр, шәт, шунда утырып калган булыр идем. Нәрсә мине шулай тетрәтте: артистканың уенымы, әллә аның матурлыгымы, белмим».

Фатих аганың төпчек кызы Җариянең язмышы ничегрәк булды икән? Аның дөньяга килүеннән бик тә курыккан иде бит ул.

Бәхетле булды Җария. Шуңа күрә исемен дә үзгәртте. Җария түгел, Зария ул. Совет власте аңа да югары белем алырга мөмкинлек бирде. Казан педагогия институтын тәмамлагач, ул күп еллар мәктәптә укытучы, уку-укыту бүлеге мөдире һәм директор булып эшләде.

* * *

Мәскәүнең нәкъ уртасында дөнья сәнгате үсешенә гаять зур өлеш керткән, исеме бөтен дөньяга атаклы булган театр бар. Ул МХАТ — Мәскәүнең М. Горький исемендәге академия театры. Ул театрның беренче нигез ташларын 1898 елда К. С. Станиславский һәм В. И. Не-



Эльвия Позднякова МХАТ сәхнәсендә.

мирович-Данченко салган. Аның сәхнәсендә илебез һәм бөтен дөнья драматургиясенең иң күренекле вәкилләре Чехов һәм Горький, Пушкин һәм Грибоедов, Ибсен һәм Шеридан, Гоголь һәм Островский, Вишневский һәм Корнейчук һәм башкаларның әсәрләре куела. Илебезнең танылган күпме артистлары үсеп чыкты ул сәхнәдә: Книппер-Чехова, Москвин, Качалов, Тарасова һәм дистәләрчә башкалар.

«Театральная жизнь» журналының МХАТның 60 еллыгына багышланган санында[1] бу сәхнәдә онытылмаслык образлар тудырган иң күренекле артистларга иптәшләрчә шаржлар урнаштырылган иде. Монда барыбызга да таныш Баталов, Топорков, Ливанов, Еланская, Тарасова, Андровская, Позднякова һәм башкалар бар. МХАТ студиясенә алынып, анда иң талантлы студентларга гына бирелә торган Чехов исемендәге иң мактаулы стипендиягә укып, студияне бик яхшыга тәмамлагач, шул театр труппасына алынган һәм егерме ел аның сәхнәсендә уйнап, РСФСРның атказанган артисткасы дигән исемгә лаек булган Эльвия Абдулла кызы Позднякова — батрак Фатих аганың оныгы, Хәлимә Булатованың кызы. Егерме ел эчендә ул бу мактаулы сәхнәдә онытылмас образлар тудырды: Чарльз Диккенсның «Домби һәм аның улы» спектаклендә Флоренс, Горькийның «Дачниклар»ында Соня, Шериданның «Ачы теллеләр мәктәбе»ндә Мария, Горькийның «Егор Булычев»ында Шурка һ. б.

* * *

Минем алдымда зур гына монография ята. «Азиянең һәм Африканың яшь дәүләтләре Берләшкән Милләтләр Оешмсында» исемле бу хезмәтне 1971 елда СССР Фәннәр академиясе басып чыгарган. Бу монографиядә Азия һәм Африкадагы яшь дәүләтләрнең Берләшкән Милләтләр Оешмасында алып барган политикаларына тирән анализ ясала, бу дәүләтләрнең тышкы политикасында Берләшкән Милләтләр Оешмасының нинди роль уйнавы, халыкара мөнәсәбәтләрнең төп мәсьәләләрендә бу дәүләтләрнең нинди тактика алып барулары, Берләшкән Милләтләр Оешмасында көн тәртибенә куелган мәсьәләләрне тикшергәндә бу дәүләтләрнең нинди позициядә торулары турында сөйләнелә. Бу китапта рус һәм төрле Европа телләрендә чыккан 252 китап, газета һәм журналлар файдаланылган.

---

[1] Театральная жизнь. 1958. № 6.



Хәлимә Булатова гаиләсе: улы Илгиз, кызлары Эльвия һәм Ләлә.

Монографиянең авторы — батрак Фатихның оныгы, Хәлимә Булатованың улы тарих фәннәре кандидаты, Илгиз Абдулла улы Поздняков. Ул совет дипломатларын әзерли торган институтны (Халыкара мөнәсәбәтләр институтын) тәмамлый һәм хәзерге көндә шул институтта өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли.

Бервакыт бу институтта бер художникның персональ күргәзмәсе булган иде. Булачак дипломатлар күргәзмәне бик кызыксынып карадылар. Кызыксынмаслык та түгел: авторның буяулар белән ясалган рәсемнәре белән берроттән чеканкасы да, ягъни металлга бизәкләр төшереп эшләнгән әсәрләре дә куелган иде. Бер почмакта художникның исеме дә язып куелган иде: И. А. Поздняков. Галим, дипломат һәм художник өчесе дә бер кеше — Илгиз Абдулла улы Поздняков икән.

Инде Мәскәүдән берничә йөз километр ераклыктагы Донецк шәһәрено юнәлик. Телестудиядә репетиция бара. Пульт янында — телевидениенең режиссеры Реини Камай кызы Кәримова. Фатих аганың оныгы — Зариянең кызы ул.

Революциягә чаклы ярлы татар крестьяны батрак Фатих Булатов, бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы эшләсә дә, тамагы туйганчы ашый алмаган, шуңа күрә ул кызлары туудан коты очып яшәгән. «Аларны ничек туйдырырмын?» Менә шул газаплы сорау аңа иркенләп яшәргә, тынычлап йокларга мөмкинлек бирмәгән. Бер тамчы суда океан чагыла диләр. Бер гаилә тарихында без халкыбызга Совет власте алып килгән чиксез зур бәхетне күрәбез.

Луиза Шәйдуллина

# ПИРАМИДАЛАР ИЛЕНДӘ



Биектән караганда Кара диңгез чынлап та кара булып күренә. Ә Урта диңгез исә бер караганда аксыл-яшел, ә вакыт-вакыты зәңгәрсу төскә дә кереп ала. Өстән, биектән Кипр утравы бик матур булып күренә: ямь-яшел, тик тау битләре, тау түбәләре генә коңгырт төстә. Диңгез өсте көзгедәй ялтырый, әйтерсең дулкыннар бөтенләй юк, ә корабльләр уенчыклар гына кебек.

Мәскәүдән Африка континентына кадәр без биш сәгать очтык. Чүл өсте сыек сары төстә булып күренде. Куе сары урыннар — калкулыклар, таулар. Алар арасында кайчандыр мул сулы елгаларның эзе аермачык булып беленеп тора. Ниһаять, Нил елгасы. Яр буйларындагы тар яшеллек бу чүлдә тормыш барлыгын белдереп тора,— димәк, монда кешеләр дә яши. Дөньяның җиде могҗизасыннан берсе булган пирамидалар күренеп кала.

Безнең самолет аэропортка төшеп утырды. Мәскәүдә декабрь салкыннары иде. Ә биредә 22 градус җылылык. Бүрекләрне, шарфларны, җылы киемнәрне чемоданнарга яшерәбез. Аэропорт бинасына юнәләбез. Документларны тикшерү, чик буе контролен узу озакка сузылмады. Безнең төркемдә күп кенә татарлар бар иде. Чик сакчысы — погоннарына өч йолдыз тагылган офицер — паспортларыбыздагы фамилияләрне укыганнан соң, мелаем итеп елмайды:

— Россия меселманнары килгән икән!..

Аэропорт янында автобус көтеп тора иде.

Караңгы төшкәндә генә без Искәндәрия шәһәренә килеп кердек, автобус тәрәзәләреннән әрле-бирле йөргән Мисыр кешеләрен, чуар итеп бизәлгән кибет алларын күрдек. Безне «Палестина» дигән кунак йортына урнаштырдылар. Бу бина Мисыр короле сарае янына бакча эченә салынган. Сарайның тышкы бизәкләре әкияттәге кебек, ә эчендә исә тагы да гүзәлрәк. Мәрмәр баскычлар, колонналар, диварлардагы бизәкләр күз явын алырлык. Сарайдагы өч йөз бүлмәнең диварларына мәрмәр өстенә алтын белән көнчыгыш бизәкләре төшерелгән. Хрусталь люстралар, кызыл агачтан ясалган мебельләр... Король, король хатыны, аларның балаларының рәсемнәре. Король тәмле ашарга, күп йокларга, күңел ачарга яраткан. Әмма азык-төлек исән бер дә яратмаган. Шуңа күрә сарайдан шактый читтәге ашханәгә тикле җир асты юлы салынган.

Диңгез буйлап кечкенәрәк сарайлар тезелеп киткән. Аларда югары дәрәҗәдәге кешеләр — вәзирләр, байлар торганнар.

Без диңгез һавасын сулап пляжда йөрибез. Диңгез буендагы йортлар хәзер буш — курорт сезоны түгел. Бу йортларны дәүләт салган һәм алар ял итәргә теләүчеләргә арендага бирелә.

Бакчаларда Африканың күп агачлары үсә: зур эвкалиптлар, хөрмә пальмалары һ. б. лар. Кыш булганга, үсемлекләр ул кадәр мул түгел әле.

Безнең гид — Хөддә исемле бер гарәп кызы — Советлар Союзында да булган икән. Ул безнең кунакчыллыкны, музейлардагы бай экспонатларны, экономика һәм культура буенча казанышларыбызны мактап бетерә алмый.

Ул безне истәлекле урыннар белән бик иркенләп таныштырды. Асуандагы куе ал төстәге граниттан эшләнгән Помпей колоннасын карадык. Колонна астында унөч метр биеклектәге калкулык кеше кулы белән өелгән. Хөддә безне Ком эл-Шукаф җир асты куышлары белән таныштырды. Алар кыя эченә түбәдән утыз өч метр астарак казылган. Бу куышлар безнең эраның II—III гасырларында үлгән кешеләрне күмү өчен казылганнар. Шунысы кызыклы: диварлардагы бизәкләр кичә генә ясалган кебек.

Куышлардан чыгабыз да күкрәкләрне тутырып саф һава сулыйбыз. Безнең автобусны бала-чагалар чолгап алган. Төрле яшьтәгеләре бар — әле генә тәпи йөри башлаганнары да, үндүрт-унбиш яшендәгеләре дә. Кычкырышалар: «Русские, хорошо! Значок, карандаш!» Полицейский аларны куа, уңайсызланып безгә аңлата: «Без теләнчеләр белән көрәш алып барабыз,— ди.— Аеруча балаларны тыябыз...» Ә балалар исә бик начар тәэсир калдыра. Киемнәре пычрак, сәләмә, аяклары ялангач. Үзе әле генә тәпи баскан, ә инде кечкенә энесен яки сеңелесен күтәреп йөри торганнары да күп.

Балаларның тыңламауларын күргәч, полицейский, бик усал кыяфәткә кергән булып, каешын чишә. Балалар чыр-чу килеп таралышалар да бер зур агач төбенә җыелышалар. Шулай да бер уналты яшьлек үсмер безнең автобус янына уза. Русча белә икән. Сөйләшеп китәбез. Исеме Мөхәммәт, әтисе үлгән, әнисе эшсез, ә алар — тугыз бала. Абыйсы корабльдә матрос булып эшли. Мөхәммәт, Советлар Союзына барып, белем алырга хыяллана. Рус телен Рус-гарәп дуслыгы җәмгыятенең культура үзәгенә йөреп өйрәнгән икән...

Тагын бер кызыклы очрашу хәтердә калган. Базарда йөри торгач, тәмам адаштык, ниндидер бер тар гына тыкрыкка килеп чыктык. Мөхәммәт Али мәйданына ничек барасын беребез дә белми. Ярдәм сорап бер хәрби кешегә мөрәҗәгать итәргә уйладым. «Әссәламегаләйкем»,—дип сәламләдем дә үтенечемне әйттем һәм сигарет тәкъдим иттем. Ә ул бик мөлаем итеп елмайды да саф рус телендә: «Сигарет үзегезгә дә кирәк булыр әле,— диде.— Ә мәйдан якын гына».

Сөйләшеп киттек. Аның да исеме Мөхәммәт икән. Советлар Союзында укыган, Совет кешеләре белән дуслашуын зур бәхет итеп саный. Шулай сөйләшеп бара торгач, мәйданга килеп тә җиттек. Бик җылы саубуллаштык.

Искәндәрия шәһәрендәге дәүләт предприятиеләренең берсе — пластмасса әйберләре ясый торган завод белән таныштык. Үз эшләрен тирәнтен белүче ике яшь инженер — Каһирә университетын тәмамлаган егетләр — безгә заводны күрсәтеп йөрделәр. Заводта бары тик ирләр генә эшли. Бөтен заводта ике генә хатын-кыз икән, алар да конторада гына утыралар.

## Каһирә

Искәндәрия белән Каһирә арасы автобуста дүрт сәгатьлек юл.

Нил елгасын Идел кебек мул сулы, куәтле елга дип күз алдыма китергән идем. Башта ул, дәреслекләрдә язылганча, ул кадәр куәтле булып күренмәде. Хәер, никадәр кешеләргә хезмәт күрсәтүче, никадәр җиргә яшәү көче биреп аккан бу елганы кимсетеп карау гөнаһ булыр иде. Нил чүлнең эссе комнарына каршы көн-төн көрәшә. Чүлне урталай кисеп аккан елга буйлары яшеллеккә күмелеп утыра.

Каһирә — зиннәтле сарайлар һәм ярлы алачыклар шәһәре. Сарайлар — чәчәккә күмелгән бакчалар уртасында, ишегалларында фонтаннар бәреп тора, анда үз дәрәҗәсен белеп кенә тәз гәүдәле хезмәтчеләр йөри.

Ә хезмәт кешеләре, ярлылар яши торган алачыкларның тәрәзәләре дә, ишекләре дә, хәтта кайберләренең түбәләре дә юк. Аларны төрле фанералардан, катыргы

кәгазьләрдән, чүпрәк-чапрактан кораштырганнар. Гид безгә аңлата: эшсезлек һәм торак мәсьәләсе хәзер Мисырда иң житди проблема икән. Торак йортлар төзү национальләштерелмәгән, шуңа күрә байлар зиннәтле сарайларда яши, ә ярлыларга торыр урын юк. Соңгы елларда муниципалитетлар һәм предприятиеләр үз эшчеләре өчен торак йортлар салырга керешкәннәр икән инде. Без утырган автобус шундый бер микрорайон аша үтте. Биш катлы йортлар. Әмма алар күңелсез тәэсир калдыра, стеналар кубып, пычранып беткән, тәрәзәләргә керләр эленгән, тирә-юньдә бер генә куак та үсми. Кая карама — бала-чага.

Безне Каһирәдә «Семирамис» дигән кунак йортына урнаштырдылар. Ул әт-Таһрир мәйданы янында гына, Нил елгасы буена урнашкан. Алтын төсендәге рамнарга куелган зур көзгеләр, паласлар... Бу кунак йортында гадәттә зур политик эшлеклеләр, промышленниклар, бай туристлар туктала икән.

Каһирә күптән түгел үзенең мең еллыгын билгеләп үткән. Шәһәрнең башлануын галимнәр 969 елдан саныйлар. Бу турыда борынгы риваять сакланган.

Шәһәр салынасы урынны башта казыклар кагып бүлеп куйганнар. Казыкларга бау тартканнар, ә бауга кыңгыраулар элгәннәр.

Астролог йолдызлардан багып, уңай вакыт житүен белгәннән соң, баудан тартып кыңгырауларны шалтыратырга һәм шул сигнал буенча меңнәрчә җир казучылар эшкә керешергә тиеш була. Әмма эш бөтенләй көтелмәгәнчә килеп чыга. Күктә кинәт Марс күренә (ә бу йолдыз гарәпләр өчен бәхетсезлек билгесе) һәм шул вакыт бауга козгын кунып кагына. Кыңгыраулар шалтырарга керешә. Йолдыз багучылар моны бәхетсезлеккә юрыйлар. Шулай да шәһәр салына. Яңа шәһәргә әл-Каһирә — «Җиңүче» дигән исем бирәләр. (Марсны да гарәпләр шулай атый.)

Төрле юрауларга карамастан, Каһирә мең ел дәвамында дөньяның зур һәм матур шәһәрләреннән берсе булып килде. Хәзер Каһирәдә биш миллион чамасы кеше яши. Ул Мисырда гына түгел, бөтен Африка континентындагы иң зур шәһәр. Мисыр Гарәбстан Республикасының баш шәһәре, илнең төп промышленность районы, Мисыр культурасы, фәне, сәнгате үзәге.

Каһирә бөтен гарәп көнчыгышы өчен политик һәм культура үзәге булып тора. Мисыр республика дип игълан ителгәннән башлап, Каһирәдә съездлар, симпозиумнар, теләктәшлек конференцияләре үткәрелә, аларда Азия һәм Африка илләре вәкилләре милли-азатлык хәрәкәтенең, империализм белән көрәшнең мөһим мәсьәләләрен тикшерәләр.

Каһирәдәге уку йортлары үзләрендә әлегә милли кадрлар булмаган көнчыгыш халыклары өчен дә белгечләр әзерли. Каһирәдәге борынгы һәйкәлләрне, истәлекләрне, музей һәм китапханәләрне күрү өчен барлык континентлардан меңләгән кешеләр килә.

Әт-Таһрир (Азатлык) мәйданына урнашкан милли музей әйруча бай. Ул дөньяның иң борынгы, иң зиннәтле музейларыннан санала. Аңа 1857 елда Франция археологы Огюст Марриэтт нигез салган. Гомерен борынгы Мисырны өйрәнүгә багышлаган бу галимгә музей алдына һәйкәл куйганнар. Музейның беренче директоры О. Марриэтт, үлгәннән соң, борынгы Мисыр саркофагында күмелүгә лаек була.

Музейда утызга якын Мисыр фиргавеннәренең мумияләре саклана. Аларның киемнәренә, зур тәгәрмәчле арбаларына да күп урын бирелгән. Зиннәтле савыт-сабалар, алтын белән бизәлгән тартмалар һәм башка көнкүреш әйберләре биредә бик күп. Тутанхамон фиргавен гробницасыннан табылган әйберләргә махсус урын билгеләнгән. Алтын бизәкле дүрт саркофаг катлы-катлы, берсе эченә берсе урнаштырылган булган. Безнең гид — Шәддия исемле Мисыр кызы (Мәскәү университетының филология факультетында укыган, ә ире биология факультетында аспирантура бетергән) — барысы турында да рус телендә бәйнә-бәйнә сөйли. Израиль белән сугыш хәлендә булганга Тутанхамон саркофагында табылган 110 килограммлы алтын мумияләрнең берсе һәм башка кыйммәтле экспонатлар Швейцариягә озатылган икән. Мин Шәддиядән: «Тутанхамонның кыйммәтле ташлар белән бизәлгән таягы табылмадымы икән» — дип сорадым. Аның моннан берничә ел элек музейдан урлануы турында белә идем. Юк, табылмаган икән. Берәрсенең шәхси коллекциясендә тора торгандыр инде.

Музейда борынгы Мисыр кешеләренең җир эшкәртү кораллары, кояш һәм су

сәгатьләре, борынгы астрологлар төзегән күк йөзе карталары саклана. Борынгы Көнчыгыш тарихы дәреслекләре буенча күптән таныш булган Мисыр сәркатибе фигурасының төп нөсхәсен дә күрдек. Төрекләр кебек аякларын бөкләп утырган бик матур яшь егетнең күзләре алга текәлгән, кулында кечкенә таяк, алдында — такта кисәге. Менә хәзер ул кулын күтәрер дә тактага чөй язмасын төшерә башлар кебек. Аның фигурасы шул кадәр төгәл эшләнгән — кулың үзеннән-үзе аңа таба сузыла, тотып карыйсы килә: бәлки, җаны бардыр...

Мисыр музеенда хатын патша Нефертитинең комташтан ясалган кечкенә генә баш сурәте (33 см) саклана. Баш киеме маңгаена төшеп тора, ян яклары колакларын томалаган. Берничә урында буяу эзләре беленә. Хатын патшаның моннан тыш тагы ике портреты бар, әмма алар Мисырда түгел. Аларның берсе — ак известняктан ясалганы — аеруча популяр. Баш тирәли чуар тасма бәйләгән. Мисыр сәнгатенең барлык әсәрләрендә, туристик компанияләрнең рекламаларында, магазин витриналарында, хушбуй флаконнары тышында, яулыкларда биек таҗ кигән Нефертити рәсеме сурәтләнә.

Сакланып калган язмаларга караганда, Нефертити Мисырның иң күренекле хатын-кызларыннан берсе булган. Әмма аның язмышы әлегә кадәр билгесез. Ире Эхнатон — Мисырда борынгы мәҗүсиләр диненә нигез салган фиргавен — үлгәннән соң Нефертитига ни булганы билгеле түгел. Гробницасы да, мумиясе дә табылганы юк.

Мисыр сәнгатендә хатын-кыз матурлыгын җырлау зур урын алып тора. Өченче гасыр ахырында ташка чокып эшләнгән хатын-кыз гаҗәеп тәэсир калдыра. Өстендә аның озын күлмәк, нәфис муены, ачык иңнәре кыйммәтле ташлар белән бизәлгән, кулында көзге. Каршысындагы хезмәтче кыз аңа күлмәк сузып тора, икенчесе чәчен матурлый. Бу — Кавит исемле хатын патша рәсеме. Анда сурәтләнгән күренеш — таш саркофагның бер кисәге.

Мондый чын сәнгать әйберләренең бик борынгы заманнарда иҗат ителүенә ышанасы да килми. Борынгы Мисыр әйберләре бөтен дөньяга таралган. Аларны Лувр, Британия, Берлин музейларында, Эрмитажда, Мәскәүдә сынлы сәнгать музеенда һ. б. урыннарда очратырга мөмкин. Һәр музейда бөтен дөньяга атаклы шедеврлар бар. Әмма Каһирәдәге музейда борынгы Мисыр әйберләренә аеруча киң урын бирелгән.

Музейда йөздән артык зал бар. Заллардагы һәр экспонат шул кадәр кыйммәтле — аларга бәя билгеләү дә мөмкин түгел...

Икенче көнне без Каһирә ныгытмаларын карадык. Атаклы гарәп полководецы Сәлахетдин салдырган бу крепостьның калын диварлары һәм нык манаралары үзләреннән-үзләре җиңелмәс дәһшәтле көчне күз алдына китерә. Җиде гасыр дәвамында бу ныгытмалар Мисырның югары әһелләре өчен тору урыны булып хезмәт иткән. Мәгаен, бөтен Көнчыгышта урта гасырлар заманында бу ныгытмалар кебек күп вакыйгалар кичергән бүтән крепостьлар юктыр. XIX гасырда салынган Мөхәммәт Али сарае һәм мәчете дә шушы крепость эчендә. Нечкә бизәкләр төшерелгән мәрмәр плитәләр белән тышланган бу матур бина берьюлы биш мең гыйбадәт кылучыны сыйдырырлык зур итеп салынган. Мәчет эчендәге мавзолейда Мөхәммәт Али үзе күмелгән.

Шул ук көнне яһүдиләр гыйбадәтханәсе — синагоганы һәм Коптлар чиркәвен карадык. Синагога — бик борынгы бина, безнең эраның II гасырында ук салынган. Ә аның эчендә синагога салынган вакытка караганда да борынгырак заманда тиресә язылган библия саклана.

Каһирәдә якынча 15 мең тирәсе яһүдиләр яши. Бу синагогадан тыш та берничә гыйбадәтханәләре бар икән.

Мондагы чиркәүдә Көнчыгыш йогынтысы сизелеп тора. Ишек яңаклары, тәрәзәләр фил сөяге һәм бака кабыгы белән матур итеп бизәлгән. Гыйбадәт кылучылар өчен куелган урындыкларга да шундый ук бизәкләр төшерелгән.

Мисырның җиде процент халкы (миллион ярым чамасы кеше) — христиан динендә.

Крепостьтан чыгып, юл буйлап түбән төшебез. Юлның һәр ике ягы буйлап мөселман каберлеге җәелеп киткән. Бу үзенә күрә бер шәһәр — үлеләр шәһәре. Нәсел

тәрбәләре гөмбәзләр белән ябылган. Менә бер изге мөселман кабере. Аның мавзолее тирәсе төрле төстәге тукыма кисәкләре белән чуарланган. Диндар кеше теләге гамәлгә ашсын өчен бирегә килә икән. Мөхәммәт пәйгамбәрнең кызы Фатыйма һәм аның улы Хөсәен дә шушы каберлеккә күмелгән, диләр. Әмма без аларның мавзолейларын күрмәдек.

Хан-әл-Хәлил базары искитмәле тәэсир калдырды. Типик Көнчыгыш базары — шау-шу, чүп-чуар, бер караганда барысы да сата, барысы да сатып ала кебек. Монда барысы да бар: бизәкле савыт-сабалар, шәмдәлләр, авторучкалар, төрле тукымалар... Сәүдәгәрләр, кофе эчә-эчә, янсә кальян суыра-суыра, бер-берсе белән гәпләшәләр. Хәтта бала-чагалар да сату итә: чәйни торган резинкалар, открыткалар саталар, сатып алучыларны зур кибетләргә чакырып йөриләр.

Тагын балалар турында сүз чыккач, шуны да әйтергә кирәк: Мисыр республикасы хөкүмәте мәгариф мәсьәләсенә хәзер зур игътибар юнәлтә. Балалар I нче баскыч мәктәпләрендә алты ел, 2 нче баскыч мәктәпләрендә алты ел — барысы унике ел белем алалар. 1 нче баскыч мәктәпләрендә кызлар да, малайлар да бергә укый. Республикада тәрбиячесез балалар өчен ясләләр, балалар бакчалары булдырыла. Әмма алар әлегә бик аз. Зур, ишле семьяларда балаларга мәктәпкә йөрүне түгел, күбрәк тормыш алып бару турында уйларга туры килә. Мин, мәсәлән, шундый күренешнең шаһиты булдым. Ресторан янына бер чит ил маркалы автомобиль килеп туктады. Шул арада әллә кайдан кара бөдрә чәчле, чем-кара күзле биш-алты яшьлек бер малай килеп чыкты һәм машинаны чүпрәк белән сөртергә кереште. Пыялаларын, ялтыравык урыннарын күз чагылырлык иткәнче чистартты. Эшен бетергәч, чүпрәкләрен киң балаклы ыштаны кесәсенә тыгып куйды да машина хуҗасы чыгып, хезмәте өчен түләгәнне көтәргә кереште...

Базарда без бик озак йөрдек. Фарфор, алтыннан ясалган әйберләр рәтеннән үтеп, һөнәрчеләр янына килеп чыктык. Биредә тәҗрибәле осталар үзләренең шәкертләрен металлдан, агачтан, дөя сөягеннән, бака кабыкларыннан төрле матур әйберләр ясарга өйрәтәләр...

Кунак йортына көн кичкә авышкач кына кайттык.

Каһирә урамнары турында берничә сүз. Каһирәнең иң матур урамнары — Сөләйман паша урамы белән Каер-Нил урамы. Бу урамнарга иң бай кибетләр, кинотеатрлар, барлар урнашкан. Машиналар агымы бер дә туктап тормый, барысы да бер-берсен ашыктыра, туктаусыз кычкырта. Һәр машинаның клаксоны аерым бер төрле тавыш чыгара. Шау-шу колаклар тонарлык. Машиналарны кирәксә дә, кирәкмәсә дә кычкырталар. Полиция машиналары исә барысын да уздырырга тырышкандай үкерә.

Каһирәдә халыкара урам хәрәкәте кагыйдәләре хакимлек итсә дә, аларны бик еш бозалар. Мин бер автобусның клаксонын кычкыртып арыгач, трамвай юллары аша үтеп, юлның икенче ягындагы машиналар агымына каршы борылуын карап тордым. Каршы килгән машиналар исә, моңа ризасызлык белдереп, ду килеп үкерешә башладылар.

Каһирәдә, гомумән, транспорт мәсьәләсе бик җитди проблема. Берничә миллион кеше яшәгән зур шәһәрдә метро юк. Башлыча трамвайларга, автобусларга, таксига утырып йөриләр. Алар көн буе тулы. Тукталыш саен транспорт көтүчеләр чираты тора. Хәтта автобус тәрәзәләреннән аякларын салындырып баручыларны да күрергә туры килде.

Мисыр пирамидалары турында без инде бала чактан беләбез. Ниһаять, без аларны үз күзләребез белән күрәчәкбез. Анда барганда, Каһирә университеты ишегалдында Мисыр скульпторы Мәхмүт Мохтар эшләгән монументны карадык. Мәхмүт Мохтар озак вакытлар Парижда яши һәм атаклы скульптор Роденның шәкерте була. Бервакыт аның янына Мисыр милли азатлык хәрәкәте лидеры, «Әл-Вафд әл Мисрыйя» партиясенә нигез салучы Сәгадәт Заглюль килә һәм аңа монументаль һәйкәл эшләргә тәкъдим ясый. Мәхмүт Мохтар тоташ Асуан гранитыннан ясалган «Мисыр уяна» скульптурасы өстендә ун ел эшли. Яшь хатын бер кулын сфинксның башына салган, икенчесе белән битендәге пәрәнҗәне алып ташлый. Мисыр кешеләре бу хатын фигурасында, мең еллык тарихларына таянып, яңа тормыш төзүче азат милләтнең киләчәк омтылышын күрәләр.

Безне башта Мемфис һәм Саккара дигән урыннарга алып бардылар.

Мемфис — Мисырның борынгы башкаласы, аңа безнең эрага кадәр дүрт мең ел элек нигез салынган. Алсу граниттан эшләнгән Рамзес II һәйкәле үзенең гаҗәеп зурлыгы белән дан тота. Фиргавен ятып торган килеш сурәтләнә. Хәзер инде аның аяклары юк. Аяклары барында статуя ундүрт метр озынлыкта булган, ике аяк арасында хатынының кечкенә сыны торган, диләр. Шунда ук сфинкс статуясы — фиргавеннәрнең куәтен сурәтләүче символ.

Саккара — Борынгы патшалык заманында үлгән фиргавеннәрне күмү урыны. Мисырда салынган беренче пирамида — Джассер пирамидасы да биредә. Ул таштан салынган, биеклеге 60 метр. Ныгытма бастионнар белән әйләндереп алынган, колонналар һәм гыйбадәтханәләр әлегә кадәр сакланган. Бер гыйбадәтханәдә үгезләрне корбан чала торган булганнар. Некропольдә археологик тикшеренүләр бара. 1965 елда Саккарада яңа ике гробница һәм алар эчендә алтыннар, фаянс белән бизәлгән мумияләр табыла. Гробница идәне астында ярты километр озынлыктагы җир асты куышы ачыла. Анда бик күп мумияле саркофаглар куелган булә. Мисыр, Польша, Англия археологлары зур реставрация эше алып баралар.

Пирамидалар районы — Гиза Саккарадан унбиш километрга төньяктарак. IV династия фиргавеннәре Хуфу (грекча Хеопс), Хафра (Хефрен) һәм Менкаура (Менерина) пирамидалары очсыз-кырыйсыз чүл уртасында утыра. Пирамидалар тирәсенә үлгәннәрне искә алу, яд итү храмнары, табыну урыннары төзелгән. Аларның һәрберсе мастаблар — югары катлау кешеләре күмелгән урыннар белән әйләндереп алынган.

Пирамидаларның иң борынгысы һәм иң зуры — Хеопс пирамидасы. Ул яңа эрага кадәр 2800 еллар элек салынган. Биеклеге — 146,6 метр, нигезенең озынлыгы — 233 метр. 1889 елда Парижда өч йөз метрлы Эйфель башнясы салынганчы, ул дөньяда иң биек төзелеш булган.

Пирамида тип-тигез итеп шомартылган 2 млн. өч йөз мең известняк блоклардан бернинди изме кушмыйча салынган. Һәр блокның авырлыгы ике ярым тонна, ә кайберләре исә утыз тоннага җитә. Аның архитектура төзелешенең монументальлеген һәм гүзәллеген борынгы заманда ук белгәннәр. Борынгы греклар дөньяның җиде могҗизасы арасында беренче урынны бу пирамидага юкка гына бирмәгәннәр.

Хефрен пирамидасының да биеклеге — 143, нигез озынлыгы — 215 метр. Хефрен пирамидасы янында тоташ кыядан юнып ясалган сфинкс статуясы тора.

Арыслан гәүдәле, кеше башлы сфинкс образы, югарыда әйтеп үтелгәнчә, Мисыр мифологиясендә фиргавеннәрнең куәтен һәм көчен гәүдәләндерүче символ. Ул — сугышчы һәм сакчы, күрәшче һәм үч алучы.

Гизадагы сфинкс иң зуры. Аның биеклеге — 70 метр, озынлыгы алгы аякларыннан койрык очына кадәр — 80 метр.

Борынгы заманда, примитив эш кораллары белән шундый камил төзелешне, шундый зур пирамидаларны кешеләр ничек башкарды икән?!

Пирамидалар һәм сфинкс бигрәк тә төнлә күркәм. Үзеңне иксез-чиксез чүл уртасында мәңгелек белән очрашкандай хис итәсең. Сахарадан салкынча җил исә, дөм караңгы, хәтта куркыныч булып китә.

Гасырлар дәвамында пирамидалар күп дәһшәтләр кичергән, дан эзләп, байлык эзләп килгән Александр Македонскийны, Наполеонны һәм башка илбасарларны күргән. Урта гасырлар заманында сфинксның горур йөзенә ныгытма җимерә торган туплардан атканнар — басып алучыларга аның буйсынмас карашы ошамаган.

Пирамидаларның төнге күренеше «Дөнья вакыттан курка, ә вакыт пирамидалардан курка»,— дигән борынгы гарәп мәкаленең дәреслеген раслый сыман...

## Луксор

Луксор — гарәпчә «сарайлар» дигән сүз. Безнең эрага кадәр 216 ел элек гарәпләр Мисырга бәреп кергәч, Фива шәһәрен күрәләр дә, гаҗәпләнеп: «Луксор!» — дип кычкырып җибәрәләр. Шул заманнан башлап шәһәргә «Луксор» исеме кушыла.

Тыныч һәм күркәм шәһәр. Нил елгасыннан җилләс һаза бәркелеп тора.

Даны бөтен дөньяга таралган гарәп юртаклары җигелгән фәйтуннарга утырып Карнак гыйбадәтханәсен карарга киттек. Карнак белән Луксор гыйбадәтханәсе арасында борын заманда сфинкслар аллеясы булган. Анда 500 сфинкс тезелеп торган. Аларның кайберләре әлегә кадәр сакланган. Сфинкслар туристларның гаҗәпләнеп аһ оруларына бер дә исләре китмичә горур кыяфәттә тора бирәләр.

Карнак гыйбадәтханәсе — Яңа патшалык чоры фиргавеннәрен зурлый торган һәйкәл ул. Биредә дә Рамзес II гә зур һәйкәл куелган. Һәйкәлнең аяк очында — фиргавен хатынының сыны.

Гыйбадәтханә Аману-Ра аллага багышланган. Аны мең ел дәвамында төзегәннәр. Гыйбадәтханәнең калдыклары гына да гигант күләме белән сокландыра. Егерме дүрт метр биеклегендәге, нигезендә өч метр ярым, очында метр ярым диаметрлы йөз дә утыз дүрт колоннаның һәрберсе гигант лотос чәчәге формасында эшләнгән. Егерме тугыз метр биеклегендәге, өч йөз дә егерме тонналы обелиск хатын патша Хатшепсут хөрмәтенә эшләнгән. Аның янында шул ук Хатшепсут образын гәүдәләндергән сфинкс тора. Сфинкс сары комташтан ясалган. Нәфис хатын-кыз йөзе дәһшәтле арыслан гәүдәсенә бөтенләй ятышсыз.

Хатшепсут Тутмос I фиргавеннең кызы һәм үзенең бертуган абыйсы Тутмос II нең хатыны була. Ә Тутмос II нең патша нәселеннән булмаган хатыннан туган улы Тутмос III атасы үлгәннән соң, сеңелесе белән ярәштерелә һәм үзен фиргавен дип белдерә. Хатшепсут аның регенты булып кала. Әмма ул моның белән һич тә риза булмый, тәхетне яулап ала һәм күп кенә еллар дәвамында Мисыр белән идарә итә.

Хатшепсут исән чагында ук Фива шәһәре турысында Нилның аргы ягында гыйбадәтханә салына башлый.

Алтын төсендәге комташтан эшләнгән колонналар белән әйләндереп алынган өч терраса кыяга килеп терәлә. Стеналардагы барельефлар хатын патшаның Ра аллададан тууын һәм аның җирдәге эшләрен сурәтли.

Хатшепсут үлгәннән соң, тәхет фиргавен Тутмос III кә күчә. Ул статуяларны, Хатшепсут исеме белән бәйле барлык нәрсәне юк итәргә куша. Янәсе, аның җаны җир өстендә сыенып урын таба алмасын. Шуңа күрә аңа бәйле иероглифлар һәм рәсемнәр аз сакланган.

Безнең гид Мостафа — тарихчы-египтолог. Ул колледжда укыта һәм Луксорда, Нилның аргы ягында — Патшалар үзәнендә — археологик эзләнүләргә катнаша. Шуңа күрә бик табигый: өстән-өстән генә сөйләми, фәнни яктан кызыклы фактлар китереп сөйли, тарихи күзәтүләре белән уртаклаша.

Мостафа безне чишмәләрдән аккан судан җыелган бер күл янына алып килде. Бу күл борынгы заманда тәһарәт алу өчен бассейн хезмәтен үтәгән. Яр буйлары гранит белән түшәлгән. Күл янына борынгы заманнарда изге дип исәпләнгән коңгызга һәйкәл куелган.

— Бер зур теләгегезне тормышка ашырасыгыз килсә,— диде Мостафа, елмаеп,— коңгыз сыны тирәли җиде тапкыр әйләнсәгез, шул җиткән. Теләгегезне эчтән кабатларга, кулыгызны коңгызга тидереп алырга гына кирәк...

Мин аның киңәшен тотам. Башкалар барысы да көлеп карап торалар, теләгемне бары тик коңгызга гына белдерәм. Әмма җиде генә түгел, сигез мәртәбә әйләнгәнмендер...

Паромга утырып, Нил аша Патшалар үзәненә чыгабыз. Кояш чиксез кыздыра, тирә-юньдә комнан башка берни юк. Аз гына да яшеллек әсәре күренми. Үле табигать...

Җир астына төшеп, гробницалар, кешелек тормышы өчен кирәкле әйберләрне күргәч кенә җиңел сулап куйдык. Монда борын заманда бала тудыру сурәтләрен дә, сыер саву, сугыш һәм әсирләрне җәзалау күренешләрен дә күрергә мөмкин.

XVIII династиянең соңгы фиргавене Тутанхамон гробницасыннан бик күп кыйммәтле ташлар, сарай әйберләре, өч меңелдан артык яткан берничә капчык бодай табылган. Аны чәчеп, үстереп караганнар. Башаклары тармакланып үскән, бер башактан йөз кырык дүрт орлык чыккан.

Тутанхамон гробницасы — кул тимәгән хәлендә әлегә кадәр сакланган бердәнбер гробница. Мостафа ярым шаяртып:

— Гробницаны талаучылар, мөгаен, еш кына фиргавеннәр үзләре булган булса

кирәк,— ди.— Алар үзләре исән вакытта ук гробница эшләткәннәр. Һәм теге дөньяда да патша тормышы белән яшәргә исәп тотып, электәге фиргавен гробницасындагы мал-мөлкәтне урлап үзенә ташыткannардыр.

Луксорда без бер егет белән таныштык. Кояшта янган, чәчләре тузган,— хиппинең нәкъ үзе. АКШта Калифорния университеты студенты икән. Кайда туры килсә, шунда ялланып акча эшли дә юлын дәвам итә. Ә Мисырда эш табуы кыен, дип зарланды, чөнки үзләрендә дә эшсезләр күп. Ниндидер тулай торакта яши. Без торган кунак йортының исемен белгәч, күзләре шар булды: «О, сез миллионерлар икән!» — ди. Советлар Союзында буласы бик килә икән дә, юлга акча эшләргә мөмкинлеге юк. «Мин барыбер Мәскәүгә барачакмын. Бу — минем хыялым»,— ди.

# Асуан

Мин университетта Мисырның яңа тарихы буенча дәресләр алып барам. Шуңа күрә Асуан минем өчен гаять кызыклы. Асуан — совет-гарәп дуслыгы символы ул. Асуан — Мисырда яңа тормышның башлангычы, Асуан — кешеләр арасында яңа мөнәсәбәтләр барлыкка килү урыны.

Биредә Советлар Союзы ярдәме белән салына торган плотинаның биеклеге 111 метр, озынлыгы — өч ярым километр, киңлеге нигездә бер километр, өстендә кырык метр. Сусаклагыч урында әле су җыелмаган. Шулай да электростанция инде энергия бирә: 10 млрд. киловатт-сәгать. Бу — Мисырда моңа кадәр салынган дүрт электростанция көче.

Плотина белән рәттән порт салына. Мондагы эш күләмен чамалау өчен Мисырдагы иң зур пирамида — Хеопс пирамидасын төзүне күз алдына китерик. Хеопс пирамидасын йөз мең кеше утыз ел буе салган. Ә мондагы эш күләме Хеопс пирамидасын төзегәндәгегә караганда 17 мәртәбәгә артыграк!

Асуанда, һич тә көтмәгәндә, Советлар Союзыннан килгән егетләр белән очраштык.

Артына цистерна таккан бер йөк машинасы безнең янга килеп җитте дә туктады. Дүрт егет машинадан төштеләр дә, исәнләшеп, безнең арадан якташларын эзләргә керештеләр. Без дә, Татарстан егетләре юкмы икән, дип кызыксындык. Юк икән. «Мәскәүгә сәлам әйтегез, без монда бирешмибез. Сау булыгыз»,— диделәр дә китеп бардылар. Күңелле очрашу.

Асуанда дуслык атмосферасы нык сизелә. Гарәпчә язылган белдерүләр, лозунглар белән рәттән русча язулар да күп: «Запчастьлар складь», «Әнвәр Саадатка һәм аның кунакларына сәлам!», «Яшәсен совет-гарәп дуслыгы!» һ. б. лар.

Плотина төзегәндә сфинкслар, фиргавен статуялары ясау, пирамидалар өчен тотылган шул ук атаклы Асуан гранитын файдаланганнар. Мин истәлек өчен бер кисәген алып сумкама салам. Кибетләрдә крокодил, зур көлтә елан — варан тиреләрен карап йөрибез. Безгә сандал агачыннан ясалган әйберләр, амбрадан ясалган тәсбихлар тәкъдим итәләр. Тирә-юньгә хуш ис бөркелә. «Мең дә бер кичә» әкиятләре искә төшә.

Җилкәнле көймәгә утырып, Нил елгасындагы утрауга чыгабыз. Анда ботаник бакчаны карыйбыз. Үсемлекләрнең исемнәре истә калырлык түгел, әмма чәчәкләргә күмелеп утырган күп төрле кыргый Африка үсемлекләре, куаклары озак вакытлар күз алдыбыздан китмәде. Асуан плотинасы су белән тулгач, Мисырның ком чүлләрендә шундый биек пальмалар, манго агачлары, мандарин һәм апельсин урманнары шаулап утырсын иде, дигән теләк калды.

— Нил елгасында коеныргa ярамый, анда микроблар мыжгып тора,— диделәр. Ә безнең көймәче — шактый олы яшьләрдәге гарәп — һәм аның ярдәмчесе — яшүсмер малай — бу турыда исләренә дә кертмиләр. Көймәчедән: «Әлле улыгызмы?» — дип сорыйбыз.

— Ганләм юк минем,— ди ул.— Өйләнү бик кыйммәткә төшә. Аннары хатынны торак белән, кием-салым белән тәэмин итәргә кирәк. Ә бездә хатын-кызга эшләргә рөхсәт ителми. Шуңа күрә, гөнаһ булса да, бездә өйләнми калган ярлылар бик күп.

Әйе, ислам дине рәсми рәвештә өйләнмичә яшәүне катгый тыя. Борынгы заманнарда ук күчмә бәдәвиләр арасында: «Терлек-туары һәм бала-чагасы күп булган кеше генә чын-чынлап бай»,— дигән караш закон булып әверелгән. Һәм бер үк вакытта шунысы да бар: чит кеше хатыны гарәпләр өчен хәрам.

Әмма байлар дүртәр хатын алырга хокуклы. Без Һинд-Пакистан исмаилитлары башлыгы Ага-хан III мавзолеенда булдык. Ул ак мәрмәр саркофаг эчендә үзенең дүртенче хатыны — француз хатыны белән бергә күмелгән.

Дингә ышанучылар исәбенә җыелган әкияттәгечә бик зур байлыкка ия булган Ага-хан III Һиндстаннан Нил буена, ак мәрмәр сарайга дәвалану өчен килеп йөри торган булган. Үлгәннән соң да үзен Нил буена китереп күмәргә васыять әйтеп калдырган. Моның белән ул үзен фиргавеннәр кебек бөек итеп күрсәтергә теләгән дигән легенда бар.

Асуан белән саубуллашып, кабат Каһирәгә юнәләбез. Поездда кайтканда, чүлдә көндез бик эссе, ә төннәрен салкын булуына кабат ышанабыз.

Каһирәгә җиткәндә поезд бик акрынайды — тимер юлда ремонт эшләре бара икән. Тире белән сөяктән генә торган ябык тәнле эшчеләр резина савытларга тутырылган таш яки гравийны баш түбәләренә күтәреп ташыйлар. Аяклары ялангач. (Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: гарәп хатыннары һәм балалары йөкне, су тулы кувшинны баш түбәләренә күтәреп йөриләр, шуңа күрә алар барысы да төз, матур гәүдәле.) Юл буйлап ни туры килде, шуннан корыштырылган алачыклар тезелеп киткән. Аларның эченә үрмәләп кенә керергә мөмкин.

Болар — Англиянең колониаль хакимлеге җимешләре — вагон тәрәзәсеннән карап барганда да күңелдә авыр тәэсир калдыра.

Безнең белән Луксорга һәм Асуанга микробиология буенча лекцияләр укыр өчен Каһирә университетына чакырылган Лейпциг университеты профессоры да сәяхәт итте. Каһирәдә өч университет бар: әл-Әзһәр, Айн-Шәмс һәм Каһирә университеты. 1952 елгы революциядән соң университетлар тормышында да үзгәрешләр күп. Ярлы балалары да хәзер Мисырдагы университетларда да, дәүләт хисабына чит илләргә барып та белем алырга хокуклы. Асылда дини университет булган әл-Әзһәрдә дә табигать фәннәре укытыла, хәтта анда хәзер хатын-кызлар да белем алалар.

Шулай да, профессор сөйләвенчә, исламның уку йортларына йогынтысы зур әле. Еш кына намаз уку, башка дини йолалар үтәү өчен дәресләр өзелә. Һәр уку йортының, хәтта һәр факультетның диярлек үз мәчете бар. Әмма бу мәчетләргә студентлар намаз уку өчен генә түгел, җыелышлар үткәрү өчен дә йөриләр...

Каһирә урамнарын, мәйданнарын соңгы кабат әйләнәбез. Гамәл Габдел Насыйр мавзолеена керәбез. Ул — Габдел Насыйр үләрдән биш ел элек салынган мәчет. Бирелә ул намаз укыган, Мисырның киләчәге, гарәп дөньясының язмышы турында уйланып утырырга яраткан...

Ак мәрмәрдән ясалган саркофаг өстенә чәчәкләр бәйләме салабыз...

**Яхъя Абдуллин,**
философия фәннәре кандидаты

# ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ ФИЛОСОФИЯСЕНЕҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Татар халкының иҗтимагый фикер тарихы буенча соңгы елларда чыккан фәнни әдәбиятта мәгърифәтчелек мәсьәләләренә зур урын бирелә. М. Гайнуллин, К. Фасеев, Р. Нафиков, И. Нуруллин, Х. Хисмәтуллин, Х. Мөхәммәтов, С. Михайловаларның хезмәтләрендә мәгърифәтчелек хәрәкәте барлыкка килүнең социаль-экономик алшартлары һәм үсеш закончалыклары, татар мәгърифәтчелегенең табигате һәм тарихтагы урыны тикшерелә, аерым мәгърифәтчеләрнең тормыш һәм иҗат юллары өйрәнелә.

Башка халыкларның мәгърифәтчелек хәрәкәте кебек үк, татар мәгърифәтчелеге дә феодаль-урта гасырчылык мөнәсәбәтләреннән арынырга омтылуның идеологик бер формасы төсендә барлыкка килә һәм бу процессның нигезендә татар халкының капиталистик мөнәсәбәтләр ташкынына тартылуы ята. Бу мөнәсәбәтләрнең татарлар арасына үтеп керүе гасырлар буе яшәп килгән традицияләрне акрынлап җимерә башлый һәм халыкның рухи тормышында тирән үзгәрешләр китереп чыгара. Мәгърифәтчелек фикеренең туып үсә башлавы үзе шуның бер нәтиҗәсе булып тора. Феодаль-патриархаль мөнәсәбәтләргә һәм дини-схоластик карашларга каршы көрәшүче социаль көчләр позициясеннән торып, мәгърифәтчелек хәрәкәте вәкилләре иҗтимагый тормышның һәр өлкәсендә урта гасырчылык калдыкларын кискен фаш итәләр һәм, шуның белән бергә, социаль-экономик, иҗтимагый-политик, әхлакый-этик, әдәби-мәдәни һәм философия мәсьәләләре буенча бай әдәби мирас калдыралар.

Әнә шул байлыкның иң аз өйрәнелгән өлеше мәгърифәтчеләрнең философик карашларына туры килә. Күтәргән мәсьәләләренең характеры ягыннан булсын, аларны чишү ысуллары ягыннан булсын, татар мәгърифәтчеләренең философик карашларына күп кенә специфик үзенчәлекләр хас. Аларны мәгърифәтчелек хәрәкәте формалашкан чорда татар дөньясында хөкем сөргән социаль-экономик мөнәсәбәтләрдәге һәм татар халкының рухи тормышындагы үзенчәлекләр китереп чыгарган. Иҗтимагый аңның бер формасы буларак, философия иҗтимагый яшәешнең чагылышы булып тора. Шуңа күрә татар мәгърифәтчеләренең философик карашлары да татар халкы тормышындагы материаль шартларның чагылышы буларак формалаша. Әмма, шуның белән бергә, иҗтимагый яшәешнең философик идея һәм теорияләр үсешенә турыдан-туры түгел, бәлки иҗтимагый тормышның башка факторлары, барыннан да элек, рухи факторлар аша йогынты ясавын истән чыгарырга ярамый. «Хезмәт бүленешенең үзенә аерым өлкәсе буларак,— ди Ф. Энгельс,— һәр эпоханың философиясе, киртәкле алшарт сыйфатында, мәгълүм бер фикри материал белән эш итә... Монда экономика өр-яңадан берни дә тудырмый, әмма ул булган кадәр фикри материалның үзгәрү һәм алга таба үсү юлын билгели,

хәттә моны да ул читләтелгән юл белән эшли, асылда исә философиягә турыдан-туры мөһим тәэсирне политик, юридик, мораль факторлар ясый». (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. 37 том. 419—420 битләр. Рус телендә.)

Тормышның социаль-экономик шартлары философик идея һәм теорияләрнең специфик фәлсәфи проблематикасын түгел, ә аларның иҗтимагый-политик эчтәлеген билгели. Ә бу проблематиканың формалашуына иҗтимагый аңның үз үзенчәлекләре, тупланган идея материалы һәм идея традицияләре кәчле йогынты ясый. Бу планда алганда, татар мәгърифәтчелек фикеренең формалашуына йогынты ясаган иң мөһим фактор — татар халкының авыз иҗаты һәм милли иҗтимагый-политик фикернең алдынгы традицияләре, аерым алганда, татар әдәбияты ядкарьләрендә борынгы заманнардан бирле кызыл җеп булып сузылган гуманизм, гаделлек һәм изүгә каршы нәфрәт идеяләре. Шуның белән бергә, татар халкы гасырлар буена башка халыклар белән тыгыз элемтәдә була, алар белән материаль һәм рухи байлыклар алмашып яши. Бу бәйләнешләр аның рухи тормышына, шул исәптән, бездәге мәгърифәтчелек хәрәкәтенең характерына һәм үзенчәлекләренә дә тәэсир итми калмаган. Татар мәгърифәтчелегендә, берьяктан, көнчыгыш рационализмының йогынтысы, икенче яктан, яңа дәвер көнбатыш фәнни фикеренең, барыннан да элек, алдынгы рус иҗтимагый фикере һәм мәдәниятенең тәэсире сизелә. Әлеге төрле-төрле рухи бәйләнешләр һәм идея традицияләре, тегеләйме-болаймы, татар мәгърифәтчелегенең философик проблематикасына да тәэсир итми калмый, татар мәгърифәтчеләренең дөньяга караш мәсьәләләрен чишүенә мәгълүм бер юнәлеш бирә.

Татар мәгърифәтчеләренең философик карашлары дини тәгълиматка каршы көрәштә формалаша. Билгеле булганча, мөселман дине дөньяга караш мәсьәләләрен шәригать законнарына таянып аңлата. Бу шулай ук татар мәгърифәтчелегендәге дөньяга караш мәсьәләләренең эчтәлегенә булсын, ул мәсьәләләрнең формасына һәм хәл ителү рәвешенә булсын, йогынты ясамый калмый. Алланың асылы һәм аның төп сыйфатлары, дөнья һәм аның яратылышы, вакытның чиксезлеге һәм чиклелеге, яшәү һәм үлем — дини тәгълимат өйрәнә торган төп мәсьәләләр әнә шулар.

Дини тәгълимат алланы зарурлык категориясенә кертә һәм аны «ваҗиб», ягъни илаһи зарурият дип атый, ә калган бөтен әйберләрне «имкян», ягъни мөмкинлек категориясенә кертә. Ваҗиб, ягъни алла мәңгелек һәм чиксез зат, ә мөмкинлек категориясенә кергән әйберләр чикле һәм үзгәрүчән нәрсәләр булып саналалар. Зарурлык, мәңгелек һәм чиксезлек кебек башлангычлардан тыш, дингә нык ышанучы мөселманнар аллага белү, күрү, ишетү, сөйләшү сәләте кебек сыйфатлар тагалар. Бервакыт алланың әлеге сыйфатлары буенча дини даирәләрдә бәхәс кызып китә, чөнки аларны зарурият дип санасаң, заруриятьнең күп булуын танырга туры килә. Бу исә алланың күплеген тану белән бер була һәм ислам диненең иң төп кагыйдәләренең берсеннән — алланың берлегеннән баш тартуга китерә. Әгәр алланың югарыда саналган сыйфатлары булырга мөмкин дип уйласак, без алла мәңгелек категория түгел икән дигән нәтиҗәгә килергә тиеш булабыз. Бу исә аның табигатьтән өстен көч булуын шик астына кую дигән сүз. Озак азаплана торгач, дин галимнәре бу четерекле мәсьәләдән дә чыгу юлын табалар. Моның өчен алар шундый бер схема уйлап чыгаралар: алланың әлеге сыйфатлары булуы мөмкин, ләкин моннан әле аларның чиксезлеге килеп чыкмый; чөнки чиклелек үзе ике төрле була: вакыт ягыннан чикләнгәнлек һәм зати чиклелек. Алладан тыш, һәр нәрсә вакыт ягыннан чикләнгән, ягъни аларның яшәмәве вакыт ягыннан яшәештән алда килә. Аллага хас сыйфатларга килгәндә исә, алар вакыт ягыннан чиксез, ә зати чикле, чөнки аларның яшәве икенче затка, ягъни алланың үзенә бәйле. Шул рәвешчә, алла белән бергә бөтен яшәешне алар өч төркемгә бүлеп йөртәләр: 1) яшәеш вакыты ягыннан да, заты белән дә зарурый, мәңгелек һәм чиксез башлангыч. Бу алла заты, ягъни алла үзе (аллага хас сыйфатлар бу төшенчәгә керми); 2) заты белән чикле, әмма вакыт ягыннан чиксез мөмкинлек. Бусы — аллага хас сыйфатлар; 3) вакыт ягыннан да, заты ягыннан да чикләнгән мөмкинлек. Бу — алланың үзеннән һәм аңа хас сыйфатлардан кала бөтен яшәеш.

Шушы тәгълиматка таянып, дин галимнәре-кәлямчеләр табигатьнең объектив законнарын таныган кешеләргә каршы чыгалар, сәбәплелек законын, дөньяның вакыт ягыннан мәңгелек, пространство ягыннан чиксез булуын кире кагалар. Шуның белән бергә, алар дөньяның юктан бар булуын

расларга, кешеләрдә дөнья алла ихтыяры белән тудырылып кына калмаган, ул, ягъни алла, бөтен күренешләргә өзлексез тәэсир итеп тора, даими рәвештә яңадан-яңа күренешләр барлыкка китерә, диган караш тәрбияләргә тырышалар. Татар мәгърифәтчеләре дин галимнәренең бу карашларын тәнкыйть итеп чыгалар. Бу эшне киң күләмдә башлап җибәргән беренче кеше Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889) була.

Дини даирәләрдә алланың берлеге һәм аллага хас сыйфатлар турында барган бәхәсне җентекләп өйрәнгәннән соң, Ш. Мәрҗани бу мәсьәлә бары тик дин кануннарына карый, ул турыда әйтергә мөмкин булганнарның һәммәсе изге китапларда язылган, шуңа күрә акылны һәм фәлсәфи фикерләрне дини тәгълимат белән бутауның кирәге юк дигән нәтиҗәгә килә. Кайберәүләр Ш. Мәрҗанинең бу фикерләрен ул дини тәгълиматны философиядән азат итәргә теләде дип аңлаталар. (Дж. Валидов. Очерк истории образованности и литературы волжских татар. Рус телендә. 1923 ел. 36 бит.) Чынында исә, шундый нәтиҗәгә килеп, Ш. Мәрҗани, барыннан да элек, кеше акылын һәм философияне аллага хас сыйфатлар заруриятьме, әллә мөмкинлекме, алар аның эчке асылыннан килеп чыгалармы, әллә юкмы кебек мәсьәләләр белән баш катырудан азат итәргә теләде. Татар мәгърифәтчесенең бу мәсьәләгә карашы XVIII йөз рус мәгърифәтчесе Я. Козельский карашларына охшаш; ул да философияне алла һәм илаһи могҗизалар турындагы бәхәсләрдән азат итәргә тели, чөнки, аныңча, «бу нәрсәләрнең һәммәсе дәлилсез, дини инану белән кабул ителергә тиеш булганга, бу эш белән философия түгел, ә дини тәгълимат шөгыльләнергә тиеш». (И. Щипачев. Философия русского просвещения. Рус телендә. 1971 ел. 130 бит.) Ш. Мәрҗани карашынча да, кеше акылы, алла һәм ул тудырган могҗизалар турында бәхәс алып барудан бигрәк, үзенең көчен әйберләр дөньясын һәм андагы процессларны танып-белүгә юнәлтергә тиеш.

Ш. Мәрҗанинең замандашлары, аерым дини авторитетларга таянып, яшәү һәм яшәмәү, вакытның чиксезлеге һәм чиклелеге, әйбер һәм күренешләрнең барлыкка килүләре кебек мәсьәләләрне бары дингә һәм шәригатькә таянып кына хәл итеп була дип саныйлар, моңа каршы чыгучыларны дәһрилектә гаепләләр, дингә таянып, алар фәнне һәм философияне кире кагалар, ә философларны һәм галимнәрне үзләренең дошманнары хисаплыйлар. Ш. Мәрҗани мондый караш белән килешми. Аныңча, әлеге мәсьәләләрнең, динилектән тыш, фәнни-философик ягы да бар, аларны фән һәм философия күзлегеннән карап тикшергән өчен берәүне дә гаепләргә ярамый.

Ш. Мәрҗани әлеге мәсьәләләрне дини яктан да, фәнни-философик яктан да тикшерә. Ул вакытның барлыкка килүе турындагы дини карашка аеруча кискен каршы чыга. Бу төшенчә чикле әйберләрнең барлыкка килүләре турындагы мәсьәләне ике мөстәкыйль категориягә: зати барлыкка килү (хөдүс зати) һәм вакыт ягыннан барлыкка килүгә (хөдүс замани) бүлү нәтиҗәсендә туган була. Ш. Мәрҗани фикеренчә, дөньяның барлыкка килүе турындагы мәсьәлә — ул яшәешнең (вөҗүд) яшәмәүгә (гадәм) мөнәсәбәте турындагы мәсьәлә, һәм югарыдагы бүленеш әлеге бәйләнешне дин ягыннан да, фән ягыннан да аңлау өчен берни бирми. Өстәвенә, вакытның барлыкка килүе турындагы категория мәгънәсе ягыннан да акылга сыймый. «Гадәмнең (булмауның) вөҗүдкә (яшәешкә) заманда алда булуы,— ди Ш. Мәрҗани,— мәгънәсе белән хөдүс заманның үзен... эченә алмыйдыр; чөнки заманның булмавы булуыннан заман эчендә алда булса, заман барлыкка килүдән элек заман булу тиеш була, бу, әлбәттә, мөмкин булмаган нәрсәдер; әгәр «заман хыял эше вә бөек үткәне чиксез, шунлыктан аның булмавына урын кирәкми» диелсә, бу сүз һәм игътибарга лаек түгелдер, чөнки хыял эше буш уй коручыдан элек гадәм сарыф булганлыктан, аның урыны булуы, әлбәттә, мөмкин түгелдер»[1]. («Мәрҗани мәҗмүгасы». 1915. 239 бит.) Күренүенчә, Ш. Мәрҗани өчен гамәлдәге вакыттан, ягъни реаль процесслардан аерылган вакыт юк, һәм вакыттан, вакытлы әйберләрдән тыш вакыт ул — абсурд, буш хыял гына. Шуннан чыгып, ул бернәрсә яшәмәгәндә булган абсолют яшәмәүне инкарь итә.

Ш. Мәрҗани күренекле дин галиме Җәләлетдин әл-Дәванинның вакытның барлыкка килүе турындагы субъектив-идеалистик аңлатмаларын тәнкыйть итә. Әлеге дин галиме «халикъ» (иҗатчы) һәм «хөдүс» (барлыкка килү) сүзләрен куллану вакытның тууына илтә, шуннан ул безнең анда

[1] Ш. Мәрҗани һәм Ш. Көлтәси әсәрләреннән алынган өзекләрнең теле җиңеләштерелеп бирелде.— Я. А.

«урнашып кала» дип расларга маташа. Ш. Мәрҗани фикеренчә, бу — ялгыш караш, аның ни логик, ни фактик нигезе юк. «Әгәр «халикъ» вә «хәдүс» терминнарыннан кайберәүләрнең зиһеннәренә хәдүс замани килеп керсә,— ди ул,— ул бу терминнарның чын мәгънәләре шулай булудан килми, бәлки аларның шул мәгънәгә теләк белдергәнлекләреннән, аларның зиһеннәре шуннан үтмәгәнлектән киләдер. Моның мисалы шушыдыр: «өй» дип адәмнәр йоклый вә тора торган бинага әйтәләр. Инде кечкенә вә түбән өйләрне генә күргән бер авыл кешесенә «өй» диелсә, ул шундый кечкенә өйләрне генә уйлый, шәһәрләрдәге олуг, биек вә мәһабәт өйләр, падишаһ сарайлары аның зиһененә һич килмидер. Шуның кебек хәдүс терминыннан хәдүс заманины аңлаучылар да зиһеннәре тар вә фикерләре кыска кешеләрдер». (Шунда ук, 238 бит.) Күрәсез, турыдан-туры ук әйтмәсә дә, Ш. Мәрҗани вакыт категориясенең табигатен ярыйсы ук объектив төстә аңлата һәм ул хакта субъектив карашлардан чыгып фикер йөртүчеләрне чикләнгәнлектә гаепли.

Вакытның барлыкка килүе (хәдүс замани) турындагы төшенчәне кире кагып, Ш. Мәрҗани алланың җир йөзендәге барлык әйберләргә кадәр үк булуы, җир йөзендәге әйбер һәм күренешләрнең аның кодрәте белән барлыкка китерелүе турындагы дини тәгълимат белән каршылыкка керә. «Дин галимнәре мәзкүр рәвешчә галәмнең бөтен өлешләре илә хәдүсенә дәлил китергәннән соң,— дип яза ул,— әлбәттә, һәр күренешкә иҗат итүче кирәк вә ул иҗат итүче бөтен күренешләрдән алда килүче санигъ булырга тиеш, дип фикер йөртәләр һәм галәмнең санигъка ихтыяҗына нисбәте бинаның төзүчегә нисбәте төреннән диләр». (246 бит.) Ш. Мәрҗани шулай ук галәмнең аллага мөнәсәбәте турындагы мондый карашны да кире кага, аны хыял җимеше дип саный. Әмма, шул ук вакытта, ул үзе дә алланың иҗади көч булуы турындагы идеяне инкарь итми, галәм үзенең бөтен кисәкләре белән илаһи башлангычтан килеп чыга дип саный. Аның фикеренчә, алла дөнья һәм андагы күренешләрдән алда килүче зат, ләкин бу алда килүне вакыт ягыннан алда килү дип аңламаска кирәк. «Аллаһ тәгаләгә нисбәтән,— дип уйлый ул,— ераклык вә якынлык, әлек вә соңгылык, үткән, киләчәк һәм хәзер юктыр; бәлки бөтен заман вә урын, вә бөтен барлык аллаһ тәгалә каршында хәзердер; барча мөмкинат вә күренешләрнең аллаһ тәгаләгә нисбәте минимум заманда булган ноктаның нисбәте кебектер». (238—239 битләр.) Моннан күренүенчә, Ш. Мәрҗани, алла — бөтен күренешләрнең һәм әйберләрнең мәңгелек һәм чиксез башлангычы, дип саный.

Алланың асылын чагылдыручы мәңгелек һәм чиксезлек кебек категорияләр белән рәттән, тагын әле вакытлы күренешләр һәм әйберләр дә яши, өзлексез һәм тотрыклы мәңгелек башлангычтан аермалы буларак, болары өзлексез үзгәреп, яңарып торалар. Бу — кешенең эмпирик дөньясы. Һәм Ш. Мәрҗани аны шулай ук мәңгелек һәм чиксез дип саный. «Үткәндә һәм киләчәктә чиге булмаган вә туктаусыз яңаручан кисәкләрнең нәүбәтләшүе нәтиҗәсендә саклана торган өзлексез бер табигать бар»,— дип яза ул. (244—245.) Шуннан чыгып, Ш. Мәрҗани галимнәрне һәм философларны «дөнья мәңгелек» дигән өчен гаепләү нигезсез дигән нәтиҗәгә килә һәм бу караш, иҗат итүче мәңгелек башлангыч буларак, алланың дөньядан алдарак килүе турындагы идеягә һич тә каршы килми дип саный. Аның фикеренчә, өзлексез яңарып торучы табигать мәңгелек һәм чиксез илаһи затның гәүдәләнеше булып тора. Бу очракта Ш. Мәрҗани, күргәнегезчә, дин белән араны өзмәсә дә, фәнне һәм философияне, аларның әйберләр дөньясын аңлатырга, ягъни кеше акылына таянып, материаль күренешләрне аңлатырга хаклары булуын яклый.

Күренүенчә, Ш. Мәрҗани алланың иҗади башлангыч булуы турындагы идеяне, тормыштагы әйбер һәм күренешләрнең яшәве илаһи затка бәйле булуын таный. Шул ук вакытта, аның алласы табигатьтән алда килүче зат та түгел. Ул — әйбер һәм күренешләрнең һәр җирдә, һәр заманда яшәве өчен зарури булган мәңгелек һәм чиксез башлангыч. Ул үткәнне дә, киләчәкне дә һәм хәзергене дә чорнап алган һәм аның асылы һәр җирдә, һәр кайда, материаль күренешләрдә дә, рухи күренешләрдә дә гәүдәләнә. Бу — Ш. Мәрҗани философиясенең пантеистик идеяләр белән сугарылуы хакында сөйли. Билгеле булганча, пантеизм өчен илаһи затның тормыш күренешләрендә эреп бетүе характерлы. Илаһи зат һәм аның иҗаты турында сөйләгәндә, Ш. Мәрҗани дә алланың асылын һәм табигый, һәм рухи реаль күренешләрдә эретеп бетерә, ахыр чиктә алланы өзлексез яңарып торган табигатькә кайтарып

калдыра. «Безләр,— ди ул,— галәм барлык өлешләре белән күренеш, санигъ вә халикый вахид вә ул халикъ галәм барча камил сыйфатлар белән сыйфатланган, мәхлукатларда булган кимчелекле сыйфатлардан пакь вә чиста булуга икътикад кылабыз». (246 бит.)

Ш. Мәрҗани мөселманнар арасында яшн һәм дини белем ала. Ә мөселман дөньясында суфичылык идеологиясе белән бәйләнгән пантеизм шактый киң таралган күренеш була. Алла дөньяны барлыкка китергән көч дип тану белән бергә, суфилар галәмне чиксез һәм мәңгелек дип саныйлар. Ә ул, алар фикеренчә, илаһи затның гәүдәләнеше булганга шулай мәңгелек; башы да, ахыры да булмаганга, ул алланы сыйдыра торган бер урын ролен үти. Алла бөтен табигатьне үтеп чыга, аның белән без һәр җирдә, һәр кайда очрашабыз. Ул — нурлары өзлексез агып, материаль әйберләр төсендә гәүдәләнә торган яктылык чыганагы. Димәк, алла галәмнән аерылган зат түгел, ә табигать күренешләрендә гәүдәләнә торган мәңгелек һәм чиксез башлангыч. Ш. Мәрҗанинең дә алла һәм галәм турындагы карашлары шундый ук. Суфилар кебек үк, ул да алланы күктән җиргә төшерә, галәм эчендә таралып бетәргә мәҗбүр итә. Суфилар кебек үк, аның өчен дә дөнья вакыт агымыннан түгел, ә үзенең заты белән генә алладан соң санала.

Күпчелек суфилар өчен пантеизм рәсми дини тәгълиматка каршы көрәштә идеологик корал һәм хөр фикерлелекнең яшерен формасы була. Әмма, тулаем алганда, суфизм идеяләре мистицизмны, дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичүне, аскетлыкны һәм төшенкелек настроениеләрен алга сөрү белән бәйләнгән. Суфилар кешене алла белән ялгыз калырга чакыралар, шуның белән бергә кеше акылын һәм аның тормышны танып-белүдәге һәм үзгәртеп корудагы көчен инкарь итәләр. Ш. Мәрҗанинең пантеистик идеяләре исә хакимлек итүче дини карашны фаш итүнең, караңгылыкка һәм торгынлыкка каршы көрәшүнең, иҗтимагый прогрессны, фәнне һәм фәнни белемнәрне пропагандалауның бер формасы булып тора. Шул идеяләргә таянып, ул кеше акылын азат итәргә, иҗади фикерне киректсез һәм файдасыз бер нәрсәгә әйләндергән богауларны өзеп ташларга тырыша.

Философия тарихында философик тәгълиматларның объектив эчтәлеге еш кына аларның субъектив формасыннан нык аерылып тора. Күп кенә философик карашларның шул үзенчәлегенә басым ясап, К. Маркс болай ди: «Хәтта, Спиноза кебек, үз хезмәтләрен системалы бер формага салган философларда да системаның чын эчке төзелеше формасыннан бөтенләй аерылып тора...» (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. 29 том. 457 бит.) Шуңа күрә, «һәм прогрессив, һәм реакцион философик тәгълиматларның объектив эчтәлеген аларның субъектив тәгъбир ителү формаларыннан катгый төстә аерып өйрәнү марксистик-ленинчыл анализның төп бер принцибы булып тора». («Методологические вопросы общественных наук» исемле җыентык. 1966 ел. 395 бит.) Ш. Мәрҗанинең дөньяга карашын бәяләүгә дә без тарихи-философик тикшеренүнең нәкъ шул принцибы белән якын килергә тиешбез. Күпчелек очракларда ул да үзенең карашларын дини тышча ярдәмендә белдерә. Әмма аның тәгълиматының объектив эчтәлеге әлеге тар тышча эченнән бик нык читкә чыга һәм прогрессив характер ала. Традицион дини тәгъбирләр кысасында ул шул ук традицияләрне җимерүгә юнәлдерелгән яңа фикерләр әйтә. Аның практик акылы яшәешнең асылы, мәңгелек һәм вакытлы әйберләрнең үзара мөнәсәбәте кебек мәсьәләләр буенча дини карашның догматик принциплары белән килешә алмый. Традицион дини кысаларны ватып чыгып, ул дөньяга караш мәсьәләләрен фәнни аңлатуга таба беренче әһәмиятле адым ясый, әйбер һәм күренешләр дөньясының чикләнмәгән булуын, мәңгелеген, аларның материаль җирлеген таный.

Чынбарлыктагы әйбер һәм күренешләр хакында сүз барганда, Ш. Мәрҗани табигатьнең үзеннән чыгып эш итәргә, алар яшәешенең объектив нигезләрен ачыкларга тырыша. Әйтик, җан турында сөйләгәндә, ул аның барлыкка килүен һәм үсешен тере организмның үсеше белән бәйләп аңлата, шул рәвешчә, үзенең үк табигатьтән тыш мәңгелек һәм космик рухи башлангыч бар дигән карашлары белән каршылыкка керә. һәм җанга организм эшчәнлеге белән бәйләнгән функцияләрне йөкли. Күренешләрне өйрәнүнең методологик нигезе сыйфатында Ш. Мәрҗани сәбәплелек принцибын күтәреп чыга. Тарих фәненең бурычы, мәсәлән, тарихи процессларның асылын һәм мәгънәсен ачудан, тарихи вакыйгаларның алмашынуларын ачыклаудан гыйбарәт. «Эчтән ныклап уйласаң,— ди ул,— тарихның төбе тирән хикмәтка

ирештерә торган тикшерү һәм җентекләү. Чөнки ул вакыйгаларның ни рәвешле булганлыкларын, тирән сәбәпләрен, барның ник бар булуын һәм аның нечкә нигезләрен ача». (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы. 22 фонд. 1 тасвирламә. Саклау берәмлеге 20. 52—53 битләр.) Тарихи вакыйгаларны тикшергәндә, ди ул, иҗтимагый-политик шартларны, әлеге вакыйгаларны тудырган объектив һәм субъектив факторларны исәпкә алырга кирәк.

* * *

Ш. Мәрҗанинең философик идеяләрен пропагандалау эшен алга таба Ш. Көлтәси[1] дәвам иттерә. Дөньяга караш мәсьәләләрен хәл иткәндә, ул әйбер һәм күренешләрнең объектив төстә яшәвеннән, аларның катлаулы табигатеннән һәм күп төрле үзенчәлекләргә ия булуларыннан чыгып эш итә. «Киң һәм чиксез пространствода күренгән кояш, ай, җир, планеталар вә йолдызлар шулай ук җирдәге һәм күктәге башка җисемнәрнең барысына,— ди ул,— галәм табигать диелер». (Ш. Көлтәси. Хикмәте җәдидә. Казан. 1899. 18 бит.) Кеше күзәтә һәм үзенең хисләре белән кабул итә торган дөньяны ул шулай ук материаль дөнья дип атый. «Бөтен галәмнең асыл нигезе һәм чыганагы,— дип яза Ш. Көлтәси,— ике шәйдер: берсе матдә вә бере шул матдәдәге хәрәкәттер». (Ш. Көлтәси. Һәйяте җәдидә. 1896 ел. 8 бит.) Беренчел матдә бик вак кисәкләрдән — атомнардан тора һәм үзлексез хәрәкәт итә. Материянең үзлексез хәрәкәте әлеге вак кисәкләрнең табигатеннән килеп чыга. Хәрәкәт процессында бергә укмашып, алар җир һәм күк җисемнәрен барлыкка китерәләр. Соңгылары (ягъни күк җисемнәре), материянең вак кисәкләре кебек үк, үзлексез хәрәкәт итәләр, бездән бик ерак булганга гына без аларның хәрәкәтен сизмибез.

Ш. Көлтәси үз алдына җанлы һәм җансыз табигатьнең барлыкка килү һәм яшәү закончалыкларын ачыклауны максат итеп куя. Бу мәсьәләне хәл иткәндә, ул, чынбарлыкны шактый гадиләштереп аңлатса да, алланы бөтенләй читләтеп үтә. Аның фикеренчә, җанлы табигатьтәге җисемнәр дә, җансыз табигатьтәге җисемнәр дә материянең иң вак кисәкләреннән — атомнардан торалар, ул атомнарның нигезләре охшаш, бер-берсеннән алар формалары белән генә аерылалар. Аларның беришләренең өслеге кабарынкы, икенчеләренеке батынкы. Шуның аркасында алар бер-берсенә ябышып бетмиләр һәм шул ук вакытта үзара бәйләнештә яши алалар. Җисемнәрне ясый торган атомнарның формасы аларның гомуми сыйфатын да, аерым үзенчәлекләрен дә билгели. Көлтәсинең җисемнәрнең барлыкка килүләрен бу рәвешчә аңлатуы аңа Эпикур философиясеннән башланып киткән карашларның тәэсире булуы турында сөйли.

Дөньяны һәм аның күренешләрен шул рәвешчә аңлатуыннан чыгып, Көлтәсинең дөньяга карашы материалистик характерда дип әйтергә булыр иде. Ләкин әлеге карашны уздырганда, Ш. Мәрҗани кебек үк, ул да ахырга кадәр эзлекле түгел һәм алланы мәңгелек, чиге булмаган, зарури башлангыч дип саный һәм аның материаль әйберләрдән алда килүен таный. Ул тормыштагы әйбер һәм күренешләрнең материаль нигезе, аларның үзенчәлекләре, үсешкә сәләтләре һәм тенденцияләре алла тарафыннан билгеләнгән дип саный. Шул ук вакытта алланы ул беренчел этәргеч көч төсендә генә аңлый; алла дөньяга һәм аның күренешләренә тормыш биргән, ә соңыннан ул табигатьтәге процессларга катнашмый. «Бу мөмкинлек дөньясындагы һәр нәрсә фәкать алла кодрәте белән бар-

---

[1] Көлтәси Шәмсетдин Мөхәммәт бине Нурмөхәммәт әт-Таһири 1856 елда Күлтәс авылының (Арча районы) имамы һәм мөдәррисе гаиләсендә туа. Башлангыч белемне атасыннан ала, аннан Курса һәм Түнтәр мәдрәсәләрендә укый. Бер үк вакытта ул рус телен дә яхшы үзләштерә. Патша армиясендә хезмәт итеп кайтканнан соң, бер фабрикантта управляющий булып эшли. Әтисе үлгәч, Күлтәстә имам була.

Бер үк вакытта, әтисе кебек үк, укытучылык эшен дә алып бара. Дин сабакларыннан тыш, балаларны математика нигезләре белән таныштыра, хисап эшенә өйрәтә, тарих, география, әдәбият фәннәрен укыта, рус теленнән дә дәресләр бирә.

XIX йөзнең ахырларында һәм XX йөзнең башларында Көлтәси фәнни белемнәрне һәм философик идеяләрне пропагандалау буенча зур эш башкара. «Һәйяте җәдидә» (1896), «Хикмәте җәдидә» (1899) һәм «Мөфассал һәйяте җәдидә» (1900) кебек хезмәтләрендә ул дини тәгълиматны тәнкыйть итә, философик идеяләрне һәм табигый белемнәрне популярлаштыра. «Хәлемездин шикаять», «Көйле иман», «Мәктәп баласы яхут Сәхилә әбы» кебек китапларында яңача укыту ысулларын яклап чыга. Аның бу хезмәтләре реакцион карашлы кешеләрнең кискен каршылыгына очрый. Патша охранкасы да алардан калышмый. Күрәсең, шулар тәэсирендәдер, 1908 елдан соң ул язу эшен ташлый.

Октябрь революциясе көннәре җиткәндә, Көлтәси хәлсез һәм авыру карт була. Революция вакыйгаларына турыдан-туры катнаша алмый. Шулай да кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Мәктәп эшләрен юлга салуда булыша, киңәшләр бирә. Шәмсетдин Көлтәси 1932 елда үлә.

лыкка кила». (Ш. Колтаси. Хикмәте җәдидә. 38 бит.) Табигатьтәге шуннан соңгы процесслар исә тормышның үз законнары буенча бара. Алланың чынбарлыкка мөнәсәбәтен аңлатуда Ш. Көлтәси, күргәнегезчә, деизм позицияләрендә тора. Философия тарихында бу позиция еш кына чынбарлыкка материалистик якын килүнең һәм хакимлек иткән дини-идеалистик карашка каршы көрәшнең бер формасы булып тора. Көлтәсидә ул шулай ук дөньяны аллаһ тәгалә барлыкка китергән дигән дини караштан арынуда мөһим бер адым булып тора. Деизм идеясенә таянып, Ш. Көлтәси тормыштагы әйбер һәм күренешләрне аларның үз эчке табигатеннән чыгып һәм сәбәплелек принцибына нигезләнеп аңлатырга кирәк дигән фикерне раслый. «Бу дөнья сәбәпләр дөньясыдыр,— ди ул,— сәбәпләр дөньясында һәр шәй бер ачык сәбәпкә бәйләнгәндер». (Шунда ук, 38 бит.) Күренешләрнең сәбәпләрен өйрәнеп, кеше әйберләрнең табигатен һәм галәмнең серләрен ача һәм андагы көчләрне үзенә хезмәткә җигә. «Галимнәр һәм философлар,— ди Ш. Көлтәси,— күз алдымызда туктаусыз булып торган табигый яңарышлар һәм үзгәрешләрнең асыл сәбәпләрен ачып, аларны файдалану юлларын күрсәтәләр». (Шунда ук, 39 бит.) Алга таба ул бу фикерен медицина өлкәсеннән алган мисаллар белән беркетә, врачлар, организмдагы төрле факторларның бер-берсенә тәэсирен өйрәнеп һәм андагы үзгәрешләрнең сәбәпләрен ачыклап, дәвалау юлларын билгелиләр һәм уңышка ирешәләр, ди.

Ш. Мәрҗани кебек үк, Ш. Көлтәси дә мөселман динен һәм шәригать законнарын таный. Шул ук вакытта, үзенең элгәре кебек үк, ул дөньяның юктан бар булуы, яшәүнең вакыт ягыннан чикләнгән булуы турындагы дини тәгълиматтан кискен баш тарта һәм аның мәңгелек, чикләнмәгән булуы турындагы идеяне яклап чыга. Өзлексез хәрәкәт итүче беренчел материя, дип яза ул, мәңге яши һәм аның булмавы вакыт ягыннан яшәвеннән алда килә алмый. Вакыт — хәрәкәтнең төп үлчәве һәм яңару процессының чагылышы. Ә хәрәкәт һәм яңару, шуннан чыгып вакыт та, материаль әйберләрнең үзлеге булып тора. Әгәр шулай икән, аның мәңгелек һәм беренчел материягә мөнәсәбәттә вакыт ягыннан алдан килүе — мәгънәсезлек. «Бөек һәм мәңгелек матди дөнья каршында заман, хәрәкәт вә озынлык кебек җисем үзенчәлекләрендә булган нәрсәләрнең беренчелеге мөхаль, сирәк очрый торган мөхальдер. Чөнки моның кебек җисем үзенчәлекләреннән булган нәрсәләрнең җисемнең үзеннән башка булулары мөмкин түгел». (Ш. Көлтәси. һәйяте җәдидә. 51 бит.) Тулаем алганда, дөнья мәңгелек һәм чиксез, мөмкинлекләр дөньясының аерым объектлары гына чикле була, дип раслый Ш. Көлтәси. Әйтик, күк җисемнәре хәрәкәтнең имманент законнары нигезендә барлыкка киләләр, аннары, шул законнарның көче тәэсирендә, юкка чыгалар, ахырдан беренчел материянең тузаннарыннан яңадан-яңа йолдызлар, кояш һәм планеталар барлыкка килә. Имам Газали сөйли торган кыямәт көне һәм яңадан терелү галәмдә материаль әйберләр барлыкка килү һәм җимерелүнең мистификациясе генә.

Вакыт ягыннан мәңгелек һәм чиксез булган кебек, дөнья пространство җәһәтеннән дә очсыз-кырыйсыз. Фәнни приборлар ярдәмендә кеше җирдән меңнәрчә яктылык елы ераклыгында булган йолдызларны һәм йолдыз системаларын ачты, ләкин бу әле кеше бөтенесен белде, дөньяда ул белмәгән әйбер юк, дигән сүз түгел, ди Ш. Көлтәси. Галәм һич кенә дә галәм киңлекләрендә бик аз урын биләп торган затның белгәннәре белән генә чикләнә алмый. «Инсаннарның бөтен мәгълүматлары илә бәрабәр ике ниһаятьсезлекнең арасында калдыклары аңлашылыр. Бу ниһаятьсезлекләрнең бере күккә юнәлгән булса, икенчесе атомнар дөньясына юнәлгән». (Ш. Көлтәси. Мөфассал һәйят җәдидә. 91 бит.)

Пространство һәм вакыт, дөньяның чиксезлеге һәм чикләнгән булуы кебек мәсьәләләрне тикшергәндә, шулай ук башка очракларда да, Ш. Көлтәси философиясенең эзлексез булуы сизелә. Ул материаль дөньяның нигезе мәңгелек һәм чиксез булуы турында сөйли, шул ук вакытта аны ул материядән дә, вакыттан да, пространстводан да өстен булган абсолют көчкә бәйле дип саный. Дөньяның вакыт һәм пространство ягыннан чиксез булуын дәлилләү өчен, ул абсолют көчнең мәңгелек һәм чиксез булуын мисал итеп китерә. Яңа йолдызларның барлыкка килүләрен, ә икенчеләренең юкка чыгуын ул шулай ук абсолют көчнең ихтыярына бәйли. Әмма шул ук вакытта күк җисемнәренең барлыкка килүләрен һәм юкка чыгуларын ул детерминизм позицияләреннән чыгып та аңлата һәм бу очракта табигатьнең үз законнарына таяна.

Галәмдәге һәм җирдәге процессларны да ул объектив законнарның көче белән, детерминизм позицияләреннән торып аңлата. Бөтен бер дөнья буларак, кояш системасының яшәвен ул тартылу һәм эзелү көчләренең үзара мөнәсәбәте белән, ә кояштагы нур энергияләренең таралуын аның эчендәге материаль процесслар белән бәйли. Кометалар, метеоритлар һәм башка космик объектларның барлыкка килүләрен дә шул ук процессларга бәйләп карый. Сәбәплелек принцибын Ш. Көлтәси иҗтимагый-политик теорияләрне һәм әдәби әсәрләрне аңлату өчен дә куллана.

* * *

Дөньяга караш мәсьәләләренә татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле К. Насыйри да (1825—1902) зур игътибар бирә. Дөрес, аның философиягә багышланган махсус хезмәтләре юк. Дөньяга караш мәсьәләләрен ул иҗтимагый тормышның һәм фәннең башка мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрендә кузгата. Теләсә кайсы мәсьәләне тикшергәндә ул аның философик ягына да басым ясый һәм аны тиешле философик тирәнлектә аңлата.

Татар мәгърифәтчелегенең башка вәкилләре кебек үк, дөньяга караш мәсьәләләрен хәл иткәндә, К. Насыйри ахырга кадәр эзлекле түгел, аңарда тикшерә торган мәсьәләләргә материалистик бәя бирү идеалистик чигенүләр белән аралашып бара. Ул, дөньяны барлыкка китерүче көч буларак, алланы таный һәм дөнья күренешләрен алла ихтыярына бәйләп аңлата, Корьәнгә һәм шәригать законнарына таяна. Инде сүз турыдан-туры иҗтимагый тормыш, фән һәм мәдәният мәсьәләләре турында барганда, табигатьтәге конкрет процессларны аңлатырга кирәк булганда, ул стихияле материалист буларак фикер йөртә. Үзенең хезмәтләрендә ул материаль чынбарлыкның бик күп якларына туктала һәм аларны хәрәкәттәге материянең бер чагылышы итеп карый, табигать күренешләрен ничек бар шулай аңлата, аларның яшәү һәм үсеш закончалыкларын ача. Чынбарлыкка якын килүнең иң төп принциплары төсендә ул сәбәплелек принцибын ала. «Ошбу дөнья галәм әсбаб булып,— ди ул,— һәр бер мәтлуб вә мәкъсуд бер сәбәпкә бәйләнгән булып, серләрне белү адәмнең уйлау-төшенүеннән чыкканлыктан, сәбәпкә тотынмакка вә сәбәпнең хикмәтен инкарь кыйлмаса кирәктер. Ирену вә ялкаулык белән... сәбәпкә һәм һөнәргә тотынмыйча тәкъдиргә ышанып яту бик зур әшәкелек һәм оятсызлыктыр». (К. Насыйри. Фәвакиһелҗөләса. Казан. 1884. 93 бит.) һәр күренешнең нигезендә берәр сәбәп ятканлыктан, алладан рәхим-шәфкать көтеп ятмаска кирәк, ә актив төстә хәрәкәт итәргә һәм кешеләргә файдалы нәтиҗә бирерлек көчләрне хәрәкәткә китерергә кирәк.

К. Насыйриның күренешләрнең объектив нигезен ачарга омтылуы табигать мәсьәләләренә генә түгел, ә иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә якын килүендә дә күренә. Аның фикеренчә, иҗтимагый тәртипләр һәм законнар халыкларның ничек яшәвенә бәйләнгән. «Низамнар, законнар күбрәк халыкның гадәтеннән, мөгамәләсеннән истихраҗ кылыналар». (К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан. 1953 ел. 87 бит.)

Кеше аңының табигатен һәм аның чынбарлыкка мөнәсәбәтен аңлау мәсьәләсендә дә К. Насыйри стихияле материализм позицияләрендә тора. Аныңча, аңның, кеше акылының нигезендә табигать һәм кешенең иҗтимагый тормышы ята. Алай гына да түгел, табигать тарафыннан бирелгән кадәресе кеше акылының даими нигезе булып тора, ә кешенең җәмгыятьтәге тормышы белән бәйләнгән кадәресе, тәҗрибәгә һәм иҗтимагый бәйләнешләргә карап үзгәрә тора. «Мәгълүм ула ки,— дип яза К. Насыйри,— гакыл ике кыйсем үзрәдер: бер кыйсеме артмак вә кимемәкне кабул итмәс. Моны гакыл табигый диләр. Бу гакыл табигый барлык гакыл ияләре арасында мөштәрәктер. Икенче кыйсеме гакыл тәҗрибәи тәсмия кылыныр ки, артмак вә кимемәкне кабул итәдер, вә артмаклыгы тәҗрибәдән киләдер. Мәсәлән, вакыйгаларны вә хадисләрне тәкрар-тәкрар тәҗрибә итмәк белән гакылга күплек һәм камәләт хасыйл булыр. Бу сәбәптән гакыл табигый иясе булган карт вә гомер иткән кешенең гакыл вә дәрайяте камилрәктер». (К. Насыйри. Фәвакиһелҗөләса. 59 бит.) Кеше акылының үсешенә ул тагы аралашуның тәэсире булуын күрсәтә.

Кеше мие аң, фикер органы булып тора. «Ми — гакыл вә тойгы әгъзасыдыр». (К. Насыйри. Мәнафигъ әл-әгъза вә канун сыйхәт. Казан. 1883 ел. 42 бит.) Әмма шул ук вакытта ул кеше аңының матди характерда булмавын әйтә. Аны күреп тә, тотып та карап булмый. «Гакыл дигән нәрсә адәмдә бер әмер мәгънәвидер, күз белән

күреп бу кешедә гакыл бар дип әйтергә мөмкин түгел. Ләкин бер адәмдә гакыл камил барлыгын аның фигыльләреннән вә холыкларыннан гына чыгып белеп буладыр». (К. Насыйри. Фәвакиһелҗөләса. 60 бит.) Шуның белән бергә, К. Насыйри өчен кеше аңы табигый-биологик субстратның һәм тәҗрибә белән тупланган белемнәрнең пассив җимеше түгел. Кеше тормышында ул актив роль уйный. «Гакыл адәмнең бәдәнендә падишаһ ролендә һәм адәмнең күркәм фигыльләре вә күркәм холыклары рәгыйять мәнзилендәдер. Әгәр гакылда зәгыйфь пәйда булса, күркәм фигыльләргә кимчелек киләдер. Гакылның кулы нәфеснең тезгенен тотар, аны яман юлга җибәрмәс». (Шунда ук, 61 бит.) Алга таба ул акыл кеше эшчәнлегенең нәтиҗәләрен күрә, аңа юнәлеш бирә, аны куркынычлардан саклый һәм дөрес юл күрсәтә, ди. Күргәнегезчә, К. Насыйри аңның табигыйбиологик нигезен дә, аның кешенең тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле булуын, материаль әйберләрдән аермасын һәм кеше тормышындагы актив ролен дә дөрес билгели, ә аның эчтәлеген һәм үсеш дәрәҗәсен кешенең практик эшчәнлегенә бәйләп аңлата. Дөрес, тәҗрибә, практика кебек төшенчәләрне ул таррак аңлый, аларны иҗтимагый җитештерү белән түгел, ә ялгыз индивидның эшчәнлегенә генә кайтарып калдыра. Аннары, аңны ул иҗтимагый байлык итеп түгел, индивидуаль күренеш буларак кына тикшерә. Әмма аңның табигый-биологик нигезенә, аның формалашуында кешенең иҗтимагый бәйләнешләре, тәҗрибәсе һәм практик эшчәнлегенең әһәмиятенә басым ясау үзе үк инде татар иҗтимагый фикеренең мөһим казанышы булып тора.

Чынбарлык процессларын һәм күренешләрен диалектик аңлау К. Насыйриның дөньяга карашына хас бер үзенчәлек булып тора. Аныңча, әйбер һәм күренешләргә капма-каршылык хас. «Дөнья бер үлчәү кебектер, бер башы никадәр авыр булса, икенче башы шул кадәр җиңел киләдер». (Шунда ук, 170 бит.) Тагын шундые бар, капма-каршылыклар гел үзгәреп торалар. Бүген яхшы булып тоелган әйбер иртәгә начарга әйләнергә мөмкин һәм, киресенчә, явызлык вакытлар узу белән яхшылыкка әйләнергә мөмкин. Ул әйберләрнең үзгәреп торуын, өзлексез хәрәкәт итүен һәм үсүен дөрес аңлый. Табигать күренешләрен тикшергәндә, К. Насыйри аларның закончалыклы бәйләнешенә, берберсе белән бәйләнештә булуларына игътибар итә, табигатьтәге хайваннар дөньясы, үсемлекләр, һава, җылылык, дым һәм кояш үзара бәйләнгән һәм бу бәйләнеш терекнең төп шарты, ди. Аның фикеренчә, кеше организмы белән аны чолгап алган тирәлек арасында да шундый ук бәйләнеш яши. «Һәркем — ди ул,— үз җиренең һавасына һәм табигатенә яраклашканлыктан, ул җирдә үскән нәбатат аның табигатенә муафыйк һәм сырхавена килешәрәк бирәдер. (К. Насыйри. Гөлзар вә Чәмәнзар. Казан. 1903 ел. 3—4 битләр.) Шуннан чыгып ул практик нәтиҗәләр ясый. Кеше организмы үз ягының табигатенә яхшырак җайлаша һәм туган якның үсемлекләре аның организмына шифалы йогынты ясый икән, читтән китерелгән дарулар белән мавыгырга кирәкми, җирле үсемлекләрнең үзлекләрен ныграк өйрәнергә һәм авыруларны дәвалаганда шуларны файдаланырга кирәк, ди.

* * *

Дөньяга караш мәсьәләләрендә Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Ш. Көлтәсиләр сайлаган юлны урта гасырлардан калган дини-идеалистик карашны җимерүгә һәм татар иҗтимагый фикерендәге рационализм агымын ныгытуга юнәлдерелгән бер форма һәм алга таба ныклы бер адым дип бәяләргә кирәк. Бу юл, мөселман диненең дөньяга караш мәсьәләләрен һәм схоластиканы рационалистик тәнкыйтьләү аша, чынбарлыкны фәнни-материалистик аңлатуга алып килә. Чынбарлыкны шулай аңлатуга башлангыч адымны алдынгы иҗтимагый фикернең күренекле вәкилләре үзләре ясадылар. Тормыштагы әйберләр һәм күренешләр турында сүз барганда, алар турыдан-туры табигатьнең үзенә мөрәҗәгать иттеләр, һәм дөнья кеше ихтыярына бәйсез, объектив төстә яши, табигать үз законнары буенча үсә дип санадылар. Аларның хезмәтләрендәге әлеге стихияле материалистик төшенчә чынбарлыкка диалектик мөнәсәбәт белән аралаша. Алар күзаллавынча, дөнья ничек бар шулай тормый, ә өзлексез үсеш һәм хәрәкәт хәлендә. Дөньядагы әйбер һәм күренешләр даими яңарып торалар, үзара бәйләнгәннәр, берсе икенчесенә күчә. Шул ук вакытта алар материаль әйберләрнең үсешенә һәм хәрәкәтенә, аларның гомуми бәйләнешенә һәм бер-берсенә бәйле булуына объектив аңлатма эзлиләр. Чынбарлык

күренешләренә шулай якын килү татар мәгърифәтчелегенең башка вәкилләренә дә хас.

Әмма татар мәгърифәтчеләренең дөньяга карашындагы бу линия ахырга кадәр җиткерелми, ә дини-идеалистик чигенүләр белән аралаша. Дөньяга караш мәсьәләләрен чишүдәге мондый эзлексезлек һәм икеләнү барыннан да элек мәңгелек һәм чиксез иҗади башлангыч итеп алланы санауда һәм аның дөнья күренешләреннән өстен булуын тануда күренә. Ләкин шул ук вакытта аларның алласы диндәге һәм дини тәгълиматтагы алла белән бер үк нәрсә түгел. Ул — табигатьтән аерылган хөкемдар түгел, ә предметлар дөньясында һәм аның процессларында гәүдәләнгән иҗади башлангыч. Алла затын шулай аңлату Ш. Мәрҗанидә алланы пантеистик күзаллау, Көлтәсидә исә деистик аңлауның чагылышы булып тора.

Дөньяга караш мәсьәләләрен хәл иткәндә мондый эзлексезлек — философия тарихында еш очрый торган күренеш; ул үткәннең прогрессив карашлы күп кенә фикер ияләренә хас. «Билгеле ки, Маркска кадәр бер генә фикер иясе дә эзлекле материалист булмады һәм була да алмый иде. Ә XVIII йөзнең бөек француз материалистларына кадәр материализм (атеизм кебек үк) пантеизм, деизм кебек аңа якын, әмма һич тә тәңгәл булмаган формаларда һәм төрле натуралистик карашларда чагылды һәм һәрвакыт рационализм белән бәйләнгән иде». («Вопросы философии» журналы. 1968 ел. 4 сан. 112 бит.) Дөньяга караш мәсьәләләрен чишүдә татар мәгърифәтчеләренә хас дини-идеалистик ташламалар, югарыда күрсәтелгәнчә, рационализм белән бәйләнгән иде, ә алланың асылын һәм аның чынбарлыкка мөнәсәбәтен пантеистик һәм деистик аңлату чынбарлыктагы әйбер һәм күренешләрнең объектив нигезен, анда барган процессларның закончалыкларын ачыкларга мөмкинлек бирде.

Алдынгы фикер ияләренең дөньяга караш мәсьәләләрен хәл иткәндә эзлексезлек һәм икеләнү күрсәтүләре экономик үсешнең һәм сыйнфый мөнәсәбәтләрнең өлгереп җитмәгән булуы белән аңлатыла. «Капиталистик җитештерүнең өлгереп җитмәгән чорына, өлгереп җитмәгән сыйнфый мөнәсәбәтләргә,— ди Ф. Энгельс,— өлгереп җитмәгән теорияләр туры килә. Әлегә тиешле үсеш алмаган экономик мөнәсәбәтләр эчендә яшеренгән иҗтимагый мәсьәләләрне чишү юлын баштан уйлап чыгарырга туры килә». (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. 20 том. 269 бит.) Татар мәгърифәтчелегендәге дөньяга караш мәсьәләләрен чишүдә эзлексезлек, дингә һәм идеализмга ташлама ясаулар, шулай ук халыкның иҗтимагый аңында дини идеологиянең көчле позиция тоту белән бергә, татарлар арасына капиталистик мөнәсәбәтләрнең йомшак үтеп керүе һәм сыйнфый мөнәсәбәтләрнең өлгереп җитмәгән булуы белән аңлатыла.

Мондый шартларда татар мәгърифәтчеләре иске дини традицияләрдән тулысынча котыла алмадылар һәм еш кына үзләренең фикерләрен дини пәрдәгә төреп бирделәр. Әмма алар тәгълиматының эчтәлеге үзләренең формасыннан күп мәртәбә баерак иде. Шәрыктагы иҗтимагый-политик һәм философик фикернең үсеш үзенчәлекләренә тукталып, «Правда» газетасы болай язды: «Күп кенә тәгълиматларның (гандизм, суньятизм һ. б.) дини-идеалистик һәм деистик формалары артындагы эчтәлекләренә тарихи прогрессив философик һәм социологик карашлар яшеренгән». Шуның кебек үк, татар мәгърифәтчеләре таянган дөньяга караш принципларының эчтәлеге дә, гадәти, традицион дини калыпта язылуларына карамастан, прогрессив иде, алар искелекне, дөньяга феодаль карашны фаш иттеләр һәм кешеләрнең игътибарын фәнгә юнәлттеләр. Бу нәрсә урта гасырчылыкны һәм тормыштагы иске тәртипләрне яклаучыларның игътибарыннан читтә кала алмады. Алар үзләренә нинди куркыныч килүен тиз аңладылар һәм өерләре белән мәгърифәтчеләр өстенә ябырылдылар. Мәңгәр мулласы Шаһиәхмәт Мөхәммәдиев «Бәянелхак» исемле хезмәтендә болай язып чыкты: «Мәшһүр Шиһабетдин әл-Мәрҗани мөхәкъкыйк әл-Дәванинең шәрех газдиясенә хәшия тәртип итеп, хедүс галәмнең зарурәт диниядән булуына инкарь кылды... Аңа таянып иярченнәре һәм дуслары кыйдәм галәм турында сөйли башладылар. Хәттә бәгъзеләре (сүз Ш. Көлтәси турында бара — Я. А.) төрки рисаләләр тәэлиф итеп философларның галәмнең мәңгелегенә китергән дәлилләрен катгый аргумент урынына кулланып, әһел исламның кыйдам галәмгә инкарьларын тискәрелек һәм фанатизм дип юрады». (Ш. Мөхәммәдиев, «Бәянелхак». Казан. 1898 ел. 2 бит.) Мәкалә авторы Ш. Мәрҗани, Ш. Көлтәси һәм аларның фикердәшләренең дөнья юктан

бар булган дигән карашны кире кагуларын зур гөнаһ дип саный һәм аларны моггәзиләләр, мөнафикълар дип атый. Бу мәкалә ул вакыттагы кара көчләрнең уртак позициясен чагылдыра. Кара көчләрнең бернинди каршылыкларына да карамастан, мәгърифәтчеләрнең алдынгы карашлары татар халкы арасында яклаучылар табуын, киңрәк тарала баруын Ш. Мөхәммәдиев үзе дә танырга мәҗбүр була. Аларны нәкъ энә шул хәл куркыта да.

Гомум кешелек күләмендә алганда, татар мәгърифәтчеләре күтәргән мәсьәләләр философик фикер үсешендә яңа сүз түгел иде, билгеле. Дөньяга караш мәсьәләләрен хәл итүгә килүдәге рационализм да, татар мәгърифәтчеләренең карашларына хас булган пантеизм һәм деизм да философик фикер үсеше тарихында шактый озын юл узган күренешләр. Әмма XIX йөздәге татар тормышы шартларында алар актуаль яңгырадылар һәм халык аңын дини карашлар йогынтысыннан азат итүдә мөһим роль уйнадылар. Әлеге карашлар татар тормышындагы конкрет ихтыяҗларга җавап төсендә тудылар, татар мәгърифәтчелегендә шул чор татар тормышы өчен актуаль булган мәсьәләләр күтәрелде һәм хәл ителде. Шуңа күрә әлеге дөньяга караш мәсьәләләре, барыннан да элек, милли әһәмияткә ия. Шуның белән бергә, алар региональ әһәмияткә дә ия. XIX йөздәге татар мәгърифәтчеләре алдында торган мәсьәләләр Россия территориясендәге бөтен мөселман халыклары өчен уртак иде, ә татар халкы ул халыклар белән экономик һәм рухи җепләр белән бәйләнгән иде. Шул бәйләнешләр аркасында, әлеге халыкларның берсендә туган карашлар башкаларның да уртак байлыгына әйләнә барды. Бу җәһәттән алдынгы карашлы татар галимнәренең дөньяга караш идеяләре дә чыгарма түгел иде, алар бер татарларның гына түгел, ә күп халыкларның тормышында әһәмиятле роль уйнадылар. Алар массаларның аңы уянуга этәргеч ясадылар, хезмәт ияләренең игътибарын алдынгы культурага юнәлттеләр, феодаль реакциягә һәм клерикаль карашларга каршы көрәшне җәелдерергә ярдәм иттеләр.

## *ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ*

**Фатыйма Ибраһимова**

# ЗАМАН ТЕМАСЫ ӨЧЕН

*Бүгенге проза турында сөйләшәбез*

„Казан утлары" журналы хәзерге проза турында сөйләшү башлап җибәргәч, мин 1970—1971 елларда балалар өчен язылган хикәя һәм повестьларны күздән кичердем. Ул әсәрләрдә илебезнең үткәне, бүгене, әти һәм абыйларыбызның ирек өчен, бәхет өчен героик көрәшләре сурәтләнә. Ләкин мин бу мәкаләдә бүгенге татар балалар прозасын, аның хәл ителергә тиешле проблемаларын тулы яктыртуга алынмыйм, әсәрләрне уку барышында туган һәм аеруча күңелне борчыган бер-ике моментка гына тукталып үтмәк булам. Шуларның беренчесе — прозада бүгенге көн темасы, аның әдәби гәүдәләнеше мәсьәләсе.

Хәзерге әдәбиятта бу теманы ике төрле аңлату бар. Берәүләр аның мәгънәсен артык киңәйтәләр. Заман темасы дигәндә һәммәбезне дулкынландырырлык мәсьәләләрне яктырткан барлык әсәрләрне күз алдында тоталар. Икенчеләре моңа бүгенге көнне чагылдырган әсәрләрне генә кертәләр. Без үзебез соңгысы ягында торабыз. Чөнки беренчесендә, әсәрнең кайсы чорны чагылдыруы әллә ни исәпкә алынмау сәбәпле, теманы конкрет күз алдына китерү кыенлаша.

Бүгенге көнне чагылдырган әсәрләр белән хәлебез ничек соң? Г. Мөхәммәтшинның «Кар астында», Б. Камаловның «Сарсаз кызы Сария», М. Харисовның «Акчарлак», А. Тимергалиннның «Рәшад эффекты», М. Шабаевның «Салда сәяхәт», Ә. Фазылҗановның «Чуалган кармак», «Гыйбрәт», Л. Бадыйкшанның «Биктимер абыйның дуслары», «Җилкәннәр», «Серле бөҗраләр»ы— менә болар барысы да соңгы ике елда көн темасына багышланып язылган проза әсәрләре. Сан ягы әллә ни куанырлык түгел. Бу әсәрләр арасында бүгенге хәлләрне бала образына бәйләп яктырткannары, аерым алып, вакыйга итеп сөйләрлекләре дә юк. Соңгы ике елда балалар прозасын шаулатырлык әсәрләр, гомумән, күренмәде. Чагыштырмача уңышлы дип әйтерлекләре, аннан түбәнрәкләре бар. Инде килеп, шул булган кадәресенең эчтәлекләре, тормышны сурәтләү алымнары хакында сүз йөртик.

Мәхәббәт хисе кешедә бик иртә, бала чакта ук уяна һәм бик саф булып уяна. Бу хәл балалар әдәбиятыннан читтә кала алмый. Үз вакытында И. Гази «Ак сирень» исемле хикәясендә 14 яшьлек Саниянең беренче саф мәхәббәт хисләрен тирән җылылык белән тасвирлаган иде. Шуңа хәзер Б. Камаловның «Сарсаз кызы Сария», М. Харисовның «Акчарлак» хикәясе истәлде. Хикәяләр мәхәббәтнең кешене баета торган иң гүзәл хис булуын төшендерерлек итеп, кечкенә геройның табигатен нечкә тоеп иҗат ителгәннәр. Хикәяләрдәге мәхәббәт балаларныкыча беркатлы һичкем белергә тиеш булмаган яшерен сер, булуы белән аеруча саф һәм матур. Б. Камаловның кечкенә Фәрвазы, мәсәлән, үзе яратып йөри торган күрше кызы Сариягә хатны менә ничек яза: «Мин сине яратам, тик моны бирәү дә белмәсен, яме. Болай

да үртәргә генә торалар. Кешеләр алдында син миңа салкын кара, мин сиңа салкын карармын». «Сарсаз кызы Сария», «Акчарлак» хикәяләре тормыштагы һәм кешеләрдәге матурлыкны күрә белүче бала образларын иҗат итүләре ягыннан да әһәмиятле.

Сурәтләү алымы ягыннан карaганда, «Сарсаз кызы Сария»дә, «Акчарлак»та җитди лирик тонда язылганнар. Ә. Фазылҗанов геройларындагы кимчелекле, йомшак якларга күбрәк басым ясый. Алтмышынчы елларда Л. Ихсанова «Космонавтлар урамы», Г. Мөхәммәтшин «Бурзайлар командасы» хикәяләрендә кызыклы комик персонажлар иҗат иткәннәр иде. Шуннан бирле прозаның бу юнәлеше читләбрәк үтелә килде. Ә. Фазылҗанов юмор, ирония алымнарын яңартуга омтыла.

Ә. Фазылҗановның көлү алымы — нигездә геройны көлке хәлгә кую. «Гыйбрәт» хикәясендәге малай әле бер эшкә, әле икенчесенә, әле өченчесенә тотынып карый, берсен дә ахырынача башкарып чыгарга көче дә, чыдамлылыгы да җитми. Ихтыярсыз булуы аркасында ахырда көлке хәлгә кала. Автор хикәяләрендә детальләрне дә кызыклы булулары ягыннан чыгып сайлый, идеяне көлкеле детальләр аша гәүдәләндерүгә ирешә. Мәсәлән, балык тотканда ике дусның кармаклары бергә чуалып бетү, ике кармакка эләккән бер балыкны бүлешә алмый иза чигү, ул балыкның туфракка буялып бетүе һ. б. Шул вакыйга аша кечкенә геройларда булган саранлык, бөтенесен үзенә генә булдырырга теләү чаткылары күренеп китә. («Чуалган кармак».) Ә. Фазылҗановка юмор, ирония көчәнмичә бирелә, ул бу өлкәдә уңышлы башланган эзләнүләрен дәвам иттерсен иде, дигән теләк белдерәсе килә.

Зур-зур океан пароходларында ил гизү, поездларга утырып ерак җирләр күрү, альпинист булып тау кыяларын штурмлау турында кайсы бала хыялланмый?! Пионер отрядлары туган як сукмаклары буйлап сәяхәткә юнәлә. Мәктәпләрдә туган якны өйрәнү түгәрәкләре эшли. Балалар, бик мавыгып, хәрби-ажаган уеннары уйныйлар, ияу һәм түземле булырга өйрәнәләр. Берниче әсәрләр балаларның әнә шул романтик омтылышларын чагылдыруны максат итеп куялар. Әсәрләрдә романтик сурәтләү чаралары, маҗаралар зур урын ала, омтылышларны, хыялларны чагылдыру өчен бу алым язучыларга зур уңайлыклар бирә. Маҗара теге яки бу күләмдә очраклылыкка нигезләнә, әмма әсәр тукымасына килеп кердеме, ул билгеле бер мәгънә йөге алырга, ышандырырга тиеш. Аның уңышлы мисалларын Г. Мөхәммәтшин әсәрләрендә күрәбез. Ул сурәтләгән маҗаралар читтән көчләп кертелмиләр, аларны геройларның тынгысыз табигате, эзләнүләре китереп чыгара, шунлыктан алар ышандыралар. Авторның «Кар астында» исемле хикәясендә Тавык авылының өч малае Әнсаф, Зәет, Котып, сугыш уены уйнар өчен җайлы урын эзли торгач, үзләре дә сизми, хәтәр хәлгә тап булалар, тирән чокырга егылып төшеп, кар ясаган туннель эчендә бикләнеп калалар. Әлеге гадәттән тыш киеренке эпизодта кечкенә геройларның бер-берсенә ярдәм итү, икенче берәү тормышы өчен үзеңне җаваплы итеп сизү тойгылары да, индивидуаль сыйфатлары да ачылып китә. Зәет куркыныч вакытта сагаебрак кала, Котып елап җибәрә, Әнсаф исә иптәшләренә караганда тәҗрибәлерәк, тәвәккәлрәк булып чыга.

Әйе, оста эш итә белгәндә, гадәттән тыш вакыйгаларны эченә алган, романтик рухта язылган әсәрләр балалар өчен бик кирәк. Андый китаплар яшь укучыны хыялланууга этәрәләр. Ә «хыялсыз кеше канатсыз кош» ди халык. Шунлыктан, балалар китабына бирелгән аннотацияләрдә маҗарага байлык ассызымлап, әсәрнең бер уңышлы ягы итеп күрсәтелә. Әйтик, Г. Гобәйнең «Каланча», «Маякчы кызы», М. Әмирнең «Батыр», Ә. Айдарның «Ташбай» повестьлары инде күптән язылган булсалар да, кызыклы маҗаралары белән бүген дә балаларның яратып укый торган әсәрләре исәпләнәләр. Бу повестьларда бала образлары тормыштагы зур иҗтимагый хәлләргә мөнәсәбәттә ачыла, алар, әтиәниләре белән бергә, яңа тормыш төзү өчен көрәшәләр, маҗаралар балаларның шул көрәштәге батырлыкларын чагылдыру чарасы булып хезмәт итә.

Маҗара элементлары кертү юлы белән әсәрне кызыклы итәргә, романтика белән сугарырга тырышу хәзерге прозада да бер тенденциягә әйләнеп бара. Әмма байтак әсәрләрдә я маҗара артык күбәеп китеп, вакыйгаларның ышандыру көче кими, яисә маҗара үзмаксат төсен ала, әсәрнең идеясе белән бәйләнеп ятмый. Ясалма романтика белән мавыгу хәзерге балалар прозасында бер чиргә әверелеп бара шикелле. Л. Бадыйкшанның «Атау егете» исемле китабындагы хикәяләрнең күбесендә бүгенге балаларның туган якны

өйрәнү омтылышлары гәүдәләнә. «Җилкәннәр» исемлесендә кайсыдыр класс укучылары (ничәнче классныкы икәнлекләре әйтелмәгән) уку елы башлангач, моторлы көймәгә утырып, сәяхәткә чыгып китәләр. Яхшы укымаганлыктан, Әхмәт белән Хәсән бу бәхеттән мәхрүм ителә. Коллективтан аерылуның зарарын күрсәтү өчен, автор Әхмәт белән Хәсәнне нинди генә кыен хәлләргә калдырмый, очраклыклар чамадан тыш күбәеп киткәнлектән, әсәрнең ышандыру көче кими. Әлеге ике малайның сәяхәткә, классташларыннан аерылып, үзләре генә качып чыгып киткәннәрен кайдан белгәннәр диген? Көймәне яр буенда калдырып, Әхмәтнең ризык юнәтү максаты белән якындагы эшчеләр поселогына килеп керүе була: «Ә, качкын малай шушымыни инде», дип беләкләренә кызыл бәйләгән ике егет аны эләктереп тә алалар, атка атландырып, өстәвенә, бер озатучы да биреп, малайны туган авылына кайтарып җибәрәләр. Юлда ул, нинди дер кодрәт белән агач ботагына асылынып, үзен озата килүчедән качып кала. Урманда берүзе адашып йөргәндә, аның каршысына, искәрмәстән, авылда калган эте килеп чыга. Сюжет әллә ни таләп итмәсә дә, автор теләге белән генә Әхмәт күлгә бата, тик очраклы рәвештә иптәшләре килеп чыгып, аны коткаралар. Безнең як урманнарында аю яшәми, моны һәр бала белә. Л. Бадыйкшанның Әхмәте пошиларны аю дип уйлап, коты алынып, агач башына менеп китә.

Тагын шунысы бар: туган якны өйрәнү үз эченә күп нәрсәләрне ала. Ул бер селтәнү белән генә тәгәлләнә торган эш түгел. Шунлыктан балалар сәяхәткә туган ягыбызның аерым бер өлкәсен өйрәнүне алып, конкрет максат куеп, маршрутның эш планын төзеп чыгалар. Әйтик, тарихка кереп калган нинди дә булса бер геройның эзеннән йөреп, аның турында материал туплау, я булмаса бер урынның үсемлекләр картасын төзү, табигый байлыкларын өйрәнү һ. б.

Л. Бадыйкшанның «Ташкыялар атавында» хикәясендә Ренат, Рамилә, Вадик, этиләре эшли торган Ташбака буксерына утырып, сәяхәткә чыгып китәләр. Сәяхәт барышында балалар нинди дер экзотик Ташкыя атавына эләгәләр, анда моңа кадәр үзләре белмәгән гаҗәеп кошлар күрәләр, искиткеч матур комлы күлгә, сирәк очрый торган ландшафтка тап булалар. Хикәядә автор боларны сурәтләп нәрсә әйтергә теләгән — аңлавы авыр. Хикәядәге пейзажның кайсы якныкы икәнен билгеләп булмый, балалар гади күзәтүчегә генә кайтып калалар, үз күзәтүләренең нигезендә яңа ачышлар, кызыклы нәтиҗәләр ясамаганда, танып-белү эшчәнлеген активлаштырмаганда сәяхәтнең нигә кирәге бар? Кызыклы ачышлар ясалганда гына балалар үзләренең романтик хыялларына азык таба алалар.

М. Шабаевның «Салда сәяхәт» әсәре, исеменнән үк күренгәнчә, тематик яктан Л. Бадыйкшан хикәяләре белән очраша. Һәр ике авторның сурәтләү объективы елга, кешеләр, сәяхәтләр, һәр икесе маҗараларга зур урын бирәләр. «Салда сәяхәт» исә танып-белү материалының байлыгы белән Л. Бадыйкшан хикәяләренә караганда күп өстен. Анда нинди дер билгесез яклар да сурәтләнми. Әсәрдә Ык буйларының табигате күп төрле төсләре белән күңелне тартырлык гаҗәеп гүзәл булып күз алдына килә. Ык буйларында үсә торган үсемлекләрне, агачларны, әрәмәлерендәге сайрар кошларны, җәнлекләрне, суындагы балыкларны М. Шабаев яхшы белеп тасвирлый. Пейзажның бай картинасын тудырырлык оригиналь чагыштырулар таба. Шул тирәне бизәп торган Ур күл буе автор күзаллавында менә ничек гәүдәләнә: «Тәбәнәк, әмма колач җитмәслек юан кәүсәле, зур яшел бүрекле тирәкләр кай урында икәү-өчәү бергә, кай урында шактый ара калдырып күл буена сакка басканнар. Алары — иң өске ярус. Астарак икенче ярус — куерак булганга күрә, каракучкылланып күренгән тал куаклары, тоташ әрәмә. Бельэтажда карлыганнар, гөлҗимешләр, эт җиләкләре. Күл үзе партер булып күренә». Ел вакытларына бәйле хәлдә, Ык буйларының үзгәреп торуы да авторның игътибарыннан читтә калмаган. М. Шабаевның осталыгы — табигатьне сурәтләгән урыннарда. Маҗараларга килгәндә исә аңарда да кызык булсын өчен, романтика өчен генә кертелгәннәре байтак. Егетләрнең браконьерларга тап булуларын, урманда Нәгыймнең үгез белән кара-каршы очрашуын, Әпләйнең кинәт кенә авырып китүен, Мәхмүтнең пионервожатый Миләүшә белән булган мәхәббәт хәлләрен һ. б. шундый маҗараларны әсәрдән алып ташласаң да, сюжетка зур зыян килми.

М. Шабаев — шагыйрь. «Салда сәяхәт» аның прозада беренче тәҗрибәсе. Шунлыктан авторга образларны индивидуаль-

ләштерү тәҗрибәсе дә җитешеп бетми. «Эшкә иң һәвәсе — Нагыйм. Күләгә шикелле ничектер тавышсыз-тынсыз гына эшли белә егет». Шул рәвешчә, автор геройларына күп урыннарда үз исеменнән характеристика бирә. Ләкин әсәрдә ул сыйфатламалар геройларны җанлы итеп күз алдына китерерлек, истә калдырырлык булып җитмиләр.

М. Шабаев, Л. Бадыйкшан хикәяләренә мажаралар аерым элемент буларак килеп керсә, А. Тимергалинның «Рәшад эффекты» тулысы белән фәнни-фантастик жанр кануннары нигезендә язылган. Чынбарлыктан шактый ерак торган вакыйгаларны сурәтләү, әсәрдә уйлап чыгарылган образлар белән эш итү бу жанрның үзенчәлеген тәшкил итә. Монда автор вакыйгаларның законлы тәртибен үзенә ничек кирәк, шулай үзгәртә ала. Мажаралылык исә бу жанрның табигатеннән килеп чыга. А. Тимергалинда шунысы үзенчәлекле: ул мажаралар тезмәсе аша киләчәкнең бүгенгә, иртәгәсе көннең бүгенгә үтеп керү мөмкинлеген, шуның фән өчен әһәмиятен чагылдыруны максат итеп куя. Әсәрдә шундый вакыйга сурәтләнә: махсус экспериментлар тәэсирендә 1980 ел малае Рәшад үткән көннәргә, Хөсәен Ямашевлар чорындагы Казан каласына күчерелә. Автор иске Казан күренешләрен матур гына сурәтли. Әмма иске Казанда Рәшад белән булган мажаралар ышандырырлык түгел, йомшак һәм ясалма эшләнгән, балаларның беркатлылыгына йөз тотылган. Мәсәлән, Әхмәт исемле малайның Рәшадны беренче мәртәбә очратуы була, шунда ук аңа революцион көрәшкә бәйле эш йөкли. Хәтта ике эшче дә беркем сизмәскә тиешле революцион көрәш серен ниндидер бер билгесез малай Рәшадка ышаттереп сөйлиләр. Автор төгәлсезлекләр дә җибәрә. «Казан, әнә Сөембикә манарасы», дип сөйләп кила дә: «Тик шулай да бу Казан түгел»,— дип, баштагысына капма-каршы нәтиҗә ясый.

А. Тимергалин татар балалар әдәбиятында фәнни-фантастика жанрында байтак еллардан бирле берүзе диярлек эшләп килә. Аның бу өлкәдә билгеле бер уңышлары да күз алдында. Шулай да әлеге хикәясен авторның иҗади үсеше дип булмый. Әсәрнең исемен дә мәктәп укучысына аңлавы авыр. Аннан соң, күтәргән проблемасы белән дә укучы башын әйләндерүнең нинди әһәмияте булыр икән?

Күрәсең, заман темасын чагылдыруда язучыларның осталыклары да, иҗат алымнары да төрле. Без лирик проза, юмор, фәнни фантастика, реалистик һәм мажара алымнары бергә үрелеп язылган әсәрләр турында әйтеп үттек. Ләкин балалар өчен иҗат иткәндә, язучылар башлыча вакыйгалылыкка, мажараларга өстенлек бирәләр. Күңелгә шундый шик төшә: мажаралар белән артык мавыгып, геройларның эчке дөньясын читтә калдырмыйбызмы икән? Балаларның таләпләре дә төрле: аның берсе детектив әдәбият яратса, икенчесенә тирән уйларга төшерә торган психологик әсәрләр ошый. Аерым уңышлы тәҗрибәләр ясалса да, тулаем алганда, бездә кечкенә геройның эчке дөньясы чикле бирелә. Бүгенге балаларның эчке дөньясына заман үзгәрешләре ничек тәэсир итә, аларның теләк һәм омтылышлары, фикерләве нинди юнәлештә үсә — әсәрләрдән шуны сиземләү авыр. Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясен без бүген дә ни өчен йотлыгып укыйбыз? Хикәя нәкъ менә авыл малаеның рухи кичерешләрен тирән һәм күпьяклы ачуы белән кызыксындыра. Нигә безгә лирик проза юнәлешен кыюрак үстермәскә, безнеңчә, ул кеше күңеленең тирән катламнарына үтеп керү өчен зур уңайлыклар тудыра. Психологик анализның җитешмәве дә бер сәбәп булып торса кирәк, балалар китапларындагы күп кенә геройларның үзләренә генә хас язмышлары юк, шунлыктан алар тиз онытылалар.

Яңа әдәби формалар эзләү эшен активлаштыруны тормыш кына түгел, татар балалар әдәбиятының бай мирасы бу[illegible]ы да таләп итә. Инде Октябрь революциясенә кадәр үк Г. Ибраһимов татар балалар әдәбиятында психологизм линиясен башлап җибәргән булса, Ш. Әхмәдиев, Ф. Агиев, С. Җәлал реалистик эчтәлекле хикәяләрдә әкият элементларын, төш күрү формасын, авыз иҗатындагы фантастик образларны куллануда сизелерлек уңышларга ирештеләр. Мажарага тартымлылык бигрәк тә совет чорында 30 нчы еллар балалар прозасы өчен характерлы. Юмористик юнәлеш Тукайдан килә. Димәк, югарыда искә алынган әдәби алымнарның күбесенең ерак тамырлары бар икән. Бу— үзе генә дә бүгенге көнне яңача чагылдырырлык яңа формалар эзләүнең сүлпәнләге хакында сөйли.

Эчтәлек белән дә шул ук хәл. Тематик ачышлар сирәк. Прозада бүгенге көннең чагылышы шактый тар. Югарыда

без бу яктан якынча дүрт моментны гына билгеләп үтә алдык. Заман темасы үзенә житди игътибар юнәлтүне сорый. Безнең чор — фәнни ачышлар, күп төрле техник информацияләр чоры. Балалар, күп көч куеп, мәктәпләрдә шул фәнни ачышларны үзләштерәләр, белем алу белән генә чикләнмичә, практик тормышка хәзерләнәләр, профессия сайлыйлар. Авыл хуҗалыгында кеше көчләре кирәк булса, мәктәпне тәмамлагач, үзләре теләп, класслары белән колхозда калалар. Мәктәп эзтабарлары моңа кадәр билгесез геройларның исемен дөньяга чыгаралар. Хәер, болай гына санап бетерергә мөмкинме соң бүгенге хәлләрне! Кама автомобиль заводы, Түбән Кама химия комбинаты төзелешләре илебезне шаулата. Шуларның байтагы балалар прозасында яктыртылмый калып килә.

Әдәбиятның традицион темасы — хезмәткә багышланган әсәрләр дә сирәк күренә. Сугыштан соңгы елларда язучылар, бик табигый, балаларның колхоз кырындагы чүп үләне утауларын, кар тотуларын, печән җыюларын, башак чүпләүләрен, фермадагы бозауларны шефка алуларын сурәтлиләр иде. Бүген бу эшләр типик түгел инде, колхозлар ныгыды, эшләр механикалаштырылды. Шулай булгач, бүгенге балаларның физик хезмәте нәрсәдә күренә соң? Физик хезмәткә мәхәббәт тәрбияләүне нинди юнәлештә алып барабыз?

Мәгълүм факт, бүгенгене чагылдырган әсәрләр шул дәвернең әдәби елъязмасы булып киләчәк буыннарга күчә. Болай барганда, киләчәк буыннарга җитмешенче еллар пионерларының эше һәм гамәлләрен, теләк һәм омтылышларын безнең әсәрләрдән күзаллау кыен булачак.

Баланы мәктәп киң тормыш юлына хәзерләп чыгара, аның характеры формалашуда хәлиткеч роль уйный. Бүген совет мәктәбе сыйфат үзгәрешләре кичерә. Моннан 10—15 елгы дәреслекләр, укыту методлары, программалар белән чагыштырганда, хәзергеләрә уңай якка аерылып тора. Байтак еллардан бирле мәктәп тормышын чагылдырган әсәрләрнең дөнья күргәне юк. Очрашулар вакытында моңа укытучылар ризасызлык белдерәләр.

Бер кимчелек икенчесен китереп чыгара: соңгы елларда балалар прозасында бала образлары азая башлады. Дөрес, балалар әдәбияты гомер-гомергә ике сызык буенча үсә. Бер очракта яшь буынны өлкәннәрнең, икенче очракта яшьтәшенең образы үрнәгендә тәрбияләү максат итеп куела. Шулай да балалар әдәбиятының идея-эстетик кыйммәте һәр чорда бала образының бирелеше белән бәйләнә, чөнки яшьтәше образы, аның язмышы укучыга ныграк тәэсир итә. Хәзерге вакытта нәшрият күбрәк яшьләргә йөз тота. 1970—1971 елларда 32 исемдә проза әсәре чыгып, шуларның 11 е генә мәктәп укучылары тормышыннан алып язылган.

Күңелне борчыган өченче нәрсә: балалар прозаиклары арасында алмашынучанлык көчле. Моның сәбәбе балалар тормышын тирән өйрәнергә теләмәүдән килеп чыкса кирәк. «Шигырьләремне балалар яратып укыйлар икән, бу җәһәттән мин, барыннан да бигрәк, балаларның үзләренә бурычлы. Һәрбер буш вакытымны мин алар арасында үткәрергә тырыштым»,— дигән К. Чуковский. Безнең язучылар мәктәпләрдә сирәк булалар, балаларның рухи ихтыяҗларын даими өйрәнәсе урында, байтагы үзләренең сабыйлык хатирәләренә таянып, күп булса бер-ике әсәр бирәләр дә, шул запас беткәч, я туктап калалар, я зурлар әдәбиятына күчеп китәләр, алмашка тагын яңа авторлар килә, шунлыктан иҗат мәйданына вакытлы кереп чыгучыларның яки әле иҗади тәҗрибәсе ныгып җитмәгән яшьләрнең зур өлеше балалар әдәбиятына тия. Язучыларның шулай әледән-әле алмашынып торуы, үз чиратында, прозада яшәп килгән кимчелекләрне китереп чыгаруга бер сәбәп була.

Рус балалар әдәбиятында хәзерге көндә С. Михалков, А. Алексин, А. Барто, С. Баруздин, М. Прилежаева, Н. Носов, Н. Дубов кебек үзләренең бөтен иҗат талантларын бары тик яшь буынны тәрбияләүгә генә багышлаган, шушы өлкәдә халыкның тирән мәхәббәтен яулап алган язучылар бар. Русларда балалар әдәбиятының үсеш дәрәҗәсе бу өлкәдә даими эшләп килүче өлеге каләм осталарының әсәрләреннән чыгып бәяләнә. Бездә соңгы вакытта Л. Ихсанова, Ш. Рәкыйпов, А. Тимергалиннан кала даими прозаиклар юк диярлек. Балаларның танылган язучысы Г. Гобәй дә ни сәбәптәндер туктап калды. Аерым балалар прозаикларының әдәби осталыгы күтәреләме, юкмы, аларның индивидуаль үзенчәлекләре нидән гыйбарәт — бу турыда фикер йөртү авыр. Кыскасы, татар балалар прозасы үсешендә шактый кыенлыклар яшәп килә.

# ПОЭЗИЯНЕҢ ЫШАНЫЧЛЫ КӨЧЕ

*С. Хәким шигырьләренең рус теленә тәрҗемәләре хакында*

Сибгат Хәким — чын мәгънәсендә татар шагыйре. Аның һәр йөрәк тибеше милли үзенчәлек белән сугарылган, бөтен рухи дөньясы гүзәллек белән тулы. Сибгат Хәким шигырьләрен тугандаш халыклар теленә тәрҗемә итүчеләргә адым саен очрый торган кыенлыклар да беренче чиратта шуның белән аңлатыла. Төрки телләргә тәрҗемә итүчеләрнең эше җиңелрәк, билгеле. Ни дисәң дә, күпчелек очракта алар турыдан-туры оригиналдан тәрҗемә итәләр. Рус тәрҗемәчеләренә, аерым алганда, шагыйрьнең узган ел ахырында басылып чыккан соңгы ике китабын[1] тәрҗемә иткән кешеләргә күп тапкыр кыенгарак туры килгәндер. Аларның күбесе татарча белми. Шуңа күрә, телиләрме-юкмы, ашык-пошык эшләнгән сүзгә-сүз тәрҗемәләргә таянырга мәҗбүр булалар. Шуңа да карамастан, әлеге җыентыкларны тәрҗемә итүчеләр үзләренең иҗади бурычларын нигездә шактый уңышлы төстә башкарып чыкканнар.

Әмма башта шагыйрьнең үзе, аның иҗатындагы төп тенденцияләр хакында берничә сүз.

Әле 1953 елда ук язмыш мине ифрат олы йөрәкле шушы кеше белән очраштырды (моның өчен аңа рәхмәтем чиксез зур). Мин аның төрле җыелышларда ясаган чыгышларын тыңлый, шигырьләрен һәм тәнкыйть мәкаләләрен укый, аның әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итүчеләр белән очрашып сөйләшә идем. Һәм һәрвакыт: «Шушы бәләкәй генә кеше татар поэзиясенең йөген ничек тартып бара ала икән», дип гаҗәпләнә идем. Ул чагында мин «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында эшлим, ә Сибгат ага журналның редколлегия члены иде. Ул еш кына редакциягә керә, әгәр эш ахырлары булса, без бергәләп өйгә кайтырга чыгабыз. Аны узып китмәс өчен, сиздерми генә адымнарымны акрынайта төшәм, үзем туктаусыз әдәбият турында сөйлим. Шулай да тоеп барам, сүзнең җеп очы барыбер аның кулында була, көтелмәгән репликалары, җае белән генә әйтеп куйган образлы сүзләре белән ул минем фикерләргә юнәлеш биреп бара. Салмак йөреше белән дә, ашыкмый, кабаланмый сөйләшүе белән дә ул: «Ашыксаң да кабаланма» дигән мәкальнең дөреслеген раслап тора кебек. Сибгат Хәким шәхси тормышында да, иҗатында да өнә шундый.

> Битне биткә куеп ни күрерсең?! —
> Күрим дисәң, бераз читкә бас,—

С. Есенинның шушы сүзләрен С. Хәкимнең бөтен поэзиясенә эпиграф итеп куярга була. Чорның катлаулы мәсьәләләрен ачыклау, геройларын гомумиләштерү һәм индивидуальләштерү өчен, аңа дистанция, вакыт аралыгы кирәк. Бу яктан ул, М. Җәлил, Ф. Кәрим кебек, иҗатлары белән сугыш елларында ук тулысынча ачылган шагыйрьләрдән нык аерыла. Әмма бу әле Сибгат Хәким фронт шагыйре түгел дигән сүз түгел, ул бары бер эпохадан торып икенче эпохага, узган эпохага күз ташларга ярата. «Үзем турында» исемле автобиографик мәкаләсендә (шагыйрьнең Казан басмасы нәкъ шул мәкалә белән ачыла) ул бу хакта үзе дә яза. Һәм сүзе эшеннән аерылмый. Башта ул, лирик шигырьләр язып, теге яки бу темага җиңелчә разведка ясый, аннан, лиро-эпик поэмалар язып, әлеге теманы берничә ел буена ныклап эшкәртә. Фронт лирикасыннан соң, «Дуга» поэмасын язганда нәкъ шулай эшләде. Татарстанда нефть промышленносте беренче адымнарын гына атлаган бер чорда

[1] С. Хаким. Вечные ветви. Стихи и поэмы. «Современник». Москва. 1971 год; С. Хаким. По зову Ленина. Стихи и поэмы. Таткнигоиздат. Казань. 1971 год.

шагыйрь нефтьчеләргә багышланган лирик миниатюраларын иҗат итте һәм, алар дөньяга чыгып байтак еллар узганнан соң, «Урләр аша» исемле поэмасын тәмамлады. Аның иҗаты нигездә хәзер дә шул рәвешчә дәвам итә. Яшьлегендә ул халык шагыйре Габдулла Тукайга багышлап күп кенә шигырьләр, поэмалар язган кеше. Узган ел басылып чыккан «Кырыгынчы булмә» поэмасында шагыйрь яңадан Тукай образына әйләнеп кайта, үзенең кырык еллык иҗат эшчәнлегенә йомгак ясый. Иҗат мәсьәләләрен чагылдырган шигъри әзекләрдән тыш (андый әзек «Кырыгынчы булмә»дә дә бар), аның әлеге мәсьәләгә багышлап язылган һәм Р. Моран тарафыннан бик яхшы тәрҗемә ителгән «Озын чылбыр, бик күп богралар» исемле махсус шигыре бар. Шигырьдә шагыйрь, зур горурлык белән, барлык нәсел-нәсәбем җир кешеләре — игенчеләр ди, буыныбызның башында гадел һәм турылыклы межачы карт Мәмкә торган, ди. Әсәрдән күренгәнчә, элекке заманда, җир бүлгәндә, межачы үз артыннан озын чылбыр сөйрәп йөргән, ахырдан шул чылбыр эзе буенча межа ярганнар.

Шагыйрьгә бу деталь нигә кирәк булган соң? Баксаң, тиккә генә түгел икән. Әлеге детальләрнең конкрет мәгънәсен саклаган хәлдә, шагыйрь үзе хакында да сөйли:

Буын-буын озын чылбырны,
Һич өзелмәс моңлы шул җырны,
Ничә еллар инде, ни заман
Үзем сөйрим хәзер межадан.

Язлар шаулар алда, боз агар,
Чыңлавыннан тынмас богралар...
Дөрес сызып микән узасың
Заманыңның син дә межасын?

Билгеле булганча, С. Хәким поэзиясенең стиле, аның тавышы ягымлы, йомшак, салмак. Болай салмаклык үзе генә әллә ни яхшы сыйфат түгел түгелен. Әмма әлеге салмаклыкта татар халкының характерына хас милли сыйфатлар, атап әйткәндә, халыкның басынкы, тыныч көче чагыла икән, бу — инде яхшы сыйфат, аның да ниндие әле.

Шагыйрь никадәр миллирәк булса, шул кадәр интернациональрәк була. Тик бер шарт сакланганда, әгәр ул үзенең әсәрләрендә «мәңгелек» мәсьәләләрне күтәрә алса. Шундый мәңгелек мәсьәләләрнең берсе — Ленин темасы. Ленин темасы Сибгат аганы һәрвакыт дулкынландырып-борчып тора. Әмма әлеге грандиоз теманы чишү өчен, үз ачкычыңны табарга кирәк була. Һәм ул «Ленин фәрманы белән», «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты», «Языгыз, җир улларыl», «Күңелем Ленин белән сөйләшә» кебек әсәрләрендә шундый ачкычны таба да. Ленин темасын ул Татарстан белән, татар халкының язмышы белән бәйләп чишә. Аның югарыда саналган барлык әсәрләренә хас төп сыйфат әнә шул.

«Тормыш поэзиясе» исемле очеркында С. Хәким болай яза: «Һәр чак, кулыма каләм алу белән, минем каршыма зур һәм чиксез Ватаныбызның аерылмас бер кисәге булган үз республикам килеп баса. Аның юлы — минем юлым, аның биографиясе — минем биографиям. Болай дип әйтергә хакым бар дип уйлыйм, менә ничә еллар инде мин республикам белән бер аякка атлыйм, аның киләчәген дә, җиңү һәм тантана елларын да йөрәккә якын кабул итеп, бергә үсәм, бергә формалашам. Һәм республикам, үз әнием кебек, барын да миңа артыгы белән кайтарды: ярлы крестьян баласыннан мин аның улы, аның шагыйре булдым».

С. Хәким әсәрләренең тәрҗемә ителү тарихына күз салыйк, кайбер шигырьләрнең тәрҗемәләрен тикшереп узыйк. Хәтеремдә, моннан күп еллар элек Сибгат ага, Р. Моранның тәрҗемәләрен карап чык әле, дип үтенде. «Володя ант итә» дигән шигырьнең ике юлын Р. Моран болай тәрҗемә иткән иде:

Эти волны на кого-то
Изливают гнев.

Исегездәме икән, үз вакытында Добролюбов Бешенцев дигән әфәнденең төче һәм баналь шигырьләреннән ничек ачы көлгән иде? Биредә дә шундый ук хәл: «волны изливают гнев» тезмәсе төче, ятышсыз яңгырый. Ә бит оригиналда: «Дулкыннар, кемгәдер ачу ячереп, шаулыйлар».

Икенче мисал. «Яратам мин» дигән шигырьне тәрҗемә иткәндә, «пылко (!) спешит молодежь в клуб», «акушерка в родилке (?) поздравляет счастливую мать» кебек бик үк русча яңгырамаган җөмләләр очраштыра иде. Бигрәк тә «родилка» дигән вульгаризм шигырьнең бөтен матурлыгын бозып тора. Әйтерсең лә сүз «бала тудыру йорты» һәм бәхетле ана турында түгел, ә тәмәке тарту урыны — «курилка» турында бара. Шушысы куанычлы, аннан бирле узган вакыт эчендә Р. Моранның рус теленә булган сизгерлеге бик нык үскән, хәзер ул С. Хәким әсәрләрен иң яхшы тәрҗемә итүчеләрнең берсе санала. Без рецензияли

торган китаплардагы тәрҗемәләр шул турыда сөйли.

Популяр җыр булып киткән «Фазыл чишмәсе»нең тәрҗемәләрен тикшереп карыйк. Аның берничә варианты бар. Менә шигырьнең күптән үк Н. Сидоренко тарафыннан тәрҗемә ителгән беренче варианты:

К ручью пришла за серебром,
Что плещет звонко на бегу.
И с полным, думала, ведром
Вернуться скоро я смогу.

Но ты взглянул,— и в том беда:
Я не ушла. О, не гляди!
То вовсе не в ведре вода,
Душа всплеснула вдруг в груди.

Оригиналдагы кебек үк, бу строфаларда гашыйкларның чишмә юлында очрашулары хакында сөйләнә. Ләкин ничек? Барыннан да элек, шигырь дүрт стопалы ямб белән тәрҗемә ителгән. Бу — оригиналның үлчәвенә якынча гына туры килә. Аннан сүзләр уңышсыз сайланган. Оригиналдагы, соң чиккә тарттырылган җәя кебек, тыгыз сүзләр тәрҗемәдә бер кузәнәкле, төссез, көчсез сүзләр белән алмаштырылган. Ләкин төп бәла әле боларда да түгел. Бәланың иң зурысы шунда: тәрҗемәдә шигырьнең асылы, аның төп идеясе үзгәртелгән. Әйтелмәгән мәхәббәт хисләрен ачасы урынга, тәрҗемәче ачыктан-ачык әрсез мәхәббәтне пропагандалый:

Я не отводила глаз
От вечереющей зари.
И что сказать,— я не нашлась,
Ну, ты хотя бы говори!

Созвездия под плеск воды
Устали плыть... устали плыть.
Смешались на тропе следы.
Что суждено, тому и быть...

Шул кадәресен истән чыгармаска кирәк, оригиналдагы кыз образын җырның музыкасыннан башка аңлавы кыен. Шигырьнең текстында булмаган сүзләр музыка ярдәмендә тулыландырыла, бу әсәр көй һәм шигырьнең бер бөтен булуын, тулы гармониясен гәүдәләндергән бер матур үрнәк булып тора. Кызга тыйнак, саф мәхәббәт хисләре турында «чылтырап аккан чишмә» моңнарына, «кызарып янган шәфәкъ» нурларына кадәр сөйли кебек. Ул — табигать баласы. Аңа сүзсез дә бөтенесе ачык. Шуңа күрә дә тәрҗемәче үзеннән өстәгән түбәндәге сүзләр:

Ну, ты хотя бы говори! —

искиткеч тупас яңгырый. «Что суждено, тому и быть» дигән икенче «өстәмә» дә бернигә ярамый. Мина калса, бу юлларны укыгач, күз алдына кимсетелгән, кыерсытылган, котылгысыз төстә язмышка буйсынырга гадәтләнгән кыз образы килеп баса.

Н. Сидоренко тәрҗемәсе, билгеле, авторны канәгатьләндерми. Һәм «Фазыл чишмәсе»н тәрҗемә итүне ул В. Ганиевкә ышанып тапшыра. Бусы — В. Ганиев тәрҗемәсе:

Под горою, под крутою,
Серебрясь бежит родник.
Я спускаюсь за водою —
Возвращусь в единый миг.

Заглянул Фазыл в глаза мне,
Душу взгляд прожег насквозь!
Не вода лилась на камни,—
Пламя сердца полилось!

От широкого заката
Мне глаза не оторвать.
Я стояла виновато.
Я не знала, что сказать.

Звезды плыть уже устали
На воде и над водой.
Мы друг другу слово дали
В жизнь идти рука с рукой.

Вьется тропка перед домом,
Окаймленная травой.
Ни соседям, ни знакомым
Ты — ни слова, милый мой![1]

Казанда чыккан китапка В. Ганиев тәрҗемәсе алынган. Ул шигырьне дүрт иҗекле хорей белән тәрҗемә иткән. Бу — шигырьнең оригиналына иң якын үлчәү. (Гомумән алганда исә, басымнар системасына нигезләнгән силлабо-тоник рус шигыре белән ачык һәм ябык иҗекләрнең үзара чиратлашып килүенә корылган татар шигыре арасында үлчәү ягыннан абсолют тәңгәллек була алмый. Безнең метрик системабыз рус поэзиясендәгедән аерыла. Бу аерымлык рус һәм татар телләренең үзенчәлекле табигате белән аңлатыла.) Һәм, укучылар күргәндер, Н. Сидоренко тәрҗемәсенә караганда, В. Ганиевнеке төгәлрәк тә, әйбәтрәк тә. Хикмәт монда кайсының талантлырак булуында яки кемнең үз эшенә җитдирәк каравында түгел. Аларның һәр икесе бөтен көчләрен куеп, җиң сызганып эшләгән. Бөтен хикмәт шунда, В. Ганиев турыдан-туры оригинал белән эш итә. Шуңа күрә аның тәрҗемәсендә «үзеннән өстәүләр» азрак, ул шигырьнең төп рухын сакларга, тәрҗемәдә «мәхәббәтнең авылча тыйнаклыгын, оялчан сафлыгын» бирергә омтыла.

Шулай да С. Хәкимне әлегә тәрҗемәләрнең берсе дә канәгатьләндереп җиткерми. Ул халык җыры бик авыр тәрҗемә

[1] Билгеле булганча, «Фазыл чишмәсе»нең 1947 елгы варианты бүген без белгәннән озынрак була. Соңыннан автор аны шактый кыскарта, камилләштерә. Н. Сидоренко да, В. Ганиев та җырның баштагы беренче вариантын тәрҗемә итәләр.

итела торган, ә еш кына гомумән тәрҗемә ителми торган жанр дип саный. Фикерләрен дәлилләү өчен, Тукай сүзләренә җырлана торган җырларның тәрҗемәләрен мисалга китерә. Күрәсең, ул хаклыдыр.

Фикерләрне җыйный төшеп, йомгак ясый башласак, шундый закончалык күзгә ташлана: Н. Сидоренко тәрҗемәләрендә С. Хәким әсәрләрен «руслаштыру» тенденциясе аеруча нык сизелә. Ул авторның татар халкының тормыш-көнкүреше, этнографиясе һәм милли культурасы белән бәйләнгән конкрет детальләрен һәм күзәтүләрен еш кына бөтенләй төшереп калдыра, шулар урынына «үзеннән» гомуми характердагы патетик сүзләр өсти. Менә бер мисал:

Я успевала, как играть ты шел,
Тебе в кармашек сунуть пирожок.

Бу юллар «Пар ат» поэмасының тәрҗемәсеннән алынды. Хәзер оригиналга мөрәҗәгать итик:

Исеңдәдер, бала чагыңда
Уйнарга дип чыгып йөгерә идең
Вак коймаклар салып алдыңа.

Күрәсез, «кесәгә» түгел (чөнки ул чактагы ирләр күлмәгендә кесә бөтенләй булмаган), ә «в подол» дип, «пирожок» дип түгел, ә «лепешки» дип тәрҗемә итәргә кирәк булган икән. Хәер, соңгы вакытларда Н. Сидоренко дустының иҗатына игътибарлырак карый башлады, аның яңа тәрҗемәләрендә мондый кимчелекләр очрамый диярлек.

«Современник» нәшриятында чыккан китапка художник В. Дианов искиткеч матур рәсемнәр ясаган. Аларда, татар халкына хас гомуми милли колориттан тыш, С. Хәким поэзиясенә генә хас күппланлылык, мәгънә байлыгы дөрес бирелгән. Менә, мәсәлән, программа характерындагы шигырьләрдән «Аккош күле»:

Бөтенләйгә инде ерак-ерак
Пар аккошлар очкан бу күлдән;
Шул аккошлар очып киткән якка карап,
Мин үкенмәм, бер дә үкенмәм.

Ни хакында сөйли бу юллар? Ерак-еракларга очып киткән аккошлар турындамы? Әйе, алар турында да. Әмма шигырь юллары арасына тирәнрәк, зуррак мәгънә салынган. Түбәндәге юллар шул турыда сөйли:

Күл камышы кебек ник саргайсын —
Үз янымда минем аккошым;
Аннан башка бәхет ничек тулы булсын,
Ничек итеп юлым ак булсын?

Инде китапта шул шигырьгә ясалган иллюстрациягә күз салыйк. Эре башаклы арыш кыры. Арыш арасына тезләнгән яшь кыз. Ул һавадан очып узган аккошлар төркемен кул болгап озатып кала. Шигырьнең тагын да киңрәк мәгънәсе китапның тышлыгында — анда пар аккош рәсеме ясалган.

1971 елның декабрь аенда Сибгат Хәкимгә 60 яшь тулды. Чиратта — КамАЗ турындагы шигырьләр һәм поэмалар. Иҗат планнары белән уртаклашканда, Сибгат ага үзенең хәзерге халәтен болайрак аңлатты. Чабыш аты сабан туе җиткәнен әллә каян сизеп тора, алдан ук үзен бәйгегә әзерли, ашамый, эчми. Шагыйрь белән дә асылда шундый ук хәл. Ул илһам килүен сизә, үзүзенә урын таба алмый, аның шигърият бәйгеләрендә катнашасы һәм, әлбәттә, беренче урынга чыгасы килә...

Ә бит аңа инде 60 яшь, бер уйласаң, лаеклы ял итәргә дә вакыт. Кайчандыр Х. Туфан турында Сибгат Хәким болай дигән иде: «Туфан — олы фигура. Татар поэзиясендә Туфан бер генә, башка Туфан юк!» Бу сүзләрне аның үзенә карата да кулланып була. Сибгат Хәким — татар поэзиясенең олы, күренекле вәкиле. Шагыйрь буларак, ул искиткеч үзенчәлекле. Безнең башка андый шагыйребез юк.

**Илдус АХУНҖАНОВ.**

# УЛ БЕЗНЕҢ ҮЗ ШАГЫЙРЕБЕЗ

Казанга ул әледән-әле килгәләп тора. Кайчан гына килсә дә, аның һәрвакыт татар шагыйрьләре арасында кайнашканын күрәсең. Соңгылары аны үзләре дә, якын туганнардай күреп, яратып кабул итәләр. Безнең шагыйрьләребезнең кайберләре аңа Рифгат дип, икенче берәүләре шундый ук гадилек һәм эчкерсезлек белән Миша дип эндәшәләр. Укучыларга исә ул күп санлы матур-матур шигырьләр иҗат иткән рус шагыйре, Мәскәү шагыйре буларак билгеле.

Башкортстанның Насибаш авылында Габитов ı Дәүләтша гаиләсендә дөньяга килгән татар малае Рифгатькә туган җиреннән бик иртә аерылырга һәм күп төрле кыенлыклар күреп үсәргә туры килә.

М. Львов поэзиягә үзенең эчке кичерешләрен, замандашларының рухи көчен, уй-тойгыларын чагылдырган шигырьләре белән килеп керә һәм тиз арада үз укучысын табып өлгерә. Михаил Львов шигырьләре белән рус укучысы гына түгел, татар укучысы да күптәннән таныш. Аның шигырьләре татар теленә дә бик еш тәрҗемә ителә. Узган ел исә Татарстан китап нәшрияты М. Львовның татарчага тәрҗемә ителгән шигырьләрен аерым җыентык[1] итеп бастырып чыгарды. Җыентыкта авторның татар шагыйрьләреннән М. Садри, Н. Арсланов, Ә. Юныс, З. Нури, М. Ногман, М. Хөсәен, Р. Гатауллин һәм Г. Рәхим тарафыннан тәрҗемә ителгән туксанлап шигыре урнаштырылган. Шагыйрь үзенең күпчелек шигырьләрен бөек Ленинга, тыуп-үскән якларына, Казандагы һәм Алма-Атадагы дусларына, нәгә яу кырында мәңгелеккә ятып калган коралдашларына багышлый. «Бөек якташ» шигырендә ул даһи Ильичны үз янында тоюын түбәндәге юллар аша чагылдыра:

Кичерәм зур горурлык.
Бәхет балкый анымда:
Ленин белән якташ мин
Кадерле Казанымда.

Казанга атап язылган шигырьләрне җыентыкта шактый очратырга мөмкин. Аларның һәркайсында шагыйрь үзен Тукай Казаны белән, аның культурасы һәм кешеләре белән аерылмас бәйләнештә торучы татар малае итеп хис итә. «Минем татар телем», «Казан», «Рус түгелләр күп безРоссиядә», «Җәлил», «Дуслар җырлый», «Әтнәмә», «Казан вокзалында ялгызым...», «Безнең исемнәр» һәм «Түбәтәй» шигырьләрендә бу тойгы аеруча көчле чагыла. «Мин Казанда татарчалап сөйлим, ә сүзләгем ярлы шактый ук»,— ди шагыйрь «Минем татар телем» шигырендә. һәм «Татар теле ярларында чит кешедәй аптырап» торуының сәбәбен болай аңлата:

Хәреф танырга да өлгермәдем.
Зур шәһәргә алып киттеләр.
Океандай тирән һәм дә ярсып
Рус телене гашыйк иттеләр.

Үз сүзләре белән әйткәндә, Михаил Львов әнә шул дәрьяда утыз ел буена моряк булып хезмәт итә. Аның иҗатында заманның кояшлы, тыныч көннәре дә, кешеләрнең күңел ярларына килеп бәрелгән көчле эмазиле дәвыллары да шактый тулы гәүдәләнә. Шагыйрь үзенең күп кенә шигырьләрендә дәһшәтле сугыш елларын, окопташ дусларын искә төшерә. Бу исә аңа бүгенге тыныч тормышның никадәр авырлыклар һәм югалтулар бәрабәренә яулап алынганлыгын тулырак, калкурак итеп күрсәтү өчен кирәк.

[1] М. Львов. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. Тиражы 3000. Бәясе 52 тиен.

«Кочаклашып ветераннар утыра», «Берлинда», «Билгесез солдат», «Һәйкәл», «Җиңү», «Нигә тагын комбриг төшкә керде», «Сугышны исемә төшермә», «Исеңдә тот плацдармны» кебек шигырьләрне укыганда совет солдатының батырлыгы, олы җанлылыгы турында кат-кат уйланасың. Башкалар исән калсын өчен үз гомерен кызганмаган билгесез солдатның сүзләре үзеннән-үзе күңелгә кереп кала:

Минем туфрак җиңел булсын өчен,
Үз даннарын өстәп данына,
Ватанымның герой калалары
Килеп басты каберем янына.

Михаил Львовның лирик герое тормыштагы вакыйгаларны читтән торып күзәтүче булып түгел, шул вакыйгаларда үзе катнашучы актив көрәшче булып күз алдына килеп баса. Аның шигырьләрендә лирик герой заманның иминлеге, кешеләрнең бүгенге һәм киләчәк бәхете, туар таңнарның матурлыгы өчен утка-суга керергә әзер тора. Моның шулай булуы табигый да. Чөнки ул ата-бабаларының, тормыштан вакытсыз киткән сугышчан дусларның васыятьләренә тугрылыклы булып калуны үзенең изге бурычы итеп саный:

Мин ышанам Россиягә, дуслар,
Мин турылыклы аңарга!
Мин сүз бирдем атам туфрагында —
Изге Россиядә янарга! —

ди автор Сибгат Хәкимгә багышлап язган шигырендә. «Рәхмәт, заман, кимсетмәдең, рәнҗетмәдең», «Өйдәгеләргә үтенеч», «Сыйфатлар», «Заман», «Берәүләр, талып ял-йокыга...» «Төш», «Мин урамга килеп чыккан чакта» шигырьләрендә дә шушы ук фикер үстерелә. Ул шигырьләрне укыганда лирик геройның эчкерсезлеген, кешелеклелеген, дуслык-иптәшлек хакына үзүзен беркайчан да кызганмаячагын тоясың. Мондый шигырьләр укучының хис-тойгыларын яңартып, көчәйтеп җибәрәләр, яшәүнең мәгънәсе турында тагын бер тапкыр ныклап уйланырга мәҗбүр итәләр. Әлбәттә, җыентыкка кергән шигырьләр поэтик эшләнешләре ягыннан бөтенесе дә бер үк югарылыкта тора дип әйтеп булмый. Мәсәлән, «Китап укучы кызлар янында», «Былбыл төше», «Мәхәббәт арифметикасы», «Мәскәү инде нейлон толым сата», «Ярат мине, кызый, ярат» кебек шигырьләрендә фикер ярлылыгы сизелә.

Китапка сайлап алынган шигырьләр нигездә әйбәт кенә тәрҗемә ителгәннәр һәм татарча яңгырашларын тапканнар. Ләкин монда да кимчелекләр юк түгел. Ул кимчелекләрнең берсе — шигырьнең техник эшләнеше һәм аерым сүзләрнең дөрес кулланылышына игътибар биреп җиткермәү. Мисалга «Туган йортыма» шигырен алыйк. Аның икенче строфасы «фетнә җанлы бала тәртә типкән кебек» дигән юл белән башлана. Безнеңчә, татар телендә «тәртә типкән» дип сөйләшмиләр. Монда, әлбәттә, «тәртәгә» сүзе кирәк иде. «Җәлил» шигырендәге: «аның якта — тантана!» җөмләсе дә «татарча» түгел. Шагыйрь Гәрәй Рәхим «Замандашлар монологлары» поэмасыннан алынган өзекне тәрҗемә иткәндә матур яңгырашлы рифмалар таба алмаган. Поэманың беренче бүлегендә «кызыксыз— кызык тормыш», «шәфкатьләрен — гаепләмәвен», «булыйм — алыйм», «чакыру — җанга дару» кебек сүзләрне ничек инде рифмадаш сүзләр дияргә мөмкин?! Шундый җитешсезлек «Минем Лермонтовым», «Сайра аулау» шигырьләренең тәрҗемәләренә дә хас. Ә бит китапны басарга әзерләгәндә мондый кимчелекләрдән арыну бер дә кыен булмаган булыр иде. Киләчәктә башка милләт шагыйрьләренең шигырь китапларын татарчага тәрҗемә итеп чыгарганда, нәшрият редакторлары тәрҗемәчеләрдән ул китапларга кергән әсәрләрнең татар телендә дә оригиналдагы кебек үк матур яңгырашлы, аһәңле булуын таләп итәргә тиешләр.

Ә, гомумән, Михаил Львовның шигырьләрен татар укучысына тәкъдим итеп, Татарстан китап нәшрияты күркәм эш эшләгән.

Рәшит ГӘРӘЙ.

# ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ ҖЫРЧЫСЫ

*Ә. Ерикәйнең тууына 70 ел*

**Әхмәт Ерикәй — күп санлы җырлар һәм романслар авторы буларак танылган шагыйрь. Аның композиторлар белән бергәләп иҗат ителгән «Дуслык турында җыр», «Рус халкына сәлам», «Ике йолдыз», «Көтәм сине», «Комсомолка Гөлсара», «Онытырга мөмкин түгел», «Дустыма», «Татарстан» кебек җырлары бүген дә яратып җырлана.**

**Әхмәт Ерикәй үзенең иҗатында туган ил, Татарстан, халыклар дуслыгы темаларын киң яктыртты. Мәсәлән, аның «Дуслык турында җыр»ында мондый юллар бар:**

Төрле безнең телләр төрлесен,
Ләкин төрле түгел теләкләр;
Бер омтылыш, бер үк уй белән
Бергә тибә безнең йөрәкләр...

Үстергән дә безне — чын дуслык,
Көч биргән дә безгә — чын дуслык.
Дуслык булса, яшәр гомергә
Бөтен җир йөзендә тынычлык!

**Ә. Ерикәй Башкортстанның Өлкәндә авылында 1902 елның 1 декабрендә туа. Аңа кечкенәдән үк тормышның ачысын-төчесен татып үсәргә туры килә. Бөек Октябрь революциясен Ә. Ерикәй бөтен җаны-тәне белән шатланып каршы ала. Совет власте урнаштыруның беренче көннәреннән үк ул партия сафына баса һәм төрле җәмәгать оешмаларында эшли башлый.**

**Ә. Ерикәй 1927 елда Мәскәүдәге журналистлар институтына укырга керә. Институтны тәмамлагач, төрле газеталарда хәбәрче, соңрак редактор булып эшли.**

**Бөек Ватан сугышы елларында Ә. Ерикәй хәрби газеталарга мәкаләләр, очерклар яза. Бу чорда аның иҗатында сугыш тәэсире нык сизелә:**

Нигә моңланмасын ялгыз каен,
Бигрәк тирән аның кайгысы;
Кеше каннарына буялып беткән
Аның тузы, аның кайрысы...
(«Каен», 1944.)

Кайгыны мин танып беләм,
Мин дөнья күргән кеше.
Мин дәһшәтле үлем белән
Янәшә йөргән кеше...
(«Мин дәртемне илгә бирдем», 1944.)

**Ә. Ерикәй шигърияте аһәңлелеге, музыкаль яңгырашы буенча халык иҗатына аваздаш. Аның ике йөзләп җырына татар һәм рус композиторлары тарафыннан көйләр язылган.**

**Сугыштан соң Ә. Ерикәй Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе булып эшли. Ике тапкыр СССР Верховный Советына депутат итеп сайлана. Иҗтимагый-әдәби эшчәнлеге өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә.**

**Шагыйрь 1967 елның 15 сентябрендә вафат булды.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ДУСЛЫК МАРШРУТЫ

Шушы елның сентябрь аенда РСФСРда кыргыз әдәбияты көннәре үткәрелде. СССРның төзелүенә 50 ел тулуга багышлап үткәрелгән ул бәйрәмне кыргыз әдипләре һәм кыргыз сәнгать осталары Татарстаннан башлап җибәрделәр. Татарстан хезмәт ияләрен бер атна буена үзләренең әдәбият-сәнгать үрнәкләре белән таныштырдылар. Шул ук вакытта үзләре дә Татарстандагы промышленность, авыл хуҗалыгы һәм культура үсешен үз күзләре белән күреп, республикабыз ирешкән уңышларга чын-чынлап сокланып киттеләр.

Кыргыз һәм татар халыкларының туганнарча дуслыгы күптәннән килә. Әле Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк бу ике халык тыгыз элемтәдә торган. Алар үзара тәрҗемәчесез аңлашканнар. Менә шуңа күрә дә кыргыз әдипләренең һәм сәнгать осталарының безнең якларга килүен республикабыз хезмәт ияләре аеруча зур кызыксыну белән көтеп алдылар. Кыргыз дуслар Казанга 10 сентябрьдә килделәр. Ә 11 сентябрьдә кунаклар көндез Казан шәһәре белән таныштылар: университеттагы В. И. Ленин мемориалын карадылар, республика Дәүләт музеенда, татар әдәбияты музеенда булдылар, В. И. Ленин, Муса Җәлил, Габдулла Тукай һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар. Аннары кунакларны КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Табеев кабул итте. Ул кыргыз дусларга республикабызның экономикасы, фәне, әдәбияты һәм сәнгате үсеше, Татарстан, Кыргызстан һәм башка республикалар арасындагы туганнарча элемтәләрнең ныгуы турында сөйләде. Иптәш Табеев Кыргызстан әдипләренә В. И. Ульяновның Казан дәүләт университеты бинасы алдына куелган һәйкәле макетын бүләк итте һәм СССРның олы юбилеена хәзерлек уңае белән кыргыз халкына уңышлар теләде.

Кыргызстан язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре Тендик Әскәров кыргыз делегациясе исеменнән партиянең Татарстан өлкә комитетына һәм республиканың иҗат оешмаларына, җылы каршы алулары һәм изге теләкләре өчен, рәхмәт белдерде.

Шул ук көнне Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында РСФСРда кыргыз әдәбияты көннәрен башлап җибәрүгә багышланган тантаналы кичә булды.

Кичәне Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Батыев ачты. Иптәш Батыев партиянең өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм ТАССР Министрлар Советы исеменнән кунакларны республикабыз җиренә килүләре белән кайнар котлады һәм кыргыз-татар әдәбиятлары арасындагы күптәннән килә торган дуслык бәйләнешләры турында сөйләде. Кунаклар исеменнән җавап сүзе белән Кыргызстан язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре Тендик Әскәров чыкты. Аннары ул кыргыз делегациясе исеменнән Татарстан язучылар союзына В. Ульянов портретын тапшырды һәм, сүзен йомгаклап, болай диде:

— Бөек Октябрь революциясенә кадәр язма әдәбияты да булмаган кыргыз халкы рус һәм татар халкының туганнарча булышлыгы нәтиҗәсендә үзенең язма әдәбиятын булдырды. Бөек Октябрь революциясеннән соң кыргызлар зур уңышларга ирештеләр, фән, культура, сәнгать олы юлга чыкты. В. И. Ленинның зирәк милли политикасы аркасында кыргыз халкы башка халыклар белән бер рәткә баса алды. Бүген ул, башка милләтләр белән бер сафта торып, коммунизм бинасын төзүдә катнаша.

РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре, М. Горький исемендәге РСФСР дәүләт премиясе лауреаты Людмила Татьяничева, кыргыз халык шагыйрьләре Тимеркул Уметалиев, Куанычбәк Маликов, шагыйрәләр Тенди Адышева, Субайылда Абдекадыйрова, республика комсомол премиясе лауреаты Турар Кожомбердиев иптәшләр дә Тендик Әскәров фикерен куәтләп чыгыш ясадылар һәм тантана кичәсенә җыелган тамашачыларга әсәрләрен укыдылар.

Кыргыз халык язучысы, Ленин премиясе лауреаты Чыңгыз Айтматовның чыгышы тамашачыларда аеруча зур кызыксыну тудырды.

— Безнең совет әдәбиятларыбыз,— диде ул,— яңа социалистик чорның үз алдына кешелек яшәешен тамырдан үзгәртүне, исеме — совет кешесе, максаты — коммунистик җәмгыять төзү булган яңа шәхес тудыру бурычын куйган сәнгать культурасын тәшкил итәләр. Шушы юлда әдәбиятларыбыз тыгыз элемтәдә һәм бер-берсен баетышып үстеләр. Минемчә, бүген шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Урта Азиянең хәзерге милли культуралары формалашуына чын-чынлап революцион йогынты ясаган рус культурасы һәм әдәбияты белән бергә, кыргыз әдәбиятына, аерым алганда, татар әдәбияты, татар художество һәм мәгърифәтчелек фикере зур йогынты ясады. Төрки халыклар арасында татарлар беренчеләрдән булып рус һәм дөнья культурасы белән аралаша башладылар һәм шуның нәтиҗәсендә үзләренең яңа чор язмаларын, яңа профессиональ әдәбиятын булдырдылар, беренчеләрдән булып газеталар, журналлар чыгара башладылар, беренчеләрдән булып милли театрларын оештырдылар. Революция алды елларында кыргыз халкы әле рус телен үзләштермәгән иде, массаларга чорның

революцион идеяләре татар теле аша ирешә. Октябрь революциясе иксез-чиксез Ватаныбызда яшәүче халыкларга аралашу һәм культура бәйләнешләре өчен моңарчы күрелмәгән мөмкинлекләр ачты. Шулай итеп, үзендә узганнарның иң яхшы байлыкларын, яңа социалистик шартларда тудырылган барлык казанышларны туплаган күп милләтле совет культурасы барлыкка килде. Бүгенге көндә әдәбият һәм сәнгать алдында хәзерге чынбарлык тудырган бик тә катлаулы һәм гел үсеп бара торган иҗат проблемалары тора. Ә чынбарлыгыбыз исә колач җитмәслек. Тормышның мондый рәвештә кайнавын, мондый грандиоз иҗат масштабларын дөнья әле белми иде. Менә, аерым алганда, иң алдынгы индустриаль-техник республикаларның берсе булып әверелгән Совет Татарстаны мисалында да ышанырга була. Фәнни-техник революция темплары һәм бу прогрессны иҗат итүче кеше — бүген бөтен дөнья художникларын дулкынландыручы проблема. Совет әдәбияты алдында бөтен тормышын халык бәхете өчен көрәшкә багышлаган алдынгы замандашларыбыз образлары аша эпохабыз портретын тудыру бурычы тора. Бу кешеләрнең интеллектуаль, эстетик, психологик дөньясы художество ягыннан эзләнүләрне һәм совет әдәбиятының сыйфат ягыннан яңа баскычында сурәтләүне таләп итә. Иптәшләр, түбәләре ак карлы Алатау якларыннан, Совет Урта Азиясенең иң ерак краеннан без сезгә, тугандаш Татарстанга, туганнарыбыз һәм дусларыбыз янына, Ленин үзенең беренче адымнарын ясаган шәһәргә, татар әдәбияты классиклары Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил яшәгән һәм иҗат иткән җирләргә башияр өчен килдек.

Татар шагыйрьләреннән М. Горький исемендәге РСФСР дәүләт премиясе һәм Габдулла Тукай исемендәге премия лауреаты Сибгат Хәким, Габдулла Тукай исемендәге премия лауреаты Хәсән Туфан һәм Зәки Нури иптәшләр дә, әлеге кичәдә чыгыш ясап, үзләренең шигырьләрен укыдылар.

Кичә татар һәм кыргыз артистларының тамашачылар күңеленә хуш килгән бик әйбәт концертлары белән тәмамланды.

12 сентябрьдә кунаклар республикабыз районнарына юл тоттылар. Иң әлек алар заманыбызның тиңсез зур төзелеше булган Кама автомобиль заводы төзелешендә булдылар. Аннан нефтехимиклар башкаласы Түбән Камага килделәр. Кыргыз дусларны шәһәр үзәгендәге «Восход» кинотеатры янында 15 союздаш республика милли киемнәрен кигән кызлар чәкчәк һәм чәчәк бәйләмнәре тотып каршыладылар. КПСС-ның шәһәр комитеты секретаре Т. Гыйльметдиновның котлау сүзеннән соң партиянең шәһәр комитетында кунаклар белән очрашу булды. Шәһәр комитетының беренче секретаре И. Садыйков кыргыз әдипләренә һәм сәнгать осталарына Түбән Кама шәһәренең, нефтехимия комбинатының, шин заводының үсеше турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде. Соңыннан, очрашу истәлеге итеп, ул кунакларга яшь шәһәрнең үсешен чагылдырган фотоальбом бүләк итте.

Кыргызстан язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре Тендик Әскәров, зурлап каршылаулары өчен, Түбән Кама партия оешмасына рәхмәт әйтте һәм эшләрендә уңыш теләде.

Смена тәмамланган чакта Түбән Кама химкомбинатының ишегалдында химиклар белән очрашу булды. Кунаклар килү уңае белән оештырылган сәхнәдә кыргыз әдипләре химкомбинат эшчеләренә, хезмәткәрләренә үзләренең шигырьләрен укыдылар. Соңыннан кунакларны нефтехимкомбинат буенча экскурсиягә алып китеп, аларга каучук цехын күрсәттеләр.

Аннары кунакларны Яңа Зәйгә — республикабызның энергетика үзәгенә алып бардылар. Кыргыз дуслар тиздән бөтен куәте белән эшли башлаячак Зәй ГРЭСын карадылар. Ә кичен энергетиклар, төзүчеләр, Зәй хезмәт ияләре шәһәренең культура сараена кыргызстан әдипләре белән очрашуга килделәр. 600 кешелек культура сарае халык белән шыгрым тулган иде. Кыргыз һәм татар халыклары дуслыгына багышланган ул кичәне Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе шагыйрь Зәки Нури алып барды. Кыргыз шагыйрьләреннән Тимеркул Уметалиевнең яшьләргә багышланган шигырьләрен, Куанычбәк Маликовның яңа поэмасыннан өзекләрен, Тенди Адышеваның Алатау турындагы шигырьләрен, Жулдашбәк Алыхалыков, Турар Кожомбердиевләрнең шигырьләрен кичәгә килгән тамашачылар зур игътибар белән тыңладылар. Ә Кыргызстан акыны Эстебик Турсуналиев, җырчылардан Эсен Молдокулова һәм Кыргызстан ССРның атказанган артисты Хөсәен Мохтаровны сәхнәгә кат-кат чакыртып җырлаттылар.

Зәй энергетиклары белән үткәрелгән дуслык кичәсеннән соң кыргыз әдипләре республикабызның нефть чыга торган атаклы Әлмәт якларына бардылар. Европаның социалистик илләренә сузылган «Дуслык» нефть үткәргеченең беренче насос станциясендә булдылар. Ул үткәргечнең нефть кудырып торучы насосларын карагач, кунаклар Европадагы газ эшкәртү заводларының иң зурларыннан саналган Ленин комсомолы исемендәге Миңлебай газ эшкәртү заводына бардылар. Заводның баш инженеры Л. Алатырцев кунакларга:

— Завод территориясен җәяүләп үтү өчен берничә тәүлек кирәк булыр иде, шуңа күрә машиналардан төшеп тормабыз,— диде һәм машинага утырып экскурсия ясаганда кыргыз дусларга әлеге завод тарихы, ирешкән уңышлары турында сөйләде.

Ә кичен Әлмәт шәһәрендәге Техника йортында кунаклар хөрмәтенә һәм алар катнашы белән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кардәш республиканың әдипләрен һәм сәнгать осталарын озатып йөрүче шагыйрь Зәки Нури алып барган ул кичәдә Кыргызстан халык шагыйре Куанычбәк Маликов, шагыйрь Насирдин Байтемиров, прозаик Шукурбәк Бейшеналиев, шагыйрә Субайылда Абдыкадырова, Кыргызстан

халык шагыйре Тимеркул Уметалиев, шагыйрь Турар Кожомбердиев һәм Әлмәтгә яшәүче татар шагыйрәсе Сажидә Сөләйманова үзләренең шигырьләрен укыдылар. Кичәнең икенче өлешендә зур концерт булды. Кыргызстанның халык артисты Эстебес Турсуналиев, артистка Эсен Молдокулова, Кыргызстанның атказанган артисты Хөсәен Мохтаров чыгышлары тамашачыларның күңеленә аеруча хуш килде.

14 сентябрьдә кадерле кунаклар республикабызның башкаласына кайттылар һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан компрессорлар заводы коллективы белән очраштылар. Бу тантаналы очрашу мәжлесен әлеге заводның партия комитеты секретаре А. Киршин ачып җибәрде. Очрашуга килгән кешеләрне кунаклар белән таныштырганнан соң, сүзне ул Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе шагыйрь Зәки Нурига бирде. Зәки Нури башта үзенең кыргыз дусларга атап язылган шигырен укыды, аннары кунакларга сүз бирде. Кыргыз шагыйрьләре Куанычбәк Маликов, Тимеркул Уметалиев, Турар Кожомбердиев, Тенди Адышева, Субайылда Абдыкадырова һәм Насирдин Байтемиров укыган шигырьләрне компрессорлар заводы хезмәт ияләре зур дикъкать белән тыңладылар. Аннары сүз Ленин премиясе лауреаты Чыңгыз Айтматовка бирелде. Бик күп телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләр авторы үзенең чыгышында кыргыз халкының үткәндәге авыр тормышы, Бөек Октябрь революциясеннән соң гына таулар иле күгендә мәңге сүнмәс бәхет кояшы балкуы, кыргыз әдәбияты тууы, аның үсү юллары турында ышандыргыч дәлилләр китереп сөйләде. Аннары, үзен тын да алмый тыңлап утырган тамашачыларга мөрәҗәгать итеп:

— Авыл һәм игенче турында миңа күп язарга туры килде. Ә менә сезнең завод кебек зур заводлардагы әйбәт коллективлар белән очрашканда үземне алар алдында бурычлы тоям,— диде һәм киләчәктә эшчеләр тормышын чагылдырган әсәрләр язарга ниятләп йөрүен әйтте.

Кыргыз халык артисты Эстебес Турсуналиевның чыгышын да завод коллективы зур кызыксыну белән тыңлады: ул әлеге завод коллективына багышлап үзе чыгарган җырын кыргыз халкының иң атаклы уен коралларыннан саналган комузда уйнап күрсәтте.

15 сентябрьдә иртәнге сәгать унга кунаклар һәм Татарстан әдипләре, тәрҗемәчеләр, тел һәм әдәбият белгечләре В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсенә җыелдылар. Анда әдәбиятның хикәя жанры турында сүз барырга тиеш иде. Бу хакта сөйләшү күренекле әдибебез, Габдулла Тукай исемендәге премия лауреаты Фатих Хөснинең тирән эчтәлекле кереш сүзеннән башланды. Ул бүгенге хикәяләрдәге уңай һәм кимчелекле яклар турында сүз алып барды һәм соңыннан нәкъ менә шул көннәрдә генә Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Кыргыз хикәяләре» җыентыгына әтрафлы анализ ясады. Аннан соң чыгыш ясаган иптәшләрдән «Литературный Киргизстан» («Әдәби Кыргызстан») журналының җаваплы редакторы Александр Жирков, Ленин премиясе лауреаты Чыңгыз Айтматов, татар язучыларыннан филология фәннәре кандидатлары Мөхәммәт Мәһдиев, Миркасыйм Госманов, Флүн Мусин, Кыргызстан язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре, философия фәннәре кандидаты Тендик Әскәров хикәя жанрының төрле проблемаларына, тәрҗемә һәм әдәби әсәрләрне пропагандалау мәсьәләләренә тукталдылар. Өлкән язучыбыз һәм драматург Нәкый Исәнбәт татар һәм кыргыз әдәбиятларының үзара тыгыз элемтәсе бик күптәннән килгәнлеген тарихи документлар нигезендә тагын бер кат дәлилләп күрсәтте.

Кыргызстан кунакларының Татарстан җирендәге соңгы көне урман хезмәткәрләре көненә туры килде. Шул форсаттан файдаланып, кыргыз әдипләре һәм сәнгать осталары Казанның М. Горький исемендәге ял паркына бардылар һәм дуслык аллеясына, үзләренең Татарстанда булу истәлеге итеп, дуслык агачы утырттылар. Ул агачны «Кыргыз кызы Айчүрәк» (татарча — айдагы Зөһрә кыз мәгънәсендә) дип атадылар. Шул ук көнне кунаклар Ленино-Кокушкинога экскурсиягә бардылар. Анда В. И. Ленинның Кокушкинода яшәгән чордагы тормышы һәм революцион эшчәнлеге белән танышып кайттылар. Аннары Идел буйлап теплоходта йөрделәр. Ә кичен кадерле кунакларыбыз, Татарстан белән саубуллашып, сәяхәтләрен дәвам итәр өчен, Пенза өлкәсенә киттеләр.

Кыргыз әдәбияты көннәре Ватаныбыз башкаласы Мәскәүдә тәмамланды.

* * *

Республикабызда кыргыз әдәбияты көннәре уңышлы үтү уңае белән, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы үзенең 15 сентябрьдә игълан ителгән Указы нигезендә, РСФСРда кыргыз совет әдәбияты көннәрендә Татарстан АССРда художество иҗатын пропагандалау һәм әдәбиятлар дуслыгын тагын да ныгыту буенча алып барган зур эшчәнлеге өчен, Кыргызстан ССР язучылар союзын Почет грамотасы белән бүләкләде.

## НУРИ АРСЛАНОВКА 60 ЯШЬ

Шушы елның сентябрь аенда талантлы шагыйребез Нури Арслановка 60 яшь тулды. Шул уңай белән 19 сентябрьдә Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрында шагыйрьнең юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Юбилей комиссиясе председателе шагыйрь Әхмәт Исхакның кереш сүзеннән соң өлкән шагыйребез Сибгат Хәким Нури Арслановның иҗаты һәм тормышы турында доклад ясады. Аннары Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары тәнкыйтьче Гази Кашшаф юбилярга Татарстан язучылар союзының бүләген — магнитофон һәм Язучылар союзы идарәсенең «Казан утлары» журналы редакциясе коллективы белән бергәләп язган түбәндәге котлау адресын тапшырды:



**Нури Арсланов.** *Б. Альменов рәсеме.*

**«ХӨРМӘТЛЕ НУРИ АРСЛАНОВ!**

Сина 60 яшь тулды.

Син алтмыш еллык бәйрәмеңне әдәбиятыбызның алтын фондына кирәрлек гүзәл әсәрләр белән каршылыйсың. Синең иҗатың чын мәгънәсендә чәчәк ату чорын кичерә. Синең шигърият бакчаңда көннән-көн матуррак, көннән-көн нәфисрәк гөлләр шытып чыга. Болар — һичшиксез, киеренке, тырыш хезмәт җимешләре.

Син кайларда гына яшәсәң дә, кайларда гына хезмәт итсәң дә, ин элек туган җир, Ватан турында уйладың, ил, халык язмышын кайгырттың. Бөек Ватан сугышына кадәр төрле уку йортларында укытучы, матбугат оешмаларында рәссам булып эшләсәң, сугыш башлангач, кулыңа корал алып, үз теләгең белән илебез иминлеген якларга киттең; рядовой солдаттан рота командиры дәрәҗәсенә күтәрелдең. Сугыштагы батырлыкларың өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләндең. Яраланып госпитальгә кергәч, дошманга каршы көрәшне иҗат фронтында дәвам иттердең.

Сугыштан соң син, иҗатыңны активлаштыру белән бергә, нәшрият, газета-журнал редакцияләрендә тырышып эшләдең, иҗат секцияләренең эшен җанландыруда зур өлеш керттең. Соңгы сигез ел дәвамында «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге мөдире вазифасын башкарганда син яшь әдәби көчләргә, яшь талантларга иркен иҗат мәйданына чыгарга булыштың. Сине халык талантлы тәрҗемәче һәм композиторларыбызны матур-матур яңа көйләр язарга рухландырган җыр текстлары авторы буларак та хөрмәт итә.

Узган ел хөкүмәтебез тарафыннан Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнүең безнең өчен әеруча олы куаныч булды.

Бүген без сине, Тукай, Муса Җәлилләр традициясен иҗади үстерүче талантлы шагыйребезне, 60 еллык бәйрәмең белән чын күңелдән котлыйбыз, сиңа яңа иҗат шатлыклары, сәламәтлек, озын гомер телибез».

Юбилярны Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге язучылары һәм нефтьчеләр исеменнән шагыйрь Равил Фәйзуллин котлады. «Яшь ленинчы» газетасы редакторы Венера Ихсанова заманында шул газета редакциясендә рәссам булып эшләгән Нури ага Арслановны күп санлы газета укучылары исеменнән тәбрик итте һәм аңа газетаның Почет грамотасын тапшырды.

Халык арасында киң таралган җыр текстлары язганы өчен, Татарстан композиторлары коллективы исеменнән композитор Җәүдәт Фәйзи дә Нури Арслановка рәхмәт әйтте һәм котлау адресы тапшырып, киләчәктә дә иҗатында уңышлар теләде. Аннары Татарстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Ренат Харисов Нури Арсланов исеменә килгән күп санлы котлау адресларын һәм телеграммаларын тапшырды.

Ахырдан юбиляр үзе сүз алды һәм юбилей кичәсенә килгән иптәшләргә рәхмәт белдерде, үз адресына әйтелгән котлау сүзләрен бер аңа гына түгел, бәлки бөтен татар әдәбиятына хөрмәт йөзеннән әйтелгән сүзләр дип кабул итүен әйтте.

Кичәнең икенче өлешендә тантанага килүчеләр Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары, Казан консерваториясе студентлары көче белән Нури Арсланов әсәрләреннән төзелгән концерт тыңладылар.

## 1972 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

### КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНДА

Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында. № 4.

### КПСС ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА ҺӘМ ТАССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫНДА

1972 ел өчен Габдулла Тукай исемендәге Республика премияләрен бирү турында. № 6.

### СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

С. Акбиев. Мәдәни бергәлек. № 6.
И. Ахунҗанов. Үткәнгә сәяхәт. № 7.
А. Гыйниятуллина. Бәхетле язмыш кешеләре. № 3.
Ф. Ермаков. Хәзинәбез уртак булсын. № 11.
И. Иванов. Рухи туганнар. № 2.
И. Колесник. Күзге кич... Шигырьләр. № 7.
Я. Купала. Минем юл. Шигырьләр. № 7.
Г. Минский. «Казан кызы» яфрак ярган якларда. № 10.
Р. Мостафин. Җәлилнең рухи туганнары. № 10.
З. Нури. Янка Купала һәм аның иҗади варислары. № 7.
К. Нәҗипова. Хезмәттәшлек. № 11.
Х. Якупов. Татарстанның сынлы сәнгате. № 9.
И. Үтәбаев. Игезәк халыкларның уртак улы. № 10.

### «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 50 ЕЛ

КПССның Татарстан өлкә комитеты котлавы. № 5.
РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретариаты котлавы. № 5.
СССР Язучылар союзы идарәсе секретариаты котлавы. № 5.
«Казан утлары»ның кыскача биографиясе. № 1.
Киләчәккә карап. № 5.
Г. Бәширов. Уйланулар. № 4.
Г. Иделле. Ул елларда. № 5.
Г. Кашшаф. Нигез ташларын салганда. № 3.
«Чаян» котлавы». № 5.

### БЕЗНЕҢ АНКЕТА

Г. Афзал. Журнал миңа нәрсә бирде. № 5.
Ә. Еники. «Безнең юл» — «Казан утлары». № 5.
Р. Ишморат. Ярату хисләре белән. № 5.
Э. Касыймов. Яшьнәп-күкрәп яшә! № 5.
Б. Камалов. Остаз, арадашчы, дус. № 5.
Ә. Маликов. Сихотэ-Алин таулары аша. № 5.
З. Нури. Журнал өчен, журнал белән. № 5.
А. Расих. Әдәбият мәйданына юл ачучы. № 5.
С. Сөләйманова. Поэзия мәктәбе. № 5.

Р. Тәхфәтуллин. Журнал миңа — мин журналга. № 5.
Р. Фәйзуллин. Журналның үз архивын булдырыйк. № 5.
Ф. Хөсни. Аның яктысында... № 5.
А. Шамов. Журналның бер нөсхәсе. № 5.
М. Әмир. Зур байлыгыбыз. № 5.
Г. Әпсәләмов. Үткән юлы зур, киләчәк юлы якты. № 5.

## ПРОЗА

Г. Афзал. Карабаш күлендә. Хикәя. № 6.
Г. Афзал. Халык белән очрашу. Хикәя. № 9.
Ш. Бикчурин. Каты токым. Роман. № 5, 6, 7.
А. Ганиев. Сүзсез җыр. Повесть. № 1.
А. Гыйләҗев. Урталыкта. Повесть. № 8.
Ә. Гаффаров. Ике хикәя. № 10.
Гөлшәһидә. Минем кала алуым. Повесть. № 12.
Н. Дәүли. Тимәгез минем Гөлзадама! Хикәя. № 7.
Н. Дәүли. Мәзәкләр. № 7.
Ә. Еники. Без дә солдатлар идек. Фронт дәфтәреннән. № 9.
М. Зарипов. Пани Сирена. Хикәя. № 2.
М. Зарипов. Су буенда. Хикәя. № 11.
Р. Исаев. Күрәзәче. Перекур. Хикәяләр. № 5.
Р. Ишморатова. Милиция лейтенанты. Повесть. № 8.
Н. Ихсанов. Давылда. Хикәя. № 8.
Б. Камалов. Урамнар киңәя. Повесть. № 12.
М. Мәһдиев. Фронтовиклар. Роман. № 1, 2, 3, 4.
Ф. Мансуров. Яктытауда бүз тургайлар. Повесть. № 5.
М. Маликова. Адашканга юл кайда! Повесть. № 11.
В. Нуруллин. Люзия. Хикәя. № 4.
Г. Насыйров. Әле ярый хатын бар. Юмореска. № 10.
М. Рәфыйков. Рәхмич. Йомышчы Әбүбәкер. Хикәяләр. № 5.
Ү. Саттаров. Кызым хикәяләре. № 5.
Н. Сәфәров. Каргышлы һәм өметле кон. Романнан өзекләр. № 6, 7.
А. Сәфәров. Дзержинский ордеры. Хикәя. № 7.
Х. Сарьян. Туган як моңы. Нәсер. № 11.
И. Туктар. Җөмләләр. № 1, 9.
Ф. Хөсни. Циклон. Хикәя. № 6.
Ф. Хөсни. Без яшь идек... Повесть. № 12.
М. Хәбибуллин. Тау белән тау очрашмаса да... Повесть. № 10.
М. Юныс. Энҗе эзләүчеләр. Хикәя. № 4.
Ф. Яруллин. Җилкәнне җилләр еккач. Повесть. № 3.
Ш. Янбаев. Ике бүләк. Хикәя. № 3.
М. Әмир. Балыкчы ялганнары. Повесть. № 1, 2.
С. Әдһәмова. Шул биш нарат. Хикәя. № 9.

## ПОЭЗИЯ

Г. Афзал. Сабан туе. Шигырьләр. № 3.
Г. Афзал. Хәерле юл. Шигырь. № 5.

Н. Арсланов. Кайтмый калмый. Шигырь. № 5.
Н. Арсланов. Кайтар мине. Шигырьләр. № 6.
Н. Арсланов. Еллар, язмышлар. Биографик парчалар. № 9.
К. Булатова. Таныш моңнар. Шигырьләр. № 3.
С. Баттал. Владивостокта татар җырлары. Шигырь. № 5.
Ә. Баянов. Хатларым. Шигырь. № 5.
Ә. Баянов. Чөлтәрләргә карап. Шигырьләр. № 7.

Р. Вәлиев. Тормыш асылы. Шигырьләр. № 6.
Р. Вәлиева. Толымнарың... Шигырь. № 10.
Р. Гатауллин. Утызынчы яз. Шигырьләр. № 2.
Р. Гатауллин. Сүнмәс утлар белән. Шигырь. № 5.
Р. Гатауллин. Март-апрель. Шигырьләр. № 11.
Ә. Гадел. Ил иминлеге. Шигырьләр. № 2.
С. Гәрәева. Урал. Шигырьләр. № 4.
Ш. Галиев. Яңгыр ява... Шигырь. № 5.
Х. Гатин. Әни искә төшкәндә. Шигырьләр. № 6.
Х. Гатин. Үкенечле үтенеч. Шигырьләр. № 10.
Р. Гәрәй. Туган-үскән җирләрем. Шигырьләр. № 7.
Ф. Гыйззәтуллина. Ничек оныттыйм! Шигырьләр. № 7.
Н. Дәүли. Тынгысыз йорт. Поэмадан өзек. № 11.
Р. Закиров. Ышаныч. Шигырьләр. № 2.
Зөлфәт. Ерактагы гудок. Шигырьләр. № 4.
Зөлфәт. Сайрамас идеммени! Шигырь. № 5.
Г. Зәйнашева. Сөләйман абзый. Шигырьләр. № 9.
Н. Измайлова. Язлар килгәч. Шигырь. № 4.
Ә. Исхак. Рәхмәт җыры. Шигырь. № 5.
С. Кудаш. Боерык. Шигырьләр. № 1.
Г. Ладонщиков. Кысыр хәсрәт. Эпиграммалар. № 5.
Г. Латыйп. Хатлар язар идем. Шигырьләр. № 1.
Г. Латыйп. Ничәнче тапкыр... Шигырь. № 5.
Г. Латыйп. Ике күрше. Шигырьләр. № 10.
К. Мостафин. Тачанкалар. Шигырьләр. № 4.
Ш. Маннур. Әйтче тагын... Шигырь. № 5.
Р. Мингалимов. Көз карасы. Поэма. № 12.
З. Нури. Яза авыл, яза диңгез. Шигырь. № 5.
З. Нури. Уйланулар дәфтәреннән. Шигырьләр. № 10.
З. Насыйбуллин. Безнең буын. Шигырьләр. № 6.
З. Насыйбуллин. Яшәү өчен! Шигырьләр. № 11.
Р. Низамиев. Привалда. Шигырьләр. № 8.
Н. Нәҗми. Мин озатам. Шигырьләр. № 9.
Г. Рәхим. Гомер чаптаре. Шигырьләр. № 2.
Г. Рәхим. Арадашчы. Шигырь. № 5.
Г. Рәхим. Китмәгәндә. Шигырьләр. № 10.
Ә. Рәшитов. Күңел бөреләре. Шигырьләр. № 4.
Ә. Рәшитов. Россия. Шигырь. № 5.
С. Сөләйманова. Гомер. Шигырьләр. № 1.
К. Сибгатуллин. Иргә чыкмый калган апалар. Шигырьләр. № 1.
Б. Сөләйманов. Ак каурыйлар. Шигырьләр. № 2.
Б. Сөләйманов. Кояшым, җаем идең син... Шигырьләр. № 11.
Ф. Сафин. Замандаш сүзләре. Шигырьләр. № 4.
Х. Туфан. Кайтмый калган дуска. Шигырь. № 5.
Е. Уткин. Күпләр аны сагынып искә ала. Шигырьләр. № 11.
Р. Фәйзуллин. Әгәр дә мин... Шигырь. № 5.
Р. Фәйзуллин. Лирик шигырьләр. № 7.
С. Хәким. Үткәнемә, узганыма бүген... Шигырь. № 5.
С. Хәким. Үлгәннәргә хәтта моң кирәк. Шигырьләр. № 8.
Р. Харис. Чаллыда уйлану. Шигырь. № 5.
Ф. Чанышева. Гомер мизгелләре. Шигырьләр. № 7.
Л. Шакирҗанова. Синең күңел. Шигырьләр. № 3.
М. Шабаев. Бар да таныш... Шигырьләр. № 4.
Ф. Шәфигуллин. Диңгез эскизлары. Шигырьләр. № 6.
И. Юзеев. Карурман. Поэма. № 3.
И. Юзеев. Ни ясар тимерче. Шигырь. № 5.
Ф. Яруллин. Кеше. Шигырьләр. № 8.

М. Әгъләмов. «Хәерле юл сүзгә». Шигырь. № 5.
М. Әгъләмов. Каурый. Шигырьләр. № 8.
Р. Әхмәтҗанов. Эх, сабый чакларымда да... Шигырь. № 5.
Роберт Әхмәтҗанов. Гомер учагы. Шигырьләр. № 12.

## ДУСЛАР ҖЫРЫ

В. Александри. Родика. Шигырь. № 10.
М. Эминеску. Ник син, урман, чайкаласың! Шигырь. № 10.
Н. Костенко. Бөтен шәһәр кызыл. Шигырь. № 10.
А. Лупан. Пахом коесы. Шигырь. № 10.
Д. Лалева. Карт ана. Шигырьләр. № 10.
М. Лалев. Тынгы бармы. Шигырьләр. № 10.
Н. Стрижевская. Үткәннәргә тимә... Шигырьләр. № 10.
А. Твардовский. Ленин һәм мич чыгаручы. Шигырь. № 10.
Шөһрәт. Кеше һәм туфрак. Шигырьләр. № 10.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. Галиев. Мин — дәвамы булып... Шигырьләр. № 9.
З. Мансуров. Казлар китә. Шигырьләр. № 9.
Г. Садә. Адымнар. Шигырьләр. № 9.

## ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Төркмән шагыйре Кәминә. № 1.

## БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

З. Гомәрова. Яфрак-парашют. Шигырьләр. № 9.
Колхәсәен Хәсәен оглы. Тыныч йокла, балам. Хикәяләр. № 6.
Х. Халиков. Яңгыр хәбәрчеләре. Шигырьләр. № 5.

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Т. Миңнуллин. Ир егетләр. Драматик повесть. № 9.
С. Шәкүров. Туган туфрак. Пьеса. № 11.

## ПУБЛИЦИСТИКА. ОЧЕРК

С. Батыева. Тугандаш халыклар гаиләсендә. № 12.
Д. Вәлиев. Хәрәкәттә бәрәкәт. № 1.
Р. Вәлиев. Каурыйлар чыныкканда. № 2, 3, 4.
В. Гудкова. Профессор Мөштәри һәм аның мәктәбе. № 8.
М. Зарипов. Диссертация. № 4.
М. Зарипов. Тылсымлы нур. № 5.
М. Зарипов. Саран катламнар хәзинәсе. № 10.
М. Зарипов. Яшел хәзинә. № 12.
И. Ишморатов. Давыл алдыннан. № 5.
Б. Камалов. Ул һаман солдат. № 8.
Ж. Кәлимуллин. Һәрбер теләк — якын кипчәк. № 9.
Ш. Мотыйгуллин. Яшьтәшләр. № 7.
М. Мәхмүтов. Ерактагы якын Чили. № 2.
М. Насыйбуллин. Прокурор. № 6.
Ф. Насыйров. Үлемне җиңеп. № 11.
М. Рафиков, Р. Зәкиев. Батырлык каласы. № 10.
Ж. Рәхимов. Өченче этап. № 9.

Ф. Табеев. Алга барышлый. № 5.
М. Хәмитов. Бәхетле язмыш. № 6.
А. Хәсәнова. Батрак Фатих кызлары. № 12.
Ф. Әгъзәмов. Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы. № 12.
З. Әхмәтҗанов. Герой каберендә чәчәкләр. № 6.

## ӘДӘБИ МИРАС

Г. Ахунов. Гомер буе үзе булып калган кеше. № 1.

И. Гази. Дуртау. Беренче сыналу. Хикәяләр. Совет язучысының байрагы. Язучының гражданлык йөзе. Публицистик мәкаләләр. Язучының хатлары. № 1.

Л. Ихсанова. Җырланмый калган җыр. № 2.

Ш. Мөдәррис. Без синеке, Партия, без — синең белән! Публицистика. Полк намусы. Трагедиядән өзек. Блокноттан. Шигырьләр. Фронт юлларында. Истәлекләр. Язучының хатлары. № 2.

Ә. Маликов. «Узсын гомер сагынып сөйләрлек...» Истәлек. № 4.

Г. Хуҗи. Съезд ачылганда. Шигырь. Йөрәк каны белән, йөрәк уты белән. Мәкалә. Хатлардан. № 4.

## СӘНГАТЬ

И. Алексеев. Кинопублицистиканың сугышчан жанры. № 6.
Р. Батулла. «Акчарлаклар» сәхнәдә. № 3.
Ә. Гобәйдуллина. Табигатьнең сәхнәгә бүләге. № 3.
Д. Гыймранова. Үз моңы, үз тавышы белән. № 10.
Л. Ихсанова. Замандашым турында. № 6.
Х. Кумысников. Тыйнак кеше, сәләтле артист. № 5.
З. Шәһиморатов. Ерактагы якты йолдыз. № 1.
В. Шнайдер. Кулыңда кинокамера. № 11.

## ЭСТЕТИКА МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

К. Гыйззәтов. Ленинның чагылыш теориясе һәм художникның активлыгы № 11.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

В. Воздвиженский. Зур таләпләр югарылыгыннан. № 8.
И. Илялова. Кеше — җирнең бизәге. № 10.
Ф. Ибраһимова. Заман темасы өчен. № 12.
Т. Миңнуллин. Без «театр» уйныйбызмы! № 5.
Р. Мостафин. Җаваплылык хисе. № 1.
Р. Мостафин. Тәнкыйтькә — тәнкыйть уты. № 4.
Р. Мостафин. Укучы һәм язучы. № 5.
Р. Мостафин. Тема, идея, әдәби осталык. № 9.
Ф. Мусин. Документаль материал һәм автор фантазиясе. № 10.
Р. Сверигин. Заман һәм тормыш таләбе. № 11.
Р. Фәйзуллин. Үр артында яңа үрләр бар. № 6.
Р. Фәйзуллин. Хикмәтле дә җыры, дәртле дә. № 9.
М. Харисов. Театр һәм драматург. № 3.
М. Хәмитов. Очерк гыйбрәтле булсын. № 7.

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Х. Госман. Эмоциональ төенләнешле шигырь. № 4.
Э. Нигъмәтуллин. Жан-Жак Руссо һәм XX йөз башы татар әдәбияты. № 11.
Ф. Урманчиев. Легендалар эзеннән. № 8.

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Х. Миннегулов. Сәйф Сараиның яңа әсәрләре. № 6.
Ә. Шәрипов. «Мөһиммәт әз-заман» кем әсәре! № 4.
М. Җәлил. Педагогия училищелары өчен төзелгән татар әдәбиятын укыту программасы проекты турында. № 3.

КИТАП КҮЗӘТҮ

И. Ахунҗанов. Кояшлы дөнья. № 11.
И. Ахунҗанов. Поэзиянең ышанычлы көче. № 12.
М. Вәлиев. Инешләр Иделгә кушыла. № 4.
Т. Галиуллин. Дөньям кызыксындырса. № 6.
Р. Галәвин. Яңа сүзлек белән танышкач. № 8.
Р. Гәрәй. Ул безнең үз шагыйребез. № 12.
М. Маликова. Тормышчанлык өчен. № 7.
Ш. Маннапов. Шагыйрьне мин шулай ачтым... № 7.
Г. Рамазанов. Заман рухында. № 5.
Җ. Сафиуллин. Уңышлы эзләнү. № 2.
Х. Сарьян. Дала иртәсе. № 2.
Ш. Хамматов. Большевистик татар матбугатына нигез салучы. № 4.
Н. Ханзафаров. Мещанлык бәхетенә каршы. № 9.
Р. Харис. Мескенлектән килгән аваз. № 4.
Ф. Әгъзәмов. Туган як әме. № 6.
Ш. Әхмәдуллин. Иҗат үзенчәлеген распаганда. № 7.
М. Әмир. Яңа аваз. № 2.

ЯҢА КИТАПЛАР

В. Брюгген. Күп еллар аша. № 9.
М. Вәлиев. Диңгездә сыналу. № 10.
М. Галиев. «Идел»нең яңа саны. № 8.
Й. Гәрәй. Күтәреләсе үрләр күп әле. № 10.
Р. Лотфуллин. Топонимнар турында яңа хезмәт. № 10.
Х. Мәхмүтов. Татар мәкальләре рус телендә. № 8.
Ә. Мәхмүдов. Тамырлар дымга сусамасын. № 10.
Л. Небенцаль. Герой шагыйрь эзеннән. Рус телендә. № 4.
Х. Сарьян. Без капчыкта ятмый. № 9.
М. Сиражи. Эшчән куллар. № 2.

ИСТӘЛЕКЛӘР

М. Таһирова. Мәдәният йортында бер кичә. № 1.
С. Чанышев. Мирхәйдәр Фәйзи. № 3.

ТӨРЛЕСЕННӘН

Х. Мәхмүтов. Алтын бөртекләр. № 3.
М. Ногман. Тагын каравмнар янында. № 8.

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

А. Халиков. Дунай Болгарстаны — кардәшләребез иле. № 8.
Л. Шәйдуллина. Пирамидалар илендә. № 12.

## МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Я. Абдуллин. Татар мәгърифәтчеләре философиясенең кайбер мәсьәләләре. № 12.
Ф. Газизуллин. Г. Фәезхановның социаль-экономик карашлары. № 2.
М. Глухов. Татар графикасы. № 10.
Г. Мөхәммәдова. Киев вакыйгасы. № 8.
Җ. Мамедов. Әхмәт ибне Фазланның Идел буе болгарларына сәяхәте. № 8.
Р. Фәхретдинов. Болгар шәһәрләре. № 9.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

М. Гайнуллин. Ш. Әхмеровның тууына 90 ел. № 11.
Х. Гобәйдуллин. Нур чәчеп туды. № 11.
Р. Гәрәй. Ул һаман да безнең арада. № 10.
К. Фәсәхов. Коммунист кадрлар мәктәбе. № 10.
М. Әпсәләмов. Ленин гвардиясе солдаты. № 2.
Көчле рухлы шагыйрь. № 9.
Халыклар дуслыгы җырчысы. № 12.

## ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА

Н. Фәттах. Тарих битләрен актарганда. № 6.
Ф. Яруллин. Кешене кешеләр күтәрә. № 10.

## ҖЫРЛАР

Х. Вәлиуллин көе, Р. Әхмәтҗанов сүзләре. Акчарлаклар. № 6.
Җ. Фәйзи көе, С. Хәким сүзләре. Оренбург шәле. № 10.
Ф. Әхмәтов көе, Р. Фәйзуллин сүзләре. Аккошлар. № 5.

Укучылар сүзе. № 9.

Бәләкәй рецензияләр. № 1, № 3.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—12.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Журналыбызның 2 санында Хәниф Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повестеның ахырын, Эдуард Касыймовның «Һаваларда тургай» романының дәвамын укырсыз. Я. Мостафинның кешенең эчке кичерешләрен сурәтләгән психологик хикәясе урнаштырыла.

Журналыбызның узган елгы 5 нче санында Үзбәк Саттаровның «Кызым хикәяләре»н укыган идегез. Бу санда Гүзәл һәм Гөлнара тагын да тапкыррак сораулар биреп, әтиләренә кечкенә-кечкенә хикәяләр яздыртканнар.

Шигърият дусларына Сибгат Хәким, Равил Фәйзуллин шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Уен-көлке, зирәк сүз яратучылар өчен юмор бүлегендә шагыйрь Зәки Нуриның әләкчеләрдән, ялкаулардан, мактанчыклардан ачы көлгән шигырьләре бирелә. Гамил Афзалның үткен эпиграммалары да күңелегезгә хуш килер.

Сәгыйть Закировның «Тормышка ашкан хыял» очеркында геройларыбыз КамАЗ өчен шиннар эшлиләр. Марсель Зариповның «Баһадир дөньяга килә» дигән очеркында Чаллы автомобиль заводы төзүчеләр тормышы яктыртыла.

Бүгенге проза турында сөйләшүне дәвам итәбез. Шул уңайдан өлкән прозаигыбыз Фатих Хөснинең «Без китмәскә дип килдек!» дигән мәкаләсе урнаштырыла.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210